ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.2012



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ



### *«Татарстан Республикасының Халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында*

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен профессиональ язучы **Галиев Марсель Баян улына** «Татарстан Республикасының Халык язучысы» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н.Миңнеханов**

*Казан, Кремль. 2012 ел, 17 май. №ПУ-349*

# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ



### *«Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында*

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен профессиональ шагыйрь **Гатауллин Рәдиф Кәшфулла улына** (Рәдиф Гаташка) «Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирергә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н.Миңнеханов**

*Казан, Кремль. 2012 ел, 17 май. №ПУ-350*

# Казан утлары
# Qazan utlari

2012

7
(1077)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

*✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*☎☎: Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—562-10-38.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—562-11-53.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—562-11-53.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.*
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Гәрәй РӘХИМ. Узасы еллар узган... *Шигырьләр*......5
Салават ЮЗЕЕВ. Үлгәннәрне бүлдермә. *Роман*......9
Рәниф ШӘРИПОВ. Без дә бит бу дөнья баласы... *Шигырьләр*......80
Фарсель ЗЫЯТДИНОВ. Авылдашның авыр юл башы. *Документаль бәян*......84
Сирень ЯКУПОВА. Уем – тамчы, моңым – чишмә. *Шигырьләр*......111
Гүзәл ӘДҺӘМ. Наласа авылы көе. *Хикәя*......114
Таһир ШӘМСУАРОВ. Синең барлык кирәк дөньяда. *Шигырьләр*......123

**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVII КОРЫЛТАЕ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Корылтай ачылышында ясалган чыгыш......128
Рөстәм МИҢНЕХАНОВ. «Төп сыйфат — талант һәм һөнәри осталык»......129
Илфак ИБРАҺИМОВ. Мәдәни үсешкә йөз тотып......131
Зиннур МАНСУРОВ. Шигърият рухын гамь яшәтә......139
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Киләчәккә ышансак кына......147
Татарстан язучыларының XVII корылтае резолюциясе......152

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Фәүзия Бәйрәмова......155

**ФӘН**

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Татарның беренче тарих профессоры......160
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы......183
«Татар энциклопедиясе» битләреннән......186

**ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР**

Госман ГОМӘР. Чыңгыз үләне. Нәкышче Нәккаш......166

**ГОМЕР ИТМЕШ, ДӨНЬЯ КӨТМЕШ...**

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Балачакта калачак......168

**УКУЧЫ СҮЗЕ**

Мансур ҖӘЛӘЛИЕВ. Сара апа дәресләре......174

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Зөлфия МАНСУР. Барыбер кайттың син......176

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

Рашат НИЗАМИ. Фетнә......182

«Казан утлары» архивыннан......158
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан......190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман С.ЮЗЕЕВА «Не перебивай мертвых»;
повесть Ф.ЗИЯТДИНОВА «Трудный путь односельчанина»;
рассказ Г.АДХАМ «Мелодия деревни Наласа»; стихи Г.РАХИМА, Р.ШАРИПОВА, С.ЯКУПОВОЙ, Т.ШАМСУАРОВА.
«XVII съезд писателей Татарстана»: выступления Р.МИННИХАНОВА, Р.ФАЙЗУЛЛИНА, И.ИБРАГИМОВА, З.МАНСУРОВА, Р.ЗАЙДУЛЛЫ;
резолюция XVII съезда писателей Татарстана.
«Видные личности»: статья Т.МИННУЛЛИНА «Фаузия Байрамова».
«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ «Первый татарский профессор по истории»;
Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень».
«Жизнь прожить...»: Г.МУХАМЕТШИН. «Останется в детстве...»
«Сенной базар»: Р.НИЗАМИ. «Путч».
«Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Рассказы из жизни»: З.МАНСУР. «Все равно ты вернулся».
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Белая мечеть в Булгаре; поэтесса Рифа РАХМАН.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by S.YUZEEV «Do not interrupt the dead»;
novel by F.ZIYATDINOV «Villager's hard way»;
story by G.ADHAM «Melody of Nalas village»; poems by G.RAHIM, R.SHARIPOV, S.YAKUPOVA, T.SHAMSUAROV.
«XVII Congress of Tatarstan Writers»: speech by R.MINNIHANOV, R.FAYZULLIN, I.IBRAGIMOV, Z.MANSUROV, R.ZAYDULLA;
resolution of XVII Congress of Tatarstan Writers.
«Outstanding personalities»: article by T.MINNULLIN «Fauzia Bairamova».
«Science»: article by D.ZAGIDULLINA «First Tatar Professor of History»;
F. GARIPOVA. «History of our villages.»
«Life is to live ...»: G.MUHAMETSHIN. «Will leave in childhood ...»
«Hay market»: R.NIZAMI. «Putsch.»
«Pages of «Tatar encyclopedia».
«Stories of life»: Z.MANSUR. «Anyway, you're back».
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: White Mosque in Bulgaria, poet Rifa RAHMAN.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 02.07.2012, график буенча 02.07.2012.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 16065 (М-560). Тираж 4075.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ТУ 16-00337.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2012 ел.



Гәрәй
Рәхим

# УЗАСЫ ЕЛЛАР УЗГАН...

## Быжылдап оча божан...

ТРИПТИХ

*Үлем турында уйлама...*

Фатих Кәрим

### – 1 –

### ГОМЕР БАКЫЙ

**Гомер – бакый...**
**Нигә мондый сүзне**
**Уйлап таптың, халкым?..**
**Гомер мәңгелек, дигән сүз**
**Ялган сүз бит, салкын...**

**Гомер — бакый түгел, гомер — фани,**
**Дип әйтәсе килә.**
**Салкын мәңгелек түгел ул,**
**Гомер — кыска, җылы, назлы,**
**Ул гел җырлый, көлә...**

**Чиксезлекле арифметикага**
**Сыя алмый гомер,**
**Ике... ун, дип санап булмый,**
**Гомер — сыңар, ул — БЕР!..**

**Гомер... гомер... гомер, диеп**
**Кабатла хет мең кат —**
**Кабатланмый гомер!**
**Ул — бердәнбер! —**
**Җөп сан түгел — ул так...**

**Гомер — бакый түгел, гомер — фани,**
**Бакый дию — ялган!..**

Гәрәй РӘХИМ (1941) – *Татарстанның халык язучысы; «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

...Гомер бакый миңа шул турыда
Уйланырга язган...
«Гомер нинди кыска...» — диеп
Сызланырга язган.

– 2 –

## ҮЛГӘННӘН СОҢ

Мин үлгәннән соң да яшәрмен, дим...
Озак түгел — бары өч-дүрт көн –
Мине юу, киендерү, кершән сылап
Экспонат итеп, залга кую,
Табутымда яту кеше көлдереп,
Гәҗитләргә кара кайма белән
Рәсемемне куяр өчен дә,
Некрологта мине, шәп иде, дип
Ак төсләргә буяр өчен дә,
Урын алу өчен бер зиратта,
Каберемне казыр өчен дә
Бер өч-дүрт көн кирәк булыр әле —
Гәрәй калыр, дим, үз көчендә...

Ә аннары — бетте!..
Г. Рәхим дә, Гөргөри дә,
Родионов та
Гел булмаган кебек кенә булыр
Дөнья дигән бу зур клубта...
...Анда тагын зур концертлар булыр,
Музыкадан шашар тыңлаучы —
Монда булмас сыңар бер адәм дә
Гәрәй Рәхимнәрне уйлаучы...

Җирдәшләргә, илгә, балаларга
Бернием дә юк бит бүләсе...
Тыныч күңел белән китеп була —
Тик үләсе килми... үләсе...

Мин үлгәннән соң да яшәрмен, дим...

– 3 –

## ЯЛГАН

Кыласылары — кылынган...
Аласылары — алган...
Югалтасылар — югалган...
Алмастайлары — калган...
Дәһшәтле гомер җилкәгә
Күтәрмәстәй йөк салган...

Буласылары — булынган...
Булмастайлары — сынган...
Гомер лепкәсендә җилдә
Җилферди ап-ак кылган —
Без бу җирдә ни кылган?!

Язмыштан узмыш — узылган...
Гомер туннары тузган...
Теге чалгылы карт кортка
Кил, диеп, кулын сузган,

**Янәсе гомер узган,**
**Күзеңдә бары тузан —**
**Кызганмасаң мыскыллап көл,**
**Кызгансаң, әйдә, кызган...**

**Узасы еллар узган...**
**...Тик алда нинди ызан?!.**
**Күр, алда яшел ызан —**
**Быжылдап оча божан...**
**Чәчәкләр башын сузган...**
**Кырмыскалар юл алган...**
**Тәкәрлек чаба алдан...**
**Яңа туган бозау юлга**
**Кайнар «тәбикмәк» салган...**
**Һавада ул «тәбикмәк»нең**
**Татлы исе дә калган...**

**«Гомер үтте» — дигән сүзләр**
**Ялган сүз, дуслар, ялган!**
**Ялган сүз!..**
**Ялган!..**
**Ялган!..**

## Ай белән Кояш кавышты

*Ай күрдем айман[1] белән,*
*Авызым тулы иман белән.*
*Шушайларда[2] уләр булсам,*
*Каберем тулсын иман белән.*

Халык авыз иҗатыннан

**Ай күрдем айман белән —**
**Зәп-зәңгәр Күк гөмбәзендә**
**Ай белән Кояш кавышты —**
**Мин шуны гына беләм!..**

**Мин шуны гына беләм —**
**Без дә бит Синең белән**
**Бу дөньяның күз алдында**
**Ай белән Кояштай идек...**
**Күк йөзе — зәңгәр келәм...**

**Күк йөзе — зәңгәр келәм...**
**Келәмгә ятып ант иттек:**
**«Син минем өчен үләсең,**
**Мин синең өчен үләм!..»**

**Айман көннәр бик сирәк шул,**
**Аеры көннәр бихисап.**
**Картаябыз...**
**Әй гомеркәй,**
**Изгелеккә бул хисап!**

**Айман көнне көтеп алып**
**Иманнар әйтәбез без.**
**Кояш белән Ай шикелле**
**Яктылар, әйбәтбез без.**

[1] **Айман** — Күк йөзендә ай да, кояш та берьюлы күренеп торган көн. Керәшеннәр аны бүген дә «айман көн» дип йөртәләр. Айман көнне иман әйтсәң оҗмахка (оҗтомакка, җомакка) керәсең, ди...
[2] **Шушайларда** — шушы айларда. Халык авыз иҗатында шигъри ритм өчен кыскартылмыш.

Кояш белән Ай шикелле
Яшибез без һаман да —
Кояш бата, Ай да калка
Бүгенге заманда да.

Тик Син баткач Мин калкамын,
Син калыккач Мин батам —
Айман көнне көтә-көтә
Озак яшик ичмасам...

...Ай күрдек айман белән,
Авыз тулы иман белән...

## Кысмыр... кысыр...

Мин сине уйламаган көн —
Кысмыр көн булыр иде.
Син төшемә кермәгән төн
Кысыр төн булыр иде.

Көннәрем дә, төннәрем дә
Синең белән уртак үтә,
Уртак үтә күптәннән...
Ә бит без күрешмәгәнгә
Ярты гасыр, аннан артык
Гомеркәйләр үткәннәр.

Нигә кайтам соң ул чакка
Еллар, киртәләр үтеп? —
Гел син чакыргандай тоям
Шул киртәләрне сүтеп!

Шул киртәләрне сүтеп без
Ашкынышып яшибез.
Бу халәткә килгәнбез бит
Унсигездә, яшьли без!..

Менә инде җитмеш яшьлек
Гомер җебен сүтәбез.
Бирсен Ходай — сиксәнгә дә,
Туксанга да җитәрбез.

Тик мин һаман... һаман... һаман...
Сине уйламаган көнне:
«Кысмыр көн бу» — диярмен.
Син төшкә кермәгән төнне:
«Кысыр төн бу» — диярмен.

## Бәхетле... бәхетсез...

*Онытылмый беренче саф мәхәббәт*
Әхмәт Рәшитов

Замана да, чор да түгел —
Гаепледер үзебез:
Мәңге бергә булалмаган
Мәңгелек мәхәббәт без!..

Җитмеш яшьлек сабый затлар —
Саф бит, ак бит йөзебез.
Мәңге бергә булмасак та,
Мәңгелек гашыйклар без!..

Кайгырырга, үкенергә
Безгә сәбәпләр юк һич —

Тәннәр бергә булмаса да,
Җаннар мәңге бергә ич!..

Без җирдә иң гөнаһсызлар —
Юк, без мескен түгелләр!..
...Тик чиксез сагынулардан
Сыкрап үтә күп көннәр...
Өзгәләнә күңелләр...

Күрәмсең безнең гомерләр
Бәхетсез дә түгелләр...
Бәхетле дә түгелләр...



Салават Юзеев

# ҮЛГӘННӘРНЕ БҮЛДЕРМӘ

РОМАН

*Әти-әниемнең якты истәлегенә багышлыйм*

— Дөньяга аваз салганмын, тәпи басып киткәнмен, әмма үз-үземне белә башлаганда, миңа биш яшьләр булгандыр. «Менә хәзер чын-чынлап акыл утырттым», — дип уйладым мин, 25не тутыргач. 40ка житкәндә дә, 82гә аяк басканда да башыма нәкъ шул уй килде. Хикмәт менә нәрсәдә: теләсә кайсы яшьтә дә син үзеңне янадан туган шикелле хис итәсең. Хәер, миңа инде барыбер: кеше үз гомерендә ике зур борчу кичерә, диләр. Берсе аша үттем инде. Икенчесе — соңгысы килсә дә, шаккатмыйм.

Купедашым — профессор Сарман Бигинең, миндә кызыксыну уятыр өчен, сүзен юри шулай башлавына шундук төшендем, әлбәттә. Бездә, журналистлар арасында, моны «каптыру» диләр. Нишлисең, бәлки профессорның күңел сәгате суккандыр, үткән гомере турында кемгәдер сөйләп бушанасы килгәндер. Күрәсең, карт кемгә юлыгуын, кемне эләктерүен дә чамалагандыр. «Журналист икәнеңне каян белсен?» — дип сорарсыз. Акыл ул — еллар саны белән генә түгел, узган юллар белән дә исәпләнә. Миңа бер күз ташлау, минем белән берничә сүз алышу — кем икәнлегемне аңларга шул житкәндер, бәлки ( тәҗрибәле укучы да шундый бит: китапның теләсә кайсы битен ачып, берничә юлга күз салуга аңлап ала — укыргамы, әллә вакыт әрәм итеп тормаскамы?).

— Инде үлем турында сүз кузгалган икән, минем фикеремчә, аның кыяфәт-рәвешен уйлап чыгару — кешенең акылга сыймаслык уйдырмасы гына. Хикмәт менә нәрсәдә: әҗәл ул — син. Туганнан алып актыккы сулышыңа кадәр син аны үзеңдә йөртәсең. Һәм иң соңгы мизгелдә, үзеңне көзгедә күргәндәй, аның белән күзгә-күз очрашасың.

Дөресен әйтим, моны ишеткәч, мин озак вакытлар көзгегә карарга шикләнеп йөрдем.

Аның авызыннан ишетелгән кайбер әйтемнәр күңелемә кереп калдылар. Мәсәлән, «кичә пешергән чәйне эчүчеләргә ышанычым юк». Яисә, «шундый акыллы кешеләр бар, мәрхүмнәргә сүз катмыйлар». Тагын, «ике яхшы кеше бер-берсен теләсә кайсы кабахәттән дә элгәре соңгы чиккә житкерә

---

Салават ЮЗЕЕВ (1966) – *язучы, телевидение һәм кино режиссеры, «Я осталась здесь», «Сквозняк тишины» һ.б. китаплар авторы. Казан шәһәрендә яши.*

ала». Яки, «кеше үлгәндә, кәлтә елан эзәрлекләүче кулында койрыгын өзеп калдырган кебек, үзенең гәүдәсен безгә калдырып китә».

Дөрес, язмама боларның барысы да сыеп бетмәс. Нишләтәсең, һөнәрем шундый: бик кызыклы булса да, артыгын төшереп калдырмый булмый.

Мин ул вакытта республика радиосының авыл хуҗалыгы редакциясендә эшли идем. Магнитофон тасмасына төрле кешеләрнең тавышларын яздырам да, соңыннан материалны эшкәртәм, ягъни редакциялим. Гомеренең күп өлешен чит-ят җирләрдә үткәргәнен белгәч, юлдашымны үзем өчен табыш санап, әңгәмә корырга булдым. Яшь чагым, юлымда очраган бер кешене сөйләтәсем килә. Хәзер генә ул, олыгая барган саен андый очыну югала. Ә ул чакта... Магнитофонымны кабызып: «Кем? Кайдан? Кая?» — кебек гадәти сорауларымны тезә башладым. Көтмәгәндә, аның җаваплары шактый озынга сузылды. Баштарак бармагымны «Stop!» клавишына куйган килеш тынласам,бераздан вакыйгалар ташкынына кереп чумганымны сизми дә калдым. Карт авызына карата белә! Нәтиҗәдә ул очрашу истәлеге булып миндә берничә дистә кассета калды. Алга китеп шуны әйтим: киштәдә озак еллар тузан җыеп яткан ул язмаларның миңа кирәге чыкты. Мактанып әйтүем түгел, бер әйбәт ягым бар минем: иске кассеталарны бервакытта да ташлаганым яисә боздырганым булмады. Бу кагыйдәне соңрак, документаль кино өлкәсенә күчкәч тә гадәт итеп алдым. Дөрес, хәзер цифрлы технологияләр үтеп керде, үзем дә «Не уйдем!», «Водопой имени Ханафи Мавлюдова» фильмнарын камерага төшердем. Ә шкафым төрле елларда җыелган материаллар белән шыплап тулган. Вакыт булганда, онытыла барган шул истәлекләр арасында актарынырга яратам.

— Мин Ай дигән авылдан. Элегрәк ничек аталгандыр, янәшә агып яткан елганы да авыл исеме белән атыйлар. Исемем — Сарман Биги...

Юлдашым өчен күңелендә җыелып килгәннән бушану киче булды бу. Хәер, хатирәләрне яңарту өчен поездддан да яхшырак транспорт юк та бугай. Ә бер телең чишелдеме, инде тиз генә туктармын димә.

— ...туган ватанымда ярты гасырга якын булганым юк.

Поезд Казанга ыргыла. Миңа соңгы тукталышка кадәр кайтасы, ә юлдашыма алдарак — узгынчы тукталышта төшеп, авылына илтә торган автобуска утырасы.

— Караңгы бик акрынлык белән инә, — диде ул тәрәзәгә карап, — бездә алай түгел. Авызыңнан бер сүзең чыкканчы кап-караңгы була да куя.

Поезд, шаулап, туннельгә килеп кергәнгә, аның соңгы сүзләрен ишетеп өлгермәдем. Поезд бермәлгә коега чумгандай тоелды да, ыжгырып, яктыга чыкты.

— Әйдәгез, чәй эчәбез, — дип тәкъдим итте күршем.

— Чынлап та. Хәзер, озата баручыдан сорыйбыз.

— Юк, аңарда кичә пешерелгән чәй генә, — диеп, сумкасыннан чәй салынган янчык чыгарды. Миннән кайнаган су алып килүемне үтенеп, танышым өстәл тирәсендә кайнаша калды. Үзе белән йөрткән кечкенә чәйнегендә чәй пешергәч, ике касә алды.

— Кичә пешерелгән чәйне эчүчеләргә ышанычым юк минем, — диде ул, чәй уртлап. — Ә яңа пешерелгәнендә, — ул касәсен күз турына китереп, сүзен дәвам итте: — адәм канында, хатын-кыз һәм әҗәлдә генә була торган хакыйкать тәме бар. Сез нишләп эчмисез?

Чәй теленне йотарлык иде. Вагон тәгәрмәчләре тукылдый, тәрәзә артында куе караңгылык, бездән өстә тимер юл чыбыклары кушылалар да янә аерылып китәләр — чәйдә туган хакыйкать алга таба омтылган поезд хакыйкате белән тәңгәл килә иде.

Сүзсез генә берничә тапкыр уртлагач:

— Чәй пешерү җыелмасын йөрткәч, үзегез белән су да алырга иде, — дидем мин.

— Тимер юлда су бөтенләй үзгә. Чәй тәменә офык, мәйдан, чит исләр килеп кушыла да хакыйкать икеләтә, өчләтә арта төшә. Нәрсәдә калдым әле мин?

— Сезнең якта карангылык бик тиз төшә, дигән идегез.

— Әйе, бер сүз әйткәнче. Ә ул сүз — хатын-кыз исеме иде. Безнең авыл ике зур калкулыкта урнашкан. Ерактан караганда алар хатын-кыз күкрәген хәтерләтә. Мин калкулыкның берсенә басып, сөйгәнемнең исемен әйтүгә, ул икенче калкулыктан миңа исемем белән дәшә. Аяк астындагы сукмакны да сизмичә, мин аның янына ашыгам. Күрше урамнан гармун тавыш бирүгә, әллә каян гына яшьләр җыела да, биюләр башланып китә. Гафу итегез, мин сөйлим дә сөйлим, ә сезгә кызыкмы соң болар?

Ул, күзлек пыялаларын ялтыратып, миңа сораулы караш ташлады.

— Беләсезме, сез танцы турында сүз башлауга, бер язучының: «Теләсә кайсы сәяхәт — Алла тарафыннан бирелгән бию дәресе ул», — дигәне исемә төште. Дәвам итегез.

— Безнең чорда сабыр тыңлаучы сирәк очрый, — диде ул, касәмә чәй өстәп. −Күпчелек сөйләргә ярата. «Сүзен көмеш булса да, дәшми торуың — алтын», — ди торган иде безнең авылда Вафа бабай. Бик сүзчән кеше булса да, күбрәк эш турында сөйли иде ул. Без, бала-чага, гел аның аяк арасында чуала идек. Яшенә караганда акыллы бабай булды. Шул ягы белән үзенә тарткандыр инде безне. Кулыннан килмәгән эше юк: үлгән кешене соңгы юлга озата, кирәге чыкса, сөннәткә дә утырта, башкалар оныткан гореф-гадәт, йолаларны исеннән чыгармый. Алардан башка тормыш, яшәеш кичәге чәй кебек мәгънәсез, буш булыр иде. Ул безнең авылның аксакалы сыман. Әгәр узынып киткән бер яшь-җилкенчәкне урынына утыртырга кирәк икән: «Тиле койрыкка үсә», — дип кенә куя. Ягъни организмны үстерергә тиешле барлык көч койрыкка китә. Күп ашарга яратучыга да әйтеме әзер: «Яшәү өчен ашамый, ашар өчен яши». Шуларга охшаш хикмәтле сүзләргә тарыганда, кылт итеп Вафа карт исемә төшә. Бервакыт шулай III Рейх архивын актарып утырганда бер кәгазь игътибарымны җәлеп итте. Бу — Гитлерның төп идеологы Альфред Розенбергка адресланган хәбәре иде. Аны төзүченең имзасы танырлык түгел, менә шул кеше татарларны борынгы кыргый кабиләгә якын дип сурәтләгән: «...алар тамаклары өчен генә яшиләр». Кызык, беркемгә мәгълүм булмаган кечкенә генә татар авылында гомер сөргән Вафа бабай үз авызыннан чыккан сүзләрнең җимергеч җәһәннәм машинасы эчендә кулланганын белсә, нишләгән булыр иде икән?

Авылыбыз ике калкулыкта утырган, дигән идем. Шуларның берсе итәгеннән Кара урман башлана. Урман авызыннан төрле якка берничә сукмак китә. Арадан берсе өрәкләр аланына алып керә. Әгәр дөньядан киткән берәрсе белән сөйләшергә телисең икән, шушы аланга юл тотасың. Кояш батып, җил тынгач килүең хәерле, чөнки мәетләр тавыш яратмый, диләр. Без, балалар, бу куркыныч, шомлы урыннан ерактарак йөрергә тырыштык. (Хәлилнең генә исе китмәде, аның турында алда сүз булыр әле). Вафа карт әйтүенчә, иң тыныч урын шушы аланда икән. Өрәкләр аланы белән авылыбызның икенче очындагы елга аръягында урнашкан зират арасында бернинди катышу юк. «Рух өчен тәннең кайда булуы мөһим түгел», — ди иде Вафа карт. Аныңча, адәм баласы кайда гына күмелсә дә, барыбер өенә әйләнеп кайта. Әгәр сезгә безнең зиратта булырга туры килсә, күрерсез: андагы каберләрнең күбесе — хатын-кызларныкы. Ирләр туган нигезләреннән еракта күмелгән. Әйтерсең, аларны авылдан ниндидер

шашкын агымлы болганчык су агызып киткән дә, соңрак рухлары өрәкләр аланына кайтып урнашкан.

30нчы еллар башында Берлин астындагы бер каберлекне зиярат итәргә туры килде. Ул чакта мин Берлин мөселманнар оешмасы тарафыннан оештырылган экскурсия составында идем. Ә аның җитәкчесе — күптәнге танышым Иоахим Вернер дигән кеше. Аның турында соңрак сөйләрмен. Ул урын Вюнсдорфтан ерак түгел, сугыштан соң совет гаскәрләре басып алган территориядә урнашкан. Тик анда керү тыелган иде инде. Әмма кабатлап әйтәм, болар әле сугыш башланырга берничә ел кала, Германия белән Советлар Союзының металлургия предприятиеләре йөзләгән мең километр чәнечкеле тимер чыбыклар җитештерә башлаганчы булган хәлләр. Андагы каберлеккә куелган зур мемориаль ташка күзем төште. Ташка иске татар язуы белән: «Монда кайзер Вильгельм II вакытында әсирлектә һәлак булган казан татарлары күмелгән», — дип язылган иде.

Күзге ачы җилне йота-йота каберләр арасыннан атлыйм. Алар күп — меңләгән. «Зәкәрия Камали. 1882 — 1915» — дип укыдым бер таштан. «Бу бит — безнең авылныкы. Кайчандыр теге ташкын белән китеп югалганнарның берсе», — дип уйлап куйдым. Менә бит ничек килеп чыга: кайдадыр, нindидер Сараевода Гаврила Принцип исемле бер бәндә Лайтенер күпере янында, бернинди аклауларга лаек булмаган адым ясап, эрцгерцог Фердинанд дигән икенче бер адәмгә атуы аркасында, Зәкәрия Камали үзенең хатыны, балалары, аты һәм хатын-кыз күкрәгенә охшаган калкулыкка урнашкан авылы белән соңгы кат саубуллашып күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга китеп черергә тиеш булган. Болганчык су алып киткән гәүдәнең рухы көзге ачы җилләргә ияреп туган якка очып кайткан.

Бер илләрдән чыгып киткәч,
Кайтып булмый тиз генә шул.
Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам;
Көзге ачы җилләрдә ләй,
Туган-үскән илләргә.

Бу юллар таныш халык җырыннан. Язучы Нәкый Исәнбәт фикеренчә, аны Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан солдатлар иҗат иткән. Шунысы мәгълүм: халыкныкына әйләнгән җырлар, зәңгәр күктә әкрен генә йөзгән болытлар шикелле, бер авылдан икенчесенә килеп сыенган. «Көзге ачы җилләрдә» дигән юллар 1917 елларда гына килеп ирешергә тиеш булса да, безнең авылда ул иртәрәк яңгырады. Бу җырны Хәлил җырлый иде. Әйткәнемчә, Хәлил өрәкләр аланына барудан курыкмады һәм бу юлларны да шуннан ишетеп кайтты.

Танышым, сүзен бүлеп:

— Арымадыгызмы әле? — дип сорап куйды.

Ул, беренче бүлекне тәмамлагандай, бераз тын алды. Ә тәрәзә артындагы дөньяны без эчкән чәйдән дә куерак караңгылык сарган иде.

— Юк, юк, — дидем мин, — дәвам итегез.

— Чәем ошадымы?

— Хикәягез кебек үк.

— Күбрәк кайсы ошый — чәйме, әллә хикәяме?

— Алар бер-берсе белән бәйләнгән. Начар чәй эчкәннәргә мин дә ышанып бетмим. Бары тик чәй рәтен белүчеләр генә шулай сөйли ала.

— Сезне сайлап ялгышмаганмын. — Ул тынычланды һәм: — Дәвам итәм алайса. Кайда калдым әле? Хәлилдәме? — диде.

Хәлил башка балалардан нык аерылып торды. Тумыштан күзләре кылый иде аның. Без аның белән бер елгылар, шуңа үз-үземне белә башлаганнан бирле аның ниләр кылганы күз алдымда. Хәтергә уелып калган берсе турында сөйлим әле. Көзге салкын көннәр. Хәлил аякларын җиргә күмеп утырган да ниндидер озын көйгә җыр суза. Күзенең берсе көнчыгышка, икенчесе җиргә төбәлгән. Хәер, җырын җыр дип атау дөрес булмас. Аның ни сүзләре, ни көе юк, әмма үзенә тартып торган ниндидер бер моңы бар. Тик ул моң әллә җир астыннан, әллә аның күкрәгеннән чыга — без анысын аңлар яшьтә түгел идек әле. Тагын бер вакыйга күңелдә сакланып калган. Күзе-башы тонган үгез безнең урам буйлап коты ботына төшкән бер хатынны куып килә. Мин тәрәз янында басып торам, капкалары төбендәге Хәлилне ачык күрәм. Ул арада соң чиккәчә курыккан хатын аның яныннан йөгереп узды. Күз ачып йомган арада котырган үгез Хәлил каршына килеп басты.

Бу вакытта миңа 5 яшьләр чамасы булгандыр, әмма бу хәл инәсеннән җебенә кадәр хәтеремдә. Күрәсең, андый сирәк очрый торган вакыйгаларны баш мие үзенә сеңдереп каладыр да еллар узып, кирәге чыккач, һәр мизгелен кабат күз алдына китереп бастырадыр.

Хәтеремә Нью-Йорктагы Роджер Смит кунакханәсендә 30 еллар элек булган хәл килеп төште.

Иртән торып, гимнастиканы тәмамлауга, тәрәзәдә кеше сыны пәйда булды. Минем номер 12нче катта, ә бу — баштүбән. Аны-моны уйлап тормыйча, ванна бүлмәсенә юл тоттым. Юынып чыккач, ни ишетәм: ундүртенче катта торган берәү тәрәзәсеннән ташланып үлгән икән. Бераздан мин бу вакыйганы өр-яңадан хәтеремдә тергездем: тәрәзәдән күренеп киткән адәмнең костюмы, каптырмалары, хәтта берсенең кояшта ялтырап алуы — барысы да исемә төште.

Тик, әйдәгез, Хәлилгә әйләнеп кайтыйк әле. Шулай итеп, берни сизмәгән малай каршына борын тишекләрен ыржайткан үгез килеп басты. Беләсезме, үгез малайга тимәде, әле киресенчә, аны таптамас өчен, юнәлешен үзгәртте. Ни өчен дип уйлыйсыз? Теге хатын якындагы ишегалдына кереп качсын дип. Әйе, әйе, Вафа бабай безгә нәкъ шулай дип аңлатты. «Безнең һәркайсыбызга карата Аллаһы Тәгаләнең үз язганы бар», — диде ул, бер гамьсез башка балалар арасында чабып йөргән Хәлилгә карап. Вафа бабай аны нигәдер башкаларга караганда үз итте һәм берәүгә дә кыерсытырга юл куймады.

Малай ятим иде. Аның әти-әнисе һәрвакыт бергә булдылар, дип сөйлиләр. Хәтта бер көнне, бер сәгатьтә, әле бер минуттадыр да, үләннәр, тик алар бу дөньядан киткәндә Хәлил туарга өлгермәгән. Вафа бабай болай сөйли: «Хәлил туганчы ук әти-әнисе бакыйлыкка күчкән. Әмма дә ләкин, — дип өстәп куя ул, — алар башкаларга уйга алырга да тыела торган чиктә очрашып өлгергәннәр».

Нәни генә чигенеш ясап алыйм әле. Сез, мөгаен, юлдашымның сөйләгәннәрен магнитофон язмаларыннан яңартырга туры килде, дигәнемне онытмагансыздыр. Эш барышында аларның тышына язып барырга туры килде, чөнки хикәяләрдә, юлга салу өчен, бернинди хронологик тәртип сакланмаган. Кассеталардагы гадәти бит номерлары булып хезмәт иткән язуларны берничә бүлекнең башы итеп чыгарырга булдым.

## Ат өстендәгеләр турында риваять

Кайчандыр безнең якларда Кара Сәет җитәкчелегендәге башкисәрләр өере башбаштаклык итеп йөргән. «Бик күп гаепсез кешеләрнең каннарын койдылар», — дип сөйлиләр иде алар турында. Кемнендер хәзер Кара

Сәетне Робин Гудка тиңләргә маташуы — чеп-чи сафсата. Ул, кемнең кем булуына карамастан, бар кешене рәттән талаган һәм бик азлар гына аның тимер кулыннан исән калган. Шулай да, Кара Сәет юлларның барысында кәсеп итсә дә, безнең авылны урап узарга тырышкан. Чөнки безнең ир-атларның ипине дә кылыч белән тураганнарын белгән ул. Шулай ук берәрсен рәнҗетә-нитә калсалар, йодрык белән маташмыйча, шунда ук коралга ябышулары да ачык башкисәргә. Шар тәгәрәтерлек киң җилкә, ат өстенә утырырга менә дигән нык камыт аяклар — гомерләренең байтак өлешен ат өстендә уздырган борынгы бабаларыбыздан калган; буйсынмас холык та — аларныкы.

Әмма бер көнне Кара Сәет үзенең кагыйдәсенә хыянәт итә. Ул шәһәр ярминкәсеннән кайтып килгән безнең олауларга һөҗүм иткән. Бу хәл авылга 10 километрлар кала булган. Кара Сәет олауларның юлын кискән дә үзенең озын сыйраклы аты өстендә утырган килеш: әгәр бар малларын, өстәвенә, хатын-кызлар белән атларын калдырсалар, ирләргә бармак белән дә чиертмәячәген, шунда ук кайтарып җибәрәчәген белдергән. Җавапка ату тавышы яңгыраган һәм Кара Сәетнең башындагы бүреге мәтәлеп төшкән. Күз ачып йомган арада, ату кораллары бертавыштан телгә килгән, ялт-йолт итеп кылычлар уйный башлаган. Безнекеләрнең саны башкисәрләрнекенә караганда шактыйга ким булуга карамастан, берсе дә бирелергә җыенмаган. Тагын шунысы мәгълүм: көтелмәгән кан коештан бер йөкле хатынның тулгагы башланган. Ире, яныннан бер адым китмичә, аны булдыра алганча сакларга тырышкан, тик дошман пулясы аны аяктан еккан. Орыш ничек тиз башланса, шулай тиз тәмамланган. Талаучылар кулыннан берәү дә исән котылмаган. Кара Сәет үзенә каршылык күрсәтүчеләрне бер дә яратмаган шул. Әмма соңыннан билгеле булганча, берәүгә бәхет елмайган икән. Сигез яшьлек малай орыш башлануга, сиздермичә генә куе үлән арасына сикергән. Авылга кайтып, барысын да түкми-чәчми сөйләп биргән. Шуннан соң ни булган дисезме? Ирләр сикереп атларына менгәннәр дә ярдәмгә ашыкканнар. Алар килеп җиткәндә, талаучылар кара эшләрен башкарып, китеп өлгергәннәр, үлеп яткан авылдашлары кайсы кайда тәгәрәп ята икән. Арада бер ир-атның күзе җирдә үлеп яткан хатынның дер-дер килгән корсагына төшкән. Зәкәрия Камали дигән ир-ат ике дә уйламый кылычын кыныннан суырып алган һәм хатынның эченә сызып та җибәргән. Озак та үтми, яңа туган бала дөньяга аваз салган. Шулай итеп, Хәлил исемле малай дөньяга килгән.

— Ул кылыч ярдәмендә туды, — дип куя ирләрнең берсе.

Икенчесе:

— Бу дөньяда әнисе белән көрешә алмады, — дип өсти.

— Әмма дә ләкин тегесендә очрашырга өлгерде, — ди Зәкәрия Камали.

Аннары ул, кан эчендә яткан хатынга карап, Кара Сәеттән үч алмый торып атыннан төшмәскә ант итә. Аның артыннан калганнары кабатлый. Барысы — 10 ир-ат — Кара Сәетне артыннан кузгалганнар. Ул көнне аның койрыгына баса алмаганнар, икенче көнне дә тотарга насыйп булмаган. Иксез-чиксез юллар, басу-кырлар буйлап алар Кара Сәетне эзәрлекләгәннәр һәм, антларына тугры калып, атларыннан төшмәгәннәр. Шуңа күрә аларны, ат өстендәгеләр, дип атаганнар. Вафа бабай сөйләве буенча, алар явыз җинаятьченең үкчәсенә берәр айдан соң гына баса алганнар. Тирә-яктагы авылларны урасаң, башка санны да ишетә аласың. Кемнәрдер сезне Кара Сәетне бер елдан, өч елдан, җиде, хәтта ун елдан соң эләктергәннәр, дип ышандырырга тырышыр.

Соңрак берәү атлыларның авыл аша узганнарын үз күзләре белән күрүе

турында сөйләде. Ул чакта бала гына булса да, жайдакларның коточкыч хәлдә булулары — кырылмаган сакаллы, тузанга манчылып, сасы тиргә батулары хәтеренә уелып калган. Төркемнең башында Зәкәрия Камали булган. Алар беркемгә сүз катмыйча, авыл халкы биргән ризыкны атларында килеш кенә үрелеп алганнар да юлларын дәвам иткәннәр.

Ул кеше тагын менә нәрсәләр сөйләде. Инде эңгер-меңгер куерган чак булган. Шуңа күрә авылны чыккач, атлылар төн үткәрергә тукталганнар.

Серле кешеләрнең төнне ничек кичүләрен беләсе килү теләге малайны иптәшләре белән шунда алып киткән. Аягүрә торган атларның өстендәге жайдагы белән бергә йоклауларын күреп, малайларның исләре киткән. Куркуын җиңеп, әлеге малай аларга якын ук килгән. Шулвакыт караңгыда, атныкы булды микән, әллә жайдакныкымы −ул төгәл генә әйтә алмады — күзләре ялтырап киткән. Малай куркуыннан кычкырып җибәргән дә җан-фәрманга өенә йөгергән. Әлеге коточарлык төн һәм ялтырап торган күзләр гомере буена хәтеренә уелып калган.

Кара Сәет тә, үкчәсенә бастырып килүләрен сизенепме, көнен дә, төнен дә аты өстендә үткәргән. Ул эзен никадәр генә жуярга тырышса да, куа килүчеләр аның хәйләсенә капмаганнар. Ә башкисәрнең дуслары, куышның ахырына җитеп килүен чамалап, күзләре караган тарафка китеп олакканнар.

Явыз юлбасарны Актай авылыннан берничә чакрым ераклыктагы изге чишмә тирәсендә, зур аланда куып тотканнар. Шуннан соң менә ниләр булган. Кара Сәетнең качар жире калмагач, үлемнең күзенә туры карап, үзен камап алган 10 жайдакның каршына килеп басарга мәжбүр булган.

— Әйт, нәрсә телисең? — дип сораган Зәкәрия Камали.

— Чын ирләрчә үләр идем, — дип, Кара-Сәет кылычын тартып алган да аңа ташланган. Ә калганнар бергә-бер орышның ни белән тәмамланасын көтеп, читкәрәк тайпылганнар.

Зәкәрия Камали дошманының берничә үтергеч һөҗүменнән елан тизлеге белән тайпылып калган һәм, уңайлы форсаттан файдаланып, Кара Сәетнең кылычын бәреп төшергән дә үзенекенең үткен йөзен моның муенына китереп терәгән.

— Әгәр син чын сугышчы булсаң, кылычтан китәр идең, — дигән һәм, кизәнеп, кылычының кыны белән башына орган. Тегесе исә атыннан мәтәлеп, жиргә тәгәрәгән. −Тик үлемең кылычтан булмас.

Зәкәрия Камали, биш иптәшен ияртеп, алгарак китә. Ә калган дүртесе башкисәрнең аяк-кулларын һәрберсе үз ияренә ныгытып бәйли дә әллә нинди кыргый тавышлар чыгарып, атларына камчы белән китереп оралар. Әсәрләнгән атларның дүртесе дүрт якка ташлана. Соңыннан авыл кешеләре үзәк өзгеч тавышның үз авылларына кадәр ишетелүе турында сөйләп йөргәннәр. Аннары дүрт атлының, чаптырып, авыл янында көтеп торган төркемгә килеп кушылуларын күргәннәр.

Исән-имин авылларына кайткан ун атлының атна буе өйләреннән чыгуын күрүче булмаган, имеш. Инде халык арасына чыккач, сүз куешкандай, бу вакыйга хакында телгә дә алмаганнар. Алдагы язмышлары ничек язылган соң бу батыр ир-атларның? Шул ук елны өчесен рус-япон сугышына алганнар. Озакламый аларның рухлары әйләнеп кайткан да өрәкләр аланына урнашкан. Калганнарының гомере исә ун елдан соң I бөтендөнья сугышында киселә һәм, көзге ачы җилләргә ияреп, туган якка аларының да рухлары гына әйләнеп кайта. Халык «ат өстендәгеләр» дип атаган әлеге кешеләрнең бу дөньядагы гомере шулай тәмамланырга язган.

Купедашым туктап калды. Озын-озак сөйләү аңа җиңелләрдән бирелми, күрәсең. Тәнәфес ясарга теләп, без яңадан чәй пешердек.

— Менә бит ничек килеп чыга, — диде ул. — Хәлил турында сүз башлавым була — үзем дә теләмәстән читкә китәм дә барам. Кайсы якка борылма — кемнендер язмышына килеп төртеләсең. Ә язмыш дигәнең синнән сорап тормый, үзе артыннан ияртә.

Тәгәрмәчләр бер көйгә тигез генә тукылдыйлар, ярым караңгы купега ян-яктагы төнге лампаларның саран уты серлелек өсти. Тәрәзә артында күренеп калган тукталыштан сузылган фонарь уты танышымның йөзеннән шуышып узды да каядыр китеп югалды.

— Теләсә кемне мисалга алыйк: башта туа, аннары үлә. Бар да гап-гади кебек. Тик алай түгел шул. Игътибарлырак булсаң, һәрбер язмышның үз язганы булуын күрәсең, — дип, сөйләвен дәвам итте танышым.

— Яңа гына «ат өстендәгеләр»нең гомерләренә балта чапкан сугышлар турында искә алдым. Бу ике сугыш һич хәтеремнән чыкмый. Балачагым белән бәйле тагын бер вакыйганы сөйлим әле. Бервакыт, ничектер, төнлә уянып киттем дә, нидер сизенгән кебек, урынымнан торып тәрәзә янына килдем. Айлы төн, тупылның озын күләгәсе урамга сузылган. Шулвакыт безнең өй яныннан бер бүре йөгереп узды. Беләсезме, авылда ник бер эт аваз салсын!

Иртән күргәнемне Вафа бабайга сөйләдем.

— Сугыш булачак, — диде ул, тыңлап бетергәч. — Лунатик бүре күрендеме, сугыш башланасын көт тә тор.

Бер-ике атна үттеме икән, ир-атларны I бөтендөнья сугышына алдылар. Рус-япон сугышы башланыр алдыннан да берничә кеше берьюлы Кара урманнан йөгереп чыккан лунатик бүрене күргән булганнар, дип сөйләделәр. Билгеле, урыс императорының башына ни килгәне бүренең төшенә дә кермәгәндер. Тик ул ирләрне үзе белән алып китеп, рухларын кире кайтаручы теге болганчык житез суны, әлбәттә, белгәндер.

Безнең авылда Порт-Артур турында ишеткән кеше юк дисәм, ялгыш булмас. Шуңадыр, японнар турында да мәгълүматлары юк иде. Кемнәрдер японнарны картинадан күргәннәр икән дә, тач безнең авылдагы Касыймга охшаганнар, дип сөйләгәннәр ди, имеш. Мондый чагыштыру Касыймга ошап житмәгән, әлбәттә. Ул, кызып китеп:

— Ә син, син үзең кем, беләсеңме? Малайлы, менә кем син! — дип кычкырырга ук тотынган.

Ни өчен бу жирле халык кеше теленә сөйкемсез булып кергән — белмәссең. Бәлки, безнең малай дигән сүз белән аваздаш булгангадыр? Малайлылар Касыймга малайларга охшап вак булып тоелгандыр?

Сугыш башлануга сәбәп итеп, урыс патшасы японныкы белән ызгышка кергәндер, дип санадылар. Нәрсә бүлешә алмаганнар — анысы берәүгә дә мәгълүм түгел. Ә менә сугышка барыргамы, әллә юкмы дигән сорау авыл ир-егетләренең башына да кереп чыкмады.

Ун ел узды. Кабат ир-атларга чакыру килде. Тик бу юлы ансат кына барып чыкмады. Габделвәкил исемле ишан авылга килеп, татарлар бу сугышта катнашырга тиеш түгел, дип сүз таратты. — Чөнки, — дип аңлатты ул, — Россия Англия һәм Франция белән бергәләп Германиягә каршы сугышка жыена. Ә Германиянең союздашы — Төркия. Төрек солтаны үзенең дошманнарына, шул исәптән Россиягә каршы изге сугыш игълан итте. Шуңа күрә татарлар, мөселманнар буларак, төрек солтанының теләгенә каршы килергә тиеш түгел. Әгәр инде сугышка баранитә калсалар, бары тик Германия һәм Төркия ягына басарга тиешләр, — диде.

Әмма авылыбыз мулласы Гыйльметдин бу фикерне хупламады. — Чит ил патшаларының башына ни килмәс, — диде ул. — Алар үзара тыныша

алмаганга безнең ни гаебебез бар? Без үзебез турында уйларга тиешбез. Төрек солтаны — әнә кайда, ә урыс патшасы — менә генә. Аннары соң, без беренче чиратта мөфтиебезне тыңларга тиешбез. Ул бит бөтен илдәге барлык мөселманның башлыгы. Ә аңардан сугышка бармау турында бернинди хәбәр килеп ирешмәде.

Ир-егетләр бу сүзләргә әллә ни игътибар биреп тормадылар — Азиянең бер почмагыннан икенче почмагына кадәрге араны ат өстендә гизәргә китеп тә бардылар. Мин инде барысын да аңлар, төшенер яшьтә идем. Безнең капка яныннан үтеп киткән ирләр әле дә күз алдымда. Иң алда — Зәкәрия Камали. Үзенең исән-сау кайтырына ышанычы зур иде аның! Тик гәүдәсенең Сербиядәме, әллә Көнчыгыш Пруссиядә калачакмы икәнен генә белми иде әле ул.

Менә инде ничәнче мәртәбә Хәлил турында сүз кузгатам. Хәзергә тыныч күңел белән үлеменә атлаган Зәкәрия Камалины калдырып торам да, уң ел булган хәлләргә әйләнеп кайтам. Кара Сәеттән үч алганнан соң, Зәкәрия Камали, өенә кайта һәм кылычы белән дөньяга туарга ярдәм иткән нарасыйны уллыкка алырга карар кыла. Үзенең өч баласы бар. Өч янына дүртенчесе сыяр, ди торганнар иде безнең авылда. Зәкәрия Камалины бу бала белән яратудан тыш тагын нидер бәйли иде бугай, тик анысы безгә караңгы калды.

Хатыны Хәнифә үксез малайны берсүзсез үз канаты астына алды. Сугыш башланганчы, тагын өч баласына сулыш өрергә өлгерде әле ул изге җан. Ул чор өчен җиде бала күп саналмый иде. Аннары соң теге шашкын су бәрәрсен алып китмәс дип, кем кистереп әйтә ала?

Ничек әле, бер күзе көнчыгышка, икенчесе җиргә төбәлгән Хәлил, аякларын җиргә күмеп, ниндидер сәер җыр суза диген идемме?

Тагын шул исемдә калган: миңа җиде яшьләр чамасы булды микән, авыл халкы ниндидер бәйрәмгә җыелды. Көе булганнар түгәрәк уртасына чыгып җыр җырладылар. Менә чират Хәлилгә житте. Хәнифә апа уллыкка алган баласын күтәреп, урындык өстенә бастырды. Малай күзләрен тирә-якка тәгәрәтеп алды да озын көйгә иске карурман җырын сузып җибәрде. Үзәк өзгеч моң сүзләрне басып китә һәм җырга ниндидер серлелек өсти, әйтерсең аны аландагы рухлар да күтәреп алды. Әмма шунысы сәер: аларның тавышларын беркем дә ишетә алмый.

Авыл халкы, тын калып, җыр тыңлый.

Ә мин бу хәлләрнең төбенә төшәр яшьтә түгелмен. Кызыксынып, тирә-ягыма каранам: авылдашлар тавыш-тынсыз гына елыйлар: ир-егетләр, хатын-кызлар... Әби-бабайларның җыерчыклары, яшь-җилкенчәкнең алсу алма кебек битләреннән яшь тәгәри. Минем кебек Хәлил дә аларны аңламый:

— Әни, нигә елыйлар алар? — дип сорый Хәнифә ападан. Әнисе исә, борынын мышкылдатып, малайны күкрәгенә кыса.

Шулай итеп, Хәлилнең бөек сәләткә ия икәнлеге ачыкланды. Ул берәүне дә кабатламый, аның моңлы тавышы теләсә кемнең җанына үтеп керә: елата, канатландыра, күкләргә чөя һәм бар дөньяны оныттыра.

Мин әле дә бу сәләт, талантның кайдан килгәнен аңларга тырышам. Һәм нәтиҗә ясыйм: бу, мөгаен, Хәлилнең шундый шартларда тууы белән бәйледер. Ул бит әнисе белән теге дөньяда очрашып өлгергән. Дөрес, барыбыз да, үлгәч, әниләребез белән күрешәбез. Тик Хәлил туганчы очрашкан бит, ә менә әнисенең җаны улыныкына ни-нәрсә күчерергә өлгергәндер — анысы безгә караңгы. Бәлки улы белән аерылырга теләмәгәндер, бәлки Хәлил әнисенең рухы чакыруы буенча өрәкләр аланына барып йөридер — кем белсен.

Купедашым туктап калды. Беравык куе караңгылык сарган тәрәзәгә карап торганнан соң, карашын миңа күчерде. Төнге саран ут яктысында аның җыерчыклары тагын да тирәнәеп киткәндәй тоелды.

— Безнең халыкка бик күп кайгы-хәсрәт күрергә, михнәт чигәргә туры килгән. Гасырлар буе килгән бу сызлау-сыкраулар кая китсен? Җырларга күчкән, билгеле. Аларның авторы билгесез, сүзләр сызгырып искән җилләрдән тугандыр кебек. Бар, эзләп кара, тотарсың койрыгын усал җилнең. Кемнедер язмышы океан артына илтеп ташлый да, еллар узган саен, ул кешедә җирсү — туган илен сагыну хисе артканнан арта бара — мин аны аңлыйм. Ә бит монда кеше үз җирендә, әмма күзләре яшьле, йөрәге урынында түгел. Бу — безнең халыкка гына хас булган сирәк сыйфат. Сорнаен тыңлаганда, берәр шотландияленең күз яшен күргәнегез бармы, йә? Америкалы турында әйтеп тә тормыйм.

Ул тагын туктап калды. Бу юлы тынлык озаккарак сузылды. Тик мин әдәп йөзеннән аны бүлдерергә кыймадым.

— Арымадыгызмы әле? — дип сорады ул миннән.

— Юк-юк, кызыксынып тыңлыйм.

— Мин еш кына фәлсәфәгә кереп китәм, ә аны тыңлап утыру — вакытны җилгә очыру. Яхшы, сезне ялыктырудан курыксам да сүземне дәвам итәм.

Безнең авыл кешеләрен җыр берләштерә дип әйтимме... Телиме-теләмиме, һәрбер кеше гасырлар буе тапшырылып килгән кайгы-хәсрәтне үзендә йөртә дә алдагы буынга тапшырып китә. Бу авырлыклар һәм өрәкләр аланы ата-бабаларыбызны безнең белән бәйләсә, без, үз чиратыбызда, киләчәк буын белән бәйләнештә.

Хәер, безнең авылда гел кайгылы хәлләр генә түгел, мавыктыргычлары да булгалап куя. Шуларның берсе турында сөйлим әле. 70нче елларда булган хәл бу. Сез төшенгәнсездер инде, минем туган якларда бик күптәннән булганым юк, бу вакыйга миңа телдән телгә күчеп йөри торгач, килеп иреште.

### Карта ачу тарихы һәм кече йомыш турында

Сүзем — безнең авыл егете Хәлиулла Камалиев турында. Шулай бервакыт аңа зур бер шәһәргә илтә торган тиз йөрешле поездның плацкарт вагонында барырга туры килә. Алда — балкып торган киләчәк, җем-җем килгән утлар, кыскасы — дөнья матур, дөнья киң. Моңарчы күрелмәгән күңелле яңалыклар үсмернең йокысын качырган.

Төнге тукталышларның берсендә вагонга шау-гөр килеп чегәннәр килеп керә. Уйлары күкнең җиденче катында йөргән Хәлиулла аларның астыртын карашларын сизәрлек хәлдә түгел.

Тәрбияле егет буларак, ул үзенең аскы каттагы урынын шактый өлкән яшьтәге юан гына бер чегән хатынына тәкъдим итә. Күреп тора: ул авырлыгы, габариты белән карчык, бик тырышса да, өске киштәгә үрмәли алмас иде. Яңа юлдашлары яшь кешенең бу адымын хуплап каршы алалар. Берничә минуттан үзара танышып та өлгерәләр.

Егетнең күзләрендә чагылган билгесезлекне чамалаган чегән хатыны катлы-катлы итәкләре арасыннан карта җыелмасы тартып чыгара да:

— Әйдә, багып карыйм әле үзеңне, — дип, карталарын таратып та сала. Шундук аның симез йөзе караңгыланып китә.

— Берәр нәрсә бармы әллә? — дип сорый егет.

— Ничек дип әйтим, — дип башлый сүзен чегән хатыны. — Гадәттә синең яшьтәгеләрнең, бер чибәр кызны очратасың, гашыйк буласың, ул да сине ярата кебек җавапларны көткәнен аңлыйм. Тик сине алдарга теләмим.

— Ничек бар, шулай әйтегез.

— Тормышында бик мөһим вакыйга булачак. Бабаңны очратачаксың. Аннары кече йомыш аша син аңа бәйле булачаксың.

— Минем бабам юк!

— Карталар шулай әйтә.

Шул ук елны Хәлиулланы армиягә алалар. Аңа совет гаскәрләре басып алган Көнчыгыш Германиядә хезмәт итәргә туры килә.

Бетмәс-төкәнмәс өйрәнүләр барган җәйге төннәрнең берсендә менә нинди хәл була.

Ниндидер таныш булмаган урында тукталып торган арада, Хәлиулла танктан тышка чыга. Кысан, тынчу урыннан чыкканга, караңгы төн шомлы тоела егеткә. Тирә-якта нарат кәүсәләре шәйләнә. Чит ил һавасы ят. Тик солдат барысына да күнегә.

Хәлиулла шлемын салып, маңгаеннан тирен сыпырып төшерә дә, кече йомышын үтәргә дип, берничә адым читкәрәк атлый. Бушану рәхәтен кичергән егет караңгыда бастырып куелган яссы ташка сиптерүен сизенә. Ул арада танк, үкереп, кайтыр юлга борыла.

— Әй, син, тиз буласыңмы анда? — дип кычкыра кайсыдыр.

— Киләм! — дип тавыш бирә Хәлиулла.

Фаралар Хәлиулла әле генә бушанган ташны яктырта. Анда иске татар язуы белән: «Зәкәрия Камали. 1882-1915» дип язылган була. Совет мәктәбендә укыган егет гарәп шрифтын ничек таныган соң? — Зәкәрия рухы таныткан.

Берничә көн уйланып йөргәннән соң, безнең герой аның I бөтендөнья сугышында хәбәрсез югалган бабасының кабере икәненә төшенә. Ташка чокып язылган язу күз алдыннан китми, җанына кереп урнаша да бар тынычлыгын ала. Шул көннән башлап үзенең җенес органын күрәлмас дәрәҗәгә җитә. Кече йомышын үтәү аның өчен бер газапка әйләнә.

Бәхетенә, хезмәте тәмамланырга күп калмаган була. Өенә кайтып керүгә, яшьләрнең горурлыгы саналган «СА» погонлы хәрби киемен салып почмакка тондыра. Егеткә бер караш салу белән барысы да аңа нидер булуын, күңел төшенкелегенә бирелүен чамалыйлар. «Нәрсә булды?» — дип сорыйлар өйдәгеләре. Хәлиулла ык-мык килә. Бернәрсәгә күңеле үсми, авыл кызлары да күз уңыннан төшә. Кече йомышны үтәү көннән-көн кыенлаша бара, йөзе каралып чыга, яшәү тоташ бер газапка әйләнә. Белмим, бу хәл кайчанга кадәр сузылыр иде, көннәрдән бер көнне Хәлиулла бер картка сүз ката. Һәрбер авылда үз чорының киңәш сорап барырлык акыллы бер өлкәне табыла. Хәтерлисездер, безнең чорда Вафа бабай бар иде.

Хәлиулла мөрәҗәгать иткән карт кайчандыр минем белән тузганаклы болыннарда куыш уйнаган, елгабызда су сибешкән чордашым була. Тик исеме ничек — анысын тәгаен генә әйтә алмыйм.

Беләсезме, нинди киңәш биргән ул Хәлиулла Камалиевка? Өрәкләр аланына барып, бабасы белән сөйләшергә кушкан. Теге дөнья белән элемтәгә керү — бик шикле, куркыныч эш, ул теләсә кемнең кулыннан килми, шуңа бу адымга иң соңгы чиктә генә атлыйлар. Тик кая барасың? Шулай итеп, кояш, тәгәрәп, йортлар артында күмелгәч, Хәлиулла аланга юл тота. Аның каршына зур бер төркем рух килеп баса. Егет бар көченә бабасының исемен әйтеп кычкыруга, рухлар төрле якка таралышып, аланда халык телендә «ат өстендәгеләр» дип йөртелгән 10 ир-атның гына җаннары кала. Берсе, аерылып, егет янына килә. Бу — Зәкәрия Камалиның рухы була.

Тик бу минем шәхси күзаллавым. Нәкъ шулай булгандыр дип уйлыйм мин. Чынлыкта, Хәлиулла Камалиев авызын йозакта тоткан.

Теге дөньядан берәүнең дә кире кайтканы юк, шуңа күрә берәү дә аның турында сөйли алмый.

Хәлиулла шуны гына әйткән: бабасы аны кичергән.

Икенче көнне иртән авылның берничә кешесе кырның авыл һәм ике калкулык уч төбендәге кебек күренә торган җирендә Хәлиулланың тезенә чүгеп, туфракны үпкәнен күргән. Бу хәлнең бабасы белән катнашы булгандырмы, юктырмы — анысы берәүгә мәгълүм түгел, әмма аның җирне үбүе хак. Шушы хәлләрдән соң берничә ел узгач, Хәлиулланы тагын шул ук урында күргәннәр. Шактый ишле гаилә башлыгы, бәхетле ир, тезләнеп, туфракны үпкән, диделәр.

Янәдән тынып калган сөйләүчене бүлдерергә базмадым.

— Сез тыңлар өчен яратылган. Шундый кешеләр бар: беренчеләре сөйләүчеләрне, икенчеләре сүзсез калганнарны бүлдермиләр. Әле тагын шундыйлар бар — үлгәннәрне бүлдермиләр. Менә мин сөйләгәннәр һәм сөйләячәкләрнең барысы да шул кавемгә карый. Инде төшенгәнсездер, безнең авыл бик үзенчәлекле. Ни өчен? Моның сәбәбе булырга тиештер бит? — дип сорарсыз. Кыен сорау, әлбәттә, тик мин җавап бирергә тырышып карыйм. Авылымның килеп чыгышы турындагы фикерләремне сезнең белән уртаклашасым килә.

## Авылның килеп чыгышы турында риваять

Халкыма хас бер үзенчәлек бар — ул котылгысызлык. Бу — яшәү урыны белән бәйле. Бездә кереп качарлык таулар да, адашып эзсез югалырлык карурманнар да, җилкәннәре офыкта эреп күмелерлек диңгезләр дә юк. Язмышыңны ат кулына ышанып тапшырырлык далада да көн күрмибез. Кая гына качсаң да, маңгаеңа корал терәп, җавапка тартачаклар. Шуңа да холык-фигылебез шундыйдыр: хәйләкәр, тапкыр, үткен. Мөнәсәбәтләрне кискенләштерергә яратмыйбыз.

Авылыбыз тарихы турында теллардән телгә күчеп килгән берничә риваять яши.

Шуларның берсендә сөйләнгәнчә, авылга Лотфулла Хәсәни дигән кеше нигез салган. Ул Емельян Пугачев отрядындагы полковникларның берсе — Бәхтияр Канкаевның сугышчысы булган. Ә кайберәүләр Лотфулла Хәсәни шул Бәхтияр Канкаев үзе бит инде, дип расламакчы. Мәгълүм булганча, ул патша гаскәрләреннән котылырга тырышып, иптәшләре белән күз күрмәгән ерак җирләргә барып чыккан һәм чит-ят җирләрдә ятып калган, исемен дә үзгәрткән булырга мөмкин. Әмма Вафа бабайның фикере башкачарак: «Авылга Емельян Пугачев восстаниесенә кадәр үк нигез салынган. Ә Лотфулла Хәсәни кешеләре белән монда көчләп чукындырудан качып килгән», — ди ул.

Лотфулла Хәсәни кылыч белән оста эш йөрткән, диләр. Ул өскә чөелгән карбызны кылычы белән тураклый алган. Нәрсәсе бар инде аның, диярсез. Булган шул: ул карбызны өч мәртәбә чабарга өлгергән. Беренче тапкырында — уңнан диагональ буенча, икенчесендә — сулдан һәм соңгысында өстән аска таба. Кылычына күз иярми торган булган.

Шулай итеп, Лотфулла Хәсәни үзенең тарафдарларын яңа тормыш башлау өчен урын эзләргә алып киткән. Ниләр генә күрергә, ниләр генә кичерергә туры килмәгән аларга: салмак кына Мәккә ягына агылган болытларга да ияргәннәр, атларны аяктан егарлык усал җилләргә дә каршы торганнар. Намазларын еш кына көчле яңгырлар астында укыганнар. Кибеп, коргаксып, корылыкны да үткәреп җибәргәннәр. Юллары төннәрен адәмнәр каршына чыгып койрыклары белән буып үтерергә сәләтле коточарлык бичуралар мыжлаган сазлыклар аша да үткән. Еш кына шүрәлеләр

яши торган кара урманнар аркылы сукмаклар салырга туры килгән. Бу — күкрәкләре тезләренә кадәр салынган килбәтсез җан ияләре нечкә озын бармаклары белән кытыклап үтерергә дә күп сорамаган.

Вафа бабай әйтүенчә, 7 ел тоташ барганнар алар. Дөрес, авылда еллар исәбен төрлечә әйткәннәр дә бар, тик моны берәү дә исбатлый алмый инде. Озын-озак сәфәр вакытында мәхәббәт уеннары да онытылмаган. Караңгы төннәрдә ишетелер-ишетелмәс пышылдаган назлы сүзләр, меңьяшәр имәннәр ышыгыннан ишетелгән татлы ыңгырашуларның нәтиҗәсе буларак, арба көпчәкләре шыгырдавын күмеп, яңа туган балалар аваз салганнар. Ә кайчакларда алар туктаган җирләрдә яңа каберләр калыккан, нишлисең: берәүләр туа, икенчеләр китә.

Бервакыт шундый хәл булган. Нургали Габбас дигән кеше кинәт кенә атын туктаткан да карашын күк йөзен сырып алган кошларга төбәгән.

— Беләсезме, без бит әйләнә буенча йөрибез, — дигән. — Менә бу алан, читтәрәк үскән агачлар, баш өстендәге кошлар өере — бары да таныш. Без бу урыннан бер уздык бит инде, әнә тегендәрәк тукталган идек. Син нигә безнең башны бутыйсың, Лотфулла Хәсәни? Сиңа ышанып туган йортыбыздан китәсе калмаган. Ялганчы, менә кем син!

Йә, ни дип җавап бирергә мондый сүзләргә? Ике ир-ат бергә-бер уртага чыгып басалар. Башкалар читкәрәк китеп сүзсез генә тамаша кылалар. Баш өсләрендә үзәк өзгеч тавышлар чыгарып, кошлар бер яктан икенче якка бәргәләнә. Күз ачып йомган арада Нургали Габбас җиргә тәгәри. Аның башы өч җирдән чабылган була.

Тагын бер кабер калдырып, олаулар янә кузгалып китә. Шул төнне лагерь өстендә тулган ай калка. Лотфулла Хәсәни, үз-үзенә урын табалмыйча, йокыга талган кешеләр арасында йөри. Күзенә өч жиреннән кылыч белән чабылган айдан кан тама кебек күренә.

— Айга карама, күзләреңне йом, — диләр аңа.

— Булдыра алмыйм. Күземне йомуга, ул миңа таба килә дә, кабат аны кылычым белән чабам, — дип җавап кайтара.

Бу хәл һәр төнне кабатлана башлый. Безнең сәяхәтчеләрнең юлы бер авыл аша узганда, аңа киңәш бирерлек карт табыла.

Карт игътибар белән тыңлый да уйга кала һәм бераздан:

— Йом күзеңне, — ди.

Лотфулла Хәсәни күз кабакларын түбән төшерә.

— Нәрсә күрәсең?

— Ул тагын минем өстемә килә. Өч урыннан чабылган. Аннары кошлар тавышы ишетәм.

Ул күзләрен ачканда, көтүче картның кулларында сарык бәтие була. Лотфулла Хәсәни күзләрен йомуга, ай аңа таба килә, ачуга — алдында бәти тора. Соңгы тапкыр йомганда, ай күктә — үз урынында, яралары әкрен-әкрен төзәлә бара, озакламый ул тоныклана һәм бөтенләй югала.

Колагына картның тавышы ишетелә:

— Исән-имин бул. Ул синең дустың, алай гына да түгел, балаларың һәм оныкларыңның ватаны булыр.

Лотфулла Хәсәни соңгы сүзләренең мәгънәсенә төшенмәсә дә, картка рәхмәт әйтеп, үз юлына китә.

Шуннан соң ул җанына тынычлык тапкан, ай да аны башкача борчымаган диләр. Риваять буенча ул, кешеләрен ияртеп, алга таба кузгалган һәм өч тулган ай аша эзләгән урыннарын тапкан, имеш. Менә шулай итеп безнең авылга нигез салынган.

Риваятьне төрлечә аңлап була. Әмма бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк, дип саныйм мин: сарык бәтие юкка гына килеп кермәгән. Корбан бәйрәменә

чалына торган хайван бит ул. Морадына ирешү өчен, нәрсәнедер корбан итәргә кирәк. Лотфулла Хәсәни коточкыч газаплар аша үтеп — аклана. Кеше үтерсә дә — аклана.

Ни өчен ул яшәү урынын шулкадәр озак сайлаган соң, дигән сорау туарга мөмкин. Мин монда берничә сәбәпне күрәм.

Беренчедән, яна тормыш башлау өчен теләсә нинди җирлек ярамаган. Ул вакытта, мәсәлән, Явыз Иван тарафыннан чыгарылган указ әле үз көчендә булган. Татарларга Казан тирәсендә, дөресрәге, шәһәрдән 40 чакрым радиуста төпләнергә рөхсәт ителмәгән. Лотфулла Хәсәнинең патша күзәтүеннән качып йөргәнен исәпкә алганда, бу очрак үзеннән-үзе төшеп кала.

Явыз Иванның тагын бер указы гамәлдә булган: татарлар Иделгә 30 (Чулманга — 30, Мишәгә — 10) чакрым ераклыкта урнаша алмаганнар. Риваятьтә аермачык ишетелгән кошлар тавышы турында язылган урыннар бар. Бу тавышларның нечкә ачы икәнен исәпкә алсаң, болар — акчарлаклар булырга тиеш дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин.

Шулай итеп, үзеннән-үзе аңлашыла: димәк, бәхәс зур суга якын урында барганга, юлны дәвам итми чара калмаган.

Икенчедән, Лотфулла Хәсәни сәяхәтне аңлы рәвештә суза килгән. Үз халкын 40 ел буе ияртеп йөргән Моисей турында, бәлки, ишеткәнегез бардыр. Ни өчен 40 ел? Монда, кем коллыкта туган, шул соңгы булып китсен, дигән фикер ятадыр кебек. Ә Лотфулла Хәсәнинең үз-үзен тотышында Моисей белән ниндидер уртаклык сизелә. Тик ул, ай-һай, чордашларын коллар дип санады микән? Коллык чаткылары күренә башлавын сизенгәндер, бәлки. Һәм бу коллыкны утраклык белән бәйләгәндер. Нәкъ менә утраклык кешеләрдә бәйлелек китереп чыгарды бит. Халык, тәвәккәлләп, баш күтәргән һәм соңыннан иң каты җәзага тартылган. Фетнә куерып килгән җирләргә шунда ук гаскәр җибәрелгән. Башлап йөрүчеләрне әллә кайлардан эзләп йөрисе юк — авылларда алар. Ә авыл үзенең йортлары, төтеннәре, коелары, мәчетләре, бала-чагасы, болытларга омтылган тупыл мамыклары, эскәмиядә йокымсырап утырган карт-корысы белән кая китеп олаксын?

Нәтиҗәдә: авыл канга батырылган, фетнәчеләр җәзасын алган, ә крестьянның күккә төбәлгән карашында — мәңгелек газап, бетмәс хәсрәт. Аларның әлеге ярдәмгә мохтаҗ карашларын берничә гасырдан соң кабат очратачакбыз әле: «Аклар килә — талый, кызыллар килә — талый. Крестьянга нишләргә?»

Лотфулла Хәсәни ни теләгән соң? Кешеләрнең күкрәк тутырып иркен сулыш алуын, янәдән күчмәләр, ата-бабалар каны уйнавын, атына һәм кылычка ышанычы уянуын теләгән. Хәтерлисезме, атаклы фетнәче Тарас Бульба сүзләрен: «Ягез әле, балалар, татарны куып тотыгыз!.. Хәтта уйламагыз да — мәңге тота алмассыз: аның аты Шайтаннан да җитезрәк».

Лотфулла Хәсәнигә ияргәннәр белә: каршы искән җилнең кыргый көе, гаҗәеп матур офык, тук-тук баскан тояк тавышлары — болар барысы бергә укмашып күңелгә кереп урнаша да искитәрлек, аңнарны югалтырлык дәрәҗәдә рәхәтлек, ирек тойгысы тудыралар.

Шулай итеп, риваятьтә әйтелгәнчә, яңа тормыш башлау өчен урын табыла. Нинди җир соң ул? Еракган хатын-кыз күкрәгенә охшаган ике калкулык та, янәшәсендә Кара урман һәм бер ягыннан икенче ягына ерып чыгарлык кечкенә генә елга.

Бу урын юкка гына сайланмаган. Алдарак мин сезгә халкымның фаҗигасе яшәү урынына бәйле: яшеренер тавы, качарлык урманы, җилкән күтәрерлек суы юк, дигән идем.

Минем уйлавымча, Лотфулла Хәсәни авыл өчен урын сайлаганда

шуларны истә тоткандыр. Аның өчен ике калкулык — биек таулар, Кара урман — иксез-чиксез карурман, ә елга — зур диңгез булгандыр.

Ул көн тоташ бәйрәмгә әйләнә. Догалар укыйлар, бер калкулыктан икенчесенә менәләр. Күзләрендә шатлык уйный: ниһаять, күпме озын юллардан соң, үзләре һәм нәсел дәвамчылары бәхеткә тиенәчәк. Аларны хәтта йокы алмый: төне буе учак ялкыннары биешә, сөенеч күнелгә сыеша алмыйча, җыр булып ургыла.

Шунда кемдер сорап куя: ә авылны ничек атарбыз? Лотфулла Хәсәни карашын елгага төбәгән дә, су өстендә чайкалган айны күреп, «Ай» дип атарбыз, авыл да, елга да шул исемне йөртер дигән, имеш. Ни өчен ул шулай диде икән?

Ул тагын бер кат айга, калкулыкларга, аннары иптәшләренә күз ташлап, авылның исемен кабатлый. Кабатлый да, картның сүзләре исенә төшеп, йөрәге урыныннан купкандай тоела: «Ул синең һәм нәселеңнең ватаны булачак».

Димәк, ул — хак юлда. Риваятьтә шулай сөйләнә.

Ләкин авылыбыз исеменә кагылышлы башка фикерләр дә бар. Кайберәүләр, мәсәлән, ул чакта барган көчләп чукындыру сәясәтен ассызыклау өчен шундый исем кушылган, дип бара. Татар телендә аның «кыйгач ай» дигән мәгънәсе дә бар, янәсе. Бу вакытта мәчетләрнең күбесе патша указы белән җимерелгән, ә безнең авыл картада ярым айлы манарасы белән балкып торган.

Миндә тагын бер фикер бар. Бу авылга исем бирүчегә — Лотфулла Хәсәниме ул, әллә башка берәүме — алдан күрүчәнлек хас булган. Шашкын кара-кучкыл суның, ирләрне алып китеп, дөнья буйлап сибәчәген белгәндер ул. Ләкин кайда гына булсаң да — Германиядәме, әллә Сербиядәме, Австралиядәме, әллә Венесуэладамы — син төнге күккә карыйсың да авылыңның йөрәгеңдә генә түгел, күктә дә булуын исенә төшерәсең.

Сүземне Хәлил, аның сәләте ачылуы турында башласам да, авылымның килеп чыгышы белән дәвам иттем. Теләсәм — теләмәсәм дә, хикәямдә янадан-яна исемнәр калкып чыгар. Кайберләре күз уныбызда озаграк тоткарланса, икенчеләре күренеп кенә китәрләр. Исемнәр дә артканнан-арта барыр, чөнки һәрберсе үзе артыннан берничәне ияртер. Безнең халыкка өйләрендә нәсел «Шәҗәрәләр»е саклау хас. Бу искереп, таушалып беткән кәгазь битендә җиде яисә аннан да күбрәк буынның кардәшлек бәйләнешләре язып куелган. Син анда үзеңне табасың да ничә сызык буенча өскә менеп әтиеңне, аннары бабаңны, очына күтәрелгәч, ыруына нигез салучыны күрәсең. Түгәрәккә алынган исемнәрнең теләсә кайсына бармагыңны төрт — фаҗигале, кан тамып торган һәм шул ук вакытта искитәрлек матур язмышка тап буласың. Аңардан сулга — унга, өскә-аска китсәң дә шуны ук күрерсең. Кайчандыр үзеннән соң фоторәсеме дә калмаган Әбделкәрим яшәгән, шуннан ни, диярсез. Мин болай дип җаваплар идем: ким дигәндә безнең өчен әһәмиятле ике вакыйгага ия ул: туган һәм үлгән. Әле тагын камчы чыжлавы, тузан, тир, ат тиресе белән янәшә җаннарны күкләргә чөярлек мәхәббәте булган. Аның хатыны Мәхфүзәдә минем ни катнашым бар, диярсез. Ана булу бәхетен татыган ул. Хәтта артыгы белән: ир-атларны шашкын кара-кучкыл су алып китәсен белгәнгә, әллә ничә балага җан өргән. Өстәвенә, ике улы рекрутлыкка алынып, беркем ишетмәгән Наполеонга каршы сугышка китәсен дә уйлаган.

Купедашым сүзеннән бүленеп, хәл җыяр өчендер, туктап торды.

— Әйдәгез, чәйне яңартыйк. Беләсезме, хикәя икенче юнәлеш алсын өчен, чәйнең сортын алыштырырга кирәк. Безнең нәрсә турында сөйләвебез нинди сорт чәй эчүебездән тора.

Ул чемоданыннан тасма белән бәйләнгән тукыма янчык чыгарды.

— Хәзер яңа чәй пешерәм. Учакта киптергәнгә, аз гына төтен исе килә аннан.

Яңа пешерелгән чәйне йотып куйгач:

— Тәмне тойган кеше күз ачып йомган араныкын да тоя, — дип сүзен дәвам итте. — Аның сыешлыгын, авырлыгын һәм матурлыгын аңлый. Чагыштырып карыйк: без утырган поезд билгесез якларга җилдерә. Тәрәзә артында агачлыклар чагылып кала. Күз алдына китерегез: көтмәгәндә поезд туктап калды, ди. Син вагоннан чыгасың — анда иксез-чиксез караңгы төн. Колагында якындагы һәм ерактагы кыштырдаулар килеп ирешә, нарат сумаласы, җир исен тоясың, янәшәдәге ерымнан килгән дым исен сизүгә, бу чокырның никадәр тирән икәнен сиземләүдән чәчләрең үрә тора.

Менә шулай. Хикәямдә тукталыш ясап, кабаттан башына әйләнеп кайтыйм әле.

Шулай итеп, мин калкулыкның берсендә басып торам һәм сөйгәнемнең исемен атыйм. Энгер-меңгер куера. Күрше калкулыктан Фатыйма җавап кайтара һәм без бер-беребезгә омтылабыз. Ике калкулык арасында очрашабыз да чишмә янындагы куе үләндә яратышабыз. Башымны ике калкулыкка охшаган күкрәкләр арасына төртәм. Аның минем балаларымның анасы булуын телим. Менә ул мизгел: мин аның тәмен тоям — аннан кан, хатын-кыз һәм үлем исе килә.

Без үлемгә шундый якын, хәтта Кара урмандагы рухлар җырын да ишетәбез.

Лунатик бүре хәзер авылга һәр айлы төндә килә.

Беркемгә мәгълүм булмаган ниндидер сугыш бара, соңрак аны гражданнар сугышы дип атаячаклар.

Ирләрне алып китә торган шашкын су туктап калган, аннары бөтерелгән дә, кайнап, юкка чыккан. Ирләрнең дә каберләре монда — үз жирендә.

Безнең арада булган мөнәсәбәтләрне белүләреннән курыкмыйбыз: аның әтисе тифтан үлсә, минеке — мәҗбүри хезмәттә.

Бер-беребезне соңгы кат яраткандай кыланабыз. Бу — чынлап та шулай. Тик мин әлегә моны белмим — ул гына белә.

Фатыйма Сакаева. Бергә аралашып үскәнгә, аның үткәне минем күз алдында.

Башта ул минем алдыма нәни кызчык булып баса. Без, кемнең төше җинелрәк, дип бәхәсләшәбез, аннары аларны җил уңаена очыртып җибәрәбез. Менә хәзер, инде күпме еллар узгач, җил аларны кабат монда китерә. Аларда таныш сукмаклар, тупыл мамыклары, онытыла төшкән тагын ниндидер күнелгә якын нәрсәләр. Ә кайберләре миңа бөтенләй таныш түгел, болары нәни кызчыкныкы икәнен чамалыйм.

Менә ул мәктәп яшендә. Кулына акбур алып сарай тактасына яза. «Сыер — хайван. Алдарга ярамый. Тормыш — матур».

Аннары хәтеремә үсмер кыз буларак килә. Ул әле миннән еракта, әмма мин аның өчен йөз тапкыр үлеп-терелергә өлгерәм.

Бу хатын-кызны күз алдына бастыру өчен болар гына аз, әлбәттә. Шуңа күрә мин аның турында күбрәк сөйләргә мәҗбүрмен. Тик, гадәтемчә, аның да нәсел агачы чытырманына кереп адашырмын кебек.

Аңа алдан күрүчәнлек хас иде. Башкаларга караганда күбрәк ишетә, күбрәк күрә, кунак киләсен һәм үлем житәсен алдан сизенә. Айлы төннәрнең берсендә безнең авылның берничә кешесе аның аяклары янында тыныч кына сузылып яткан лунатик бүрене сыйпап утырганын күргәннәр. Бу алдан тоемлау аңа бабасының атасы Бату Сакаевтан күчкән диләр.

Бу династиягә нигез салучы Бату чәй сәүдәсе белән баеп киткән. «Сәүдәгә аяк атлавы булды, шунда ук уныш елмайды», — дигәннәр аның турында.

Аның исеме белән бәйле истәлекләр һәм риваятьләр күп сакланган. Сезгә шулардан өчесен сөйләмәкче булам. Яшь чагында, өстәвенә, өчесе дә аучылык белән кызыксынган вакытында — йә ауда, йә анда барганда, йә аннан кайтканда булган бу хәлләр. Менә шуларның беренчесе.

## Бату Сакаевка кагылышлы беренче риваять

Бервакыт шулай Бату аудан кайтып килә. Кара урманнан чыгып авылга күтәрелгән мәле. Көн уртасы. Тынны куырырлык эссе. Шулчак ул, нидер сизенеп, уң ягына борылып карый һәм үзе белән куышып дигәндәй барган печән чүмәләсен күреп ала. Явыз көчләр белән бер генә тапкыр булса да очрашкан кешеләр белә: коточарлык хәлләр карангыда түгел, киресенчә, якты кояшлы көндә башлана. Үз күзләренә үзе ышанмагандыр, диярсез. Яисә аягүрә төш күрәм дип, ботын чеметкәндер, дип уйларсыз. Ялгышасыз: ул — күзләре очлы, аңы ачык чып-чын ир-ат иде.

Каушавын җиңеп, печән чүмәләсенә таба атлый ул. Әмма чүмәлә, Бату якынлашуга, юкка чыга. Егет авыз эченнән догаларын кабатлап, авыл ягына юнәлә. Егерме адымнар атлаган микән, ниндидер бер хатын-кыз аның юлын кисеп маташа. Үзенең кыяфәте бик сәер: буе — бер ярым аршын, таратып салган чәчләре карга канатыдай чем-кара, күлмәге җиргә өстерәлеп бара. Буена карата табигый булмаган адымнар белән кызу-кызу атлый, уттай кызган һавада очып бара, диярсең. Бату адымнарын тизләтүгә, хатын тузан болытына әверелеп бөтерелә дә җиргә төшеп куна. Артында ат пошкыруын һәм арба шыгырдавын ишетеп, егет борылып карый. Арбада сеңелкәшен утырткан Яхъя Атнагулов дигән күршесе булып чыга.

— Сез аны күрдегезме? — дип сорый Бату.

— Кемне? — тегесе аңламый.

— Аны.

Хәйран калган күршесе атына сыптырып ала да юыртып китеп бара. Бату арба артыннан күтәрелгән тузанга карап кала. Ана кабат догаларын укырга туры килә, чөнки арбада Яхъяның артында сеңлесе түгел, юл тузаны аша егеткә күзләрен төбәп, теге хатын утыра.

Авылга кайткач, Бату күргәннәрен төкми-чәчми сөйләп бирә. Авылдашлары аны тел шартлатып тыңлап торалар. Яхъя исә ялгызы гына булуына, сеңлесенең ул вакытта бакчада эшләвенә ышандырырга тырыша. Кызчыкны чынлап та бакчада күргән берничә кеше аның сүзләрен җөпләп тора.

Араларында күпне күргән акыллы кешеләр ни-нәрсә булганын аңлатып биргәннәр. Бату Сакаев каршына албасты чыккан икән. Ул төрле кыяфәткә керә ала, шулай да, күбесенчә, бер ярым аршын буйлы хатын-кызга әйләнә икән, ди. Ул адәм баласы йоклап ятканда, килеп, басып үтерергә дә күп сорамый икән. Юкка гына, бастырылдым, дип әйтмиләрдер — бездә, татарларда шундый сүз бар бит.

Албасты синең үткәнең белән бәйләнгән. Әгәр ул килгән икән, димәк, сина үткәндәге кыланмышларың өчен җавап тотар вакыт җиткән дигән сүз. Картлар кинәт кенә үлеп китә, син аларны авыру екты дип уйлыйсың. Белмәсәң-бел: аларның күбесен йоклаган чагында түшәмнән сикереп төшкән албасты басып үтерә.

Һәркемнең үз албастысы була. Әгәр йокылы-уяулы килеш боргаланып-сыргаланып ятасың, сине нәрсәдер изә-сыта кебек тоела икән — бел: албастың килгән. Билгеле, ул яшьләргә, картларга караганда, азрак зыян сала, ә сабыйларга бөтенләй кагылмый (Соңрак сөйләрмен әле: берничә буыннан соң дөньяга киләчәк Миңлебай Атнагулов дигән кеше үзенең албастысын атып үтерә).

Өлкән яшьтәгеләр инде ярты гасырлар әүвәл булган бер вакыйганы исләренә төшерделәр.

Авыл көтүчесе Минвәли белән инде исеме дә онытылган бер карт юктан гына эләгешеп китәләр. Ызгыш җир аркасында чыга, ахрысы. Үзара мөнәсәбәтләрен ачыклап маташканда, көтүче, кызып китеп, картка китереп тондыра. Карт җан тәслим кыла. Бәлки сукканнан да үлмәгәндер, ул инде күптәннән йөрәген тотып, аякларын көч-хәл белән шудырып кына йөргән. Шул хәлләрдән берәр ай үткәч, менә ниләр булган.

Әйткәнемчә, Минвәли авыл көтүен көткән. Башка каба торган эсседән әлсерәгән көтүче тумалып утырган өянке күләгәсендә ятып бераз хәл алмакчы булган, әмма, үзе дә сизмәстән, йоклап киткән. Шулвакыт үгез, көтүдән аерылып килгән дә, Минвәлине мөгезләренә элеп, каурый ыргыткандай, күккә чөйгән һәм янәдән мөгезләренә эләктереп алган. Ерак түгел печәнче ирләр, моны күреп, йөгерешеп килгәннәр һәм көч-хәл белән үгезне тынычландырганнар. Шул рәвешле Минвәли исән калган. Тәнендә тырналган эз дә юк, әмма хәтерен җуйган, ди. Ун еллардан соң микән, хәтере кайткан, әмма сәламәтлеге ташка үлчим калган. Ир-атлар аңа үзе белән булган хәлне сөйләп биргәннәр, вак-төягенә кадәр искә алганнар.

Үгезне тынычландырган вакытта агачлар арасында бер ярым аршынлы хатын шәүләсе чагылып киткәнен күреп калучы булган икән. Ул адәм хатынның үгез янына килеп, колагына нидер пышылдаганын күргән.

Шулай итеп, албасты, кул астына эләккән теләсә кемне котыртып, синең белән алыш-биреш ясарга да мөмкин икән.

Күпчелек кеше үзенең албастысы белән үлем түшәгенә яткач кына очраша, ди. Ә менә Бату Сакаевка сәләт башкаларга караганда күбрәк бирелгән, ул албастысын күрә алган. Әмма албастысы япь-яшь егет белән исәп-хисап ясарга уйламагандыр. Шулай да Батуга өчләтә игътибарлы булып, һәр адымын намусы белән үлчәп атларга туры киләчәген, әгәр сәләтен зыянга файдаланса, аңар бик начар булачагын искәрткән ул.

Бату Сакаев белән бәйле риваятьнең беренчесе менә шушы иде. Авылда бер елдан соң булган икенчесен дә онытмыйлар, буыннан-буынга күчә барып, әле дә сөйлиләр.

## Бату Сакаевка кагылышлы икенче риваять

Монысында да Бату аудан кайтып килә икән. Көн уртасы. Күктә болытның әсәре дә юк. Нәкъ теге вакыттагы кебек тынны капларлык эссе. Ике калкулыкка урнашканга, безнең авылга төрле яклап керергә була. Бату исә чишмә ягына юнәлә. Килеп җиткәч, коралын җилкәсеннән алып җиргә куя да кайнарланган башын салкынча йөгерек суга тыга. Шулвакыт ул суның төшен күрә. Бу төш аның башыннан үкчәләренә кадәр үтеп керә. Башын судан алганда, артындагы агач кәүсәсенә аркасы белән сөялеп утырган таныш түгел бер адәмне күрә. Адәм сүзсез генә Батуга карап тора. Кояшта янган йөзе кылыч белән телгәләнгәндәй җыерчыклы, күзләрендә — бушлык. Бату карашын суга төшерә: су инде йокламый, ул — уянган. Кинәт егетнең колагына Кара урмандагы рухларның җыры килеп ирешкән. Таныш түгел кеше аягына торып баса, күзләре — егеттә. Бату күз ачып йомганчы кулына коралын эләктерә дә тегеңә төбәп атып җибәрә.

Ул көнне бу хәбәр өйдән-өйгә йөреп чыга. Имеш, Бату чишмә янына су эчәргә килгән кешене атып үтергән. Авылдашлары, аны шелтәләп, башларын чайкаудан узмаган. Араларыннан берсе дә бу темага сүз катарга теләмәгән, чөнки беләләр: егет яшь булса да бик кодрач — кылычны да бик оста уйната, мылтыктан аткан ядрәсенең дә тимичә калганы юк, бер сүз белән әйткәндә, ул сүз күтәрүчеләрдән булмый. Бату карашын кайсы тарафка төбәсә дә тынлыкка килеп төртелә, бу тынлык шулкадәрле көчле була ки, очар кошлар бәрелеп, үлемнәрен шунда тапканнар, дип сөйлиләр.

Инде нишләргә? Карангы төшкәч, егет ятагына чумган да үзенең албастысын көтә башлаган. Йөрәге котылгысыз хәл буласын тоеп, күкрәгеннән чыгардай булып типкән. Төне буе керфеккә — керфек какмаган ул. Ниһаять, ачык тәрәзә аша кояшның беренче нурлары үтеп кергән, кошлар аваз салган. Бату күзләрен түшәмгә төбәп, кымшанмыйча яткан да яткан. Менә берзаман каяндыр бер үрмәкүч килеп чыккан да нәкъ аның күкрәге өстендә асылынып калган. Авыл кешесе белә: албасты соңгы тапкыр килүендә алагаем зур үрмәкүчкә әверелеп, корбанына өстән сикерә, ди. Әмма Батуның көтүе юкка була: берникадәр асылынып торганнан соң, үрмәкүч кайсыдыр бер почмакка кереп югала. Егет, догаларын кабатлаганнан соң, тынычланып кала. Әмма озакка түгел: кемнеңдер аякларына килеп елышуын сизенә. Бу — шул, буе бер ярым аршыннан артмаган теге хатын-кыз булып чыга. Бату, селкенергә дә куркып, ни үле, ни тере килеш ята бирә. Бераздан ул үзендә хатынның йөзенә багарлык көч таба... һәм уянып китә. Бүлмәдә беркем юк, стеналарда иртәнге нурлар биешә. Бату, урыныннан торып, тәрәзә янына килгән. Кояшлы матур иртә, тик шаян җил малае гына агач башларында уйнап йөри. Шулчак сарай янында нindидер карамчык күренеп ала да читәннәр артына китеп югала. Бу — буе бер ярым аршынлы теге хатын булган.

Албастысы аңа кагылмый.

Иртән күрше авылдан шундый хәбәрләр килеп ирешә: имеш, бер көн элек анда берничә кешене үтергәннәр, үлекләр арасында хатын-кызлар белән балалар да булган, ди. Батуга чишмә буенда очраган таныш түгел адәм — мәрхәмәтсез кеше үтерүче булып чыккан. Имеш, чишмә буена килүчеләргә, бигрәк тә хатын-кызларга үчле булган, ди. Ул үзенең корбаннарын бик күп авылларның елга буенда калдырган. Бу явыз адәм пычак белән оста эш иткән, дип сөйлиләр. Әйтүләренчә, ике дистә адымнан корбанының күзенә тидерә алган, ди. Бу юлы нәкъ менә Батуны очратуы аркасында гына яман эше барып чыкмаган икән. Бату Сакаев турындагы риваятьнең икенчесе менә шундый.

Әйтергә кирәк, бу риваятьләр кәгазьдә сакланмаган, телдән телгә күчеп, буыннан-буынга тапшырылып килгәннәр. Хәер, соңгы очрак өяз полициясенең архивында теркәлеп калган. Аннан тыш «Волжский вестник» гәҗитендә: «1842 елның 29 июнендә Ай авылы кешесе Бату Сакаев тирә-юньгә билгеле адәм җанын кыючы Хәмди Вадасны атып үтерде», — дигән хәбәр дә сакланган. Билгеле, бу саран гына юллардан тулы картинаны күз алдына китереп булмый.

Шул ук гәҗиттә бу вакыйгага кадәр ун еллар чамасы алдарак басылган: «...елның 14 октябрендә Ай авылы крестьяннары тарафыннан ат карагы Валюшка Взвесь ерткычларча кыйнап үтерелде», — дигән хәбәрдән нинди нәтиҗә ясарга була? Күңелләрдә кызгану хисе туа да, йөрәкләрдә күңелсез эзе кала. Әмма бу вакыйганы башка күз белән, Ай авылы кешеләре ягыннан торып карасаң, алдыбызга бөтенләй башкача килеп баса. Кайвакытларда ат карагы турында шәхес итеп, романтик данга күмеп сөйләнә. Тик сорау туа: авыл кешесе өчен ат нәрсә ул? Күченеп йөрер өчен генә дип әйтү дөреслеккә туры килмәс. Сука вакытында аннан аккан тир синеке белән кушыла. Ул — синең җан дустың, аңа беркем белмәгән серләрең сыя. Сине күрүгә, кырның икенче башыннан шатлыклы кешнәп тавыш бирә. Ул синең йөрәгеңнең бер өлеше. Менә шул сиңа үтә кадерле җан иясен урлап, өстәвенә, бөтенләй билгесез якларга сатып җибәрүче белән үзеңне башкача ничек тотасың? Шуңа күрә ат каракларын әләктерә-нитә калганда, аның ахыры ни белән бетәсе алдан ук билгеле булган.

Күптән түгел күземә күпләргә таныш совет журналының тышын

бизәгән бер фоторәсем чалынды. Кулына гармун тоткан бер авыл агае төшерелгән иде анда. Тупас йөзе аяусыз җилдә кискәләнгән, җыерчыклар белән ермачланган. Өстендә рәешкә генә киелә торган таушала төшкән пиджак. Күкрәгендә соңгы сугышның истәлекләре — медальләр. Агай елмаеп төшкән, әмма күзләрендә — мәңге җуелмас борчу-хәсрәт. Шәхсән үземә мондый караш таныш: җиргә сыенып калу өчен ниләргә генә бармаганнарның карашы ул. Гармун планкалары өстендә яткан, җир өчен тырмаша-тырмаша агач тамырларына охшап калган кулларны да таныйм. Рухлар тавышын ишетерлек үткен, әрекмән кебек тырпайган колаклары да таныш. Ә янәшәсендә — ат танавы. Хәер, башкача була да алмас иде.

Теләсә кайсы авыл кешесен ал: аты белән икесе арасында ниндидер бер серле бәйләнеш бар кебек. Ул бик күптәннән — аттан башка тормышны күз алдына китерә дә алмаган заманнардан ук яшәп килә. Тарас Бульбаны искә алыгыз: «Ягез әле, балалар, татарны куып тотарга тырышыгыз!.. Хәтта уйламагыз да — аның аты Шайтаннан житезрәк».

Ат карагы — үзенең ирегең урлаучы адәм ул.

Валюшка Взвесь кушаматлы ат карагын ни өчен сөнгегә алуларын, шәт, аңлата алганмындыр, дип уйлыйм. Тагын читкә китеп маташам лабаса. Шуңа озын-озакка сузып тормый Бату Сакаевка бәйле чираттагы риваятькә күчәм.

### Бату Сакаевка кагылышлы өченче риваять

Берчакны шулай ау белән мавыгып, Бату авылдан шактый еракка китә һәм үзенә бөтенләй таныш булмаган җиргә килеп чыга. Юлындагы акчарлакларның чыр-чуын ишетеп, зур елгага якынлашуына төшенә. Чынлап та, бара торгач, безнең каһарман Чулманга килеп житкән икән. Ауга хирыслык Батуны яман даны таралган урынга китергән. Бу бик миһербансыз бер алпавытның биләмәләре булган. Тирә-якка аның крестьяннарына карата үтә явызларча кылануы хакында имеш-мимешләр дә таралган. Үзенә ярап бетә алмаганнарга нинди генә җәзалар уйлап тапмаган ул. Мәсәлән, корбанын эссе итеп ягылган мунчага чакырган да, үзенең ярдәмчеләре белән теге бичара тыныннан аерылганчы себерке белән чапкан. Бу бәдбәхет бик күпләрне үзенең төрмәсендә иза чиктергән, дип сөйлиләр.

Якын-тирә авылларда яшәүчеләр байның төннәрен ут ашавын да күргәннәр. Тагын кемнәрдер болай дип сөйләгән: имеш, бервакыт бай нарат кәүсәсе артына кереп киткән дә, аннан, пырылдап, мәче башлы ябалак атылып чыккан, ди. Ә теге явыз үзе җир тишегенә кереп киткәндәй юкка чыккан. Халык аны убыр дип атаган. Ләкин иң мөһиме монысы түгел әле. Күз алдына гына китерегез: күршеләре белән дустанә мөнәсәбәттә булган, үзен әдәпле тоткан, җәмгыяте хәйриягә шактый мул ярдәм күрсәткән кеше — төннәрен юлбасарга әйләнеп, үзенең биләмәләре тирәсеннән Чулман буйлап узган баржаларны талаган. Моның өчен каторгадан качучыларны, тегендә-монда кагылып-сугылып йөргән юлбасарларны, бу юлны сайлаган хезмәтчеләрне махсус кул астында тоткан. Бу сүзләрне ишеткәч, алпавыт турында икеле-микеле уйлар тумадымы? Туса, мин аларны таратырга ашыгам. Алда әйткәнемчә, бай үзенең кул астындагыларына карата үтә явыз булган. Үз җирлегендә тагын шундый тәртип булдырган: байның юлында кем генә очраса да шундук тез чүгәргә тиеш булган. Ул кагыйдәләрне үтәмәүчеләргә менә нинди җәза уйлап тапкан ул хәшәрәт: шул кешене өенә чакыртып китергән, ә үзе бу вакытта анар аркан торган. Әйләнеп бакмастан якынрак килергә боерган. Аннары кинәт кенә борылган да карап-нитеп тормастан аңарчы яшереп тоткан кылычын муен биеклегендә айкап җибәргән. Әгәр гаепләнүче тез чүккән булса, кылыч аның баш өстеннән үткән, инде аяк өсте калса, күз ачып йомган арада башы өстәл астына тәгәрәгән, ә гәүдәсе әкрен генә идәнгә ишелеп төшкән.

Моның өеннән исән-сау чыккан кеше хуҗасын очратканда гына түгел, хәтта исемен ишеткәндә дә тезләнергә ашыккан.

Ниндидер чит-ят кешенең үз җирендә сунарлык итүен ишеткән алпавыт ачуыннан тиресенә сыеша алмый һәм гаеплене үз янына китерергә боера. Бу вакытта аның белән бер юлда йөрүчеләре инде аучыны эләктереп тә өлгергәннәр һәм хуҗалары янына китереп тә җиткергәннәр. Батуны озата килүчеләр анарга бер сүз дә дәшмиләр, алда бу бичараны ни көтәсен белеп, мыек астыннан көлемсериләр генә. Шулай да берсенең әле югалырга өлгермәгән намусы уянып, егеткә, бай өенә керүгә, тез чүгәргә кушкан. «Бәлки, исән калырсың», — дигән. Бату бу кешегә рәхмәтен белдереп, ачык ишектән өйгә атлаган.

Биек тәрәзәле иркен зал уртасында хуҗа кеше, гадәттәгечә, ишеккә аркасы белән басып торган. Өстендәге кара-кучкылт киеме аның кемлеген, ни гамәлләр кылырга җыенуын яшереп торган. Бату, бусаганы атлауга, кыенсынып туктап кала. Теге дә дәшми — бу рәхәт мизгелләрне озакка сузасы килгәндер, күрәсең. Ниһаять:

— Яныма кил! — дигән боерулы тавыш ишетелә.

Бату берничә адым алга атлый.

— Якынрак!

Бату аның артына килеп баса. Кабат озакка сузылган тынлык. Бату, нидер чамалап, тиз генә унга таба бер адым ясап өлгерә.

Нәкъ шул мизгелдә, инбашын җинелчә генә яралап, кылыч очы идәнгә килеп кадала. Тимернең ташка орыну тавышы иркен залда янгырап, почмакларга китеп бәрелә. Алдан яхшылап хәзерләнгән үлем спектакле бу юлы Бату тарафыннан өзелә. Тез чүккәнме ул, әллә юкмы — хуҗаның исәбе егетне баш түбәсеннән касыгына кадәр урталай ярып төшерәсе булган.

Каршында аягүрә торган аучыны күрү аны чыгырыннан чыгара. Кешеләрен дәшеп, Батуны төрмәгә ябарга куша. «Ачлыктан әкренләп үлү белән чагыштырганда, кылычтан китү — бу адәм өчен бәхет булган булыр иде», — дип үзен-үзе юата.

Бату, шулай итеп, караңгы юеш подвалда үлем көтеп ятучылар янына килеп эләгә. Як-ягына карангалап алганнан сон, көченең дә, ирегенең дә шушында өзеләчәген аңлый.

Ләкин Аллаһы Тәгаләнең һәркемгә язган язмышы бар. Шул төнне, безнең каһарманның бәхетенә, канэчкеч бай хөкүмәт гаскәре тарафыннан тотыла һәм, озак та үтми, өере белән суд каршына баса. Аны ерак Себергә сөрәләр, әмма анда озак эшли алмый: бик серле рәвештә шундагы елгага батып үлә. Җир өстендәге гомер юлы шулай тәмамлана явызның: бер елгада таласа — икенчесендә үлемен таба. «Аккан су юлын тапмый калмый. Ә язмыш — сине», — дияргә ярата иде Вафа бабай.

Бу риваятьнең төбенә төшәргә теләүчеләр аның чынбарлык белән бәйләнешен дә күрерләр иде, мөгаен. Мәсәлән, кайчандыр Чулманда капитан Нормацкий юлбасарлык иткән. Ул кеше Шуран авылының явызлардан-явызы — алпавыты булган бит. Шуны да әйтеп үтим: Бестужев-Марлинский үзенең «Латкин» романындагы бер персонажына аны прототип итеп алган. Әмма вакыт аралыгында кайбер аермалар да күренә. Өяз юлбасарының явыз гамәлләре Екатерина II патшалык иткән чорга карый, Бату Сакаев белән бәйлесе ким дигәндә 100 елдан соң булгандыр.

Әйткәнемчә, безнең авыл риваятьләренең үз кануннары бар: аларга берникадәр тылсым кушыла яисә бөтенләй дөньяда булмаган бер персонаж килеп чыга. Ә сез ничек уйлыйсыз — тылсым кайда күбрәк: риваятьләрдәме, әллә чынбарлыктамы?

Бу вакыйгада үземә, шәхсән, Бату Сакаевның кылычтан сакланып

кала белүе кызыклы тоелды. Халкымның асылы һәм аның холык-фигыле — яшәү урыны белән бәйле, дигән идем. Әйләнә-тирәдә ни таулар, ни дингез, ни карурман юк — кая качарга да белмәссең. Кайдан да табалар, эләктерәләр һәм үлемең каршына китереп бастыралар. Котылу юлы бер генә — тез чүгү.

Әмма халкым үзенә генә хас гаҗәеп бер сизгерлек белән бер адым читкә тайпыла да үлемнән котылып кала. Һәм кабат, инде ничәнче мәртәбәләр, коллык белән юклык арасында, уйласаң, баш житмәслек өченче юл табыла.

Сез, бәлки, риваятькә үзең теләгәнчә бәя бирергә тырышасың, дип әйтерсез. Бу бәлки шулайдыр да.

Миңа калса, фикерләрем белән сезне ялыктырдым булса кирәк. Житмәсә, гадәтемчә, янәдән хикәямнең төп сызыгыннан читкә тайпылдым. Нишлисең, авыл хәлләре, үзем дә сизмәстән, үз эченә тартып кертә; аларда сюжет сызыгыннан мөһимрәк ниндидер яшерен төш-үзәк бар.

Хәлил турында башлаган сүзем тагын башка юнәлеш алды. Менә әле дә Фатыйма Сакаева турында сөйлисе урынга, бетмәс-төкәнмәс сүз башы белән мавыгып киттем. Шуңа карамастан, Фатыйманың бабасының атасы турындагысын да дәвам итәсем килә. Теләгем — авылымда булган вакыйгаларны авылдашлар телендә генә калдырмыйча тынлаучыга илтеп житкерү.

## Тагын Бату Сакаев турында

Судан ераграк йөзә, сүздән күбрәк сөйләшә, фикердән күбрәк уйлый, диләр Бату Сакаев кебекләр турында.

Күз алдына китерегез: сыер көтүе утлаган калкулыкка үгез менеп баса. Колакларын торгызып, танавы белән һаваны сөзә һәм беравыктан көтү эченә кереп, үзенә кирәкле сыерны эзләп тә таба. Күпме сыер арасыннан теләккә килгәнен ялгышмыйча сайлап ала.

Батуда да тормышка карата шуна охшашлы тоемлау була. Ул һәрвакыт кирәкле урынга килеп чыга. Алда әйткәнемчә, чәй сәүдәсе белән баеган кеше буларак, сизгерлеге монда да урап узмаган. Кайсы тауга менгәндер, бәлки үзебезнең калкулыккадыр — әмма барыбер Кытай якларыннан искән жилне сизеп алган.

Аз-маз сату-алу эшеннән башлап жибәргән эшен, арадашчылар ярдәменнән баш тартып, тиз арада жайга салырга өлгергән. Сигез микән, әллә унмы елдан, хәер, анысы мөһим түгел, Бату Сакаев безнең якларда зур уңыш казанган сәүдәгәрләрнең берсе булып танылa.

Тагын шунысы билгеле: зур күләмдәге күмәртәләп сату итүдән тыш, күп шәһәрләрдә кибетләр һәм чәйханәләр тоткан, Мәкәрҗә ярминкәсендә, шулай ук Казандагы Печән һәм Ташаяк базарларында лотоклары булган. Шуны да әйтим: бездә һәм тирә-күрше авылларда Сакаевларның кибетләре бар иде.

Бату Сакаев, баеп киткән башка сәүдәгәрләр шикелле, шәһәргә күчеп китмәгән. Эшен башлап жибәргәндә еллар буена авылда күренмәсә, вакытлар узу белән, эше гөрләп киткәч, еш күренә башлый. Сүз дә юк, аның йорты башкаларныкыннан аерылып тора, ул үз байлыгын яшерүне кирәк тапмаган.

Бу кеше турында белгәннәрем менә шушылар.

Ә халык телендә йөргән риваятьләр буенча, Бату Сакаев бездә иң күп телгә алынган кеше. Аның белән Лотфулла Хәсәни генә ярыша аладыр.

Инде әйтүемчә, авылда булган хәлләр чынбарлыкта булган вакыйгалар белән туры килергә дә, килмәскә дә мөмкин. Халык телендә йөргән

имеш-мимешләргә карасаң, Батуның өч хатыны булган. Аның өлгерлеген, байлыгын исәпләсәң — аптырыйсы юк. Әгәр шул еллардагы статистика мәгълүматларына күз салсак, 1866 елда Казан губернасындагы татарларның 0,2%ы өч хатын белән яшәгән. Шулай булгач, ул бәхетлеләр арасына нигә әле Батуны да кертмәскә, ди?

Әлеге сәүдәгәрнең бер сәер ягы турында да имеш-мимешләр бар. Сәүдә эшләрен башлап җибәргәндә, аңа элемтәләр булдырырга, йөкләрен үзенә озата барырга туры килгән, шуңа күрә бик озын чакрымнар узган. Аның юллары Кытай империясе һәм Ерак Көнчыгыштагы Кяхта шәһәре аша үткән, ул Монголия һәм Көнчыгыш Төркестан һавасын сулаган, аның итекләре Сәмәрканд һәм Хәрәзм күперләре аркылы атлаган. Ташкентның Чилонзар районында һәм Оренбургның Сәет бистәсендә үз кеше саналган. Билгеле булганча, чәй бары тик киптерелгәннән соң гына кумәртәләп сатуга чыгарылган. Бату Сакаев, нигәдер, чәйне тагын бер кат киптергән. Юлда кайтканда, ул олауларны туктаткан да капчыктагы чәйне җиргә җәелгән калын киндерләргә бушаттырган. Чәйне дала кояшы һәм җиле ихтыярына тапшырган.

«Хуҗа бигрәк шикчел», — дип уйлаган аның кешеләре. Күпме мәшәкать өстенә вакыт һәм акча җилгә оча, дип санаганнар алар. Әмма Бату үз сүзендә нык торган.

Минем бу вакыйгага үз фикерем бар. Бату Сакаев, мөгаен, олауларын ата-бабалары күчмә тормыш алып барган билгеле урында туктаткандыр. Мин аны бик ачык күз алдыма китерәм: менә ул олаудан төшә, кулларын каш өстенә куеп зәңгәр күккә күз сала һәм тирән итеп дала һавасын сулый. Батуны бик яхшы аңлыйм: чәй үзенә күкнең киңлеген һәм йөгерек җилнең үзенә генә хас көен сеңдерергә тиеш.

Чәй ул — хәтернең нигезе. Ул хәтердә ис тә, аз гына дым да, җил дә саклана. Кеше чәй уртлаганда, чәйнең хәтерендә ни булса, шуны исенә төшерә.

Бату Сакаевның чәе Казанда гына түгел, гомумән, безнең якларда да уңыш казана. Шиһабетдин Мәрҗани мәчетенең имам-хатыйбы белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә нигез салган Галимҗан Барудинең нәкъ менә шул чәйгә өстенлек бирүләре мәгълүм. Әмма мин Бату Сакаев чәен милләтнең рухи күтәрелеше һәм татар мәдәниятенең алтын чоры белән бәйләргә кыймас идем. Тик шунысын да әйтергә кирәк: әлеге процесс алдыннан халыкның күбесе бу эчемлеккә тартыла.

Әйткәнемчә, бик күп йортларда Бату Сакаев чәе пешерелә, бер-ике йотып куюга, кеше үзен хөр, ирекле итеп сизә. Әмма азатлык хисен тою кайнар башларны акылдан да яздырырга мөмкин. Шуңа күрә ул кайнарлыкны сөт белән басалар. Белдегезме инде, чәйне сөт яисә сөт өсте белән эчү күптәннән килә икән.

Бату Сакаев теләсә нинди дуамаллык кылырга сәләтле булган, дип сөйлиләр. Шул ук «Волжский вестник» гәҗитенең 1898 елгы бер санында болай дип язылган: «Беренче гильдия купец, хөрмәтле аксакал Бату Сакаев Захарьев урамы урнашкан районда хулиганлык кылды. Ул кибеттә, сатучы һәм сатып алучыларның котын алып, коралыннан ут ачты». Бу вакыйга безне гаҗәпкә калдыра, билгеле, тик полиция жандармериясенең архивына кереп актарынсаң, бу хәлнең ничек булуы турында беләсең. Беренчедән, бу — аракы сата торган казна кибете булган. Икенчедән, безнең хөрмәтле аксакалыбыз юкка гына ут ачмаган, ул киштәдә тезелеп торган шешәләргә аткан. Ә Захарьев урамы исә Казанның Бату кабиләдәшләре күпләп яшәгән Татар Бистәсе районына караган икән.

Бату Сакаевның авылдашлар теленнән төшми торган: «Аракының хәтере юк», — дигән канатлы сүзләре бар. Ул моны гомер йомгагын сүтеп бетергән

мәлендә бигрәк тә еш кабатлаган. Мәгънәсен, шәт, аңлагансыздыр: чәй хөрлекне искә төшерсә, аракы берни хәтерләми, дип әйтергә теләгән ул.

Күп еллар элек, ничектер, кулыма аның контор кенәгәләренең берсе килеп эләкте. Кенәгәнең бер битендә шундый юллар бар: «үсентегә су сибәләр, гаебе булган кешегә — аракы». Минемчә, сәүдәгәр күз унында менә нәрсәне тоткан: эчү мәҗлесләреннән соң кеше үзен гаепле саный. Намусын югалтып бетермәгәннәр тагын да ныграк газаплана. Аны кем ничек тели — шулай бөгә: әмма ул — ләм-мим. Тик син аның гаебен юарга гына онытма, юкса ул да үсенте кебек кибеп корыр.

Сөйләсәң, күп инде аның кыланмышлары. Менә тагын берсе. Бату Сакаев 1905 елгы инкыйлабта катнашкан кеше бит. Шуның белән бәйле рәвештә әлеге дә баягы полиция жандармериясе архивында аның фамилиясе дә еш күзгә ташлана. Батуны Казанда чуалышлар оештыручылар арасында күргәннәр, дип әйтүгә, күз алдына аерылмас җан дусты — коралын кочаклаган, акылы зәгыйфьләнә башлаган карт килеп баса. Әйтүе генә ансат: сиксәннең теге ягына атлаган чагы була бит. Бер аягы белән кабернең читендә басып торган картка баррикадаларда ни калган иде икән соң? Җавапны Россия тарихы битләреннән табып була. «Мәгънәсез, коточкыч һәм рәхимсез урыс бунты»ның төп терәге — татарлар изелгән халкының азатлыгы турында хыялланган, шуңа күрә аның өчен барыбер — Степан Разинмы ул, Емельян Пугачевмы яисә Владимир Ленинмы — кем ирек вәгъдә итә, шуның артыннан барган». Шуңа күрә азатлык турындагы хыялның ахыры кан, үлем белән тәмамланса да, калтыранган кулларына утлы корал тотып баррикадаларга омтылган Бату картны аңларга була, минемчә.

Никадәр генә сәерлекләр кылмасын, Батуның картлыгы берәүгә дә, шул исәптән сезгә дә кызыклы түгелдер, әйдәгез, аның тагын көче ташып торган чакларын урыйк әле.

## Бату Сакаевка кагылышлы дүртенче риваять яки күз күрмәгән, колак ишетмәгән алмашу

Хикәямне дәвам итү өчен сезгә таныш булган бер персонажны — Яхъя Атнагуловны телгә алмый булмый. Ул Батуның замандашы гына түгел, яшьтәше дә, күршесе дә, әмма иң мөһиме — иң явыз дошманы да.

Кайберәүләр хакында, һи, улмы, ул — һәрвакыт судан коры чыга, диләр. Ә монын турында, һавадан юеш чыга, дип әйткәннәр. Бәлки, бик нык тирләгәнгә шулай дигәннәрдер, кем белә? Әмма, минемчә, бу сүзләрдә Яхъяның асылы чагылыш тапкан. Аның беркайчан да эшләре шома гына бармаган, юлында һәрвакыт нindидер киртәләр очраган, гомумән, кайда гына булмасын, кем белән генә очрашмасын, гел зарлана торган адәм булган. «Кошлар белән ята, балыклар белән тора», — дип тә әйткәннәр аның турында. Безнең авылда балыкларның кайчан уянганын беркем дә белмәгәнлектән, Яхъя Атнагуловның да кайчан аякка басуы турында бихәбәр, һәрхәлдә, иртә таңнан торып басуда бил бөгүчеләр арасында аны күрүче, очратучы булмаган.

Әмма аның бик дәгъвачыл адәм икәнлеге бик күпләргә мәгълүм икән. Менә, мәсәлән, өстәлгә пешкән тавык чыгаралар, ди, ә бу аның һәрвакыт аягын, өстәвенә, гел уңын бирүләрен таләп итә икән. Әле тагын бер гадәтен сөйлиләр: ике кашык белән берьюлы ашый, әмма уңы сулын куып тота алмый иде, диләр.

Яхъя Атнагулов авыл читендәге иске, бер якка кыйшаган өендә усал, өстәвенә ямьсез хатыны белән көн күргән. Алар йөз-битләре белән аерылып

торсалар да, һәрбер үткән-сүткән кеше артыннан шикләнүчән күзләрен кысып карап калулары белән охшаш булганнар.

Кеше үз күләгәсеннән кыска чак, кояш Кара урман артына тәгәрәргә әзерләнгән. Бала-чаганың чыр-чуына көтүдән кайтып килгән сыер-сарыкларның тавышы кушыла. Беләсезме, көтү кайту күренеше — көн дә кабатлана, әмма туйдырмый торган спектакль. Капка төбе саен кеше, алар көне буена юксындырып өлгергән хайваннарын каршыларга чыкканнар. Менә авыл башында энгер-менгергә кушылып, тузан болыты күтәрелә. Ин алда — беркатлы сарыклар теркелди. Алар артыннан үзләренең бәһаләрен белеп кенә сыерлар атлый. Аларга борын аслары кипмәгән таналар, бозаулар ияргән. Алары таралып-чәчелеп кайталар: кайсыларыдыр чит урамга борылган да монсу тавыш белән хуҗаларын чакыра, икенчеләре кырый-ярыйдагы агачларны кимермәкче.

Ниһаять, өйләрен табалмый адашып йөргән соңгы сарыклар да абзарларга кайтып керә. Хатын-кызлар, тынычлап, сыер саварга утыра, урамда ирләр генә кала. Өе каршында өелгән бүрәнәләр өстенә утырып, Бату Сакаев та һәр көн кабатлана торган шау-шуны күзәтә икән.

Ул кичне Яхъя Атнагулов нигәдер бик ачулы була. Сәбәбе нидә — беркем бернәрсә белми. Менә берзаман ул Бату каршына килеп баса да аның күзләренә кадала. Карашыннан бөркелгән ачу-нәфрәттән икенче берәү булса, валлаһи, утырган урыныннан егылып төшәр иде.

— Нигә бар нәрсә сиңа гына, ә миңа — шымытыр? — дип ярсый ул.

Бераз сүзсез торганнан соң, Бату тыныч кына җавап кайтара:

— Синең белән мин генә хәл итә торган мәсьәлә түгел ул.

Ачуыннан шартларга житешкән Яхъя аның аяк астына төкергән. Бу исә — йөзенә китереп орудан да мыскыллы, яман билге-ишарә икән. Моны күреп, Бату урыныннан сикереп торган да тегенең якасына барып ябышкан. Якындагы ир-атлар, Батуның холкын белеп, араларына керергә ашыккан.

Бәхәскә ноктаны куя торган иң шәп нәрсә, әлбәттә, кылыч. Тик ир-атлар каршы төшә, чөнки беләләр: Бату Сакаев теләсә кайсы корал белән эш итә белсә, Яхъя Атнагулов исә үз гомерендә аны тотып та карамаган. Бердәнбер коралы — кашыклар. Менә, ичмасам, алары тәлинкә белән авыз арасында йөреп күрсәтә. Мондый батырлык өстәл артына гына бара шул. Моның шулай икәнен Бату да белә, шуңа тынычланырга теләп, читкәрәк атларга мәҗбүр. Ә дошманы исә бу адымны жинелүгә саный. Ул янәдән, теленә ирек биреп, инде тәмам гарык иткән сүзләрен такмаклый: бу нинди гаделсезлек, берәүләргә өеп бирә, икенчеләре ярык тагарак янында кала, янәсе.

— Ә син ни телисең? — дип сорап куя ир-атларның берсе.

Яхъя Атнагулов кашларын жыерып уйлап торса да, җавабын әйтә алмагач, Бату ягына карап тагын бер мәртәбә төкереп куя. Нәкъ шул минутта Бату буыннардан-буынга күчеп сөйләрлек адымын ясый. Дошманының күзенә батырып карый да:

— Мин сиңа үземдә булганның барысын да — хәзергесен дә, киләчәген дә бирәм. Бары бер нәрсәне — үткәнемне генә алмашмыйм, — ди.

Яхъя Атнагулов шатланып риза була. Бу хәлләргә шаһит авыл агайлары, нәкъ шулай булды, дип сөйләгәннәр.

Аннары, авыл мулласын чакырып, аның хәер-фатихасын алганнар да — эш беткән. Бату Яхъяның кыйшайган өенә киткән. Аны тегенең ямьсез чырайлы, нурсыз карашлы хатыны каршы алган. Бусагадан атлауга, идән тулы кимереп ташланган сөякләрдән гайре нәрсә күзгә чалынмаган. Тәрәзәдән күренеп торган яшелчә бакчасын тутырып әрекмән белән явыз көнчелекне хәтерләткән сары чәчәкле тузганаклар гына үсеп утырган.

Ә Яхъя Атнагулов Батуның иркен өенә килеп кергәндә, аның өч хатыны

һәрберсе үз бүлмәсендә хуҗаларының кичке ашка кайтуын көткән. Өстәлдә, пар бөркеп, зур корсаклы самавыр җырлап утырган, өй тутырып, яңа пешерелгән чәйнен хуш исе таралган, төбенә кадәр ачылган тәрәзәләрдән, юка нәфис челтәрләрне җилфердәтеп, Бату алмашырга риза булмаган үткәннең исләрен һәм төшләрне үзенә сеңдергән уйчан җил саркып кергән.

Шәт аңлагансыздыр: Бату Сакаевның бар байлыгын: өч хатынын, күчемсез милкен, мал-туарын, офисларын, сатып алу конторларын, дистәләгән шәһәр һәм авыллардагы кибетләрен, берничә йөз сәүдә хезмәткәрен, шулай ук адәм ышанмаслык, акылга сыймаслык файда китерә торган эшен Яхъя Атнагулов үзенә алган. «Кирәк бит, ә, — диешкәннәр яңа пешеп чыккан сәүдәгәргә карап. — Шайтан ...тан чук ясады да куйды».

Әмма Аллаһы Тәгаләнең һәрберебезгә тәгаенләп куйган язмышы бар. Еллар үткән. Көтмәгәндә Яхъяның кулына килеп кергән байлык аның бармак араларыннан шуып юкка чыга бара. Йорт кыйшайган, яшелчә бакчасын көнчелек төсендәге сары чәчәкле тузганаклар басып киткән, бер-бер артлы өч хатыны бакыйлыкка күчкән. Зыянга эшли башлаган сәүдәсе дә, көннәрдән бер көнне, бөтенләй туктап калган. Эше комга тәрәлгән хуҗа, юлында очраган бер кешегә котырган эттәй ташланган.

Сезне Батуның хәле кызыксындырадыр инде. Күз ачып йомганчы бер тиенсез калган Бату Сакаев бусаганы атлап керү белән шыксыз йорт аның ныклы кулы белән күзгә күренеп үзгәрә, ямьләнә барган. Яхъяның элекккеге хатынын күреп, авылдашлары үз күзләренә үзләре ышана алмаган: аның җансыз, нурсыз тоелган күзләре миләүшә чәчәге кебек икән бит, тирә-якка нур чәчеп, матур кара кашлары астында җем-җем килгәннәр. Үзе көлә, йөзе көлә — бәхетле булуы чыраена чыккан. Сүз уңаеннан, бервакыт Яхъя Атнагулов килеп, үз хатынын кире кайтармак булып дулый башлаган. Ләкин, беренчедән, соңлап булса да бәхеткә тиенгән хатын аны күрергә дә теләмәгән, икенчедән, авылдашлары алмашу үз көчен югалтуы турында аның исенә төшергән.

Бату исә теге чакта күрше-тирәдәге бер сәүдәгәрнең яңа гына ачып җибәргән читек тегү фабрикасының конторына эшкә урнашкан. Аның тырышлыгы аркасында, фабрика өчләтә файдага эшли башлаган һәм көннәрдән бер көнне ул җитештерү хуҗаларының берсе булып киткән. Һәм, ниһаять, бурычлары өчен сатып җибәрелгәннәрне кире кайтарып, чәй алып-сату буенча туздырылган эшен кабат аякка бастырган.

«Бар нәрсәне алмашып була — хәтта хатын-кызны да. Тик үткәнне алмашырга ярамый.» Шулай диләр авылдашлар бу истәлек турында сүз кузгалганда. Алыш-биреш корбаны булган Яхъяның хатыны үзе теләп яңа ире белән яшәп калган, Бату да соңгы көннәренә кадәр аңарга тугрылык саклап яшәшәсендә булган.

Ә Яхъя Атнагулов үзен алданган кешегә санап, карасына кабынып йөрүен дәвам иткән. Әмма безнең каһарман өчен инде ул әллә бар, әллә юк кешегә әйләнгән.

Бату Сакаев турында күбрәк сөйләдем шикелле. Тик, нишлисең, Кара урманда җиләк җыя-җыя кереп адашкан шикелле, күңел һаман үзе теләгән якка каера.

Ул арада поезд зуррак станциягә килеп керде, ахры. Тәрәзә аша саркып ингән шау-гөргә репродуктор тавышы да килеп кушылды. Бу тукталышта, ниһаять, сөйләүче ял итеп алыр, дип уйладым мин. Ә соңрак, кассетаны әйләндергәндә, нәкъ шушы тормыш ыгы-зыгысы аны чынбарлыкка кайтарганына төшендем.

Тукталыш мәйданчыгына чыктым да, кирәге булыр дип, кассеталар

сатып алдым. Чыннан да, поезд кузгалуга, күршем хикәясен дәвам итте. Мин аның сөйләгәннәрен, гадәтем буенча, II бүлек дип билгеләп куйдым. Аң булыгыз: бу яңа бүлектә үзем катнашмыйм, сүзне тулысынча хикәячегә тапшырам.

## II бүлек

Әгәр мин язучы булсам, роман иҗат итәр идем. Роман ул — юл күрсәткеч сыман, минем фикеремчә, аңа, һичшиксез, карта да өстәргә кирәк. Күз алдына китерегез: автор, экскурсия җитәкчесе кебек, безне үзе артыннан ияртә дә юлда очраган һәрбер йорт турында мәгълүмат биреп бара. Төшенәсездер, мин туган авылым Ай турында язар идем. Идеямне ошаткан башка берәү безне, мәсәлән, Санта-Феның Даун Таун районында, Истанбулның Бишек-Ташында яисә Казанның Иске Татар бистәсендә йөртә ала. Автор кайсыдыр бер йорт янында туктала да аның болдыры йә фронтонының үзенчәлекләре турында сөйләргә тотына. Сүз әкренләп хуҗаларына күчә, аннары инде бу нәселгә кагылышлы нинди дә булса бер риваять яки ахыры фаҗига белән тәмамланган бик матур бер мәхәббәт тарихы телгә алынмыйча калмый. Алга таба атлыйсың, бу йорт белән башка фамилия тарихы бәйләнгән. Әмма алар турында сөйләгәндә, күршеләре буларак, беренче йортта яшәүчеләр дә әйтеп кителә. Ә өченчесендә баштагы ике йорттагыларның кайберләре белән янәдән очрашасың. Шулай итеп, хикәяләү урамның бер очыннан икенчесенә,талгын искән җил кебек, акрын гына өйдән-өйгә күчә бара.

Бер урамны әйләнеп чыккач, экскурсия җитәкчесе сәяхәтне иртәгесен дәвам итәргә тәкъдим итсә, син эчтән генә чираттагы урамны күзаллый башлыйсың. Монысында инде бүтән геройлар, башка тарих — кичәгеләр онытыла. Менә сез алдагы көнне күргән йорт янына килеп чыгасыз — бактың исә, икенче урам беренчесе белән кисешә икән. Безнең күз алдына кабат кичә телгә алынган Әбделхәмит Мәүлиев килеп баса, бу юлы ул башка хикәяләүдә катнашса да, урам чатында үзәк фигура булып тора. Без алга атлыйбыз һәм, яңа вакыйгаларга уралып, вакытлыча бу герой турында онытып җибәрәбез.

Урамнан урамга күчкәндә, Әбделхәмит Мәүлиевка охшашлы берничә персонаж очратабыз — алар безнең картада аерым билгеләп барыла. Нәтиҗәдә, төрле чорларда яшәгән, төрле Аллаларга табынган бу кешеләр картада өчпочмак, дүртпочмак яисә күппочмаклык хасил итеп, романга гомумилек һәм бетемне бирергә тиешләр булып чыга.

Кемдер, урамнары кисешми торган авыллар да бар бит, диярга мөмкин. Сүз дә юк, андыйлар бар һәм шактый еш очрый. Бәлки бу туры килү генәдер, әмма андый җирлекләрдән әллә кемнәр чыкмаган һәм колакка эләрлек вакыйгалар да булмаган.

Янәдән үз авылыма әйләнеп кайтыйм әле. Сүземне, сез каршы түгелләр, күз төшкән кызым турында дәвам итәр идем.

Үзебезнең урамга чыгам да, җил эченә кереп басам. Беләсезме, җилнең гомере кыска бит. Гадәти җилләр елгага, хәтта авыл очына да җитә алмыйлар — үләләр. Әмма монысы — мин эчендә басып торганы — юл узган саен көче арта бара торганнардан. Бу — Казанда эшче Федор Игнатьевны янгын каланчасыннан кагып төшергән, Чистай янында телеграф баганаларын аударган җил.

Кошлар да каршы искән бу җилдән ояларына кайта алмый тилмерә. Хәтта болытлар да тузанга әверелеп, аякларым арасыннан ургылып, киртәләр артына китеп югалды.

Без аның белән шунда очраштык. Ул җил белән бергә бөтерелеп килеп

чыкты да куеныма елышты. Кочаклашкан килеш, озак басып тордык, агымсу юлындагы зур ташларны әйләнеп үткән кебек, җил дә безне уратып узды.

Еллар бер-бер артлы артта калган саен, ул минем төшемә ешрак керә: җил эченнән килеп чыга да кочагыма сыена.

Фатыйма Сакаева өермәләрне кулына ияләштерә ала, лунатик бүре аның янында сыенып урын таба, дип әйткән идем инде. Аның күргән төшләре дә Идел суы кебек тирән, кайчакларда Фатыйма аларда елганың ләм каплаган төбен, караңгы суүсемнәрне, шулар арасында, саңакларын кыймылдатып, зур-зур балыклар йөзеп йөрүен күрүе турында сөйли. Үземә дә шуларга охшаш төшләр кергәнгә, мин аңа берсүзсез ышана идем. Безне үзара төшләр бәйләде, дисәм дөрес булыр. Идел турындагысын исә Вафа бабай болай дип юрады: «Аккан су үз юлын тапмый калмый. Кайчандыр ярларыннан куылганнарны елга үзе эзләп таба».

Минем балачак Фатыйма белән бергә узды, гашыйк булу чоры житкәч, арабызда әллә каян гына Хәлил пәйда булды. Дөрес, анарчы да ул безнең тирәдә чуалды. Әмма монысы бөтенләй башка Хәлил иде. Без — сөт, тирес исе катнаш болын исе аңкып торган авыл малайлары — арабызда «мәхәббәт өчпочмагы» дип аталган ниндидер геометрик фигура урнашканын, әлбәттә, аңлап җиткермәгәнбез.

«Кылый күзле, карар күзгә килбәтсез Хәлил кызны кайсы ягы белән үзенә каратты соң?» — дип сорарсыз. Җавабы гади: әлеге дә баягы Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән моң, җырлау сәләте. Һәм иң мөһиме: аның кебек теге дөньяга якын торып, өрәкләр аланындагыларның тавышын ишетү башка берәүгә дә бирелмәгән иде. Өермәләрне буйсындырырга сәләтле Фатыйманы Хәлилнең җыры үзенә тартып, җанына үтеп кереп, еларга мәҗбүр итә иде.

Алга таба безнең «өчпочмак»ның үзара мөнәсәбәте төрле елларда төрлечә булды. Фатыйма, икебезне дә якын күргәнгә, кайсыбызны сайларга белмичә бәргәләнде. Безгә унөч яшьләр булганда — самими хисләр йөрәкне өтеп ала торган вакытлар — Фатыйма Хәлилгә өстенлек бирсә, ундүрт — унҗиде яшьләрендә мине якынрак күрде. Унсигезгә аяк баскач, мәхәббәтле карашын янә Хәлил ягына төбәде. Ничек инде, диярсез. Хәзер аңлатам: 14 — 17 яшьләрендә үсмерләрнең тавышы алмашынган чор, шуңа вакытлыча җырлавыннан туктап торырга мәҗбүр. Хәлил ансат кына «мәхәббәт өчпочмагы»ннан төште дә калды. Ә инде тавышы яңадан-яңа аһәңнәргә баеп, ирләрчә ныгуга, ул югалтканын артыгы белән кире «кайтарды». Дөрес, «кайтарды» сүзе туры килеп тә бетмәс, чөнки инициатива күбрәк кыз ягыннан булды шикелле.

«Мәхәббәт өчпочмагы» дигәннән, хәзергеләр, бигрәк тә европача фикерләүче яшьләр, җенси бәйләнешләрне күз алдында тотып, берьяклы гына аңларга да мөмкиннәр. Исегезгә төшерәм: татар авылында ир-атка күз уйнатучы хатын-кызның «сөйрәлчек» дигән даны чыга. «Бервакытта да ир-егетләрнең күзенә туры карама, — дип өйрәтә иде абыстай, яшь кызларны үз янына җыеп. — Аларның һәрберсенең күңеленә иблис оялаган, ул нәкъ шул мизгелне көтә — дөрләп янган утка сикереп төшкәненне сизми дә калырсың». Шунадырмы, безнең авыл хатыннары каршы җенестәгеләр белән күзләрен түбән төшереп сөйләшәләр иде. Ә кызлар! Яннарына егетләр якынлашуга, кызларның ике битенә ут каба иде.

Сонрак, туган яклар белән хушлашкач, миңа битләре кызылга манчылган хатын-кызларны шактый очратырга туры килде, тик сәбәпчеләре генә башка: виски, тоник белән джин иде.

Без, малайлар да, мәчет каршындагы мәдрәсәдә укыганда, Гыйльметдин мулла авызыннан кешелекнең гүзәл затлары турында шактый мәгълүмат

алдык. Аның сөйләве дә кисәтү тулы булгангадыр, без дә кызлардан ераграк торырга тырыштык. Мине Фатыйма белән күбрәк төшләр бәйләде булса кирәк, бу исә тән якынлыгына караганда көчлерәк дисәм — ялгышмам. Ә Хәлил белән Фатыйманы Алла тарафыннан индерелгән моң бәйләгәндер.

Авылда бер-берең белән очрашмый торалмыйсың, безгә дә уеннарда, бәйрәм-кичәләрдә гел аралашырга туры килде. Аннары алардан башка тормыш та кичә пешерелгән чәй кебек ямьсез, тәссез булыр иде. Мулла белән абыстай никадәрле генә тукымасыннар, барыбер кызларның яшерен карашлары синең йөзеңнән шуып үтүе була, кисәтүләрне бер якта калдырып, ике йөрәк арасында очкын кабынырга шул җитә кала.

Алда әйткән идем инде, тавышы ныгыган Хәлил кабат Фатыйманы яулап алды. Төшләремдә аның белән янәшә булсам да, өнемдә бәгыремне көнчелек корты кимерде. Ә Хәлил барыбызны да уздырды: туганнарының рөхсәте белән кызның өенә барып йөри башлады. Бездә, югыйсә, никахсыз килеш кыз янында тоткарлану гадәте юк иде. Ләкин бу — аерым очрак. Хәлил җырлаганда, Фатыйма аңарга кушылып рояльдә уйный иде.

Рояль дигәннән, бу уен коралы безнең авылда берничә еллар элек күренде. Кызның әтисе — Сакаевлар эшен дәвам итүче беренче гильдия купец Солтанәхмәт Сакаев — кызының буш вакытын музыкага багышлавын теләде.

Әле дә исемдә: рояльне олаудан төшереп капка төбенә куюга, Сакаевлар тирәсен бу могҗизаны күреп калырга теләүчеләр сырып алды. Гаҗәеп серле кара инструментны кара атны күзләгәндәй тикшереп чыктылар, ә кайбер кыюраклары, атның тешен карагандай, капкачын ачарга да батырчылык итте.

Бу ыгы-зыгыны тамаша кылып, болдырда тәмәке көйрәткән Солтанәхмәт Сакаевның йөзенә елмаю җәелде. Ул үзенең авылдашларын ярата: аларны кан-кардәшлектән тыш, әкрен генә Мәккә ягына агылган болытлар да, иксез-чиксез көтүлекләрдәге тояк тавышларын исендә тоткан чәй дә бәйли иде шул. Аның күпсанлы бай туган-тумачалары кайсы Оренбургка, кайсы Питерга, кайсы Казанга китеп урнашсалар да, ул бабасы Бату кебек, туган җиреннән кубарга теләмәде. Авылдашлар да аны үз күрде.

Кешеләрне байлар һәм ярлыларга аерган гаделсезлек һәрвакыт Вафа бабайның таныш сүзләренә кайтып кала: «Аллаһы Тәгаләнең һәркайсыбызга карата үз язганы».

Бала-чага арасыннан кайсыныңдыр инструментта уйнарга маташуын да Солтанәхмәт Сакаев көлемсерәп күзәтте. Ул да булмады, берничә малай берьюлы клавишларга бәрүдән чыккан яшелле-зәңгәрле тавышлар, монарчы гармун моңыннан башканы ишетмәгән авылны сискәндереп, тирә-якка таралды.

Бер-ике көн үтте микән, өяз шәһәреннән музыка укытучысын чакырттылар. Озын буйлы, аксыл чырайлы алман Иоахим Вернер алып килү һәм илтеп кую шарты белән атнасына ике тапкыр дәрес бирергә ризалашты. Дәрес өчен түләү янына шактый гына түгәрәк юл чыгымы килеп кушылса да, байлыгы чиктән ашкан Солтанәхмәт Сакаев өчен ул чыгымнар ике тиен бер акча иде. Алманны кичке чәйгә күндерделәр һәм ул куна калды.

Ә кичен, зәңгәр күктә ай калыккач, безнең колакка бер көй ишетелде. Алманның әллә чит урынны үзгәләве, әллә илһамы килгән чак булдымы, көй үсканнән-үсә барды һәм, өйне кысан санап, тышка ургылып чыкты да тын урамнар буйлап таралды. Бу көй күңелнең түренә үк үтеп керде. Абыстайның кисәтүләре әкрен-әкрен генә чигенә барып тәмам югалдылар. Көй җаныбызны тоташ ялкыннан торган утка салды да, бар дөньябызны оныттырып, үзе артыннан ияртеп китте. Юк-юк, кеше берүзе бу кадәрле булдыра алмыйдыр, аңар күктәгеләр микән, әллә астагылармы булышадыр. Миңа хәтта өрәкләр аланыннан да кыштырдаулар ишетелгәндәй булды — анда да тыңлыйлар иде, күрәмсең.

Соңрак, күп еллар узгач, бу көйне миңа берничә кабат тыңларга туры килде. Беренчесендә Миңлебай Атнагулов үзе оештырган үтереш-кырылышта алманны, пистолет көпшәсе терәп, уйнарга мәҗбүр итсә, икенчесендә Прага залларының берсендә тыңладым һәм моның Бетховенныкы икәнен белдем....

Алман ул төнне «Ай сонатасы»н уйнаган икән.

Ә өченче тапкырында, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң ике дистәләп ел узгач, Мюнхенда, Гитлерның Кениге-платц мәйданы янында урнашкан элеккеге резиденциясендә ишеттем. Бетон һәм мәрмәрдән төзелгән ярым караңгы заллар буйлап йөргәндә колагыма таныш ноталар чалынды. Кемнеңдер, берәр баланыңмы, ныгып җитмәгән бармаклары аша саркып чыккан көй өске катларның берсеннән агыла. Аннары белдем, хәзер биредә музыка мәктәбе урнашкан, диделәр...

Алман Иоахим Вернерга аерым тукталасым килә. Дәресләр башланып, берәр ел узгач, ул безнең авылга күченеп, Сакаевларның иркен йортында яши башлады. Аның күченүен мин үземчә болай аңладым: бу вакытта Беренче бөтендөнья сугышы бара, музыка укытучыларына ихтыяҗ кимегәннән-кими, өяз шәһәрендә алманның тора-бара бөтенләй эшсез калуы да ихтимал. Өстәвенә, бу сугышта алманнар — безнең дошманнарыбыз, шуңа Вернер кешеләрдә ватанпәрвәрлек хисләре кабынуыннан куркып, өяздән ерак урнашкан авылда үзе өчен тынычрак булыр, дип санагандыр. Бу — минем фаразлавым.

Безнең авылда аңа куркыныч янамады. Фронттагы ир-атларыбызның күпчелеге Сербия һәм Көнчыгыш Пруссиядә ятып калды, рухлары өрәкләр аланына кайту юлында. Күпме җан кыелса да, алманны дошман санау берәүнең дә башына кереп чыкмады, минемчә. Әле киресенчә, дәртләндереп тә җибәрмәде микән: тегендә алманнар белән сугыш бара, ә безнең авылда чын, тере алман яши, янәсе. Алай гынамы, алманга өяз шәһәрендә генә түгел, башкалада да куркыныч янамас иде. Бу канкойгыч сугышның нигезендә башка берәүнекен эләктерү максаты ятканга, күрәлмау, нәфрәт кебек хисләр икенче планда калды. Ә менә II Бөтендөнья сугышында исә нәфрәт иң югары ноктага күтәрелде, шуңа күрә монысында югалтулар ифрат дәрәҗәдә күп, нәтиҗәсә дә коточкыч булды.

Шулай итеп, алман авылда яшәп калды һәм без аны көн саен диярлек күреп тордык. Миңа калса, Иоахим Вернерны күченеп килергә мәҗбүр иткән төп сәбәп — аның холык үзенчәлекләре. Авыл өчен ятрак тоелган алман бик тиз тәртәгә керде: күрәсең, мондагы мохит аның җанына туры килгәндер.

Озакламый ул безне мәдрәсәдә алман теленнән укыта башлады. Беренче тапкыр Гетены төп нөсхәсендә укый алуым белән мин аңарга бурычлы. Ә инде соңрак, илдән-илгә кангырап, иртәгесе көнне үземне ни көткәнен анламый-белми йөргәндә, алман телен белү ярап куйды. Ул гына да түгел, икенче бөтендөнья сугышында әсирлеккә эләккән кайбер ватандашларыма да телне белү ярдәм иткән. Болар — гап-гади авыл мәктәбендә белем алган татар егетләре. Ул елларда безнең илдә сөрелгән алманнарның исәбе-хисабы юк иде.

Шулай итеп, Вернер безгә алман телен өйрәтә башлады. Озак та үтми, мин аның яраткан укучысына әйләндем. Берничә ел эчендә телне шактый камил үзләштердем. Уйлап йөргән ниятемне тормышка ашырырга булдым. Дөрес, мондый сүзләрне үз телемдә әйтергә батырчылык итмәс идем. Шулай көннәрдән бер көнне Фатыйма янына килдем дә, алдан дәфтәргә язып куелган сценарий буенча:

— Фрейлейн, тотнаксыз булып күренәсем килми, әмма бүгенге төнне мин сезнең белән үткәрер идем, — дигән җөмләдән башладым.

Әйттем дә, күзләремне чытырдатып йомып, янак төбенә кундыруын көттем. Көткәнем рас килде: Фатыйма янакка менеп төште. Әмма мин уйлаганча каты итеп түгел, сыйпап алгандай итте. Аннары, көлә-көлә, кулымдагы дәфтәрне тартып алды. Минем тәржемәмә күз йөгертеп чыкты да, башын артка ташлап, чыркылдап көләргә тотынды. Ә мин исә, дәфтәрне эләктерергә тырышып, аның тирәсендә чәбәләндем. Фатыйма, читкә тайпылып, миннән ычкынды да дәфтәрдәге җөмләләрне кычкырып укый башлады: «Сезгә салкын түгелме? Минем пиджакны алыгыз! Күнелегезне кайтармам, фрейлейн!»

— Бир монда! — Мина кыен булып китте. Үземнең көләсем дә килә. Балачактан бергә тәгәрәп үскән Фатыйма күп нәрсәне кичерә, гафу итә иде шул.

Тагын алманга әйләнеп кайтыйм әле. Тора-бара ул мулла белән уртак тел тапты. Әйткәнемчә, Гыйльметдин мулланың халык арасында абруе зур иде. Үзегез беләсез, мулла авылда дин өчен җаваплы кеше. Ул — тәрбияче, дини җитәкче ролен үти. Бу икәүнең дуслыгы, нигәдер, берәүне дә гаҗәпләндермәде.

Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланып килгәндә, яһүдләрнең бик күптәнге, гыйбрәтле хикәясен ишеткән идем. Аны мина Варшава геттосыннан могҗиза белән генә исән калган берәү сөйләде. Эчтәлеге якынча болайрак.

Кайсыдыр авылга кунакка килгән яшь кенә егет халык арасында ыгы-зыгы тууга сәбәпче була. Әсәренгән авыл кешеләре яһүд рухание — раввин янына киләләр.

— Ишеттегезме? Ул Аллага ышанмый!

Рухани авыр гына сулап куя да кунак янына юнәлә. Егет белән озак кына ни турындадыр гәпләшә. Халык ишек төбендә, бөялеп, рухани чыкканын көтә. Менә рухани күренә. Аны шунда ук сырып алалар.

— Куркырлык берни дә юк, — ди ул тыныч кына. — Ул ышанмаган Аллага мин дә ышанмыйм.

Минем уйлавымча, динсез кеше белән Гыйльметдин мулла да үзен шул хикәядәге каһарман кебек тотар иде, мөгаен. Безнең муллага элек-электән кемгәдер боеру, кемнеңдер җанында актарыну ят булды. Аның хәтта хәрәкәтләре дә уйлары кебек салмак иде. Ул бәхәс корудан бервакытта да курыкмады, һәм, кагыйдә буларак, фикер алышуда һәрвакыт өстен чыга иде.

Җомга намазларында хәзрәтне тыңларга күрше-тирә авыллардан да килгәнгә, мәчеттә алма төшәрлек тә урын калмый торган иде. Гыйльметдин мәдрәсәсе дигән дан еракларга таралган иде шул. Күрше авыллардан үзгә буларак, бездә дини сабактан тыш, дөньяви фәннәр дә укытылды. Ай авылы балалары үзләренә җитәрлек белем алды, дип горурланып әйтә алам. Җәдитче буларак, Гыйльметдин мулла иске карашлы мөселманнарга ошап бетмәсә дә, алдынгы карашлы зыялылар тарафыннан хуплап каршы алынды.

Бәлки төшенгәнсездер, авылга җәдитче мулла чакырту уе Солтанәхмәт Сакаевның башына килгән. Минемчә, сәүдәгәр болайрак фикер йөрткән: кайчандыр очар коштай иректә булган ата-бабаларыбыз иңләгән иксез-чиксез көтүлекләр безнең халык хөр, азат булсын өчен, хәзер чиксез зур белем һәм фән киңлекләренә әйләнергә тиеш.

Солтанәхмәт Сакаев мәгариф белән бәйле теләсә кайсы яңа башлангыч өчен акчасын кызганмаган. Алманны калырга да ул үгетләгәндер, дип уйлыйм. Тегесе бераз ялындыргандыр: иртән мина кофе, кичләрен ике бокал бавар сырасы кирәк, дигәндер. Хет унны эч, ә кофены ятагыңа китерерләр, дип әйткәндер сәүдәгәр.

Әле дә хәтеремдә, Иоахим Вернер мольбертын алып, калкулыкларның берсенә менә дә, авыл табигатен рәсемгә төшерә иде. Каядыр юлы төшкән Гыйльметдин мулла, аның янында тукталып, ясалып бетмәгән картинага күз сала. Аннары берәр, кайвакыт икешәр сәгатькә сузылган әңгәмә башлана. Гәпләшү фәлсәфи характерда барганга, без барыбер берни аңламас идек.

Бер-берсеннән ерак торган бу ике кешенең урыс телендә бәхәсләшүе бигрәк кызыклы. Аларның берсе — берничә гасыр буена Россияне Европага һәм Көнбатыш мәдәниятенә тарту өчен чакырылган тел-теш тидермәслек тигез сафлардан булса, икенчесе — тарихчылар фикеренчә, Россия белән Европа арасына тирән упкын ясап, урыс халкын әллә кая — артка алып ташлаган кыргый когортага карый. Беренчесенә Бетховен якын булса, икенчесенең күңелендә — ирекле җайдаклар чабышкан иге-чиге булмаган көтүлекләр. Артыгы белән якын түгелләрмени? Вернер белән Гыйльметдин мулла, мөгаен, моны чамалагандыр.

Алар минем хәтеремдә болай сакланып калдылар. Алман, гаять зур буталчык бер картина төшергәндәй, кулындагы пумаласын тирә-якка селтәп, кызып-кызып, нидер аңлата. Аның мольберты тирәсендә әйләнгәләп йөргән мулланың тавышы, киресенчә, салмак, тыныч. Мулланың сөйләшкәндә бер урында тыныч кына басып тора алмый торган гадәте бар иде. Хәрәкәттә бәрәкәт, диләрме әле? Аның аяклары белән акылы бер ритмда эшлиләр иде.

Унбиш еллар узгач, без Вернер белән Берлинда очраштык. Кечерәк кенә уңайлы кафе тәрәзәсеннән шау-гөрле Фридрих-штрассе урамын тамаша кылып, ашыкмый гына чәй уртлап утырганда, алман үзенең мулла белән дуслыгын искә алды. Мин дә, җаен туры китереп, теге чакта калкулыкта ни турында гәпләшүләре белән кызыксындым. Гаҗәпкә, бу бәхәсне Вернер да онытмаган икән. Ул сөйләшү менә нәрсә турында булган, хәтеремдә ничек калса, шулай тапшырам.

Алман мулла белән бик якынаеп киткәнгә, аңардан бар ислам дөньясы өчен җаваплылык таләп иткән.

— Бездә сынлы сәнгать бар. Мәсәлән, шәмаиллар һәм орнамент, — ди мулла.

Шунысын да әйтергә кирәк, Гыйльметдин мулла сынлы сәнгатькә каршы кеше түгел иде. Аннан соң яңа карашлы мәктәп-мәдрәсәләрдә төп фәннәр белән беррәттән сынлы сәнгать дәресләре дә каралган була. Бары тик Вернер белән бәхәскә керүдән кызык тапкан ул, минемчә.

— Бу бит сынлы сәнгать түгел! Бу бит язу сәнгате! Кешегә күзне күрер өчен биргәннәр. Иҗат итүне бар тулылыгы белән тойсын өчен. Киндергә үзе илаһи фикер төшерә алсын өчен. Ахыр чиктә, иҗат итүдә катнашсын өчен!

— Катнашсын өчен дисезме? — ди мулла, гадәтенчә алман тирәли әйләнгәләп. −Бәлки партнер яки хезмәттәше буларак диярсез тагын? Ай-һай, үз өстегезгә күпне алырга батырчылык итәсез түгелме? Онытмагыз, адәмне Иҗатчы дөньяга китергән. Киресенчә түгел. Ә нигә? Нигә тудырган ул аны? Сезненчә фикер йөртсәң, аңа партнер кирәк булган.

— Нәкъ шулай.

— Ә мин әйтәм, Иҗатчы — иң төп һәм бердәнбер рәссам. Ул бу дөньяны тудырган да үз эшенә хәйран калган.Әмма сез яхшы беләсез, тамашачыдан гайре бернинди сәнгать тә була алмый. Менә шуңа күрә Иҗатчы кешене тудырган. Хәзер аңладыгызмы инде, без — шушы эшләрне лаеклы бәяләргә тиешле тамашачылар. Ә Иҗатчыны беләсез — ул мактаганны ярата. Һәм без аның иҗатына сокланабыз, дөрестән дә, ис китәрлек нәрсәләр бар. Тирә-ягыңа каран! Моннан да матур картина була алмый. Ә сез...

Мулла алманга күз ташлый да йөренүен дәвам итә.

— Сез бөек останын эшен күчереп кенә язасыз. Начар, унышсыз күчермәсен. Тфү!

Мулла, күнеле тулып, төкереп куя.

— Картинам ошамый икән — әйтегез. — Вернерның тавышында хәтер калу сизелә.

— Үпкәләмә, кадерлем. — Мулла таякны артыграк бөгеп ташлаганын аңлый. — Ышаныгыз, сезнең картинагыз искиткеч. Иҗатчыныкыннан калышу турында гына әйтергә теләвем иде, ләкин бу оттырыш сезнең кәефегезне төшерер дип уйламыйм. Әйдәгез, миңа кайтып, чәйләп алыйк әле.

— Бик рәхәтләнеп.

Авыл ягыннан искән җил үзе белән талгын гына көй иярте килә. Бу — Фатыйма Сакаева, рояльдә уйный.

— Укучыгызның уңышлары күзгә күренеп үсә, — ди мулла.

— Ул бик сәләтле кыз, — дип җаваплый Вернер, мольбертын җыя-җыя.

— Миңа калса, Аллаһының фикерен бары тик музыка гына житкерә ала.

— Көй белән Аллаһы Тәгаләне сурәтләп була.

Җыенып беткәч, мулла өенә кайтып китәләр. Өстәлдә аларны пар бөркеп утырган самавыр каршы ала. Әңгәмә чәй янында дәвам итә.

Вернерның картиналарына килгәндә, аларның сыйфатын бәяләүне үз өстемә алырга кыймас идем. Тик шунысын әйтә алам: Фридрих-штрасседагы иязлэнгән кафеда чәйләп алганнан соң, ул мине, кайбер эшләрен күрсәтергә дип, остаханәсенә алып бара иде. Аның аерата яттан ясалган рәсемнәре күңелемдә калган. Алар арасыннан хатын-кыз күкрәгеп хәтерләткән ике калкулыкны, елганы, аның аша салынган күперчекне, офыкка китеп тоташкан Кара урманны шундук шәйләп алдым. Туган-үскән якларымнан аерылганга ун еллар чамасы узганга һәм кайтып күрү өмете калмаганга, күземне яшь пәрдәсе каплады. Күңелем йомшавын алманга сиздермәскә теләп читкә борылдым: әмма сизгер йөрәкле рәссам, бу халәтемне алдан тоеп, бүлмәдә ялгызымны гына калдырган иде.

Тормышымда җирсү аеруча көчәеп алган вакытлар да булмады түгел. Шулай ун еллар чамасы элек Гамбург урамнарының берсе буйлап ашыкмыйча гына университеттагы хезмәттәшем белән очрашуга барам. Кичке эңгер-меңгер чак, карангыдан әледән-әле автомобиль утлары яктырып, реклама язулары жем-жем килеп ала. Безнең колаклар күнеккән шау-шу. Кинәт каршымда гына диярлек юлга кыйгачлап зур йөк машинасы килеп туктады. Кабинасыннан сикереп төшкән шофер үткән-сүткәннән нидер сораштыра, дөрес юлдан кермәгән, күрәмсең. Мондый хәлләр еш булганга, игътибарсыз гына узып бара идем — бер тавыш сагаерга мәҗбүр итте. Бу — җанга якын мөгрәү тавышы иде. Әйе-әйе, мин аны автомобиль кычкыртулары, двигательләрнең шау-шуы, тормозлар чыелдавы аша бик ачык ишеттем. Чыннан да, машинаның арбасында мал-туар иде, терлек сую урынына — бойняга алып барышы булды, ахры. Карашымны өскәрәк күтәрдем: арттагы бассейн бинасы, супермаркетлар фонында ярым түгәрәк мөгезле сөзәк башлар шәүләсе күренде. Неон утлардан сибелгән төрле төсләр якынлашып килгән үлемне хәтерләтеп биешәләр. Терлекләр дә, мөгаен, үзләрен кая илтүләрен аңлаганнардыр.

Мин янә йөк машинасына карадым һәм йөрәгем чеметеп куйды: бу җан ияләре миңа бик якын, кадерле икән ләбаса. Монда, Европада,

минем хәлем дә аларныкына охшаш икән бит. Өстемдә кыйммәтле костюм булса да, кыяфәтем авылныкы икәнемне кычкырып тора: кечкенәдән эш белән чиләнгән кулларым агач тамырлары кебек каткан, аякларым гомере буе ат өстеннән төшмәгән ата-бабаларымнан мирас булып күчкән — камыт, рухлар тавышын ишетергә сәләтле колакларым тырпайган. Юллар чатында ялгызым басып торам: әллә кайда — еракта калган туган авылыма кабат кайтып сыена алырмынмы — билгесез. Карашымны күккә төбим, ә анда — Ай. Сагынудан күзләремнән яшь бәреп чыга.

Машина кузгалып китте. Ә мин таш түшәлгән урамда, кая барып бәрелергә белмичә, басып калдым. Кая барасымны онытып, бик озак, аякларым талганчы, урам буйлап атладым да атладым. Хезмәттәшем белән очрашу бөтенләй башымнан чыккан.

Тагын шуңа охшаш хәлне ике ел элек Бродвейда кичердем. Тәүлегенә егерме дүрт сәгать тынмый торган, төрледән-төрле утлар биешкән төнге урам буйлап барам. Көтмәгәндә күзем юл читендә чиләктән су эчеп торган атка төште. Аның янәшәсеннән генә Тайм-сквер ягына лимузиннар, роллс-ройслар, жир шарының төрле почмакларыннан килүчеләр агыла. Бу көннәр, төннәр буе туристларны тегендә, монда йөртүче экипажга жигелә торган атларның берсе булып чыкты. Аны-моны сизенмәгән ат, чиләккә иелеп, су эчә. Әнә шул муенының бөгелешендә күңелгә якын газизлек күреп, җаным кинәт икегә ярылгандай булды.

Менә тагын читкә киттем. Сүзем Иоахим Вернер турында иде бит. Аның хакында шактый күп мәгълүмат җиткердем шикелле, хәтта үзем дә сизмәстән хикәямә Гыйльметдин мулла да килеп керде. Тик мин хәзер алманның безгә беренче тапкыр килеп куна калган, рояльдә Бетховенны уйнаган кичәнә тукталыр идем. Бу — хикәямә тагын бер персонажны кертеп җибәрергә ярдәм итәр дип уйлыйм.

Шулай итеп, Вернер рояльдә уйный, җәйге җылы кич, төбенә кадәр ачык тәрәзәләр аша өйләргә моң ургылып керә. Әйткән идем инде: мондый көйне кемнеңдер ярдәменнән башка кеше үзе генә иҗат итә алмас. Шулай уйларга бирелеп утырганда, авылны караңгылык чорнап алды, алман белән миннән башкалар күптән төш күрәләрдер, мөгаен, дип уйлыйм. Тәрәзәдән күз салсам, ай яктысында урам аша узган юл читендә Миңлебай Атнагуловның күләгәсе тирбәлә.

Яшьтәшем буларак, телгә алып кителсә дә, аңа аерым тукталасым килә. Ул — Яхъя Атнагуловның оныгы. Бернигә яраксыз гөмбәләр дә нәселен калдырып китә — нишлисең, табигать шулай яратылган — ыруны дәвам итәргә яраклымы ул, юкмы — бу турыда уйлап тормый. Миңлебай Атнагуловның бала чагы күз алдында үтте, ул гел безнең тирәдә бөтерелде. Тышкы яктан башка малайлардан аерылып тормады, ләкин, вакытлар узу белән, аның эче бездән бик күпкә үзгә икәнлеге ачыкланды.

Вафа бабай бала-чаганы гел үзенә тартып тора иде. Ул үзе дә безнең белән аралашуны кирәк тапкан, күрәсең. Үземнән беләм: тормышта шундый вакытлар була — кем беләндер белгәненне уртаклашасың килә. Картлык һәм балалык — болар арасында нindидер үзенә бер аерым ярашу бар. Гомереңнең ахырына кадәр дөреслек эзләп газапланган кеше көннәрдән бер көнне гадилеккә омтыла башлый. Ә гомер башында бу сыйфат анарда болай да була. Шуңадырмы, картлар һәм балалар һәрвакыт уртак тел табалар.

Без дә гел Вафа бабай тирәсендә бөтерелдек. Исегезгә төшерим әле, кеше исән калу өчен иң элек үз кулларына таянырга тиеш, без менә шундый мохиттә үстек. Ә инде янәшәңдә сиңа киңәш бирерлек кеше дә табылса — уңыш елмайды дип сана. «Һөнәргә өйрәнегез, — дип кабатларга ярата

иде Вафа бабай. — Тормышта бар нәрсәне югалтырга мөмкинсең, әмма кәсебең сине коткарыр».

Хәтеремә Микеланджелоның картайгач әйткән сүзләре килә: «Үз һөнәремнең төбенә төшкәндә генә үлүем кызганыч». Тик безнең Вафа бабай әйтүенчә, «һөнәреңнең теге дөньяда да кирәге чыгуы бар».

Ул үзе искитмәле агач остасы иде, агачның җанын аңлый иде. «Елганың агымы булган кебек, агачның да ризалык сызыгы бар, — ди иде бабай. — Әгәр шуларны тоемлый алсаң, син йөзә дә аласың, агач та сиңа ризалыгын бирә».

Аның нык куллары бик күп нәрсәләр иҗат итсә дә, арадан берсе — елга аша кичәргә мөмкинлек биргән көймә истә калган. Каек безнең табигатьнең аерылгысыз бер өлешенә әйләнде дисәм ялган булмас. Минем күңелемә елга шәхсән болай кереп калды: яр буйлатып суга иелгән таллар, казыкка бәйләп куелган көймә, чак кына өстәрәк авылга илтә торган сукмак. Без, авылның бар бала-чагасы, тирә-юньне яңгыратып, көймәдә йөрергә ярата идек.

Вафа бабай, каекны ясаганда ниндидер яшерен максат куймагандыр дип беләм. Менә хәзер, күп еллар узгач кына, гади бер авыл карты, үзе дә сизмәстән, безгә яшәешебезгә үтеп кергән агым, ризалык сызыгы кебек төшенчәләр биргән икән бит. Аннан тыш ярга бәйләп куелган көймә авылның килеп чыгышын искә төшерә. Хәтерлисездер, Лотфулла Хәсәни бу урынны юкка гына сайламаган.

Көймә исә теләсә кайсы вакытта сине башка киңлеккә алып чыгарга әзер кечкенә караб ролен үтәде. Ул котылу, ирекккә омтылуга ишарә кебек иде. Билгеле, бу чагыштыру кемгәдер ясалма кебек тоелыр, тик бу образлар минем язмышым белән бик нык бәйләнде.

Вафа бабай үзенең һөнәрен безгә дә өйрәтергә тырышты. Юк, басым ясамады ул. Иң беренче итеп агачтан төрле-төрле уенчыклар ясарга өйрәтте. Йә әйтегез, кайсы гына малай баш тартыр икән мондый шөгыльдән? Безнең остаз, бик тәфсилләп, эш коралларын ничек тотарга, кайсы агач материалын сайларга икәнлеген аңлатты. Дөрес, безнең ясаган әйберләребез дә үзебез кебек үк гади: арба, өй, кое, бугазлары кисек бәрәннәр (ислам дине, билгеле булганча, ниндидер тере җан иясе ясауны өнәми, ә кисек исә бу хайванның җаны чыкканын белдерә), агач кылыч, тырма, тегермән ишеләр.

Әмма Миңлебай Атнагулов ясаган уенчык безгә беркадәр сәер күренде. Бу аңлаешсыз корылмада аслыкка утыртылган ике таяк арасына бритваның сынып төшкән кисәге урнаштырылган, анысы исә аска-өскә шуып йөри. Вафа бабай, бу уенчыкны күргәч, борчылган кыяфәттә башын чайкады. Ул да безнең кебек корылманың мәгънәсенә төшенмәсә дә, анда ниндидер яшертен нәрсә барлыгын аңлады, ахры.

«Аллаһы Тәгаләнең һәркемгә үз язганы бар», — диде ул, малайга карап.

Бу әйбер — кечкенә генә гильотина булып чыкты. Каян мондый нәрсә авыл малаеның башына килгән диген. Тирес исе аңкып торган ялан тәпиле башкисәр белән бу җәһәннәм машинасын уйлап табучы доктор Жозеф Игнас Гильотен арасында нинди бәйләнеш булсын? Баксаң, Миңлебай гильотина рәсемен күрше авыл ярминкәсенә баргач кулына килеп эләккән китаптан күреп калган икән. Китапта, мөгаен, француз революциясе турында язылгандыр. Тарих буенча житәрлек мәгълүматы булмаган, русча укый белмәгән малай каян килеп аңласын аны. Малайны бары тик машина гына кызыксындыргандыр, китаптагы рәсемне карап (анда, мөгаен, корбан да сурәтләнгәндер) аның ничек эшләвен күз алдына китерү кыен булмагандыр.

Соңрак Миңлебай Атнагулов гильотинада чикерткәне җәзалап үтерде. Вафа бабай яныбызда юк, без әле явызлыкка юл куймаска кирәклекне аңлар яшьтә түгел идек, шуңа бичара бөҗәкне җәзалау күренешен җыелышып тамаша кылдык.

Истә калган вакыйганың икенчесе үсмерлек чорына карый. Үзегез дә беләсез: бу яшьтә балалар үз яшьләренә караганда олырак күренергә яраталар. Авылда көннәр бер-берсеннән аерылмый диярлек, әкрен генә үтәләр дә китәләр. Әмма игътибар беләнрәк карасаң, ниндидер аерма тапмый калмыйсың. Шундый көннәрнең берсе иде.

Мин Миңлебайга:

— Мәчең дә үзеңнән олырак бит синең! — дип кычкырдым. Шуннан алда гына без бәхәскә кергән идек, кайсыбыз кайсыбыздан олырак, янәсе. Теш агартыр өчен шул җитә калды, бәхәс кызды: «Минем белән чагыштырганда син маңка малай гына бит», «Синең әтиең миңа уллыкка бара», «Син тәпиләп киткәндә, мин инде полкны һөҗүмгә алып бардым» һәм шуларга охшаш җөмләләр. Кыскасы, телгә ни килә, шуны әйтештек. Миңлебай Атнагулов үз коймаларына сөялеп торган җиреннән: »Минем яшем бөтенегезнекен бергә җыйганнан да артыграк», — дигәнрәк җөмлә ычкындырды. Кирәк бит, ә, нәкъ шул вакытта каяндыр мәчеләре килеп чыкты да, малайның аякларына ышкына башлады. Аны-моны уйлапнитеп тормый, мин аңа теге «мәчең дә үзеңнән олырак бит синең!» дигән җөмләне юлладым.

Мин-минлегенә тидем ахры, Миңлебайның йөзе кара янып чыкты. Ни өчен икәнен дә беләм, чөнки мәченең яше, дөрестән дә, бер яшькә зуррак иде.

Адәм баласының яше маңгаена язылган була. Ата-анаң кушкан исемне алыштырып була, җенесне үзгәртергә мөмкин, хәтта диннең дә, әмма яшьне — юк. Безнең ише малай-шалайның башына ул вакытта мондый уйлар кереп тә чыкмаган, әлбәттә. Олырак булып күренәсебез килгәндер инде.

Шул хәлдән соң, озак та үтми, Атнагуловларның мәчесе юкка чыкты һәм башка күзгә-башка чалынмады. Авыл җирендә мәче югалу гадәти нәрсә булганга, берәүнең дә артык исе китмәде.Ә менә ат яисә сыер югалсамы — монысы инде башка эш.

Әкренләп җәй көзгә авышты. Елгабызның суы, ярларын ялангач калдырып, тәмам саекты. Бу күренеш миндә авыр тәэсир калдыра: читятларга күренергә тиеш булмаган ниндидер яшерен нәрсәнең кинәт кенә кеше хозурына чыгуы кебек кабул итәм. Әйтерсең елга үзенең караңгы эчке дөньясын ачып сала да, кешеләр әдәпсез кыланып, аның ялангач төбен кызыксынучан күзләре белән айкыйлар. Шул көзне, елгадан су киткәч, югалган мәченең үләксәсе килеп чыкты. Бичараның муенына таш бәйләнгән иде. Минем уемча, мәче җәен, теге бәхәстән соң батырылган булгандыр. Шушы хәлдән соң, Миңлебай Атнагулов белән беркем сөйләшмәс булды. Сүз кушмакчы булганнар да, малайның җилкәсе аша үрелеп караган мәче өрәген күреп, телләрен тешлиләр иде.

Балачактагы вакыйга булса да, бу очрак аның турында бик дөрес мәгълүмат бирә. Аннан соң кеше гомер йомгагын сүтә барган саен әллә ни үзгәрми бит: нинди булса, шундый булып кала.

— Җирәнгеч, кылый, чалыш имгәк!

Бу — Миңлебай авызыннан чыккан сүзләр. Хәлилнең күзләренә туры карап әйтте ул аларны. Сәбәбе ни булгандыр — анысы безгә караңгы, балачакта юк-барга да эләгешергә генә торасың бит. Хәлил дәшмәде — монысын ачык хәтерлим. Янамады да, үпкәләмәде дә, — гомумән, бу мыскыл сүзләргә керфеген дә селкетмәде. Ишетмәде дә бугай ул аларны:

күрәсен, уе бөтенләй читтә йөргән. Шулай итеп, дәшми калуы белән жинде ул Миңлебайны.

Нигәдер минем балачак истәлекләремдә Хәлил белән Миңлебай гел бергә күренәләр. Ни өчен икәнен беләм — яхшылык белән явызлык берсеннән башка икенчесе була алмый бит. Бу — бер медальнең ике ягы, бер битнең ике янагы, бер таякның ике башы шикелле.

Теләсә кайсы авылның — кечкенәме ул, зурмы — тилесе һәм акыллысы, ялкавы һәм эшчәне, сараны һәм юмарты, яхшысы һәм явызы — барысы да бар; Аллаһы Тәгалә боларны ничек бер жирлеккә жыя алды икән дип шаккатасы гына кала. Әгәр игътибарлырак булсаң, монда ниндидер закончалык барлыгын чамалыйсың. Мәсәлән, авыл үзенең бер явыз кешесен югалтса (мәсәлән, ул кабахәтнең ауда гомере фажигале очланырга, йә булмаса үпкә авыруыннан вафат булырга мөмкин), аның урынын яшь буыннан кемдер алачак, әгәр алар арасында андые табылмаса, бер юньлесе барыбер шул юлга басачак. «Бер авылда — бөтен бер илнең хакыйкате» , — дип әйтә иде Вафа бабай.

Миңлебай Атнагуловка бәйле тагын бер вакыйга исемдә. Безгә ул чакта ундүрт яшьләр булгандыр. Бу истәлектә Миңлебай төп каһарман булмаса да, сөйләргә булдым, укучым беренчелекне кемгә бирәсен үзе хәл итәр.

## Көзге белән булган вакыйга

Ул елны жәй бик эссе килде. Әмма авыл халкы күләгәдә качып утыра алмый. Кызу печән өсте, бар халык басуда. Маңгайдан агып төшкән тир күзләрне әчеттерә, тәнне зәһәр бөгәлчәннәр сырып алган. Шәһәр кешесе моңа түзә алыр иде микән — белмим. Авыл халкы чыдам, шулай тиеш кебек саный.

Көн кичкә авышты, рәхимсез кояш та әкрен-әкрен генә офык артына үрмәләде. Өлкәннәр, эшләрен тәмамлап, өйләренә таралышкач, без, бала-чага, су коенырга йөгердек. Әллә нинди кыргый тавышлар чыгарып, кыйкылешкә суга сикердек. Мин елганы иңләп-буйлап йөзәргә тотындым, аратирә караңгы салкынча су астына чумып алам — рәхәтләндем генә. Ярты сәгать үтте микән, әллә күбрәкме, судан башымны калкытсам, малайлар ялгызымны гына калдырып, шау-гөр килеп авылга кереп баралар, бераздан тавышлар бөтенләй тынды. Соңгы тапкыр чумгач, су астында минем башыма бер уй сукты: калкып чыккач — нидер булачак.

Башымны күтәрүгә, алдымда каршы яр, биек булып үскән таллар, алар өстендә баеп барган кояшның нурлары биешкән аксыл болытлар күренде. Аякларым жирне тоюга, артыма әйләнеп карадым. Яр буенда үзгәреш юк шикелле, әмма кинәт кенә су буйлатып тезелгән таллардан төшкән күләгәләр тирәсендә алтын сыман нидер ялтырап китте. Бу әйбер салмак кына өскә-аска хәрәкәт итә. Күземне ачыбрак карасам, ул нәрсә тарак булып чыкты. Алай гына түгел, тарак бер хатын-кыз кулында, ул исә талның елгага авышкан ботагына утырган да чәчен тарый. Мине әллә күрмәдеме, әллә күреп тә игътибар итмәдеме, һәрхәлдә, ничек утырган, шулай утыра бирде. Хатынның өстендә суүсемнәр төсендәге озын иркен күлмәк, чәчләре үкчәсенә тигән.

Ул кулындагы көзгесенә караштырып, чәчен таравын дәвам итте. Ниһаять, башыма барып житте — бу бит Су анасы! Элегрәк аның турында авылдашларым авызыннан күп мәртәбәләр ишеткәнем булды. Аны күрү бәхете бик сирәк кешегә генә тәтүен дә белә идем.

Тавыш чыгармаска тырышып, әкрен генә шул ярга таба йөзә башладым. Үз шөгыле белән артык мавыккангамы, ул миңа борылып та карамады. Карашым белән тирә-юньне никадәр генә айкасам да, су буенда Су анасы

белән миннән башка эт-адәм күренмәде. Су анасы һәм мин — икәүдән-икәү, моны аңлауга йөрәгем куырылып килде. Ничек кирәк алай ярга килеп төртелдем дә, әкрен генә өскә үрмәли башладым. Су анасы уң кул якта, миннән унбиш адымнар чамасы гына. «Ул якка карама!» — дидем үз-үземә. Тик барыбер түзә алмадым — борылып күз салдым һәм аның йөзен күрдем.

Аның чыраен сурәтләп булмый. Шунысын беләм: андыйларга вакыт тамгасын сала алмый. Бер мизгелгә генә күзләребез очрашты. Аягым атламас, тамырларда кан акмас булды. Ул арада Су анасы шуышып төште тә чумып юкка чыкты. Бу хәл шулкадәр тиз булды, хәтта су өстендә түгәрәкләр ясалырга да өлгермәде. Аңыма килеп, яр өстенә мендем дә, ашыгып, киенә башладым.

Күзем яңа гына Су анасы утырган ботакка төште: теге көзгесен онытып калдырган бит. Озак уйлап тормастан, бардым да көзгене эләктердем. Йөрәгем күкрәгемнән чыгардай булып талпына, менә-менә, көзгесен исенә төшереп, Су анасы килеп чыгар шикелле. Нишләргә? Табылдыкны учыма кысып, тиз генә табанымны ялтыраттым. Күперне чыктым да бер тында авылга күтәрелдем. Капка төбенә җиткәч, тыныма капланып, туктап калдым. Ниһаять, күкрәк тутырып сулыш алып, кулымдагы әйбергә күз салдым. Кечерәк чәй тәлинкәсе зурлыгындагы, шома авыр саплы көзгедә искитәрлек нәрсә тапмадым. Аның читен урап алган тупас, тигезле-тигезсез тимер кысасы су өермәсе кагылудан, балыклар орынып китүдән шомарып беткән.

Кулына көзге алдыңмы, аңа күз саласың. Мин дә шулай иттем. Алга сузылган кулымдагы көзгедә алгы планда минем чыраем күренде, артта — тезелеп киткән коймa, эңгер-меңгергә чумган урамның теге очыннан арба тулы печән тартып әлсерәгән ат килә. Ә тагын даерактарак — күктә Чулпан йолдыз күз кыса.

Искитәрлек берние юк, дигән нәтиҗәгә килеп, артыма борылсам — авып китә яздым: бернинди ат та, арба да юк. Караңгылык куеруга карамастан, аргы очы күренеп торган урам буп-буш. Күктә дә, никадәрле карансам да, йолдыз табалмадым.

Ул арада мине кичке ашка чакырганнары ишетелде. Көзгене күлмәк астына яшереп, өйгә кердем.

— Кайда югалып йөрисең? — дип каршылады мине әни.

— Су коендым, — дидем мин.

— Озак маташтың, тиз, өстәл артына. Кулыңны юдыңмы?

— Юк!

— Бар, юып кил!

Янадан ишегалдына чыктым да кулъюгыч янына килдем. Кулымны югач, көзгене лапас буенда яткан бүрәнә астына кыстырдым. Түзалмадым, капканы ачып, янәдән буш урамга күз ташладым. Арбасына печән төялгән атны, күктә җемелдәгән Чулпан йолдызны күреп, чүт артыма утырмадым.

— Нәрсә соң бу? — дип сөйләндем үз-үземә. Ул да булмады, ат якынлаша төште, печән өстенә Гайнан Яушев дигән безнең авыл абзые кырын яткан иде.

— Нигә исәнләшмисең, ә? — диде ул, минем белән тигезләшкәч.

Һушыма килеп сәлам бирдем.

— Шул-шул, мәҗбүр итмәсәң, хәзергеләр исәнләшә дә белмиләр. Без яшь чакта өлкәннәргә сәлам бирми кара — шалт берне янагына, колакның чынлавы атна буена бара иде.

Чаттан борылганчы, абзыйның борын астыннан нидер мыгырдаганы ишетелеп торды.

Төнлә, кемдер төрткәндәй, кинәт кенә уянып киттем. Тәрәзәләрдә ай нурлары биешә. Этиләр ягыннан җиңелчә генә гырлау ишетелә, мич

башындагы эне-сенелләрем тыныч кына мышныйлар — бар да тирән йокыда. Бүтән йоклый алмаячагымны аңладым. Ниндидер сәер көч урынымнан кубарып, үзе артыннан әйдәде. Аңа ияреп, өйдән чыктым, ишегалды аша урамкапкага килдем дә ачмакчы булдым. Күңелемнең бер кырые белән ачарга ярамавын сизенсәм дә, куркуымны кызыксыну җиңде. Анда нидер бар, нәрсәдер булачак — сүз дә юк.

Тимер келәне күтәреп, урамга чыгуга, артымнан капка шыгырдап ябылды. Ай нуры яктырткан урам буйлап алга атладым. Унга каранам, сулга — сәер нәрсә күрмим. Кинәт урамның караңгылыкка чумган очында нидер селкенгәндәй тоелды. Агач күләгәләренә кача-поса шул тарафка юнәлдем. Ай шәүләсе кешене күренмәс итә, өстәвенә ялантәпи булгач, аяк тавышы да ишетелми. Ничек кирәк алай барып җиттем теге шомлы урынга — берни юк. Моннан юл аска төшеп китә, күзгә төртсәң берни күренмәслек куе караңгылык, ай нурына юл биреп, юл буенча аска шуыша. Бу дымлы, салкынча һава аңкып торган якка атласаң, кая барып чыга — билгесез.

Бераз икеләнеп торганнан соң, кайтыр якка борылыйм дисәм, янымда нидер бар сыман тоелды. Бу тавышка да, кыштырдауга да охшамаган; үзе җинел сыман, мин аны күзләрем белән түгел, кинәт туңып киткән үпкәләрем белән тойдым. Үземнән ун адымнар читтә, караңгылык эчендә басып торган шәүләне шәйләп алдым. Ир-атмы ул, хатын-кызмы — абайларлык түгел.

Кыймылдарга да куркып торам. Үземне сиздерергә ярамый, бәлки ул мине күреп өлгермәгәндер. Берничә минут миңа мәңгелек кебек тоелса да, дөрес юл сайлаганымны аңладым. Сез, мөгаен, беләсездер, әгәр өйдә берникадәр вакыт селкенмичә утырсаң, почмаклардан тычканнар йөгерешеп чыга. Күзләрен-колакларын булса да, суласаң да — алар сине җиһаз диеп кабул итә. Монда да шулай килеп чыкты. Шәүлә, урыныннан кубып, авыл ягына китте. Бераз сабыр иткәннән соң, мин дә аның артыннан кузгалдым. Шәүлә, агачлар арасында бераз югалып торганнан соң, кабат күренде һәм авыл читенә таба атлады. Кая бара ул — һич аңламадым. Аңардан калышмаска тырышып, шул ук вакытта уяулыкны да киметмичә, артыннан иярдем. Бар кыюлыгымны җыеп, якынлаша төштем дә әле караңгыда, әле яктыда чагылып киткән аркасына карап юлымны дәвам иттем.

Менә адәм заты каршыда үсеп чыккан киртәгә терәлеп туктап калды. Куллары белән киртәгә таянып, баскан урынында тынды. Мин дә әкренәергә мәҗбүр булдым. «Хәзер әйләнеп карый да ниндидер куркыныч хәл булачак», — дигән уй миемне телеп үтте. Ул аркасы белән тора бирде. Ниһаять, әкрен генә миңа таба борыла башлады. Аның һәр хәрәкәтеннән аяк астымда җир убыла кебек тоелды. Ай яктысы аның миңа таба борылган чыраена төшүгә, куркуымнан кычкырып җибәрдем.

Ышанасызмы, аңарда минем йөзем иде. Тавышым шулкадәр көчле булган, күрәсең, тирә-ягым калтыранып куйды. Күз алдымнан упкын арты упкын чагылып узды, аннары гына үземнең ятагымда икәнем башыма барып җитте.

— Төшләнәсең, улым. Авырып киттең мәллә? — дип сорады әнием, миңа иелеп.

Тәрәзәләрдә ай нурлары биешә. Төн уртасы авышып бара.

— Мөгаен, кояш суккандыр. — Монысы әти тавышы.. — Су китер.

— Йә коенганда арттырып җибәргәндер, — диде әни.

Әле акыл кермәгән малай-шалай гына булсам да, төшендә бәхетсез кешене өнендә дә шул көтәчәген аңлый идем. Шуңа иртән торуга, бүрәнә астындагы көзгене, читкә карап, аяк чолгавына төрдем дә күлмәк астына кыстырып куйдым. Исәбем — чит кеше әйберсеннән котылу иде.

Төнлә төшемдә йөргән урамны үтеп, аргы очына чыкканда Хәлил,

Фатыйма һәм Миңлебай Атнагуловны очраттым. Аларның өчесен бергә күрү сәер, билгеле, әмма нишлисең, дөнья түгәрәк, кайвакыт юллар кисешкәндә үзең дә гаҗәпкә каласың. Фатыйма миңа нидер булганын шундук чамалады:

— Нәрсә булды? Берәрсен очраттың мәллә?

Күлмәк астындагы көзгене тартып чыгардым һәм барысын да сөйләп бирдем. Өчесе арасыннан Миңлебай Атнагулов кына миңа ышанмады.

— Су анасына көзге ниемә? Ул бит судан да карана ала, — диде ул.

Фатыйма белән Хәлил, киресенчә, бик җитди иделәр. Мин көзгене сүтеп тормадым, нишләргә белмичә, басып тора бирдем.

— Бу көзгедә үзеңнең киләчәгеңне күреп була, дип әйтәләр, — диде Хәлил.

— Ә минем анда үзеңнең үлемеңне күрәсең, дип ишеткәнем бар, — дип дәвам итте Фатыйма.

— Үлем киләчәкнеке түгелмени?

— Әлбәттә, киләчәкнеке.

Көзге кулымны өтеп алгандай булды.

— Нишләтергә инде моны? — дип сорадым.

Моңа чаклы авызына су капкандай сүзсез торган Миңлебай Атнагулов телгә килде:

— Сафсата бу, минемчә.

— Ә миңа алай тоелмады, — дидем мин.

— Алайса бир, күз салыйк.

— Авызыңны да ачма, — дип каршы төште аңа Фатыйма.

— Куркасыз — менә шул. — Миңлебай бирешергә теләмәде.

— Курыкмассың.

Шулвакыт Миңлебай һич уйламаганда кулымнан көзгене тартып алды да, читкәрәк китеп, чүпрәген чишеп атты. Исемә килгәндә, ул көяз кияү кебек, үзен көзгедән карап тора иде. Мин аңа ташландым, әмма ярты юлда каккан казыктай катып калдым. Йөзе үзгәреп китүен күреп, без аның көтелмәгән нәрсә күрүен аңладык.

Кызыксыну куркудан өстен, диләр. Мин дә гипнозланган шикелле көзгедән күзен аера алмаган Миңлебай артына килеп бастым.

Искиткеч бүләк ясаган икән көзге аңарга!

Елга буе. Каяндыр кара-кучкыл су ишелеп төшә, урыны белән зур йомры ташларга бәрелеп, күбекләнеп тора. Ярлары биек, текә. Бөтенләй чит-ят, күз күрмәгән урыннар. Аннан бөркелгән салкынлык тыннарны куыра. Каяндыр әллә җил тавышы, әллә бүре улавы ишетелә.

Бу картинаны бик кыска арада күреп калсам да, хәтеремә шулкадәрле уелып калды ки, күп еллар узгач та күз алдымнан китми йөдәтте. Бер детале дә игътибардан читтә калмаган. Шуңа күрә ышанып әйтә алам: ярның бер ягында биек кыя таш янында шәйләнгән шәүлә — бүренеке иде.

Утыз елдан соң моның тәмугка таба аккан елга икәненә инандым.

Тагын утыз ел узгач, бу елга турында тагын да күбрәк белдем. Әмма монысы турында соңрак, хикәямнең соңгы бүлегендә сөйләрмен.

Шулай итеп, көзгедә кара-кучкыл сулы елга күбекләнеп-кайнап, чоңгыллар хасил итеп ыргыла, Миңлебай Атнагулов башына балта тигәсе белән органдай селкенә дә алмыйча басып тора. Мин дә урынымнан кузгала алмыйм.

Шулай тагын күпме торган булыр идек — кемнеңдер ышанычлы нык куллары аңыбызга кайтарды.

Фатыйма Сакаева эшнең нидәлеген шундук аңлап алган. Ул Миңлебайның кулыннан көзгене тартып алды да култык астына кыстырды.

— Тиз бул, чүпрәкне бир!

Жирдән, иелеп, аяк чолгавын алдым да Фатыймага суздым. Ул көзгене тиз генә төреп кулыма тоттырды да:

— Котыл ятьрәк аннан, ишеттеңме? Хәзер үк!

— Ничек итеп?

— Каян алдың, шунда куй. Аңладыңмы?

Уйланып торыр ара юк, тын да алмый, калкулыктан елгага атылып төштем, күперне очып диярлек кичтем дә Су анасын очраткан урынга чаптым.

Читкә карап чүпрәкне чиштем дә көзгене алган урынга куйдым.

Кичен малайлар белән елга буена барсам да, су керергә базмадым: сунын күренеше тынычлыгымны алды. Иптәш малайлар сай җирдә чупырдашкан арада, ауган агач янына барып, көзгенең юкка чыгуына инандым.

Шулай да куркуымнан тиз генә арына алмадым. Су анасы тынычлыкта калдырмас дигән уй башымнан чыкмады. Аптырагач, Вафа бабайга киңәшкә киттем.

Агачтан нәрсәдер юнып маташкан бабай тыңлап торды да:

— Башыңнан чыгарып ташла, — диде.

— Әгәр ул миннән үч алырга теләсә?

— Нәрсә өчен? Алган әйберенне кайтаргансың бит инде.

— Ә сезнең аны күргәнегез булдымы?

— Күрдем.

— Мин куркам.

— Акыллым, — Вафа бабай йөзе белән борылды. — Син алардан үзенә тиеш булмаганны алгансың, юлы булмаган җиргә керергә маташкансың. Хәзер үзеңнең хаклы булмавына төшенгәнсең. Алардан куркырга кирәкми. Кешеләр — хәтәррәк.

— Алда ни булачак?

— Берни дә.

Ул мине тынычландырды. Дөрестән дә, алдагы төннәрдә төш күрми йокладым.

Мин сезгә алтмыш ел элек үзем белән булган вакыйганы сөйләдем. Хәзер гомеремнең көзе якынлашып килгәндә, икенче төрле — кыя башында басып торганда диләрме әле, күп нәрсәгә бәя бирә алам. Нәрсәсе кызык: алтмыш ел элек булган хәлләр утыз ел элгәре булганнарга караганда ачыграк истә калган. Әгәр хәтерне магнит тасмасы, кинопленка яки күргән, ишеткән, кичергәннәрне саклаган башка шуның ише әйберләр белән чагыштыра калсак, балачакныкы күпкә югары сыйфатлы икәнен белер идек.

Менә тагын читкә киттем. Сүз яшьтәшем Миңлебай Атнагулов турында иде бит. Дөресен әйткәндә, көзге белән булган вакыйганы аның исеме белән бәйләп сөйлисем килгән иде. Күләгәдәрәк калса да, барыбер төп каһарман дип мин аны саныйм.

Бу кеше балачакта ук башбирмәс, кыю булуы белән истә калган. Анардан салкын тимер ныклыгы бәрелеп тора иде.

Миңлебайга уналты яшьләр булганда, Атнагуловлар гаиләсе Казанга күченде. Үсмер кичләрен шәһәрне икегә — татар һәм урыс ягына аерып торган Болак суына карап утыра башлый. Борылышларда әрле-бирле килгән үтәли җил белән аның бит-йөзе ашалып тупаслана, йодрыклары рәхимсез урам сугышларында ныгый. Үпкәләре иртән Кабан күле өстендә эленеп торган сыра парлары, үкереш-елаш, сатлык мәхәббәт белән тулы куе кызыл томан сулый. Арабыздан кемдер, Казанга барып кайткач, Миңлебай Атнагулов революционер булган, дип сөйләде. Тагын кайсыларыдыр моның дөреслеген раслап, аны полиция эзли икән, фоторәсеме баганаларга

ябыштырылган, табып бирүчегә зур күләмдә акча вәгъдә ителгән, дип тә өстәделәр. Әле тагын, Минлебай бомба ыргытучы икән, аның кулыннан киткән бик күпләр аның намусында, дип әйтүчеләр дә табылды.

Ике революциядә дә безнең авылдаш җимергеч дулкынның иң өстендә йөргән, диделәр. Кызыл комиссар булган, тирә-яктагыларны дер селкетеп тора икән ише имеш-мимешләр дә килеп иреште.

Соңрак, гражданнар сугышының иң кызган чагында, ул үзе житәкләгән отряды белән авылга кайтып төште. Шыксыз көз көннәре, кичләрен бик нык салкынайта, шунлыктан офык кылыч белән ясалган озынча җәрәхәт кебек, кансу кызыл төскә керә иде.

Без нәрсәдер буласын көтеп сагаеп калган идек, чөнки берничә көн элек янәдән лунатик бүре күренеп алды. «Урамның бер башыннан икенчесенә чабып үтте», — дип сөйләделәр ул кичтә капка төбендә утыручылар. «Кара урманга алып төшә торган юл читендә, аска — караңгылыкка текәлеп бик озак утырды», — диделәр. Бу хәлне аңлау өчен миңа шактый еллар кирәк булды. Ирләрнең рухы өрәкләр аланына әйләнеп кайтасын аңлатырга теләгән икән бүре.

Минлебай Атнагуловның төс-кыяфәте нык үзгәрсә дә, без аны шунда ук танып алдык. Бергә уйнап үскән яшьтәшебез безгә биек ат өстендә утырган килеш кенә күз ташлады, аның карашыннан туган якка кайту сөенече белән бергә әллә нинди чәнечкеле салкынлык бөркелде.

Штаб Сакаевлар йортына урнашты. Хуҗаларына исә урын калмады. Бәхетенә, Солтанәхмәт Сакаев бу вакытта Бөредә үз эшләре белән тоткарланган иде. Алгарак күчеп шуны әйтим: соңгы китүеннән ул авылга кабат әйләнеп кайта алмады. Сугыш тудырган матавыкта кайтырга дип кузгалган жиреннән тимер юлдагы станцияләрнең берсендә тифтан үлеп калды.

Минем әти дә әллә аклар, әллә кызыллар тарафыннан мәҗбүриләп окоп казырга барган җирдә үлеп китте. Яше дә бар, өстәвенә ачлык, салкын, түзә алмаслык авыр хезмәт үз эшен эшләде. Ике айдан әнием дә әти артыннан китеп барды. Тигез озак гомер иткәннәр бер тирәдә китәләр диюләре хак икән.

Вафа бабай да теге дөнья кешесе булды. Ул узган яз майның матур бер көнендә елга буенда соңгы сулышын алды. Кояш нурларының суда биешкән ак тапларын күзәткәндәй, зур өянкенең кәүсәсенә сөялеп утырган килеш таптылар үзен. Бер кулында пәке, икенчесенә юнылып бетмәгән курайны кысып тоткан иде. Аста, су өстендә, аның оста куллары ясаган көймә тирбәлә. Картның йөз-кыяфәте тыныч, ирен кырыена елмаю кунып калган. Хәер, анысы минем күземә генә күренде бугай. Сәбәбен дә әйтим: күптән түгел без аның белән ни турындадыр — вак-төяк турында, ахры — сөйләшеп утырдык. Тик шунысы истә калган: әңгәмәбездә авылның ялгызак төмсә бер адәме Күкчәбай телгә алынды.

— Гел күңелсезләнеп, кара янып йөргән көне, теге дөнья белән аралаша диюләре чын микән? — дип сорадым мин бабайдан.

— Ә син каян алып анда күңелсез дип әйтәсең? — дигән иде Вафа бабай.

Инде җирдәге һәм күктәге юлларга кагылганбыз икән, Гыйльметдин мулла турында да бер-ике сүз әйтеп үтим. Бу мәхшәрләр барган вакытта ул исән иде әле. Тынычрак булыр дип, ул өяз шәһәрендә яшәп калды. Әмма язмышы аны барыбер егерменче елның урталарында эзләп тапты. Хөкүмәтнең, җин сызганып, руханилардан котылырга маташкан вакытлары. НКВД ишегалдында Гыйльметдин мулланың да гомере чикләнә. Күкрәгенә пуля килеп эләккәч, аның җаны, изге ташны әйләнгән кебек, түгәрәк буйлап йөреп чыга да әкрен генә күккә күтәрелеп юкка чыга.

Әйткәнемчә, Сакаевларны үз йортларыннан куып чыгардылар. Фатыйма әнисе белән, төенчекләрен төйнәп,берсеннән-берсе кечерәк алты баланы житәкләп, авылның икенче очындагы туганнарына күчтеләр. Беребезнен дә башына аларның үз ояларын озакка калдырып чыгарлар дигән уй кереп карамады, чөнки соңгы айларда авыл әле аклар, әле кызыллар кулына күчә торды. Әмма Фатыйманың ни буласын башкалардан алда күрә торган күзләре башканы сөйләде.

Вернерга Сакаевлар йортында калырга рөхсәт иттеләр. Дөрес, башта аны да куып чыгарганнар иде, тик соңыннан, ни сәбәпледер, Миңлебай Атнагулов аның калуын теләде. Алманга чарлакта урын бирделәр.

Ә берничә көннән халыкның исен китәргән вакыйга булды. Иртән иртүк Миңлебай калкулыкка терәлеп торган Кара урман итәгендә йөренгәли икән. Көтмәгәндә уң кул яктан ун адымнар ераклыкта итәкләре үкчәсенә тиеп торган күлмәк кигән, чем-кара чәчле аршын ярым буйлы хатын-кыз пәйда булган. Ул ашыкмыйча гына, Миңлебайның адымына яраклаштырып йөренә башлаган. Командир албасты белән очрашуны күптән көткән булган. Браунингын тартып чыгарган да борылып атып жибәргән. Хатын чалкан килеп төшүгә, күкрәгеннән кара кан сиптерә башлаган. Күз ачып йомганчы, тирә-як, хатын үзе дә канга күмелгән һәм бераздан бөтенләй юкка чыккан. Менә шулай Миңлебай үз Албастысын үтергән.

— Үткәненнән котылган кеше тормышын киләчәктән башлыйм дип уйлый, — дидем мин, Миңлебайны Сакаевларның йорты янында очраткач.

— Минем киләчәгем — пуля сызгырулары, — диде ул. — Ә пуляны куып тотканнары юк әле.

Ул күзләремә карады, аның карашында ни үкенү, ни янау, курку сизелмәде. Ә мин исә аның артында тирән упкын сулышы сиздем.

Шул арада солдатларның берсе дәште дә ул Сакаевлар ишегалдына кереп китте.

Анда башланган бик жанлы әңгәмәдән өзек-төтек жөмләләр ишетелде: «армия штабыннан телеграмма», «әсирләр»... Минем аңлавымча, авыл аша әсирләр төялгән олау узачак иде.

Авылда көннәр гадәттә бер-берсенә охшаш була. Әмма Миңлебай Атнагулов кайтканнан бирле көн саен бер яңалык өстәлә торды. Шушы берничә көнне үлчәүгә салып карап булса — алар, мөгаен, ярты, хәтта тулы бер гасырдан өстен чыгарлар иде. Бу вакытларны искә төшерәм дә вакыйгаларны яңадан кичергәндәй булам.

Ул көз үзәкләргә үтәрлек жилле булды. Усал жил урамнар буйлап йөгереп үтә дә, чатка житкәч, өермә булып, өскә күтәрелә.

Авыл буйлап йөренгән кораллы адәмнәрнең йөзләрендә рәхим-шәфкать күренми. Хәер, аңлатып торасы юк: сугыш бара, мондыйлардан изгелек көтү — мәгънәсез.

Кояш баюга таба барганда, авылга дүрт атлы кызылармеец озатуында өч арба килеп керде. Соңрак аңлашылганча, алар бездә төн кичеп, иртәгесен өяз шәһәренә юл тотасы, анда әсирләрне трибунал көтә икән.

Урам буйлап барган олауларны, моңарчы әсирләр күргәне булмаган авыл халкы, кайсы тәрәзәгә капланып, кайсы капка төбенә чыгып карап калды. Алар уникеләп кеше иде. Араларында ниндидер сәбәпләр белән ир-ат уенына катнашып киткән өч хатын-кыз да бар. Шәһәр кешеләренә хас булганча әсирләрнең өс-башлары юка, киемнәре аша үтәли жил уйнаклый. Ул чакта боларның ни өчен авыл кешесеннән нык аерылып тору сәбәбен аңламаганмын, хәзерге акылым белән аларның югары катлау (дворян) кешеләре булганын әйтә алам.

Араларыннан төз, ыспай гәүдәле, матур чырайлы урта яшьләрдәге бер ир-ат аеруча исемдә калган. Аның өстендә солдат шинеле, ул миңа, нигәдер, Иоахим Вернер китапларының берсендәге рәсемдә күргән доктор Фаустны хәтерләтте. Үткен карашлы әсир ни язган булса, шуны кичерергә әзер кыяфәттә күренде. Олаулар авыл үзәгенә юнәлүгә, юлда тузан туздырып күтәрелгән җил арасыннан Фатыйма Сакаева килеп чыкты.

Әсирләрне Сакаевлар йортында урнашкан штаб каршындагы лапаска тутырдылар. Мылтык тоткан ике кызылармеец ишек төбенә басты. Бераздан авылга караңгылык җәелде. Гадәти авыл төне. Беренче карашка гына шулай, алдагысыннан берни белән аерылмастай тоелган төнге караңгылыкта нидер яшеренгән кебек.

Күнелләр тыныч түгел. Безнең авылда бервакытта да монын кадәрле кешенең берьюлы тукталганы булмады. Моңарчы ике калкулык арасында җәлладлар белән үлемгә дучар ителгәннәр янәшә туры килгәннәре юк иде.

Бүген төнлә күземә йокы кермәячәгенә инангач, капкадан урамга чыктым. Як-ягыма каранып торганда, айның саран яктысында кулына төенчек тоткан Фатыйма Сакаева күренде.

— Мин аларга ашарга илтәм, — диде ул.

— Алар инде йоклыйлардыр.

— Юк, йокламыйлар, — диде ул, кистереп.

Без Сакаевлар йортына киттек. Беренчедән, солдатлар әсирләргә нидер тапшырырга рөхсәт итмәсләр, дип уйласам, икенчедән, Фатыйма өчен куркам. Кызыллар аны һаман да сыйнфый дошман дип саныйлар бит. Башымда икеле-микеле уйлар кайнаса да, Фатыйма белән җир читенә китәргә дә риза идем.

Сакаевларның капка төбендә сакчы тора. Аңа күренмәскә тырышып, җәлт кенә ян урамга борылдык, ишегалдына арт яктан үтәргә уйладык. Текә калкулыктагы котырып үскән үләннәрне, куакларны аралап, көч-хәл белән арт капкага якынлаштык. Анда нидер булган: ишегалдында ыгы-зыгы кайный. Коймага елыша төшеп күзәтә башладык.

Ишегалды уртасына зур учак тергезгәннәр. Учакның йортка караган ягында унлап кызылармеец тигез рәт булып тезелгән. Икенче ягында урнашкан лапастан әсирләрне чыгарып маташалар. Миңлебай Атнагулов бу вакыйганың уртасында — ул ниндидер фәрманнар бирә, әмма җил аның сүзләрен читкә очырганга, без берни аңламыйбыз.

Шайтан котырттымы, мин якынрак барырга уйлап, урынымнан кузгалдым. Бәхеткә, Фатыйма миңа иярмәде, югыйсә, андагы хәлләрне күреп, һушыннан язар иде.

Әйткәнемчә, безнең авыл ике калкулыкка урнашкан. Шуңа аяк асты тигезле-тигезсез: әле таулы, әле чокырлы урынга эләгәсең.

Сакаевлар ишегалды аска төшеп киткән аланны хәтерләтә. Мин кеше биеклеге киртләчнең итәгенә туры килдем, әйтерсең тамаша залыннан сәхнә кырыена килеп чыктым. «Сәхнә»нең идәне күзләрем белән бер тигезлеккә туры килде. Моннан учактан биеккә ыргылган ут телләре яктысында бөтен нәрсә уч төбендәгедәй күренә.

Миңлебай Атнагулов, учак янына басып, үзенең кешеләренә нидер сөйли. Мәгънәсе менә болайрак. «Армия штабыннан телеграмма килде. Аклар һөҗүмгә күчкән, озакламый өяз шәһәренә килеп җитәчәкләр. Мөгаен, безгә чигенергә туры килер. Шуңа әсирләрне атарга боерганнар».

Йөзләре ап-ак булган әсирләр тезелешеп торалар. Учак янында урнашкан тынлыкны бүлеп, кайсыдыр төн кошы өзгәләнә. Кинәт хәле начарланып, ава башлаган хатынны янындагысы тотып калды.

Моңа игътибар итмәстән, Миңлебай Атнагулов дәвам итте: «Сугыш-кирәк яраклары житешми, кайчан жибәрәчәкләре дә билгесез. Беренче чиратта патроннарны сакларга тиешбез, шуна аларны әрәм-шәрәм итә алмыйбыз. Әсирләрне кылычтан үткәрәбез».

Дәһшәтле тынлык урнашты, бары учактагы утынның чарт-чорт итеп янганы гына ишетелә.

Миңлебай әмерне үтәргә тиешле кызылармеецларның фамилияләрен атады. Әсирләргә тезләнергә куштылар.

Беренче итеп матрос Игнатий Хлеб чакырылды. Аның чырае үлемгә хөкем ителгән әсирләрнекенә караганда да аграк төскә керде Кулына кылыч тоттырдылар. Әмма матрос, ана күз дә салмый, чайкала-чайкала читкә таба китте.

Икенче булып чыккан латыш укчысы Григас кылычны алды да тезләнгән кешеләргә таба ике-өч адым атлады. Йөреше аучыныкын хәтерләтә. Корбанына якынлашуга, сабы кулын пешергәндәй, кылычын кинәт төшереп жибәрде.

Савелий Перегуда дигәннәре кыю гына атлап беренче торган әсир янына килде дә кылычын баш өстенә күтәрде. Кеше соңгы минутында үткән гомерен күз уңыннан уздыра, диләр. Тик бу үлемгә дучар ителгәннәргә карый. Ә жанын кыючысы үзе турында уйлый икән. Савелий Перегуда да үзенең сугышчы улы, сугышчы оныгы икәнен, гомумән, ата-бабаларының сугышчы булуларын исенә төшерде. Алар сугышта үтергәннәр, үзләре дә шунда һәлак булганнар. Казак кинәт айнып киткәндәй булды, кылычын жиргә кадады да күләгәгә кереп югалды.

Миңлебай Атнагулов аларны сүзсез ачы көлемсерәү белән күзәтеп торды да кискен генә: «Революциягә нык куллар кирәк. Безгә йомшак характерлылар, кулларын буярга куркучылар кирәкми», — диде. Ул сөйләгәндә, кызылармеецлар әкрен генә караңгыга таба чигенделәр. Уртада Миңлебай берүзе калды. Күзгә-башка чалынмаска тырышсам да, ул мине күреп алды.

Аннары менә нәрсәләр булды. Миңлебай Атнагулов хөкем карарын үзе жиренә житкерергә ниятләде. Тик башта өйдән рояльне чыгартты,

Алманны китертеп, уйнарга боерды. Иоахим Вернер катгый рәвештә баш тартты. Әмма чигәсенә пистолет терәгәч, инструмент артына утырырга мәжбүр булды. Ул «Ай сонатасы»н уйнады. Ай исемен йөрткән авылда, айлы төндә янәшәдә үлем сагалаганда тагын нинди көй уйный алсын инде ул?

Тын авылга Бетховен яңгырады. Миңлебай да бу көйне онытмаган, әлбәттә. Ул кечкенәдән көй-музыкага сизгер иде. Шулай итеп, жәза «Ай сонатасы» астында башланды.

Әсирләрнең яртысын теге дөньяга озаткач, жәллад, тукталып, маңгаеннан аккан тирен сөртте. Шул арада корбаннарның берсе аңарга нидер әйтергә өлгерде. Мин аермачык ишетмәдем. «Ни өчен?» — дип сорады, ахры. Бу — доктор Фаустка охшаган ир-ат иде.

— Ни өченме? — дип кабатлап сорады Миңлебай. Аның йөзендә учактан төшкән ут шәүләләре биеште. Ул әсирнең күзенә текәлде, әмма тегесе дә каушап калмады. Хәер, аңа барыбер иде инде.

Беравык алар күзгә-күз карашып тордылар.

— Ни өчен дисезме? — Кулына кан тамып торган кылычын тотып, Миңлебай әрле-бирле йөренергә тотынды. Ә Вернер исә «Ай сонатасы»н уйнавын дәвам итте. Ул арада болытлар арасыннан килеп чыккан ай тирәюньне яктырдып жибәрде.

— Жавап бирәм, — дип, сүзен дәвам итте жәллад. — Безнең авылның бер карты: «Аллаһы Тәгаләнең һәркемгә үз язганы», — дияргә ярата иде.

Ә минемчә, кеше җаны рояльгә охшаган. Анда клавишларның агы да, карасы да бар. Һәм Теге, кемнең ихтыярында булуына карап, капкачны ача да бездән үзе теләгән көйне чыгара. Бу Бетховен да яки, киресенчә, бер алак-шалак эт вальсы да булырга мөмкин. Хәзер, — Минлебай Атнагулов миңа таба атлады, — мин чынбарлыкның мәһабәт көен тоям.

Ул, сөйләнә-сөйләнә, минем каршыма килеп басты.

— Карагыз! Искитәрлек матур Ай! — дип кылычы белән төртеп күрсәтте. Баш өстемдәге кылычтан битемә кан тамчылары чәчрәде.

Аннары җәллад корбаннары янына килеп, коточкыч спектаклен дәвам итте. Бу юлы кылыч ялсыз эшләде.

Күз алдымда булган фаҗигадан башым түнеп, Фатыйма янына килсәм, ул да тораташ кебек катып калган.Ерактарак торса да, димәк, ул барысын да күргән. Кулыннан тотып, аны читкә әйдәдем. Күзгә ак-кара күренми, андый чакта бар ышаныч аякларда. Беркадәр вакыттан без елга янында идек инде. Иң беренче эш итеп, битемнән кан тапларын юып төшердем. Ә Фатыйманы, никадәр тырышсам да, шок хәленнән чыгара алмый гаҗиз булдым.

Шул вакыт миңа әллә нәрсә булды. Үзем дә сизми калдым — аны үземнеке иттем. Бу төн минем өчен үлем исе белән хатын-кыз тәмен тату төне булып уелып калды. Бу адымым әхлаксызлык булып күренер, әмма үземне аклар өчен бер мисал китерергә батырчылык итәм.

Күптән түгел миннән шактый яшь коллегам үзе белән булган бер вакыйга турында сөйләде. (Онытмагыз, мин күптәннән картлар исемлегендә.) Бервакыт ул бер хатын белән төн үткәрергә булган. «Анадан тума чишенгәч, көтеп торырга кушты да үзе душка кереп китте. Мин башын калкыткан «малаем» белән бергә-бер торып калдым. Бүлмәдә телевизор эшләп утыра. Анда ниндидер фильм тәмамланды да яңалыклар башланды. Төп сюжет палестина качаклары лагерена бомба ташлау турында иде. Камера өлкәннәрнең дә, балаларның да гарипләнгән, яра-җәрәхәт тулы тәннәрен җентекләп күрсәтеп чыкты. Коточкыч картина! Әмма, ни гаҗәп: минем «байлыгым» шул үрә каткан көе калды. Ничек? — дигән сорау бирдем үз-үземә, шаклар катып. Бер-берсенә һич сыеша алмый торган ике көч ничек кушыла алды соң? Шулчак юыну бүлмәсенең ишеге шыгырдады, хатын минем янга килде дә, без бер-беребезгә ташландык... Тик бу сорау миңа тынгылык бирмәде. Ниһаять, уйлый торгач, җавабын таптым шикелле: бу дөньяда кемнедер үтергәннәрен күргәч, син үзең дә аңламастан, аңар алмаш тудырырга ашыгасың икән. Синдә, димәк, кешелек буынын саклау инстинкты яши».

Мөгаен, ул кичтә минем белән дә шулай булгандыр, әмма мин аны аңлар яшьтә түгел идем. Моннан тыш безнең кыргый, йөгәнсез ата-бабаларыбызның үзләре кебек күршеләренә яу чапканнарын искә аласым килә. Алар дала җиле кебек, көтмәгәндә килеп чыкканнар, берничә секундта офыкны карага манган болыт шикелле җайдаклар көтүен күреп, бөтен киңлекне тутырган тояк тавышын ишетеп, кешеләрнең куркудан йөрәкләре кагарга тотынган.

Җайдаклар ябырылып килеп кергәннәр дә, кара эшләрен башкарып, юкка да чыкканнар. Бәлки үч итептер, бәлки юктыр — кем белгән, ул заманда күрше күршесен таламый тормаган. Шулай итеп, алар кулларына ни туры килсә, шуны әләктереп киткәннәр. Әмма киткәнче... Ирләрне үтергәннәр, хатын-кызларны көчләгәннәр. Димәк, ата-бабаларыбыз да корбаннар хисабына, үзләре дә аңламыйча, яңа гомерләргә сулыш өрүне кирәк тапканнар.

Күпләрне бу аклануым ышандырмаса да, менә ни өчен мин ул төнне Фатыйма белән үткәргәнмен.

Үзебезнең елга буенда бер-беребезне шашып яратышканда, әйтерсең бу дөньяда икәү генә калганбыз кебек тоелды. Ике калкулыкны хәтерләткән күкрәкләре арасына башым белән капланута, эреп югалдым.

Без таң беленгәндә генә аныбызга килдек. Үземнең кичерешләрем турында сөйләгәндә, нигәдер Фатыйманы онытып җибәрәм. Ул төнне кыз ниләр кичерде икән? Башта әйткәнемчә, ул шок халәтендә иде, аннары нәсел дәвам итү инстинктына бирелеп, аның җаны минем җаныма килеп кушылды. Соңыннан, аңына килгәч, ул кылган гамәленә хисап бирә алды микән? Безнең авылда хатын-кызлар ирләр күзенә күтәрелеп карарга да тартыналар, кайда ул кочагына ташлану?! Әмма Фатыймада алдан күрүчәнлек көчле. Миңлебай Атнагулов авылга аяк басу белән баш очында кылыч уйнаячагын, кайчан гомерләрнең кыл өстендә калачагын алдан сизде, күрде. Шуңа бу тәвәккәл адымына баргандыр дип уйлыйм. Хәер, тагын бер сәбәбе — төп сәбәпне әйтим: ул мине ярата иде.

Бу хәлләрдән соң бик күп сулар акты. Кайбер вакытта вакыйгаларны кабат искә төшерәм, һәрберсен вак-төягенә кадәр тикшерәм дә алай иткән булсам, болай булган булыр иде дип уфтанып куям.

Миңлебай Атнагуловны никадәрле генә хәтеремнән куарга тырышсам да — булмый: курку белмәс, салкынлык бөркелеп торган карашлы адәм күз алдымнан китми.

Әсирләр белән булган фаҗига авыл халкын тетрәндерде. Миңлебай Атнагулов белән сөйләшергә дә теләмәделәр, хәер, ул үзе дә аралашырга ашкынып тормады шикелле. Әсирләрне зират белән янәшә урынга җирләделәр. Авыл ирләре кабер казыдылар: кызыл командир шулай боерды. Йоланы җиренә җиткерделәр, мәетләр җир куенына тапшырылды.

Иоахим Вернер дәһшәтле төннең иртәгесен үк, җаен туры китереп, авылдан китеп барды. Соңрак ул Германиягә күченә алган дип ишеттек.

Кайчандыр Гыйльметдин мулла белән гәпләшеп утырганда, Вернер: «Көй белән Аллаһыны сурәтләп була», — дигән иде. Бу җөмлә Бетховен безнең авылда беренче тапкыр яңгыраган кичкә туры килә. Ә тагын бер кич — әсирләрнең башларын кыйганы турында ничек әйтергә? Вернерның нәрсәне сурәтләргә мәҗбүр булганын, шәт, үзегез дә аңлагансыздыр.

Алда әйтеп киткән идем, соңрак алман белән минем өчен чит-ят җирдә очрашырга насыйп булды. Мюнхенда яшәгән елларымда аның янына еш сугыла идем. Чәй янында сөйләшеп, үткәннәрне искә алдык, кайчакларда күңелдә уелып калган хатирәләрне яңартып, сүзсез генә утыра идек.

Ике дистә еллар элек ул да китеп барды. Сентябрь ае иде. Аллаһы Тәгалә уйлаганын уйнап кайтарды — табут капкачы рояль капкачы сыман шап итеп ябылды.

Кабат авылдан әйләнем. Шулай итеп, әсирләрне җәзалау төненнән соң авылда тирән тынлык урнашты. Бу газаплы, авыр тынлыкны күтәрә алмыйча, хәтта кошлар күчеп китте. Әйе, ышанмассыз, нәкъ шулай булды: башта кошлар юкка чыкты, аннары атлар, бераздан ирләр...

Атлар ничек югалсын инде? дип сорарсыз. Кызылармеецлар киткәндә, аларны да үзләре белән ияртteләр. Күрше-тирә авылларда ат калмады.

Сугыш дәвам итә, авылларда хакимият көн саен диярлек алмашынып тора: әле аклар, әле кызыллар киләләр, өстәвенә әллә кайдан гына коралланган банда килеп чыга да күзгә күренгәнне, кулга эләккәнне урлап, «әх» дигәнче күздән югала.

Тик безнекеләр бирешми. Ай авылыныкылар тамырында буйсынмас җайдаклар каны ага. Без атларны Кара урманга илтеп яшердек. Атыңны тартып алдылармы — син транспорттан, яисә дустыңнан гына колак какмыйсың: син ирекле булудан туктыйсың. Без моны яхшы аңлый идек.

Адәм баласы ирекле булуы белән җилдән житез атына бурычлы. Ирек ул — тояк тавышы, камчы чыжлавы һәм җилнең кыргый көйләре белән бергә генә була ала.

Миңлебай Атнагулов боларны бик яхшы белә. Фажигадән соң берәр көн үткәч, Кара урманда Гайнан Яушев дигән крестьянны атып үтерделәр. Аты янына барганда артыннан солдатлар күзәткән, диделәр. Атын бирергә теләмәгәне өчен генә крестьянның гомерен өзүләрен һич аңлый алмыйм. Үтеручеңең жир кешесе белән аты арасындагы изге бәйләнешкә тупас рәвештә бәреп керүенә берни аклану табып булмый. Гайнан абзыйның жаны чыкканда хәтта өрәкләр аланындагылар да «аһ» итеп куйгандыр. Фәрештәләрнең барысы да: мөселманныкымы ул, әллә христианныкымы яисә башка бер диннекеме — барысы бергә кычкырып елаганнардыр. Бу вәхшилеккә шаһит булган үләннәр үсүеннән туктаган, Жир шары әйләнми башлаган, чөнки нәкъ шушы урында дин мыскылга дучар ителгән...

Хәлил турында да берничә сүз әйтеп үтим. Алар хәтеремдә ни өчендер Миңлебай Атнагулов белән икесе гел бергә сакланган. Һаваны дары һәм төтен исе каплап алгач, үзалдына бикләнгән Хәлил тагын да сәерләнде. Шомлы төннең иртәгесен без аны, нәкъ бала чагындагы кебек, басуда аякларын жиргә күмеп утырган килеш таптык. Гадәттәгечә, ике күзе ике якка караган, үзе авыз эченнән генә — жаныннанмы, әллә жирдәнме саркып чыккан ниндидер озын көйгә шыңшый.

Озакламый ул көнгә берничә тапкыр, әнисе белән сөйләшергә дип, өрәкләр аланына йөри башлады. Кара урманда аны бер-ике мәртәбә кулга да алганнар, әмма ат янына бармавын белгәч — җибәргәннәр.

Авылда тынлык дәвам итте. Әмма тынлыкны бүлеп, вакыт-вакыт корычка ышкылган наждаклы таш тавышы яңгырап ала: ирләр кылыч үткерләргә тотынды. Ата-бабадан калган бу кылычлар моңарчы диварда гына эленеп тора, кайберләре лапас почмакларында тузанга батып аунап яталар иде.

Беркөнне авылга: «Кемнең аты бар — Кызыл Армиягә тапшырырга!» — дигән боерык житкерелде. «Кем карарны үтәүдән баш тарта, шул сугыш вакыты законы буенча атарга хөкем ителә», — дип тә өстәделәр. Берәү дә әмерне үтәргә ашыкмады. Әмма алсуланып атып килгән таң барыбызны да кайгыга салды: Кара урман аланында тагын ике авылдашны үтергәннәр. Алар да, Гайнан Яушев шикелле, атларын барларга барганда, кызылармеецлар тозагына эләккәннәр.

Шул төндә ир-егетләр атлары янына китеп бардылар. Унжиде яшьлектән башлап алтмышны тутырган ике дистәдән артык кеше бер төркемгә берләште. Унжиде һәм алтмыш яшьлекләрен аерым атыйсым килә: болар — нык куллы, бер буйдагы аталы-уллы Иманкуловлар иде. Әтисенең йөзен вакыт жилләре аркылы-торкылы сырлар белән бизәмәсә, аларны аерып та булмас иде, мөгаен. Арабызда корал тотардай кешеләрдән Хәлил генә юк, әмма моңа берәү дә ризасызлык белдермәде, чөнки аның төркемнән читтә, ялгызы калырга яратуын белә идек. Яныбызда Беренче бөтендөнья сугышынан исән кайткан берничә солдатның булуы безгә ышаныч өстәде. Калганнарыбызның дары исен иснәгәне юк, әмма безнең сафларда берничә оста аучы бар. Тагын шушыларга нәселдән нәселгә кылыч белән эш итү осталыгын һәм тамырларыбызда шаулап ирекле җайдак каны агуын да өстәгез.

Төннең калган өлешен учак янында үткәрдек. Тирә-якка сибелгән ут чаткыларына карап, сүзсез генә таң аттырдык.

Офыкка алсулык йөгергәч, урман авызына чыктык та кызылармеецлар засадасына һөжүм иттек. Мондый хәл булыр дип башларына да китермәгән өч солдатны жиргә сузып салдык. Гомеремдә беренче тапкыр кеше үтердем. Нинди хисләр кичерүем турында сөйләп тормыйм, эчемнән ниндидер

иң кирәкле әгъзамны тартып алган халәттә калуымны әйтсәм — шуннан аңларсыз.

«Әгәр мин үтермәсәм, алар минем гомеремне кыярлар иде», — дип үз-үземне юатырга тырышсам да, эчемдәге бушлык күңелемне бик озак тырнап торды.

Шул көннән башлап Кара урман өебезгә әйләнде. Тайга кебек иксез-чиксез булмаса да, үзебезне куркынычсыз урында итеп тойдык.

Миңлебай Атнагулов отрядына каршы торуыбыз кан, нәфрәт, үлем тулы берничә көнгә сузылды. Безне эләктерергә тырыштылар, әмма җилдән җитез атларыбыз ышанычлы иде. Кара урман безнең яклы, хәтта өрәкләр аланынан килгән тавышлар да кайсы яктан куркыныч янавын әйтеп, кисәтеп тордылар. Сафлар сирәгәя торды, әмма артка юл юк иде.

Азык-төлек запасы кимүгә барды, шуна ара-тирә авылга кайткаларга туры килде. Авылга төрле яклап юл керә, өстәвенә шактый зур тирәлекне саклау өчен дошманнарның саны җитенкерәми, шунлыктан без сакланып кына якыннарыбыз яшәгән йортларга үтеп кереп алдык.

Көннәрдән бер көнне азыкка барырга аталы-уллы Иманкуловларга чират җитте. Үз йортларына кереп, кадерле кешеләрен кочарга да өлгермиләр, аларны эләктереп тә алалар. Дөресен әйтә алмыйм: Миңлебай үземе, әллә башка берәрсеме, авылга кергәндә Иманкуловларның эзенә төшеп, артларыннан ияреп килгәннәр. Аннары менә ниләр булган. Аларның күп санлы туган-тумачаларын өйләренә куып керткәннәр дә ишек алдында басып калган Иманкуловларны уратып алганнар.

Миңлебай Атнагулов алар каршыннан әрле-бирле йөренеп, мондый карарга килә:

— Берегезгә исән калу мөмкинлеге бирәм. Бергә-бер чыгасыз да, исән калганыгыз шул минутта йорттан чыгып югала. Тырнак белән дә чиертмәскә сүз бирәм! — ди.

Әтиле-уллы сүзсез генә басып торалар. Ишегалдында колакларны чыңлатырлык тынлык.

— Кылычларын бирегез! — дип боера Миңлебай.

Кулларына кылычларын тоттыралар. Кызылармеецлар кызык көтеп, корулы мылтыкларын тоткан килеш, аз гына артка чигенәләр.

— Без көтәбез! — Кызыл командир, түземсезләнеп, тавышын күтәрә. — Башлагыз!

Йорт эчендә берсенә әни, икенчесенә хатын тиешле кешенең иңрәп кычкыруы ишетелә. Иманкуловлар, кылычларының сабын кулларына кысып, бер-берсенең күзләренә карыйлар. Аннары, сүз куешкандай, икесе берьюлы дошманнарына ташлана. Улы, пуля килеп эләккәнче, бер солдатны чәнчергә өлгерә. Әтисе Миңлебайның башын кыярга күтәргән кылычын айкаганчы, тегесе атып җибәрә.

— Кызганыч, — диде Миңлебай Атнагулов, браунингын кобурасына (кынына) тыга-тыга. — Ә мин аларның берсенә исән калу мөмкинлеге биргән булам.

Шул кичтә Кара урманда учак тирәсенә җыелыштык һәм Миңлебайдан үч алырга ант иттек.

Ул арада агачлар арасында нидер селкенеп куйгандай булды. Караңгылыкта безне кемдер тыңлап тора, ахры, дип уйладык. Ныклабрак карасак, кәүсәләр ышыгында безгә таныш шәүлә тора.

— Бу бит лунатик бүре, — диде кемдер. — Берничә төн инде бу тирәдә әйләнә.

Без учак өстендә биегән ялкын телләренә карап, антыбызны кабатладык. Ут белән бергә җанга үтеп кергән сүзләр, мәңгелеккә анда кала диләр.

Таң беленер-беленмәс арабыздан өчәү кулларына антыбызга шаһит ут кисәвен тотып авыл ягына юнәлде. Берсенән берсенә күчә барган факел уты кечерәйгәннән-кечерәя барып күздән югалды да, шактый вакыттан соң кабат күренде: авылда Сакаевлар йорты дөрләп яна башлады.

Таң алды йокысы аеруча татлы була. Штабны каравыллаган ике сакчы йокыларыннан айнырга да өлгермиләр. Өйдә унлап кызылармеец белән командирлары тирән йокыда. Янгында бар да һәлак була. Утта янмас, суда батмас Миңлебай Атнагуловтан кала — һәммәсе дә.

Авылда янгын-фәлән чыга калса, бар да иләген-чиләген дигәндәй тотып шунда йөгерә. Әмма монысында берәү дә өеннән чыкмый. Көн яктыргач кына, янгыннан ни калганын белер өчен баралар. Сакаевлар гаиләсе дә килә. Фатыйманың энекәшләре әле дә төтенләп яткан утлы кисәүләр, күмерләнгән чит сөякләр тирәли әйләнәләр. Әниләре исә коточкыч күренешне күтәрә алмыйча, аркан борыла да кычкырып елап җибәрә. Кечерәк кызлары, итәгенә ябышып, әниләренә кушылалар. Фатыйма гына дөньядан киткән шикелле үз уйларына чума. Әз генә читтәрәк Миңлебай Атнагулов солдатларына ниндидер әмер бирә. Күзләрендәге чоңгыл тагын да тирәнәйгән. «Ут та алмый бит үзен», — диешәләр карчыклар, җиргә төкереп.

Шул ук төнне мин Фатыйма белән очраштым. Аннан соңгыларында да. Дары, төтен исе аңкып торган хәтердән җуелмас вакыт аралыгында аның белән бергә булдым. Ир белән хатын арасында бервакытта да үзара тигез мөнәсәбәттәшлек булмый диләр. Без бер-беребезгә тулысынча бирелдек. Хәтта беребез өчен икенчебез үләргә әзер идек. Бу очрашу — соңгысы булмагае, дигән шик белән үз-үзебезне белештермәс дәрәҗәгә житеп яратыштык. Пычак йөзе буйлап атлавыбызны икебез дә белә идек. Шуны белү безнең бәйләнешкә, киресенчә, аерым бер тәм өсти: сулышлар кысыла, йөрәкләр менә-менә туктап калыр шикелле. Сонрак ничә мәртәбәләр үлем белән күзгә-күз очраштым, жаным җәһәннәмгә очып, ничә тапкыр кабат терелде — тик яраткан кешем кочагында тойган хис-кичерешләрне башка һичкайчан татыганым булмады.

Өй күләгәсенә сыенып, әкрен генә калкулыкларның берсенә күтәрелдем. Авылның теләсә кайсы җирендә качып калырга уңайлы, төннәрен бигрәк тә. Аяк астындагы чокыр-чакырлы урыннарны үткәндә, инде ничәнче тапкырлар Лотфулла Хәсәнигә рәхмәтләр укыйм.

Тауны хәтерләткән ике калкулык артында ышыкланыр өчен урын җитәрлек. Иксез-чиксез тайга урынына менә дигән Кара урман — кер дә чум, эзенне дә таба алмаслар. Ә елга? Дингезне алыштырырга тиешле елга мәсьәләсендә Лотфулла Хәсәни бераз сынаткан. Әмма кем уйлар шушы елгачык мине үлемнән коткарып калыр дип?

Фатыйма белән соңгы кат очрашуга барган теге кичтә елга кырыйлатып атларга туры килде. Юлымда Вафа бабай куллары ясаган көймәгә тап булдым. Ярдагы казыкка бәйләп куелган көймә салмак искән җил уңаенда әкрен генә тирбәлә. Зирәк карт турындагы уйларым балачак истәлекләренә бәйләнеп китте. Шулчак суга иелгән тал ботагы өстендә нидер ялтырап киткәндәй булды. Бу шул — теге көзге иде. Теге чактагы шикелле Су анасы мина таныш көзгегә карангалап, чәчен тарап утыра. Ботак-чатакларны аралап, сак кына янына якынлаштым. Аяк астымдагы корыган ботак чыртлап сыну тавышына ул берни аңлатмый торган карашын мина төбәде. Күзләребез очрашкач, үземне төпсез коеда кебек хис иттем. Тирә-якта кан, үлем исе килеп торганга, бу юлы әллә ни өркетмәде. Ул арада өстән, авыл ягыннан чит-ят тавышлар ишетелде.

— Су анасы, тизрәк кит, — дидем мин. — Алар сине үтерәчәкләр.

Ул суга шуып төште дә эзсез-нисез юкка чыкты.

Бернигә карамый мина Фатыйма белән очрашырга кирәк иде. Күләгә кебек тавыш-тынсыз гына калкулыкка күтәрелдем. Очрашу урынын алдан билгеләп куймасак та, бер-беребезне табасыбызны белә идек.

Ул да булмады, икенче калкулыктан ай нуры елышкан коймалар буйлатып Фатыйманың төшеп килгәне күренде. Ул да мине абайлап алды. Аякларым үзеннән-үзе ике калкулык арасындагы тарлавыкка — сөю-сәгадәт кичергән оҗмахыбызга алып төште. Фатыйма йөгереп килгән уңайга кочагыма атылды, һәм без, икебез бер тән булып, җиргә аудык. Аның күкрәгенә башымны төртүгә, вакыт агышы онытылды.

Исебезгә килеп аңышканда, якында гына затвор шалтыравы ишетелде. Агач кәүсәләре арасында кеше шәүләләре шәйләнде.

— Тынычлыгыгызны бозганыбыз өчен гафу үтенәм. — Бу — Миңлебай Атнагуловның тавышы иде.

Шунда ук сикереп тордым да кылыч сабына тотындым. Берьюлы берничә мылтыкның көпшәсе мина төбәлде:

— Тынычлан, егет. Типтердең — булды.

Миңлебай каршымда тора, әмма караңгы булу сәбәпле, йөзе ачык күренми. Тик аның мыскыллы елмаюын күңелем белән сизәм.

Фатыйма, яныма килеп, кулымнан тотты.

— Син бар, өеңә кайт, — диде аңа Миңлебай Атнагулов. — Әле сиңа чират җитмәгән. Килер вакыт, үзең белән дә, гаиләң белән дә исәпләшербез.

Фатыйма кулларымны ычкындырмады.

— Карагыз әле, карагыз! Нәрсә ул? — Бер солдат кинәт кулы белән өскә төртеп кычкырып җибәрде.

Таң шәүләсе төшкән агачлар арасында, күзләрен безнең якка текәп, лунатик бүре утыра иде. Миңлебай браунингын тартып чыгарды да, озаклап төзәп торганнан соң бүрегә атты. Фатыйма йөгереп барып, аның кулларына асылынды.

— Ах син, ана көчек! — Миңлебай ачу белән кызның яңагына чапты.

Мин, ярсып, аңа барып ябыштым да җиргә сузып салдым, әгәр кайсыдыр арттан башыма мылтык түтәсе белән кундырмаса, буып үтерәсе идем хәшәрәтне.

Аңыма килгәндә, таң аткан, мин ниндидер такта бинада ята идем. Кулларым артка каерылып бәйләнгән. Әзрәк баш-күз алу белән, шуышып барып, ярык аша тышка карадым. Мине Яушевларның лапасына ябып куйганнар икән. Штаб аларның йортына урнашкан, күрәсең. Таң яңа атып килүгә карамастан, кораллы солдатлар әрле-бирле йөренеп торалар. Димәк, моннан качу — икеле.

Лапас ишеге янында өч сакчы басып тора. Берсенең чыраен кайдадыр күргәнем бар шикелле. Әйе, исемә төште, бу — матрос Игнатий Хлеб дигән кеше. Аларның үзара сөйләшүеннән командирларыннан канәгать түгеллекләрен аңладым.

— Тамырларында бозык кан ага, — диде Игнатий Хлеб.

Икенчесе болай дип өстәде:

— Бер дә юкка күпме кешенең гомерен өзде.

— Кайвакыт төшемдә мыскыллы елмаюын күрәм дә котым очып уянам, — диде өченчесе.

Колакларны торгыздым. Ярыклар аша җилгә ияреп авыл шау-шуы үтеп керә.

— Моны нишләтерләр инде? — дип сорады берсе. Сүз минем турында иде.

— Нишләтәсе билгеле инде. — Аның әйтү тоныннан үземне алла нәрсә көткәнен чамаладым.

— Кайчан?

— Тиздән.

Түшәмгә текәлеп, лапаста ятам. Башым тубал кебек. Әле хәзер дә, күпме еллардан соң, шул вакыттагы халәтем исемә төшсә, чәчләрем үрә тора.

Минем шуңа охшаш хәлләр сурәтләнгән әдәби китаплар укыганым бар. Менә-менә гомере өзелергә торган каһарманны сурәтләгәндә язучылар гадәттә ике төрле вариант тәкъдим итә. Беренчесе: герой ахыргы минутлары якынлашканын сизә. Әдип аны: «ул үзенең кичкә кадәр яши алмасын белә иде», « бу аның өчен соңгы көрәш булды», «үлем аның күзләренә бакты да — бүген киләм, диде»... һәм шуларга охшаш җөмләләр белән бирә.

Икенче вариантта каһарман, киресенчә, үләренә ышанмый: «үлем карары үтәлер минутлар якынлаша, әмма аның ышанычы зур — ул үлмәячәк».

Болар барысы — чеп-чи сафсата. Гомерендә кылыч сабы тотып карамаган каләм иясенең уйдырмасы, буш хыялы.

Бер тапкыр гына үләсе, шуңа да без аны күз алдына китерә алмыйбыз. Үлем белән чагыштырыр нәрсә юк. Мин дә берни сизенмәдем. Бары җәзаларга ике сәгатьләп калганда, аяк астымдагы җирне тоймадым. Әйтерсең, күктә эленеп торам, кечкенә генә җил малае да очыртып алып китәр шикелле.

Соңрак, шактый сулар аккач, миңа мондый халәтне тагын берничә тапкыр кичерергә туры килде. 67 елда Санта-Фе шәһәреннән Альбукерке аэропортына бару юлында каршыма атылып зур йөк машинасы килеп чыкты. Мин көчхәл белән рульне борып өлгердем. Ул чакта да җаным бер генә мизгелгә тәнемнән аерылган кебек тоелды. Тагын берсе 44нче елда Франциядә булды. Алманнардан качып барганда, текә ярдан очканда калдым. Аңыма килгәндә, кулларым ниндидер куакны чытырдатып кыскан, ә аста — төпсез, тирән упкын. Саклаучы фәрештәләрем бу юлы да коткардылар. «Аллаһы Тәгалә тарафыннан һәркемгә үз язганы». Вафа бабай шулай ди торган иде.

Дөрес, берничә секунд эчендә булган бу очраклар үз авылыңда үлем көтеп яткан ике сәгать белән чагыштырырлык түгел. Гәрчә ул вакытта вакыт төшенчәсен югалтсаң да, алып китәселәрен белеп торасың.

Кояш нурлары ярыклар аша үтеп кергәч, ниһаять, келә шалтырап төште һәм, шыгырдап, ишек ачылды.

— Тор. — Бу — Игнатий Хлеб иде. Сакчы ролен үз итмәве аның йөзенә чыккан.

Торып, өстемдәге саламны каккандай иттем.

— Минем сиясем килә.

Ул кулларымны чиште. Лапас почмагына барып озак кына бушандым. Матрос ашыктырмады.

— Сине атачаклар, — диде ул, билгесезлеккә нокта куярга теләп. Игнатий Хлеб үзен гаепле санагандай йөзен чытты. Аңардан: «Качарга ярдәм ит, туган!» — дип сорасам, мөгаен, каршы килмәгән булыр иде, дип уйлыйм.

Матрос кулларымны бәйләде дә, без лапастан чыктык. Сакчылар, корулы мылтыкларын әзер тотып, икесе ян-яктан, берсе алдан мине урам буйлап алып киттеләр. Капка төпләренә чыгып баскан хатын-кызлар, балалар, карт-карчыклар күзләре белән озатып калдылар. Әле берничә көннәр элек кенә олауда килгән әсирләр артыннан шулай карап калган идек. Бүген менә мине озаталар. Каршыда юл тузаннарын туздырып, өермә бөтерелде. Көзге җил аны сакчылар белән минем арадан шудырып чыгарды да, куып, әллә кайларга алып китте. Кемдер төрткәндәй артыма борылып карадым, безнең эзгә басып Фатыйма килә иде.

— Алдыңа кара, — сакчыларның берсе миңа мылтык түтәсе белән төртте. — Ә син бар, яхшы чакта ычкын моннан, — дип җикеренде Фатыймага. Кызга мылтыгын күтәргәнен күреп, Игнатий Хлеб каршы төште:

— Йә житәр, кагылма кызга!

Без Сакаевлар йортына якынлаштык. Янгын хәрабәләре янындагы шактый зур мәйданда берничә рәткә тезелгән кызылармеецлар алдында, әтәч кебек кукраеп, Миңлебай Атнагулов йөренә.

Ул — бүгенге драманың режиссеры, булачак спектакльнең җеп очы аның кулында. Шунадыр, үзен бик ышанычлы тота. Мине янгын булган җиргә аркан бастырдылар. Күземне рәтләр буенча йөртәм: гомерем кайсының кулыннан китәр? Озакламый бар да бетәр. Авылдан читтә атсалар, дөресрәк булыр иде. Әмма Миңлебай авыл кешеләренә, Кызыл Армиягә каршылык күрсәткән урмандагыларга сабак булсын өчен юри шулай эшли. Нәкъ шулай дип сөйләде ул үзенең озакка сузылган чыгышында. «Сугыш чоры законнары, — диде ул, — революция дошманнарына карата аяусыз булуны таләп итә. Бандитлар безнең сугышчан иптәшләребезне үтерәләр, әгәр без аларны тәртипкә китермәсәк, иртәгә дә үтерәчәкләр».

Ул сөйләгән арада авылдагы халык мәйдан янына җыелды. Болар, әйткәнемчә, хатын-кызлар да карт-корылар. Балаларны, билгеле, ияртәсе итмәгәннәр. Үзенә текәлгән нәфрәтле карашлар астында Миңлебай нотыгын дәвам итте. Аның урынында башка берәү булса, бу нәфрәттән көлгә әйләнеп, көзге җил белән китеп югалыр иде. Яшьтәшем Миңлебай, кызганыч, андыйлардан түгел иде шул.

Үз авылында шундый гамәлләр кылып ятуы өчен, мөгаен, сез аны икеләтә күралмыйсыздыр. Мин менә аңа гаҗәпләнмим.Әгәр мондый хәл аның тарафыннан күрше авылда булса? Яки күрше өлкәдә? Яисә бер революция икенчесен алмаштырып торган Латин Америкасы илләренең берсендә? Бераз гына булса да, бездән кичерү өмет итә алыр иде микән ул? Юктыр, дип уйлыйм. Аның кебекләрне ярлыкап булмый.

Кызыл командир, ниһаять, нотыгын тәмамлады һәм хөкем карарын укыды. Кораллы банда әгъзасы, ягъни мин, атарга хөкем ителдем. Спектакль иң кызыклы бүлегенә якынлашты. Җыелып торган халык төркеменә күз йөртеп чыктым, әмма алар минем карашым белән очрашудан курыктылар. Бар да бетте, дип уйлыйлар иде булса кирәк. Шулай да арадан икәү туп-туры миңа карап торалар иде. Берсе — Фатыйма, ул минем арттан җир читенә китәргә дә әзер кыяфәттә күзләрен миңа төбәгән. Икенчесе — Хәлил, ул, гадәтенчә, артта, төркемнән читтә. Хәер, миңа карап тора дип, алдашам бугай, балачак дустым тумыштан кылый дип, алда әйткән идем инде. Шулай да каз мамыгына охшап җиңеләп калган җаным кечкенәдән Хәлил генә үтеп керә алган ике тау арасындагы упкында асылынып калганга, аны янәшәмдә хис иттем.

Менә тагын хәтеремдә ике яшьтәшем бергә туры килде: Миңлебай Атнагулов — үз сугышчыларының башында, Хәлил — гадәтенчә, читтә. Яхшылык белән яманлык та шулай гел бер тирәдә йөри бит.

Ул арада кызыл командир чыгышын түгәрәкләде. Авыл халкы аның сыңар сүзен дә колак яныннан уздырмый тыңлады. Нәрсәнедер үзгәртергә соң иде инде, һәм алар, барысын да Аллаһы Тәгалә кулына тапшырып, тын гына басып торуларын дәвам иттеләр. Кызылармеецлар үзара чыш-пыш килделәр, алар үзләренең бу тамашага тартылып, арадан берәүсенә төп рольне башкарырга туры киләчәген чамалап алдылар. Дөрес булып чыкты: Миңлебай хөкем карарын җиренә җиткерергә тиешлеләрнең исемлеген игълан итте. Алты исем арасыннан өчесе миңа таныш: Игнатий Хлеб, Григас, Семен Перегуда. Күрәсең, командир, теге әсирләр белән булган хәлдән соң, аларга үзләрен чын сугышчы итеп күрсәтер өчен тагын бер мөмкинлек бирергә теләде. Өстәвенә, кылыч уйнатуга караганда мылтык белән эш итү күпкә җиңелрәк.

Сафтан аерылган солдатларга урын бушату өчен, миңа якынрак елышкан Фатыйманы, аңа якын торган берничә хатын-кызны читкәрәк кудылар. Кызылармеецлар тигез рәткә тезелеп, каршыма бастылар.

— Төзәргә! — дигән әмере яңгырады командирның.

Солдатлар мылтыкларын күтәрделәр.

Минем өчен бик озакка сузылган тынлыкны ишетелер-ишетелмәс кенә искән көзге җил өзде. Юк, бу җил тавышы түгел, ә көй-моң иде. Җыр көчәйгәннән-көчәя барды: бу — Хәлил иде, тик аның бу кадәрле үзәк өзгеч итеп җырлавын моңарчы ишеткәнем булмады. Теләсә кемнең каткан күңелен тезләндерерлек таланты хәлиткеч роль уйнады. Иске карурман җыры үскәннән-үсә барып, тирә-юньне моң белән күмде.

Упкын өстендә торган кешегә һәммә нәрсә мәгълүм, мин дә башкалар ишетмәгәнне ишеттем: Хәлилгә өрәкләр аланындагылар да кушылды.

Исемә килеп, мәйдандагыларга күз төшердем: барысы да елыйлар. Картлар мышкылдый. Хатын-кызлар үкси. Чөнки бәгырьләрне телгәләгән бу татар җыры каныбызга без туганчы ук үтеп кергән. Бу җыр — туган-үскән җирләрен калдырып, Мәккә тарафларына агылган болытлар арасыннан бер күренеп, бер югалып очкан киек казлар аһәңе белән охшаш. Бу җырның хәтерендә иксез-чиксез далаларны яңгыраткан тояклар тавышлары саклана. Ниһаять, бу безне бишектә тирбәткән җырыбыз һәм әҗәл якадан тоткач, ябышыр нәрсә калмый күңелебезгә тынычлык иңдергән көебез.

Җыр үзенекен эшләде, каршымда торганнарның миңа төбәлгән мылтык көпшәләре түбән карады. Матрос Игнатий Хлеб тыела алмый елый. Латыш укчысы Григас ихтыярсыз тәгәрәгән яшьләрен сөртеп өлгерә алмый. Күз яшьләренә буылган казак Савелий Перегуда бу дөньядан киткән сыман.

Кечкенәдән көй-моңга үтә сизгер Миңлебай Атнагулов та, күңеле нечкәргәнен күрсәтергә теләмичә читкә борылды. Минем уемда исә сәер уй бәргәләнә: әсирләрне җәзалау Бетховенга кушылып башкарылса, хәзергесен иске карурман көе озата. Беренчесе Миңлебай Атнагулов боеруы буенча, монысы — Хәлилнең үз теләге белән.

Яманлык һәм яхшылык бергә йөргән шикелле, ике яшьтәшем истәлекләремдә гел янәшә.

Хәлилнең җыры күпмегә сузылгандыр — төгәл генә әйтә алмыйм, әмма моң еракларга китеп югалуга, ялгыз ату тавышы сискәндереп җибәрде. Матрос Игнатий Хлеб җиргә ауды. Бер үк вакытта яңгыраган ике ату латыш укчысы Григас белән казак Семен Перегуданы аяктан екты. Кайдан аталар — бар да аптырашта. Ул да булмады, кызыллар рәтенә җайдаклар очып керде дә уңлы-суллы кылычларын айкый башлады. Болар — Кара урмандагы коралдаш дусларым, мине йолып алу өчен ярдәмгә килгәннәр.

Янарак кына упкын авызында басып торган аякларым каты җирне тойгандай булды. Кемдер артка каерып бәйләнгән кулымны чиште. Атыш, ат тояклары тавышы, кычкырыш-елаш — бар да бергә буталган арада үлгән матрос янына килеп, мылтыгын кулыма алдым.

Ыгы-зыгы арасыннан Фатыйманы тапмакчы булдым. Бу хәлләргә исе китеп, дөньядан киткәндәй басып торган кызны күреп, янына йөгердем. Килеп җитәр-җитмәс:

— Кит! — дип кычкырдым аңа. — Ишетәсеңме? Хәзер үк кит!

Кулыннан эләктердем дә артымнан сөйрәдем. Урамга чыккач, әрле-бирле чабышкан авылдашларга табан этеп җибәрдем:

— Кит!

Үгетләп торыр ара юк. Үзем дә әле генә теге дөньядан әйләнеп кайткандай, башым эшләми. Тик бер нәрсә мине игәүләп торган шикелле:

бу хәлләрнең сәбәпчесе — мин. Минем аркада кешеләр канлы башларын җиргә салалар.

Вакыйга барган урынга әйләнеп килгәч күрәм: Кара урманга юл ябык. Иптәшләремнең исәбе: көтмәгәндә һөҗүм итү һәм тар-мар итү булган, күрәсең. Мондый план кайсының башына килгән булгандыр — белә алмый калдым. Бәлки, карурман җыры да шул планның бер өлеше булгандыр. Бәлки юктыр — кем белгән. Ир-егетләр иртәнгә кадәр көткәннәрдер дә, әләккәнемне аңлаганнардыр. Кылыч сапларына ябышып ни кылырга белми торганда, авыл ягыннан искән җил Хәлилнең җырын ишеттергәндер. Аның Кара урманны ярдәмгә чакыруын үзләренә дип кабул иткәннәрдер дә, ат менеп, авылга чапканнардыр. Хәлилнең тавышы көчәя барган саен, тамырларындагы кан агышы да тизләгәндер, шул сәбәпле җыр ахырына килеп өлгергәннәрдер.

Шулай итеп, көтмәгәндә башланган һөҗүм дошман сафларында ыгы-зыгы тудырды. Минлебай Атнагулов ниятләгән тамаша бөтенләй башка юнәлеш алды. Әмма Миңлебай югалып калучылардан түгел. Бу спектакль, киресенчә, күңеленә хуш килде бугай. Күзләреннән очкын сибеп, тирә-юньдәге шау-шуны басарлык итеп: «Читкә китегез! — дип акырды ул сугышчыларына. — Читкәрәк китегез, дим!» Бу тавыш этеш-төртеш аркасында кая барып сугылырга белмәгән кызылармеецларны бик тиз аңнарына китерде: кызу атыш башланды. Берничә иптәшем күз алдымда атларыннан очып төште. Җиргә түшәлгән көзге яфраклар кызыл төскә керделәр. Калганнары, кылычларын айкап, Кара урман ягына борылдылар.

— Җибәрмәгез, — дип акырды Минлебай. — Юлларын кисегез!

Тагын бер җайдак җиргә капланып төште. Исәннәре солдатлар тырнагыннан ычкынырга җай эзләделәр. Мин кулымдагы матрос мылтыгыннан атып җибәрдем һәм атлыларның юлын каплаган солдат җиргә ауды.

Җавапка берничә ату тавышы бергә яңгырады. Күрәсең, күктәгеләр аякта икәнемне исләренә төшерделәр һәм янәдән җәза вакытына әйләнеп кайттылар. Күкрәгемә пуля тиюгә, дөньяның асты өскә килгәндәй булды да тоташ караңгылыкка чумдым. Кабат упкын өстендә торсам да, җанымның җиргә якын икәнен тоям. Беренче тапкыр күземне ачканда, көзнең соры күген абайладым. Икенчесендә калкулыктан төшеп барганда аңыма килдем — мине каядыр өстериләр иде. Борыныма таныш ис, сөйгәнемнең исе кагылып үтте һәм чынбарлыкка кайтарды: бер кулым Фатыйма җилкәсендә, икенчесе — Хәлилнекендә икәнен күрдем. Артта тояк тавышлары, атыш бара, — димәк, бәрелеш дәвам итә.

Өченче тапкырында елга буенда аңыма килдем. Мине Вафа бабай ясаган көймәгә тартып маташалар. Көймә төбенә яткырып, язмышымны елга иркенә тапшырдылар. Житез агым исә шундук әләктереп алды да үзенә ияртте.

— Нигә алай эшләгәннәр? — дип сорарсыз. Бу, — минемчә, бердәнбер дөрес юл булган. Авылда качар урын юк — барыбер эзләп табарлар иде. Гомерне елгага ышанып тапшыру — теге дөньяга озату белән бер инде, диярсез. Фатыймада алдан күрү сәләте бар, дигән идем. Димәк, ул белеп эшләгән.

Артымнан икәүләшеп карап калулары әле дә исемдә. Үземнең хәл эчендә ятуыма карамастан, көнчелек уты көйдереп алганы да хәтеремдә. Фатыйма кабат Хәлилгә тартыла кебек тоелды. Сәбәбен иске карурман җырында күрдем. Моң каршында Фатыйма да көчсез калгандыр дип уйладым.

Алар — кыз белән егет — миннән ераклашканнан-ераклаша бардылар да, борылышка житкәч, күздән юк югалдылар. Әмма шулвакыт күз кырыем

белән алар янына бер төркем кеше якынлашканын күреп калдым. Болар — Миңлебай Атнагулов һәм аның солдатлары иде. Язмышым агым ихтыярында булганга, берни эшли алмадым.

Бераздан бер-бер артлы ике ату тавышы яңгырады, һәм мин янә аңымны җуйдым.

Елга Кара урманга елышкан урында күзләремне ачтым һәм аланнан эчкә таба алып керә торган көзге яфраклар белән бизәлгән юлны шәйләдем. Ул арада өрәкләр аланына таба баручы ике рухны абайладым. «Бәхил бул, Фатыйма. Хуш, Хәлил, — дип пышылдады иреннәрем.

Көймә, әкренәеп, әрәмәлек янында туктап калды. Баш очымдагы тал ботаклары арасыннан өскә карадым. Кемдер миңа таба иелгән кебек тоелды. Бу — Су анасы иде. Бераз карап торганнан соң, йөземә көзгесен китерде.

Көзгедә — очсыз-кырыйсыз зәңгәр диңгез. Ул җиңелчә томан белән өртелгән. Сыек томан аша зур шәһәр шәйләнә. Ярга каккан дулкын өстендә биек диварлар күренә, алар артында күккә ашкан кыйгач айлы мәчет манаралары. Моның кайсы шәһәр икәненә төшенгәнче, миңа күп еллар кичәргә туры килде.

Гаҗәеп Константинополь. Бөек Царьград. Искитмәле, тел белән әйтеп, аңлатып биралмаслык гүзәл Истанбул...

**III бүлек**

Июнь төнен ертып, поезд алга ыргыла.Тәрәзә аша шәһәрләр һәм авыллар күренеп кала. Карт әледән-әле чәен яңартып тора. Тәгәрмәчләрнең рельстан чыгардай булып ярсу тукылдавына кушылып, магнитофон тасмасы әйләнә һәм ихлас күңелдән бәян ителгән чит-ят тарихны үзенә сеңдереп бара. Мин дә кызыксынып тыңлыйм. Әле менә егерме еллар узганнан соң, кассетаны кулыма алам. Хикәядә буш урыннар бар: карт туктап торган араны поезд тавышы, тәгәрмәчләр тукылдавы, станцияләрдән ишетелеп калган шау-гөр тутыра. Бу бушлыклар, хикәяләүнең аерым өлешләрен бергә китереп бәйли шикелле. Игътибар иткәнегез булды микән: карлыгачлар ояларын төкерекләре (селәгәйләре) белән ябыштырып ясый икән. Монда да шулай. Картның һәр җөмләсе, һәр сүзе тынлык белән уратып алынган. Кәгазьдә моны тасвирлавы кыен, әлбәттә, әмма мин көчемнән килгәнчә булмастайга тотынып карарга җөрьәт итәм. Кайбер укучылар гафу итәлер дип ышанам, сүз җанрында берникадәр иркенлек комачау итми (югыйсә, тынлыкны ничек сурәтләргә: күп нокталар беләнме, әллә буш урыннар калдырыпмы — әйтегез?)

Инде ничәнче мәртәбә шул чакта яздыруны өзмәвемә шатланып туялмыйм. Югыйсә, картның сөйләгәннәре онытылыр, эзсез югалыр иде. Хәтердә тергезгәне — минем тарафтан иҗат ителгән әсәр булыр иде, чөнки бу вакыйгаларның күбесе хәтер иләгеннән коелып беткән. Магнит тасмасындагы язмалар, билгеләр куелган юл, чик баганалары һәм күрсәткечләр сыман, читкә тайпылырга ирек бирми.

Шул язмаларны ак биткә күчергәндә, башыма бер уй килде. Егерме еллар элек магнитофон тасмасы мәңгелекнең кеше язмышы белән бәйләнгән бер тамчысын хәтеренә бикләгән икән. Хәзерге цифрлы технологияләр заманын күз алдына китерегез. Һәр адымыбыз, һәрбер сүзебез теркәлеп, язылып барыла. Без һәрдаим кадрда. Ишектәге «күзчек», супермаркеттагы күзәтү камерасыннан башлап меңләгән объективлар безнең арттан күзәтә. Банкоматтан акча аласың, йөз-чыраен балкытып каршы алган кунакханә портьесы янына киләсең, мәдәният министрлыгы гардеробында пәлтәңне тапшырасың — барысында да күзәтү астына эләгәсең. Әле ничек кенә,

кайчакларда бу матавыкка үзең теләп катнашып китәсең: «Әйдәгез, фотога төшәбез!» — диюгә, салатлы тәлинкәнне читкәрәк этәсең дә йөзеңә елмаю катырасың — «якынрак басыгыз, кадрга керми каласыз!», янәсе. Һәр җирдә — син, уйлап-нитеп тормастан, йөзеңне мәңгелектә калдырасың. Ә синең чыраеңнан мәңгелекнең күңеле болганадыр, моны сизенәсең — әмма беркая кача алмыйсың.

Аңа син кирәкме, хет бер генә мизгелгә булса да карашы синдә тукталганмы — барыбер.

Моннан ике йөз еллар элек бу дөнья белән хушлашканнарны исеңә төшер: алардан ни калган? (Иң яхшы очракта туу һәм үлү турындагы язма — әле аларын да өлкә шәһәре архивларыннан таба алсаң — яисә кабер өстенә куелган таш, анысы да вакытлар узу белән җил-бураннан кителеп, язуы танымаслык хәлгә әйләнә. Хәер, танылган очракта да бу исем нәсел дәвамчыларына берни аңлатмаска мөмкин). Үткәннең караңгылыгына китеп югалганнар янында үзеңне отышлы хәлдә хис итәсең.

Тик үзеңнең дә алардан ерактан китмәвеңне аңлыйсың. Еллар үтү белән, сиңа да югалу куркынычы яный: нәсел дәвамчылары өчен син кипкән үлән, тирес, көл йә балчык өеме кебек гадәти бер нәрсә булып каласың. Көннәрдән бер көнне киштәләрдәге фотонегативлар, видеокассеталар, ДВД дисклары белән бергә тузып юкка чыгасың.

Шулай да еллар сынавы аша исән-имин үтә алган кайбер нәрсәләр бар. Халык җырлары, мәсәлән. Озын, сагышлы, күңелләрне айкап чыга торган көйләр. Алар бит кәгазьгә язып калдырылмаган. Җырлаганнар-көйләгәннәр дә чылбыр буенча киләчәк буынга биреп барганнар. Кошлар балаларына эчәр суны томшыкларына алып барган шикелле, кешеләр дә телдән-телгә күчергәннәр.

Яки минә юлдаш картның сөйләгәнен искә алыйк. Персонажларының һәр адымы — видеокамерадагы кебек — билгеле. Аларның исемнәре халык хәтеренә уелып калган. Сүз җаенда, карт авызыннан чыккан риваятьләрнең кайберләрен элегрәк тә ишеткәнем бар иде. «Ат өстендәгеләр» турындагысын төрле елларда, төрле авылларда тыңларга туры килде. Бату Сакаевның исеме дә колакка чалынганы бар. Шулай да моны белән тирә-юньдәгеләрне үксеп елатучы кеше турындагы истәлекләр ешрак очрады. Карт хикәясендә бу кешене Хәлил дип атаса, төрле авылларда исемнәр төрлечә яңгырады. Һәм бу һич гаҗәп түгел: һәр җирлекнең үз Хәлиле булырга мөмкин бит.

Нәрсә турында әйтергә телим? Күктәгеләр кушуы буенча арабыздан кемнәрдер замандашына караганда озаграк яши. Димәк, хатирәләр буыннан-буынга тапшырылса, җаннарны рухландыра торган чылбыр өзелмәс, дигән ышаныч бар. Бәлки бу истәлекләрне укучыларга җиткерүем — әнә шул чылбырның бер өлешедер? Минемчә, нәкъ тә шулай. Югыйсә, башымда, бу эшне башкарырга тиешмен, дигән катгый ихтыяҗ тумас та иде.

Вакытыгызны шактый алдым, ахры, сүзне янәдән купедашыма бирим әле.

«Минә гомеремнең күпмедер өлеше — күз алдыгызда. Әгәр ялыкмаган булсагыз, калганын да ишетерсез.

Күптән түгел бер атаклы кино режиссеры катнашында телетапшыру караган идем. Аңар мондыйрак сорау бирделәр: «Эшкә ашкан фильммы бу, яисә бернәрсәгә яраксызмы икәнен белү өчен сезгә күпме вакыт кирәк?» «Гадәттә бер-ике секунд җитә, — диде ул. — Мин моны төп каһарманның йөзенә төшкән яктылык буенча ачыклыйм». Бу фикерне әдәбиятка яраклаштырып болай диясе килә: җитди иҗатка тап булганыбызны аңлау өчен берничә биткә күз салу җитә. Ә кеше гомере буенча фикер йөртсәк? Гомеренең башыннан азагына кадәр, бер вакыйгадан икенчесенә геройның эзенә басып йөрсәң дә — берни аңламаска мөмкинсең.

Мисалга, бернччә ел рәттән күргәннәрем турында язарга теләдем. Янәсе, шундый итеп тасвирлыйм, укучыны беренче юллардан ук әсир итәм дә 300ме, әллә 400ме бит буйлап үз артымнан ияртеп барам. Соңрак моның мөмкин түгеллегенә инандым. Миңа андый сәләт бирелмәгән икән бит. Йөрәксенеп тотынсам да, булдыра алмадым. Соңгы җөмләм болайрак язылды: «Аның күзләре тормышта булмый торган мәгънә белән тулы иде». Һәм шунда әдәби эш белән шөгыльләнүемә нокта куелды.

Тынлыкка кереп чумудан башка юл калмады. Анда миңа үз өемдәге кебек рәхәт, уңайлы иде. Үткәнемә сәяхәт кылганда, очы-ахыры булмаган роман язам кебек тоелды. Ул төрле исләр, тавышлар, өянкеләр күләгәсе яткан елгалар белән тулы иде. Урыны-урыны белән әсәрем өн белән төш арасында була торган иң югары ноктага җитә: сюжет уйларымнан ташып чыга да, агымга ияргән көймә шикелле, үз иркенә агыла башлый. Шул чакта күз алдына онытыла төшкән йөз-битләр кала. Теге дөнья белән безнең төшләр арасыннан искән җилгә ияреп Фатыйма килеп чыга да, теге чактагы шикелле куеныма елыша. Ул да түгел, җитез җил китергән өзек-төтек сүзләр җыр булып яңгырый. Хәлил җырлаган иске карурман көе жаныма үтеп керә, күзләремә яшь тула. Аның кебек бу җырны җиренә җиткереп бирәү дә башкаралмый.

Вакытлар узу белән туган якларымнан ераклашырга туры килде, дип әйткән идем инде. Башта авылыбыз елгасы мине, үлемнән йолып, билгесез тарафка ияртеп китте. Хәер, үлемнән качу мөмкин түгел. Дөньяга аваз салган көнеңнән ул— синең янәшәңдә!

Шулай итеп, Вафа бабай куллары ясаган көймә төбендә чит-ят суларга барып кушылдым. Таныш булмаган җирләр аша үттем. Шул чакта җир йөзенең нинди киң икәнен, бер халыкның икенчесенә охшамавын, тәннәренең башка төстә булуы өстенә һәркайсының үз җыры булуын аңладым. Кешенең аңы, зиһене үсү өчен еллар гына җитми, чакрымнар узу да кирәк икән.

Ераккарак киткән саен елга-суларның исемнәре дә үзгәрә барды: Шпрее, Темза, Сена, Нил, Рио-Гранде, һәм, ниһаять, язмыш җилләре дүрт диңгезле Истанбулга сыендырды. Гомеремнең соңгы өлешен монда үткәрдем. Көн саен диярлек Босфор ярына чыгып басам да, якыннан гына үтеп киткән корабларны озатып калам. Бу яр минем өчен картлык дигән кыяга әверелде: менеп басасың да, борылып, үткәннәргә күз саласың.

Еш кына үз-үземә сораулар да бирәм: ни өчен Миңлебай Атнагулов Хәлил белән Фатыймага карата шундый гамәл кылды икән? Нигә кирәк булды аларны үтерү? Үземчә, җавабын эзлим. Мөгаен, бандитка, ягъни миңа, качарга булышканнары өчендер, сугыш елларында мондый адым өчен зур җәзалар каралган бит. Командир булганга, башкача булдыра алмагандыр. Тик бу бик гади аңлатма. Сәбәбен, минемчә, яшьтәшебезнең характерыннан эзләргә кирәктер. Башлаган спектаклен ахырына җиткерергә теләгәндер. Финалда төп каһарманның берсе үләргә тиеш, югыйсә, тамаша көткән нәтиҗәне бирмәс — төссез булыр иде. Мин үлемне урап узганга, эстафета үзеннән-үзе Хәлил белән Фатыймага күчкәндер. Өстәвенә, Миңлебай Атнагуловның уйлаганын җиренә җиткерүчеләрдән икәнен дә әйтсәк...

Шулай да бер шик баш миемне бораулый: миңа калса, Миңлебай көймәне күргәндер. Ни өчен күреп тә, миңа качарга юл куйды икән? Җавабы, бәлки, болайрактыр: беренчедән, Фатыйма белән Хәлилнең канын коеп, канәгатьләнү хисе алгандыр: икенчедән (монысы күбрәк ышандыра), спектакльнең төп тамашачысы буларак, миңа юл сапкандыр, ягъни аңлы рәвештә исән калдырырга тырышкандыр. Шәп спектакль караганнан соң, күңелдә нинди хисләр тууы сезгә таныштыр дип беләм. Ахырда нидер

әйтелеп бетми сыман, тамашаның дәвамы булып тормыш, яшәеш үзе кала. Миңлебай Атнагулов та шуны теләгәндер. Беренче чиратта сюжетны минем өчен тәмамламый калдыргандыр: сулар һавам кысылганда, ниндидер үч алуны максат итеп куймасымны сизенгәндер.

Тик шулай да Миңлебай кебекләрнең кылганнарын аклап булмый. Мин шулай уйлыйм.

Сезне, билгеле инде, елга борылышыннан соңгы тормышым кызыксындырадыр. Көймәм, ага торгач, аклар кул астында калган күрше авылга китереп җиткерде. Андагы хәрби врач күкрәгемә кереп урнашкан пуляны тартып алды. Аякка басар өчен бер-ике атна кирәк булганга, чигенеп баручы чехларга ияреп Ерак Көнчыгышка килеп чыктым. Мина карата мәрхәмәтле булган язмышым үзенчә уйнап алырга теләдеме — байтак илләр гизәргә туры килде. Кайчандыр ата-бабаларыбыз йөргән юллар аша уздым. Офыкларга барып терәлгән дала киңлекләрендә көтү тавышлары ишеткәндәй булдым. Көн эссесен ярып җайдаклар килеп чыгар кебек тоелды. Кайчандыр Бату Сакаев үзенең чәен ышанып тапшырган кайнар кояшка, көйдергеч җилгә битемне куем басып тордым.

Озакламый Төньяк Кытайга барып эләктем, аннары Маньчжурия, Японияләрне урап, Көнбатыш Европага килеп чыктым.

Беләм: сезне үз гомерләрен куркыныч астына куеп мине коткарырга ашыккан авылдаш ир-егетләребез язмышы борчыйдыр. Мин дөртесенә генә Кара урманга кереп качарга насыйп булганы турында ишеттем.

Иртәгесен кызыллар авылны калдырган. Көзге һавада арба шыгырдавы, яралыларның ыңгырашуы ишетелгән. Каршыларында тузан туздырып бөтерелгән өермәләр калкып чыккан. Олаулар башында, гадәттәгечә, биек аты өстендә Миңлебай Атнагулов барган. Җилнең усал улавына тол калган хатыннарның сыкрап елавы кушылган.

Шыгырдап ачылган капкада бер хатын күренгән. Бу Хәнифә Камали дигән тол хатын була. Иренең үле гәүдәсе инде дүртенче елын Көнчыгыш Пруссия җирендә ята, ике улын алдагы көндә үтергәннәр. Ул сүзсез генә чыгып баса да дошманының китәр юлына карап төкерә. Ачуына буылган Миңлебай, хатынга үткен күзләрен батыра да:

— Минем киләчәгемә кагылма, барыбер эләктерә алмассыз. Пуля сызгыруы белән бер ул! — дип кычкырган.

Кызыллар күздән югалуга, урмандагы ирләр авылга кайта. Әйткәнемчә, алар дүртәү калган була. Шул тынгысыз төндә янәдән лунатик бүрене күрәләр. Калкулык өстенә баскан бүре улавын ишеткәч, авыл халкы: «Алла тагын ниләр күрсәе бардыр», — дип уфтанып куя.

Урманнан кайткан Әбүбәкер Субаев дигән ир-ат үз-үзенә урын таба алмый. Ул төнге урам буйлап әрле-бирле йөренә. «Нигә йокламыйсың?» — дип сорыйлар анардан. «Мине беркайчан да йокы алмаячак», — дип җавап бирә Әбүбәкер, кылыч сабын кыса төшеп. Учак янында биргән анты аның җанын кимерә. Ул кабат урам буйлап китә, бераздан туктала да, кылычын кыныннан тартып чыгарып, озак кына аның үткен йөзендә уйнаган ай шәүләсен карап тора, аннары кузгалып китә. Кемнәрнеңдер өе каршыннан үткәндә, ачык тәрәзә аша хатын-кызларның үзара сөйләшкәнен ишетеп кала:

— Болай булганы юк иде.

— Нәрсә булганы юк, әни?

— Урамда өрәкләр аланындагылар йөри.

— Син нәрсә, әни. Бу бит — Әбүбәкер Субаев, әнә кара — ул сау-сәламәт!

Телдән телгә күчеп, бу хәбәрләр миңа да килеп ирешә. Очраклы

кешеләрдән ишеттем. Аларның да күбесе туган илләреннән китәргә мәҗбүр булган. Җепшек карда тәгәрәгән саен зурая барган кар йомарламы шикелле, бу хәбәрләр дә үзгәреп, сөйләүчеләрдән өстәлеп ирешкәнгә, кайбер вакыйгаларга төшенеп, ышанып та житәлмадым.

Шулай бер төнне Әбүбәкер Субаев калкулык түбәсенә менеп, караңгылыкка карап тора һәм атына сикереп менеп, каядыр китеп югала. Аннары ниләр булуы турында берничә төрле ишеттем.

Берәүләр: берничә төн узгач, Миңлебайны куып тотып үтергән, диләр. Имеш, кызыл командир бәдрәфкә йомышын үтәргә кергәч, такта аша чәнчегән, ди. Әйткәнемчә, болар — имеш-мимешләр генә, чөнки кеше, гадәттә, вакыйганы үзе теләгән якка борырга ярата. Хак булса, безнең каһарман, үч алганнан соң, үзен камап алган кызылармеецларның берничәсен чәнчеп өлгерә. Аннары аны, әләктереп, сөйрәп киткәннәр. Имеш, ул шунда ук йокыга талган да атар алдыннан гына күзләрен ачкан, ди.

Икенчеләре, Әбүбәкер Субаев, хәшәрәтне эзәрлекләп, Казанга барып житкән, дип сөйли. Ниндидер парад вакытында сәүдәгәр Кекин йорты урнашкан урамда үтерергә маташкан, ди. Кеше арасыннан килеп чыккан да, ди, кылычы белән ташланган. Каршына төшкән ике кызылармеецның башын кыйса да, командирларына барып житәлмаган, имеш. Башкача сөйләгәннәрен дә ишетергә туры килде, әмма аларның барысы да бертөрле тәмамлана: аны үтерәләр. Үлем кеше өстеннән теләсә кайсы җаваплылыкны төшергәнгә, ул антына тугрылыклы калган, диләр. Дөрестерме-юктырмы — Миңлебай Атнагуловны да үтергәннәр дигән хәбәрләр йөрде. Мин үзем ышанып бетә алмадым, чөнки аның кебекләрне ни пуля, ни кылыч алалмый. Аннары бер кытай «Үзгәрешләр мәҗмугасы» китабын ачып: «Үлем теләгән кешенә тешен үтмәс», — дип юраган иде. Парижда, чынаягымдагы кофе куесына карап, өлкән яшьтәге әрмән карчыгы, Каракастагы шаман да шул ук җөмләне кабатладылар.

Шул сәбәпле, мин четерекле хәлдә калдым. Бер яктан, антыма тугры калып, Миңлебайдан үч алырга тиешмен, бу — үлгәннәр алдында минем бурычым. Икенче яктан, үч алырга омтылышым үземне һәлакәткә китерәчәк. Аннары гомерем буе, антымны үтәр өчен барысын да эшләдемме? дигән сорау тынгылык бирмәячәк. Бәлки мин, теге явыз еракта, дип, үз-үземне генә юатырга тырышамдыр? Иң дөресе: Әбүбәкер Субаев кебек намуслы үлем белән китүдер, бәлки?

Менә шундый авыр йөк белән яшәүне күз алдыгызга китерә аласызмы? Нинди генә биекләргә күтәрелсәң дә, нинди генә җиңүләргә ирешсәң дә — күңелне өзми-куймый тырнап торган ант һич башымнан чыкмый.

Ике көннән соң авыл аклар кулына күчкән. Исән калган теге өч ир-атны атып үтергәннәр. Ни өчен диген? Бәлки, үзегез дә төшенгәнсездер. Тегеләр атларыннан колак кагарга теләмәгәннәр. Җәза алдыннан кабат ярсып җил искән, кешеләр менә-менә җил сызгыруы җырга әверелер дип көтсәләр дә — могҗиза булмаган — Хәлилнең өрәкләр аланына күчкәненә атна тулган була инде.

Авыл ир-атларсыз кала, тик тормыш дәвам итә. Хәтерегездәдер, безнең авыл хатыннары итәк тутырып бәби алып кайтырга ярата, дигән идем. Берничә елдан егет исемен йөртәчәк үсмерләрнең тавышы алмашып килгән чак. Беләкләренә көч тулгач, алар да әти-абыйлары кебек кулларына корал алырлар.

«Бер авылга бөтен дөньяның хакыйкате сыйган», — дип әйтә торган иде безнең Вафа бабай. Чыңгыз хан вакытында яшәгән бер канун исемә төште. Шәһәр-калаларны яулап алгач, бу канун буенча барлык ир-егетләрне, хәтта

малайларны да үтергәннәр.Әмма барысын да түгел, кайсының буе арба тәгәрмәчен узмаган — аларны исән калдырганнар (Явыз Иван да Казанны алганда шул кагыйдә буенча эш иткән). Шулай итеп, дошманнарын уеннан чыгарганнар, һәм әз дигәндә унике еллар, ягъни теге почык борыннар үсеп, кулларына корал алганчы, алар ягыннан куркыныч янамаган.

Дәһшәтле, шомлы урта гасырлар, дибез.

Ә егерменче гасырда ничек? Газ камераларына керү юлында буе тәгәрмәчтән узмаган ише тамгаларны күрәбезме? Качаклар лагерена бомба ташлаган очучы тәгәрмәч турында уйлыймы? Ә кеше тулы вагоннарга шартлаткыч куючы? Гомерләрен кыясыларның ничә яшьтә икәнен беләме ул?

Әйтергә теләгәнем шул: бу гасыр халык нәфрәте белән сугарылган. Бер авылга бөтен дөньяның чынлыгы сыйган. Тик дөнья хакыйкате һәрбер язмышта та бар. Анда — нәфрәт тә, мәхәббәт тә... Моңа үз тормышымнан да мисаллар житәрлек.

Белүегезчә, миңа бик күп жирләр гизәргә туры килде. Европа хакында ни әйтим? Парижда иртәнге томаннар, Сен Лазар вокзалындагы гудоклар исемдә. Лондон кичке томаннары белән хәтердә калды. Юлларым пароходның колак яргыч тавышына чумган Ливерпуль портына алып килделәр.

Чит-ят жирләр жаныма хуш идеме?

Кешенең акылы, зиһене еллар узу белән генә түгел, чакрымнар белән дә арта, дигән идем. Миңа башкалалардан тыш, дөньяның куркыныч иң ерак, аулак почмакларына да аяк басарга туры килде. Чит жирләрдә яшәү — сынауга тиң. Күз алдыңа китер: язмыш сине таныш булмаган жирләргә китереп ташлады, ди. Баштагы бер-ике атнада мондагы табигать күренешләренә карап хозурланасың: алдыңда очсыз-кырыйсыз чүл яки иксез-чиксез диңгез ярлары. Юлыңда очраган һәрбер ташны кызыксынып күзәтәсең. Тик көннәр артта калган саен, боларга исең китми башлый. Үзеңне монда кирәксез тоясың, бу табигать синең өчен түгел, гомумән, бу жирләр өчен син әйтерсең үле жан. Корыган агач яисә ярга кагып чыгарылган үлгән балык. Яки елан өстеннән төшеп калган иске кабык. Көннәрне санарга тотынасың — тагын күпме яшисе калды? Кинәт күңелеңне борчу биләп ала: әгәр сиңа монда бөтенләйгә калырга туры килсә? Шундый уйлардан хәтта бүре булып улыйсы килә. Сайлау мөмкинлегем булмаганга, тешләремне кысып, сагыну-сагышымны тирәнгәрәк кудым. Сулык-сулык килгән күңел сызлавын басарга теләп, һөнәр арты һөнәр алыштырдым, иң авыр эшләргә барып ябыштым. Жир тырнап үскәнгә, агач тамырларын хәтерләткән кулларым, ата-бабаларымнан калган көчле камыт аякларым, рухларның тавышларын ишетергә сәләтле колакларым миңа яшәргә көч бирде. Эт булып арыганнан соң, тизрәк ятакка чумасы килә. Кеше ныграк газапланган саен, төшләре шулкадәр жиңелрәк була икән. Төшләремдә туган-үскән якларыма кайтам, авылым урамнарын урап киләм.

Озакламый төшләремнең эчтәлеге үзгәрде. Күп еллар узгангадыр, очсыз-кырыйсыз коридорлар керә, алар буйлап барам да барам: кая, нигә — белмим.

Хәтеремдә нык уелып калган бер төшемне сөйлим әле. Күчмә тормыш артта калган вакытлар. Инде берничә ел Берлинда яшим. Тормышым әзме-күпме эзгә төште, төшләрем исә, киресенчә, борчулы, буталчык. Ниндидер оешма коридорында чират көтеп утырам, имеш. Тирә-ягымда ник бер таныш чырай күренсен. Чираттагылар йөзләренә берни чыгармый, тезелешеп утыралар. Коридорда ишекләр күп булса да, барыбызга да бер бүлмәгә керергә кирәк икән. Утыра торгач, чиратның кыймылдамавын,

ишекнең ачылып-ябылмавын абайладым. Урынымнан торып, ишеккә юнәлдем, үзем: «Ник чиратсыз керәсең?» — дигән җөмләне көтәм. Ни гаҗәп: берәүнең дә миндә эше юк, хәтта игътибар да итмиләр. Ишекне ачам, бүлмә уртасында кәгазьләр тулы өстәл, артында берничә кеше үз эшләре белән мәшгульләр. Мине үзләре янына чакырып алдылар. Чиратсыз бәреп керүем өчен унайсызлансам да, алга атлыйм. Алар ниндидер кәгазьләр тутырттылар, ә мин ризалыгымны белдереп кул куям. Башыма барып житкәндә соң иде инде. Карасы төшми башлаган ручкамны сылтау итсәм дә, яңасы белән алыштырдылар. Үзем язам, ә башым тулы уй: җәза урыны кайда икән? Ул арада күзем бүлмәнең аргы башында тыгыз, кара тукымадан тегелгән пәрдәгә төште. Аның артында гильотина икән, имеш. Кемнеңдер аяк тавышлары да ишетелә. Монысы — җәлладтыр, дип уйлыйм. «Үтегез», — диләр миңа. Үтәм һәм каршымда басып торган Миңлебай Атнагуловны күреп, уянып китәм.

Нәрсә әйтергә теләвем. Төш ул — бер үткәннең икенчесе белән буталу урыны. Уйлаганың төшеңә керә, диләр. Бу төшне берничә көн элек Иоахим Вернер белән очрашканнан соң күрдем. Без Фридрих-штрассе урамындагы алда телгә алынган кафеда утырдык. Вернер да минем кебек чәйгә мөкиббән икән. Сөйләшә торгач, сәясәткә дә кагылып алдык. Вернер Гитлерның бер заводка егерме гильотина эшләргә тапшыруы турында ычкындырды. Дустыма ышанмый хәлем юк, чөнки ул металл эшкәрту белән бәйле бер ведомствода эшли иде. Бу гильотиналар алман төрмәләрендәге балталарны алмаштырырга тиеш икән. Аннары Вернер мине алдагы көнне генә тәмамлаган картинасын күрсәтергә остаханәсенә чакырды. Картина миндә әйтеп бетергесез тәэсир калдырды, әмма бу турыда әз генә соңрак сөйләрмен.

Бу сөйләшү турында шундук оныттым дисәм дә, ул мине төшләремдә үткәнем белән бәйләде дә куйды. Менә Миңлебай ныгып җитмәгән куллары белән уенчык гильотина ясый, соңрак анда безнең күз алдында чикерткәне җәзалап үтерә. Бу төшләр кабат антымны алгы планга чыгарды.

Авылым турында хәбәрләр бик сирәк килеп ирешә. Баштарак гражданнар сугышы вакытында чит җирләргә китәргә мәҗбүр булган якташларым белән аралашсам, соңрак ачлык елларында киткәннәрне, кулаклар дип авылдан сөрелгәннәрне очраткаларга туры килде. Алар тирә-күрше авылныкылар булганга, хәбәрләренә бик ышанып җитмәдем. Соңрак Берлинда укучы совет студентлары аша шактый нәрсәләр белештем. Утызынчы елларда Германиянең югары уку йортларында белем эстәгәннәр арасында якташларым да очрады. Миңлебай Атнагулов турында төрлечә сөйләделәр. Берәүләр Урта Азиядә басмачыларга каршы сугышырга киткән дә шунда калган дисә, икенчеләре, аны Кремльдә зур чиновниклар арасында күргәннәр, дип бара. Ә өченчеләре Әбүбәкер Субаев чәнчеп үтергән дип ышана.

Чынлыкта исә бөтенләй башкача булган икән. Миңлебай Атнагулов Мәскәүнең үзендә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре әзерли торган курсларны тәмамлаган. Аннары Икенче бөтендөнья сугышына кадәр республика колхозларының берсендә агроном булып эшләгән. Әлбәттә инде, ул бездән шактый ерактагы районны сайлаган. Ул чоры турында миңа берни мәгълүм түгел. Бары тик күз алдыма гына китерә алам: иртә таңнан торып эшкә киткәндер, иртәнге кояш нурларына төренгән бодай басуларына карап, булачак уңышны исәпләгәндер. Өйләнгәнме ул, гаиләсе булганмы — анысы мөһим түгел. Бары шунысын беләм: андый кешеләрнең сәер гадәтләре вакытлыча югалып тора да, хәлиткеч минутларда кабат калкып чыга.

Миңлебай Атнагуловның ул чактагы тормышы турындагы бердәнбер

хәбәрне 30нчы елларда Россиядән китеп монда килеп эләккән күрше авыл кешесеннән ишеттем.

— Җәяүләп үз авылыма кайтып киләм, — дип сөйләп китте ул. — Күрәм: юл кырыенда бер автомобиль туктап тора. Янында кешесе дә бар. Ул каядыр еракка төбәлгән дә кымшанмый басып тора. Карыйм — Минлебайга охшаган. Исеме белән дәштем. Минлебай, борылып, күзләрен тутырып карады да автомобильгә кереп утырды, йөртүчесенә нидер әйтте. Ул арада машина, юл тузаннарын куптарып, кузгалып та китте. Мин, аптырап, ул карап торган якка борылдым. Ерактa, шәфәкъ нурларына төренеп, Ай авылы җәелеп ята: хатын-кыз күкрәген хәтерләткән ике калкулык, йортлар, боргаланып киткән елга, Кара урман.

— Чынлап та ул идеме? — дип сорадым.

— Белмим дә инде, мин бит аның бала чагын гына хәтерлим.

— Бәлки йомышын үтәргә тукталган кеше булгандыр?

— Алай да булырга мөмкин.

Шулай да иманым камил: бу кеше Минлебай булгандыр. Монда аны ике сәбәп китергәндер. Беренчесе: Ай — аның туган авылы. Хәтта адәм актыклары да җирсү кичерә. Икенчесе: һәрбер җинаятьчене җинаять кылган урыны тарта. Ә менә кайтуы ничә тапкыр булгандыр — анысы сер булып кала.

Еш кына үз-үземә шундый сораулар бирәм: авылдашларым Минлебай Атнагуловны искә алалармы икән? Аның дөньяда яшәве белән килешәләрме? Үч алырга теләүчеләр булды микән?

Башкисәрнең яшәү урыны, мөгаен, мәгълүм булмагандыр. Исәнме, юкмы икәнен дә белделәр микән?

Менә хәзер чират Вернерның картинасына житте. Остаханәгә аяк басу белән, үземдә нindидер тынычсызлык тойдым — сәбәбен картинага күз ташлауга аңладым. Вернерның иҗаты белән монарчы да таныш идем. Табигать күренешләре, портретлар язарга яратуын да белә идем. Әмма монысында башка тема. Бер төркем кеше өстәл тирәли тамак ялгап утыра. Беренче карашка, гаҗәпләнерлек берни юк. Тик өстәл янында әйтелеп бетмәгән нindидер авырлык хөкем сөрә.

— Картина ничек атала? — дип сорадым мин.

— «Үлем җәзасыннан соң».

Ниһаять, башыма барып житте. Персонажларның алъяпкычына кан тамчылары чәчрәгәне җәллад икән ләбаса! Калганнары — корбан ителгәннең туганнары. Күзләренә чыккан югалту ачысын күрсәтмәскә тырышып, ни турындадыр гәпләшәләр: һава торышы турында микән, бәлки танылган композиторның яңа куелган операсы турындадыр? Җәллад һәм корбанның якыннары бер-берсенә гаҗәп игътибарлы, хәтта салаттыр, минераль судыр тәкъдим итешәләр.

Вернер бу картинаны Гитлерның гильотина ясарга кушуы тәэсире белән язгандыр, күрәсең. Өстәл тирәли утырган кешеләрне ясаганда үз халкын — алманнарны күз алдында тоткандыр. Әмма теләсә кайсы сәнгать әсәрендә дөньядагы хакыйкатьне берләштергән уртаклык табып була. Шәһит китүчеләр һәм җәлладлар — бергә, сәер дуслык, әлбәттә.

Тик уйлап карагыз: исәпсез-сансыз кешеләр бер гаепсезгә лагерьларда, төрмәләрдә газап чиктеләр, күбесен теге дөньяга озаттылар — ә аннары ни булды? Җәлладлар үз корбаннары яисә аларның туганнары белән терәлеп диярлек яшәделәр, бергә бәйрәм иттеләр, бер сукмактан эшкә йөрделәр, бер өстәл артына утырып ашадылар-эчтеләр. Берәүләре бернинди явызлык кылмаган кыяфәт чыгарса, икенчеләре, якыннарын югалтып, кайгы кичермәгән кебек кыланды. Дөрес, араларында кабахәтлекләре өчен

тиешлесен алганнар да булгалады. Мисалга, 15 елын тикмәгә лагерьда калдырган берәү, кайтып төшешкә үзен рәшәткә арасына тыккан адәмне очрата. Бу очрашу шаһитлардан башка, бер учреждениенең баскыч мәйданчыгында була. Безнең каһарман нишләгән дисез? Каерылып торып, хәшәрәтнең нурсыз чыраена чәпегән. Тегесе, яңагына ябышып, ыңгырашырга тотынган. Һәм вәссәлам! Хәер, халык вакыйганы һәрвакыт гаделлек ягына борырга тырыша. Сорау туа: бер печтек кенә күгәргән урынны әрәмгә үткән 15 ел белән чагыштырып буламы? Ни өчен халыкның үче янакка менеп төшүдән узмый? Нәрсә, шуның белән шул булдымы?

Ул чакта Ватанымда кылынган бар явызлыкны шушы картинада күргән кебек булдым.

Өченче Рейх турындагы китапларның берсендә шундый эпизод очрады. Җәлладны кулга алалар. Тегесе исә шаккката: «Ни өчен? — ди ул. — Мин үз эшемне генә башкардым. Бер баш өчен миңа алтышар шиллинг түләделәр!» Ә мин, шәхсән, башкача күзаллыйм: вакыйга Вернер картинасында сурәтләнгән өстәл артында бара. «Спектакль тәмам. Тор әйдә, киттек». Җәллад, агарынып, аягына күтәрелә, авызын салфетка белән сөртә дә үзенә төзәлгән мылтык көпшәләре астында, ава-түнә, чыгар юлга юнәлә.

Ә минем илемдә үзбуйлы кыланган җәлладлар хакында ни әйтергә? Аларны алырга килсәләр — аптырашта калмаслар иде, дип уйлыйм. Тик кулга алучысы гына булмады. Шулай итеп, бу кабахәтләр корбаннары белән бер өстәл артында калдылар.

Миңлебай Атнагуловны беркем эзләмәве, җәзага тартмавы да аңлашыла. Моны эшли алырдай ирләрнең барысы да гүрдә ята, аларга алмашка теләсә кайсы хәшәрәтне үз өстәле артына утыртырга риза буын килгән.

Фикерләремне Вернер белән уртаклаштым.

— Өстеңә артык күпне алгансың, — диде ул, касәсеннән чәй уртлап ( төшенгәнсездер, әңгәмә әлеге дә баягы Фридрих-штрасседагы кафеда бара). — Ни-нәрсә булганын күз алдыңа китермәгән килеш хөкем итәргә алынасың. Син үзең үк җәллад белән бер өстәл артына утырырга, өстәвенә чәй дә тәкъдим итәргә бик мөмкинсең.

Түзә алмыйча, урынымнан сикереп тордым.

— Утыр, — диде ул тыныч кына. Ярсуым бераз басыла төшкәч, дәвам итте. — Беләсеңме, кадерлем, эш нәрсәдә: күпчелек аларның җәлладлармы, әллә корбаннарны икәнен аера алмый. Дөрестән дә, бу адәмнәрнең бер үк вакытта кан коючы да, корбан булуы да ихтимал.

— Аңламыйм, бу — минем өчен артык катлаулы.

— Дөрес, — Вернер кабаланмый-нитми, тавышы ышанычлы, вакыт-вакыт ул безнең Гыйльметдин муллага охшап китә, хәтта урыныннан торыр да хәзрәт кебек минем тирәли әйләнгәли башлар шикелле тоела. — Син хәзер башка чор кешесе. Үткәннәр үткәндә калды. Син аларны беркайчан да аңлый алмаячаксың.

Миңа, чыннан да, туган җиремдәниләр кылынганы билгеле түгел. Ни өчен риваятьләр тынып калды? Кан коючылар нигә үзләренә тиешлене алмадылар? Теләсә кайсы әкиятне ал, анда явыз көч җиңелүгә дучар ителә (урман сарыгы — Шүрәлене алыгыз, усал бай йә көнче Яхъя Атнагуловны?). Баштанаяк канга чумган НКВД хезмәткәрләре, әләкчеләр, яла ягучылар, төрмәчеләр кайда, йә әйтегез?

Җавабы бик ансат: аларны үзләренеке санадылар. Менә бәланең башы кайда. Шуңа җәлладлар белән табын бүлешкән ватандашларымны гаепләргә хакым бармы минем?

Вернер белән сөйләшүне һич оныта алмадым. Үз-үземә читтән күз ташламак булдым. Һәм, беләсезме, нинди нәтиҗәгә килдем? Үч алырга

теләге булмаган авылдашларым өстенә гаеп ташлау — үз өстемнән җаваплылыкны төшерергә маташуым икән.

— Син аларга Минлебай Атнагуловны җәзага тарту бурычы йөкләмәкче буласың. Исән калган бердәнбер кеше — син түгелмени? — ди намусым.

— Мин бик еракта, — дип акланмакчы булам.

— Шуннан ни?! — намусымның туктар исәбе юк. — Исеңә төшер — син бит ант бирдең!

— Мине барыбер чик аша үткәрмәячәкләр.

— Тик антның чикләр белән бәйләнеше юк.

— Әгәр мин ант итмәдем дисәм? Исәннәр арасында аның турында беркем дә белми бит?

— Алай эшләргә хакың юк.

— Мин барысын, барысын да хәтеремнән сызып ташлаячакмын.

— Хәтта синең гомерең бәрабәренә башын салганнарны дамы?

Кабат күз алдыма Фатыйма белән Хәлил, Кара урманнан килгән коралдаш иптәшләрем килеп бастылар. Йә Ходам, мондый авыр йөк белән алга таба ничек яшәргә?

Тышкы төс-кыяфәтем үзгәреп, европалыларга тартым булганга, мине берәү дә әллә кайдагы авылдан чыккан татар кешесе дип, башына да китермәс иде. Мин ни өчен Германиягә барып чыктыммы? Иртәме-соңмы бу хәл булырга тиеш иде, чөнки кайчандыр минем сыман авыл малайларына алман телен өйрәтергә алынган Иоахим Вернер тормышыма килеп керде. Һәм икенчесе: Гыйльметдин мулланың мәдрәсәдә дөньяви фәннәр укытуы. Мин аларга гомерем буе рәхмәтле булдым. Мондый мөмкинлектән күрше авылныкылар мәхрүм иделәр бит. Әлеге сөйләшү барган вакытта минем Берлин университеты аспирантурасын тәмамлап, докторлыкны якларга йөргән чагым ( алда әйтеп узган совет студентлары белән аралашуым да шул чакка туры килде). Әмма Берлинга эләгүем урау юллар аша булды. Әүвәл безнең елганың йөгерек суы, онытмаган булсагыз, дүрт дингезле Истанбулга алып килде. Византия ныгытмалары калдыклары, Солтан Әхмәт мәчетенең мәһабәт манаралары, Алтын мөгез култыгы, Босфор аша узган корабларның артыннан кул болгап калу — болар бар да минем өчен могҗизага тиң булды. Мин, беркемгә мәгълүм булмаган бер татар авылы егете, туфрак, тузан, балчык, тирес, — гомумән, пычрагы юылырга өлгермәгән учыма карап, язмыш сызыгымны укырга маташтым.

Монда мин чит-ят — беркем түгел идем. Бөек шәһәр серле ишекләрен ачарга ашыкмады. Әмма бирешергә теләмәдем. Тирә-ягым тулы кешеләр. Күзләрендә — яшәүгә ышаныч ярылып ята. Болар — урыс эмигрантлары. Мин дә шуларның бер вәкиле. Вакытлар узу белән, монда тукталганнарның күбесе Европага юл тотачак. Әкияти Царьград алар өчен вакытлыча лагерь булачак һәм алар Россиядәге бинигһая янгыннан калган куркыныч яраларын төзәтү мөмкинлеге алачаклар. Татарларга килгәндә, аларның барысы да диярлек Төркиядә төпләнәчәк. Безнең бабаларыбызның эзләре Мәккәгә илтә торган юлларда сакланып калган. Максатларына ирешә алмый, сәяхәтләрен монда өзәргә туры килгәннәр шушында күмелгән. Мондагы җирле сөйләш алар өчен ят тоелмаган (билгеле булганча, татар һәм төрек телләре — бер гаиләдән).

Чапан итәкләрен җилфердәтеп, намазга баручы кешеләре артыннан карап калам. Алардан кыздырган май, төрек каһвәсе исләре аңкып кала һәм мин, ирексездән, тынны буар суыклар, үтәли җилләрдә йөреп чыныккан, тузан катыш ат тире исе килеп торган камыт аяклы, гаярь йөрәкле кабиләдәшләремне күз алдыма китерәм. Ни гаҗәп: бер-берсеннән әллә кайда — җир читендә яшәгән шулкадәр төрле халыкның телләре

охшаш. Шуны уйлап, җаным күккә күтәрелә һәм кайдадыр янәшә ике җил — далалар һәм диңгезнеке — бергә килеп кушыла төсле тоела.

Хәзер, күп еллар узгач, телләрнең дә җилләр кебек үзара якын булуларына инандым. Бервакыт юлларым инклар җиренә китереп чыгарды. Мең еллар элек суы кипкән елга юлы буйлап барам, якында гына, камчыларын шартлата-шартлата, кара-кучкылт тәнле икәү сөйләшеп тора. Бер сүзләрен дә аңламыйм, әмма игътибар белән тыңлаганда, туган телем белән аларның сөйләмендә гаҗәеп охшашлык чагылып китүен тоеп, катып калдым. Шул чакта баш түбәмнән аяк табанына кадәр сәер бер калтырау төшеп китте — хакыйкатьне аңлау шулай итә.

Кабат пароход кычкыртулары, исәпсез-сансыз мөәзиннәре тавышы яңгыраган Истанбулга кайтыйк әле. Тәэсирләрем искитәрлек булуга карамастан, баштагы көннәрдә шәһәрдә сыеныр урын табылмады. Баш өстемдә ышыкланыр түбәм дә, акчам да, ярдәм өмет итәрлек танышларым да юк. Шулай да яртылаш Европада, яртылаш Азиядә яткан Истанбул теләсә кайсы вакытта үз җиреннән сөрелгәннәрне, канаты астына сыендырып, тернәкләнеп китәр өчен мөмкинлекләр бирде.

Шәһәр буйлап йөри торгач, балык базарына йөкче булып урнаштым. Балыктан бушаган тартмалар — ятагым иде, дулкын шавы, акчарлаклар тавышы назлап йоклатты. Арудан арка-җилкәләрем әрнеп сызласа да, тормышымнан зарланмадым. Гомер юлымда иртәге көнгә ышаныч калмаган мәлләр күп очраганга, һәр иртәне куанып, сөенеп каршы алдым.

Уйламаганда бер матур кояшлы иртәдә базарда Миңлебай Атнагуловны очраттым. Бу шулчаклы көтмәгәндә булды — үз күзләремә үзем ышанмыйча, тораташ кебек катып калдым. Дошманым җирле халыклар киеменнән булганга, артык күзгә ташланмый. Каршымдагы сатучы һәм алучыларны аралый-аралый, артыннан иярдем. Миңлебай ныклы адымнар белән базар эченә атлый.

Бу минутларда ниләр кичергәнемне белсәгез иде? Әйтерсең, сыңар аягым белән дөнья читендә басып торам. Исегездә булса, багучылар миңа: «дошманыңа тешең үтмәс», — дип юраганнар иде. Әмма аны-моны уйлап торырга вакыт юк — дошманны күз уңыннан ычкындырмаска тырыштым.

Менә ул күрмәгән-белмәгән адәмнәр белән очрашты. Астыртын елмаюларына караганда, болар юньле кешеләргә охшамаган. Сөйләшү кыска булды, аннары Миңлебай базар капкасына таба китте. Мин аны Сөләйман мәчетенә илтә торган юлда куып тоттым.

Янына килеп, җилкәсенә кулымны куйдым да: «Киләчәгеңне пуля сызгыруына тиңли иден, әмма пуляның юлы бик кыска икәнен онытып җибәргәнсең», — дидем. Ул миңа борылгач, артыма утыра яздым — бу Миңлебай Атнагуловка охшаган, әмма бүтән адәм иде. Бер секундка гына күзләребез очрашты. Әллә каян гына җил килеп чыкты да аның чәчләрен тузгытты.

— Ак диңгез җиле, — диде ул. — Ә кичке якта Кара диңгездән исә. Аларның моңарчы очрашканнары булмады.

— Гафу итегез, — дидем, — Башка берәү белән бутаганмын.

— Булгалый.

Гаҗәп: аның уң бите сул битенә охшамаган. Уң яктан карасаң: суйган да каплаган Миңлебай! Ә сул яктан... Башыма кинәт сул яктан ул Хәлилгә тартым булырга тиеш иде, дигән уй килде. Чөнки кабатлап булса да әйтим: яхшылык белән явызлык бер йөзнең ике яңагы кебек.

— Гафу итегез, ашыгам, — дип, таныш түгел кеше мәчет ягына таба китеп барды. Исемә килә алмый, кадакланган кебек урынымда торам.

Калку җиргә күтәрелгәч, теге адәм артына борылып карады, әмма минем карашымны сизүгә, юлын дәвам итте.

Беләсезме, бездә шундый ырым бар: әгәр танышына охшаган кешене очратасың икән — тиздән үзе белән күрешәсең, диләр. Һәм күнелен шул очрашуны көтә башлый. Мин исә Миңлебай Атнагуловны очратмасымны беләм, әмма йөрәгем, алда тормышымны үзгәртерлек ниндидер вакыйга буласын сизенеп,тынычлыгын югалтты. Язмыш күктә языла, дигәнгә ышанабыз, ник бу ырымга да ышанмаска. Билгесезлек җанны кимерә.

Кичен тартмалардан әмәлләгән ятагыма сузылдым. Гадәттә йокым каты минем. Тик нигәдер ул төнне кинәт кенә уянып киттем. Куеныма җил тулган. Теге таныш түгел кеше сүзләренә караганда, Кара диңгез ягыннан искән җил. Кайдандыр акчарлакларның ачыргаланып кычкырганнары ишетелә.

Башка йоклый алмасымны аңладым. Аякларым үзләреннән-үзләре бушап калган балык киштәләре рәте буйлап алып китте. Базардан чыгу юлында туктап калдым. «Нәрсә соң бу? — дим үз-үземә. — Кая барам? Чит-ят караңгылыктан ни көтәм?»

Кинәт аяк тавышлары ишетелде. Урам буйлап кемдер килә иде. Аяк тавышы җил белән вакыт-вакыт йотылып, югалып тора. Ниһаять, караңгыда кеше сыны шәйләнде. Бер уйлаганда, аптырыйсы юк, кем кая бармас? Өстәвенә, бу — базарлар урнашкан район, ә андый урыннарда тормыш төнлә дә дәвам итә. Килүче ай юлына туры килде һәм мин аны танып алдым: бу — көндез очраткан адәм иде.

Ул мине искәрмичә юлында булды. Игътибарын җәлеп итмәскә тырышып, артыннан иярдем. Адымнары көндезге кебек ышанычлы, караңгылык белән дуслыгы күренеп тора. Артыннан көч-хәлгә житешәм. Әгәр борылып күз салса — эш харап, тик ул ашыга идеме — әйләнеп карамады.

Чатка җиткәч, кайсы юлдан китәргә дигәндәй, чак кына тукталып торды. «Ай-һай, кыенга туры киләдер мона: сул аягы сул якакка, уң аягы уңына ышанса — юлны табуы кыендыр», — дигән уй килде башыма.Ул арада теге кузгалып китте.

Берара сатучы, һөнәрчеләр яшәгән йортлар яныннан туп-туры бардык, аннары урам өскә күтәрелә башлады. Берничә тапкыр аны күземнән югалттым. Әллә нинди күз күрмәгән җирләргә килеп чыктык. Бер якта моңарчы күргәнем булмаган ниндидер мәчетнең манарасы калыкты. Әле анда, әле монда кәкре тар урамнар кереп киткәнгә, бару кыенлашты. Ташлар арасында буталып, җил тынып калды. Аяк тавышлары килгән якка чамалап атлыйм. Бераздан тегене бөтенләй күздән яздым, әмма аңсыз рәвештә баруымны дәвам иттем.

Ниһаять, яктылык күренде, урам кечерәк кенә мәйданга китереп чыгарды. Ул арада икенче бер урамнан таныш түгел кеше дә күренде. Тиз генә якындагы бинадан төшкән күләгәгә постым. Адәм мина арты белән туктады да каршында сузылып яткан урамга карап тора башлады. Шактый вакыт узды. «Теге мине абайлады, ахры», — дип уйладым.

Хәзер бу якка борыла да...Һәм мин балачактагы кебек каршымда үз йөземне күрдем. Йөрәгем еш-еш тибәргә тотынды, маңгаемны салкын тир каплады. Үземне ничек тотарга белми торганда, тегенең тавышы ишетелде:

— Килмисең дип торам.

Янымнан гына кемдер үтеп китте.

— Кара диңгез ягыннан искән җил ирек бирмәде. Исмәгыйль кайда?

Тавыш иясе мине күрмәде.

— Әнә ул.

Караңгылык эченнән Исмәгыйль дигәннәре калыкты.

— Тизрәк, соңга калабыз.

Алар, өчәүләп, ян урамга кереп, караңгылыкта эреп юкка чыктылар. Мин дә алардан калмадым. Бер өскә күтәрелеп, бер аска төшеп барганда, теге мәчет манарасы чагылып калды. Колакка диңгез шавы килеп бәрелде, янәдән җил уйнаклый башлады.

Урам кинәт кенә турайды, кинәйде, сиздермәс өчен арттарак калырга туры килде. Бер араны аларны янә күз уңымнан югалттым. Мөгаен, ян урамнарның берсенә борылганнардыр. Туктадым, куып тоталмасыма төшенгәч, үземне битәрләргә тотындым: ни калган иде соң миңа?

Ул да булмады, якында гына шау-шу ишетелде. Тавыш килгән якны чамалап киттем. Чаттан борылып, күрше урамга чыктым.

Анда... Теге «өчлек» үтеп баручыны талап маташа. Узгынчы, олы яшьтә булуына карамастан, шактый нык күренә. Бергә-бер чыксалар, боларны урыннарына утыртасы күренеп тора. Ул бар көченә тегеләр белән тартыша, әмма, әйткәнемчә, көчләр тигез түгел.

Катнашыйммы, юкмы дип, бераз тамашаны карап тордым. Кеше еллар үтү белән генә түгел, чакрымнар белән дә акыл җыя, дип әйткәнем булды инде. Ә мин узган километрлар мондый очракларда алтын урталыкны сайларга өйрәтте: дөреслек кайсы якта икәнен кем белгән!

Әмма йөрәгем кушканга буйсынып, үтеп баручыга ярдәмгә ташландым һәм йодрыкларымны эшкә җиктем. Вакыйганың мондый борылыш алуын көтмәгән караклар табаннарын ялтыраттылар.

Мин коткарган адәм аягына басып, өс-башларын каккалады.

— Сездән балык исе аңкый, тик ул җир, кара туфрак исе белән катнаш, — диде ул. Бу кеше, мөгаен, минем ватандашларымның берседер. Нигә гаҗәпләнергә, Истанбулда Россия кешеләре җитәрлек дип әйткән идем. Яңа танышым Исламбәк Топчибаш Төркиядә туып-үссә дә, әти-әниләре татар качаклары, 19 гасыр ахырында үз җирләреннән күчеп киткәннәр икән.

Соңрак Исламбәк Топчибаш белән очраштырган теге төнне кабат-кабат искә төшерәм һәм күп нәрсәләр ачыклана. Миңлебай Атнагуловка охшаган теге адәмне очраткач, нидер буласын сизенгән идем бит. Шулай булды да: ул кабахәт мине уңай персонаж янына китерде. Ахыры яхшы булып беткән романнарда гел шулай, диярсез. Әмма уйдырма чынбарлык белән кулга-кул тотынып атлаганын беләсезме? Исламбәк Топчибаш та соңрак болай диде:

— Уйлап чыгарылган белән чынлыкны чагыштыру — игезәкләрнең кайсысы кайсына охшаган дип баш вату шикелле мәгънәсез шөгыль.

Бу кеше минем тормышымда зур роль уйнады. Әйтерсең, мин җирдән әз генә күтәрелдем дә бөтен дөньяны күз карашым белән айкап чыктым.

Исламбәк Топчибашның тормыш-көнкүреше җитеш, ул Истанбулда берничә ювелир товарлар кибете тота булып чыкты. Аннан тыш тире иләү эшен җайга салган, тагын шәһәр базарларында келәмнәр сата торган берничә сәүдә урыны да бар икән.

— Минем беркайчан да туган илемдә булганым юк, — дигән иде ул беренче очрашуда. — Аның турында ишетеп кенә беләм.

Ул мине сатучы ярдәмчесе итеп эшкә алды. Белемле, намуслы булуымны чамалап, мине үстерде. Берничә ел эчендә аның уң кулына әйләндем.

Коткарган өчен түләве идеме бу? Юк, әлбәттә. Яклаучым чит-ят илдә үзен минем өчен җаваплы санаган.

— Сез ничек Төркиягә килеп чыгасы иттегез? — дигән идем танышу башында.

Ул болай диде:

— Мин үзем ил гизгәндә яралганмын. Тумышым белән сезнең тирәдән. Авылыгыз, елгагыз турында ишеткәнем бар.
— Нигә киттегез?
— Язмыш шулай язгандыр.
Ул туган якларыннан китү тарихы белән таныштырды. Аңар исә бу турыда әтисе сөйләгән булган.

## Яңа җирләргә күченү һәм чишмә тарихы

Берничә ел рәттән безнең якларда уныш булмаган. Корылык шул дәрәҗәгә житкән ки, кеше һавадан алданган. Булмас, дисезме? Ышанмасагыз тыңлагыз, әти миңа менә нәрсәләр сөйләде: урам буйлап барасың, көтмәгәндә каршыңа бер атна ук гүргә кергән кеше килә. Тегенә якынлашкач кына алданганыңны сизәсең. Каршыңа атлаучы ир-ат — көтүче Әбдразак икән. Ә өенә кайтып кергәч, чүт артыңа аумыйсың: көтүче алдагы көнне жан тәслим кылган. Аптырарлык түгел, амбарлар буш, теш арасына кыстырырлык та ризык юк. Ачлыктан бер-бер артлы кырыла башлаганнар. Иң көенечлесе — балаларны саклап калып булмаган. Аларга алмашка туар жаннар да күренмәгән.

Алда озын, салкын кыш. Авыл картлары тагын бер кат утырып киңәшәләр дә, озакка сузмый юлга кузгалырга булалар.

Төенчекләр төйнәлә. Күнелдә тик бер сорау: дөнья киң, әмма дүрт якка чыгып киткән юлның кайсысы аларны үлемнән йолып алыр? Берәү дә беренче булып сүз башларга кыймый.

Шулчак, алар бәхетенәме, биек күктә кыр казларының кыйгылдашкан тавышлары ишетелә. Бар да башларын күтәреп, тавыш килгән якка карыйлар. Кайсыдыр, күнеленең иләсләнүенә түзә алмыйча, киек казлар турындагы жырны сузып жибәрә. Үзәк өзгеч көй тамак төпләрен ачыттырып, күзләргә яшь китерә.

Үзләре дә сизмәстән, халык кошлар очкан якка атлый. Киек казлар, туган-үскән якларын калдырып, жылы якларга юл тотканнар, көчле канатлары белән жилпенеп, алар ераклашканнан-ераклаша барган һәм бераздан офык артына кереп күздән дә югалганнар. Күктәге бушлык әле генә өмет чаткылары биешкән йөзләргә сары сагыш булып яткан, күзләр янәдән жиргә төбәлгән, адымнар салмакланган. Шулвакыт күктә кошларның икенче төркеме күренгән. Аларны чираттагысы алмаштырган. Киек казлар кешеләрдә сүнгән өмет чаткысын кабат тергезеп, илгизәрләрне үз артларыннан калдырмаганнар.

Чакрымнар артта калган. Берәү, арган аякларга көч кертерлек хәбәр ирештерә: бу юл — боларның ата-бабаларын Мәккәгә, хажга алып киткән юл булып чыга. Юлчыларның күнелләре күтәрелә. Бара торгач, үзләрен сыендырырлык жиргә килеп житәләр. Алар яшәр түбә тапкан Азиягә ул чакларда дөньяның төрле почмакларыннан качаклар агылган. Татар эмигрантлары, гадәттә, Төркиянең далалы ягы — Анталиядә төпләнеп калганнар.

Ни өчен безнекеләр шунда каласы иткәннәр? Моның үзенә күрә тарихы бар. Әйткәнемчә, мин юлда, тукталышларның берсендә яралганмын. Әти-әнием әле бөтенләй яшь булганнар, якындагы чишмәгә суга дип киткәннәр. Бәлки юри икесен бергә жибәргәннәрдер, аларның бер-берсен яратулары берәүгә дә сер булмаган. Нәсел жебе өзелүдән курыккан картлар эше булмады микән? Кыскасы, яшьләр казан асып суга киткәннәр.

Әнием чишмә буенда булган хәлләрне миннән яшермәде һәм ничек булганын сөйләде.

«Һич онытасым юк. Янәшәдә генә көмеш су чылтырап агып ята. Син

матур төш күреп уянган халәттә: бу дөньяда синнән дә бәхетле кеше юктыр сыман.

Чишмәнең җаны бар бит. Кулыңны суга тыгуың була — астан кемдер эткән кебек тоела. Беләсеңме, бу чишмәнең йөрәге — ул шулай тибә. Әтиең белән без дә шул ритмда тирбәлдек.».

Әтием дә шул сүзләрне кабатлады. Андый нәрсәләр турында кем инде балаларга сөйли, диярсез. Хикмәт менә нидә: әти белән әни бәхетле булуны җенси мөнәсәбәткә генә бәйләп калдырмаганнар. Аларның бәхете — физик якынлыктан күпкә өстен булган. Алар — миңа — туачак сабыйга сулыш өргәннәр.

Ай арты ай үткән, болар һаман юлда. Әнинең тудырыр вакыты якынлашкан. Тик сәфәрнең очы-кырые күренмәгән.

Гадәттәгечә, төн кичәргә тукталалар. Хәлимә исемле хатын шул төнне төшендә мәрхүм бабасын күрә. Иртән торгач, аның сүзләрен башкаларга да җиткерә. Бабасы, арагыздагы көмәнле хатын кайда бәбили, шунда тукталырсыз, дигән.

Төшкә карата фикерләр төрле булган, әмма уртага салып уйлашканнан соң, бабай белән килешкәннәр

Шул ук көнне әнинең тулгагы башланган. Ирләр, йола буенча, читкәрәк киткәннәр, әни янында хатын-кызлар гына калган.

Иртәнге сөйләшүне дәвам итеп, ирләрдән берсе:

— Шушында төпләнергә туры килә, — дигән.

Икенчесе каршы төшкән:

— Суы да юк җирдә ничек көн итмәк кирәк?

Тегесе сүзен бирми:

— Хәлимәнең бабасы шулай кушкан. Мәрхүмнәрнең сүзен җилгә очырырга ярамый.

Ул арада, тирә-юньне яңгыратып, яшь бала елап җибәргән: шулай итеп, дөньяга мин туганмын. Бар да миңа ябырылган, күтәп алынган сабыйны кулдан кулга йөрткәннәр. Ә эсседән һәм сусаудан әлсерәп яткан әнием турында бөтенләй истән чыгарганнар.

— Карагыз әле, карагыз! — дип кычкырган тавыштан бар да айнып киткәндәй булган. Әнием ягына карап, тораташтай катып калганнар. Әнием һавада асылынып тора икән. Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз — юк, аның җирдән ярты аршын чамасы күтәрелгәнен үз күзләре белән күргәннәр, соңрак миңа да сөйләделәр.

Бу хәл күз ачып йомган арада — бик тиз булган. Ачкан авызларын ябарга онытып торган кешеләр, әнием яткан урыннан чишмә тибеп чыккач кына аңнарына килгәннәр.

Энгер-меңгер төшкәч, зур итеп учак тергезгәннәр. Йокы кайгысы качкан, бар да учак тирәли утырышкан. Һәркемнең йөзеннән шатлык бөркелә: ниһаять, ил гизү тәмам, алар шушы урында төпләнәчәк. Юлчылар кулларына чит ил туфрагын алалар, борыннарына ят исләр бәрелә. Аларны алда ни көтәчәк — әлегә беркем берни белми.

Ул да булмый, күнелләренә шом салып, якында гына тояк тавышлары яңгырый. Җайдаклар, ат өстеннән төшеп, учак янына киләләр. Болар — күрше авылныкылар булып чыга. Соңрак аларның сугыш-җәнҗалга һәвәслеге, яна килгәнәрне өнәмәүләре турында беләләр.

— Нәрсә кирәк? — дип сораган безнекеләрдән берәү.

Тегеләр, билләренә кыстырылган хәнҗәр сапларын тоткан килеш, каш астыннан гына карап торалар. Бер генә мизгелгә тынлык урнаша. Шунда дәһшәтле тынлыкны бүлеп, чишмә телгә килә. Гаҗәпләнүләре соң чиккә җиткән бар халык башларын чишмәгә таба бора.

— Нәрсә бу? — дип кычкырып җибәрә җайдакларның берсе. — Су?! Каян килеп? Бу чишмә күптән кипкән бит инде!

Алар чишмәнең тарихы турында сөйләп биргәннәр. «Берничә гасыр элек бу чишмәнең суы качкан, аның белән бергә монда тереклек кылган халык та юкка чыккан, — дигәннәр алар. — Инде чишмәгә кабат җан кергән икән, сезне моннан куарга безнең хакыбыз юк», — дип өстәгәннәр. Башына тай типмәгән кеше су иркенә каршы килеп булмасын бик яхшы аңлый, әлбәттә.

Чишмәне, барысы бертавыштан, Яңа туган чишмә дип атарга килешкәннәр. Соңыннан үз куллары белән төзегән авылга да шул исемне биргәннәр.

— Шулай итеп, чит-ят җирдә иң беренче булып мин туганмын, — дип кыйссасын тәмамлады Исламбәк Топчибаш.

Минем яралуым турында сүз йөртсәк, әти: «кеше яралганчы ук аның инде җирлеге була, — дип санады.— Җир астыннан бәреп чыккан чишмә турында да шулай әйтеп була. Без аның юл ярган урынын күрәбез, әмма җир астындагы хәрәкәте турында берни белә алмыйбыз. Кеше дә унайлы мизгелне сайлый һәм, чишмә суы шикелле, җирдә үз урынына дәгъва кыла. Шәһәрләр, авыллар белән дә шулай. Авылның килеп чыгышы җир астыннан су бәреп чыгуга бәйле булуы шул фикерне раслый түгелме?»

Миннән соң яшь ярымлык аерма белән алты энекәш-сеңелкәшләр дөньяга килгән.

Бу вакытта без Исламбәк Топчибаш өендә каты итеп пешерелгән төрек каһвәсе йоткалап утыра идек. Яклаучым сөйләгән тарих ахырына җиткәндә, төн уртасы авышкан иде инде. Безнең янда аның исәпсез-сансыз туган-тумачасы да утырды. Көнчыгышта шулай кабул ителгән — авыллардагы кардәшләре, гомумән, ике туган, өч туган, оныклары — бар да шәһәрдә яшәүче бай туганнары янына елышалар.

Вакыт соң булуга карамастан, балалар да безнең тирәдә чуалды, аннары аларны йокларга салдылар. Башкалар да әкренләп таралышты, чөнки иртән барысына да — кемгә кибеткә, кемгә базарга — эшкә барасы.

Без исә таң атканчы, якындагы мәчет манарасыннан, иртәнге намазга чакырып, азан ишетелгәнче утырдык. Мин дә үз авылым тарихы турында сөйләдем. Ул бик бирелеп тыңлады, Бату Сакаев турындагысын ишеткәне булган икән.

Сүз иярә сүз чыгып, ул шактый вакыйгаларга тукталды. Сезгә менә аның авызыннан ишеткән беренче кыйссаны җиткердем, икенчесе белән дә таныштырасым килә. Анысын үземчә гади генә «Зариф картның мыгырдавы» дип атадым. Монысын да ул әтисе Мәхмүт Топчибаштан ишеткән һәм мин хикәяне беренче зат исеменнән бирергә телим.

*Ахыры киләсе санда*



Рәниф
Шәрипов

# БЕЗ ДӘ БИТ БУ ДӨНЬЯ БАЛАСЫ...

## Тел

**Ах, зәмһәрир суык «урыс» кышы!**
**Тырмыйм, ертам ишек чыптасын.**
**Ябыштым да каттым телем белән,**
**Яладым да тимер тоткасын.**
**Чирле әнкәм өйдә үлеп ята.**
**Ә мин ача алмыйм ишекне.**
**Тел очымны тота салкын тимер...**
**Тынсыз елыйм.**
**Беркем ишетми.**
**Кычкырып та, ычкынып та булмый.**
**Дөньяның мин чүп бер баласы.**
**Бөтен телең бозга әйләнгәнче,**
**Әллә кисәк тартып аласы?..**
**Җәрәхәте телнең тирәнәя,**
**Күбрәк түзгән саен, селкенми.**
**Балачакта эләккәнем булды**
**Шул тозакка, салкын бер көнне.**
**Кем ябыша, шулай, кызык эзләп,**
**Бирелә дә, кайчак, коткыга.**
**Су агызса кемдер чәйнектән,**
**Тотка коллыгыннан котыла.**
**Нигә әле искә төште соң бу?**
**Дөрес кенә булмый һәр адым...**
**Бүтән шундый хәтәр «тотка»ларны,**
**Кайвакыт, мин ялап карадым.**
**Ник яладың, димә.**
**Ахмак идем.**
**Кыйбласыз җан, денсез, шук идем.**

---

Рәниф ШӘРИПОВ (1950) – *шагыйрь; «Тәрәзәдә утлар», «Ян, учагым!», «Мәңгелек сер» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Ятим идем, хәтта, фәкыйрь идем,
Хөр күңелем белән тук идем.
Фәкыйрьлегем — дүрт як ятимлектән,
Хөр күңелем — дүрт як кыйбладан.
Ахмак башым, диңгез тубыктан, дип,
Ә Алланы юк дип уйлаган.
Айкап атты диңгез давыл булып,
Алдымда тик кыя ташлары.
Ачы суы авызыма тулып,
Тончыктыра, буа башлады.
Сискәндем дә, күтәрелдем кинәт,
«Улым! Үләм...» дигән тавыштан.
Кыйбла яктан — әнкәм ягыннан бу...
Тик, телемә тотка ябышкан.
Тоташ бозга әйләнәм бит хәзер,
Соң, бу әллә әҗәл көнемме?
Бар хәлемне җыеп, ыргылдым да,
Умырдым да алдым телемне.
Ишек ачык.
Мин атылып кердем.
Ә әнкәем инде җан бирә.
Сүзләрем күп,
Тик, сөйләшеп булмый.
Авызыма тулып кан килә.

Мин аңладым — кемнеңдер илен
Бетерәсең килсә, җимереп,
Аякларын түгел, кулларын да түгел,
Телен бәйлә икән, иң элек.
Тел — тамыр ул,
Нәсел-кавемнәрнең
Кендекләре шуңа береккән.
Үз-үзләрен саклар өчен алар,
Телен саклый элек-электән.
Шуннан үсә яме күңелеңнең,
Шуннан үсә гаме җаныңның.
Тел биргәнгә Ходай, җиһанга без
Адәм заты итеп таныл дык.
Адәм затын бетерәсең килсә,
Телен бетер икән иң элек.
Ә аннан соң, телсез адәм үзе
Илен таптар, ватып-җимереп.
Күрәсезме, күпме ятим калган,
Телсез калган апа-абыйлар,
Тотка түгел, телен өзгән кулны,
Койрык болгый-болгый ялыйлар...
...Ишек ачык.
Әнкәй үлеп ята,
Бәхилләшеп чыгыйк булмаса.
Тәүбә кылган ихлас адәмнәргә
Ходай тагын бер кат юл ача.
Селкенергә, кычкырырга куркып,
Бозга катып барган көнеңме?
Алла хакы, әнкәң хакы өчен,
Ал умырып тизрәк телеңне!
Без ятимнәр кебек барыбыз да,
Салкын, тимер тотка ялаган.
Әнкәй үлеп ята.

**Телебез юк.**
**Ә авыздан шаулап кан ага.**
**Селкенеп тә, ычкынып та булмый.**
**Без дә бит бу дөнья баласы!**
**Авыз тулы кан булганда, ничек**
**Адәм заты булып каласы?**
**Кузгалырмы кавем беркөн айнып,**
**«Улым! Үләм...» дигән тавыштан.**
**Вакыт — бикле.**
**Көннәр — кадакланган.**
**Телебезгә еллар ябышкан.**
**Хезмәт итә Вакыт залимнәргә,**
**Тарих — үзе ата ялганчы.**
**Адәм заты булып ничек калыйк,**
**Адәм көлкесенә калганчы?**
**Алла хакы өчен, әнкәң хакы өчен,**
**Ал умырып тизрәк телеңне!**
**Акса аксын каның...**
**Адәм булып,**
**Яшәп күрсәт калган көнеңне!**
**Тәүбә кылган ихлас бәндәләргә**
**Мәрхәмәтле Ходай юл ача.**
**Ишек ачык,**
**Әнкәй исән әле.**
**Бер дәртләнеп карыйк, булмаса.**
**Дүрт як ятим булсак, илсезлектән,**
**Күңел богаулары нәрсәдән?**
**Бар бит җаннар, билен-телен бирми,**
**Адәм заты булып яшәгән.**
**Киң шикелле иде безгә җиһан...**
**Иксез-чиксез дөнья тар икән.**
**Дүрт як кыйбла — Ирек түгел икән!**
**Диңгез - тирән, Алла бар икән!**

## Ике күрше

*Казан йорты илә Нугай йорты*
*борынгыдан бирле үзара орышып*
*яшәделәр...*

Һади Атласи.

**Сугышырга җитеп, хәтта,**
**Куралмыйча берсен-берсе,**
**Тигезли алмый ызанны,**
**Талашты гел ике күрше.**
**Икесе дә төпле хуҗа**
**Баш күтәрми эшли торган.**
**Юктан башлап, җирен ашлап,**
**Үз тормышын үзе корган.**
**Эшләделәр, ызгыштылар,**
**Тормады берсе дә җебеп.**
**Көн артыннан көн узганны**
**Күрми дә калдылар кебек.**
**Шулай узды гомерләре,**
**Юкка түгел берничек тә.**
**Бәби арты бәби үсте,**
**Матчага элгән бишектә.**
**Балаларын борчымады,**
**Бакчаның бер карышы да.**

**Вакыт җиткәч берәм-берәм,**
**Читкә очты барысы да.**
**Бушап калган нигезләрнең**
**Тышы да юк, эче дә юк.**
**Ызан аша бер-беренә,**
**Сүз әйтерлек кеше дә юк.**
**Элек ялт иткән бакчада**
**Шаулап үсә кыргый үлән.**
**Китеп бетте бала-чага,**
**Үлеп бетте күрше-күлән.**
**Капкалар күптән ачылмый,**
**Шомлы тынлык буш нигездә.**
**Әҗәл чалгы белән үткән,**
**Кыек ызанны да тигезләп.**
**Тәрәзәләр кара, җансыз,**
**Юк анда гөл, юк анда ут.**
**Беркемгә берни кирәкми,**
**Бакча да юк, ызан да юк.**
**Нәрсә эзләп тырыштык соң?**
**Нинди тормыш булды соң бу?**
**Бәрәкәт китә нигездән...**
**Нинди ым бу? Нинди шом бу?**
**Кардәшләрнең чардуганын**
**Якын куеп бер-берсенә,**
**Вакыт үткәч, соңлап безне**
**Тигезләрме кабер генә?**
**Юктан башлап, эшне ташлап,**
**Үпкәләшү чиктән ашкан.**
**Гомер узган, бакчабызны**
**Чүп үлән, чит үлән баскан...**

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

Фарсель
Зыятдинов

# АВЫЛДАШНЫҢ АВЫР ЮЛ БАШЫ

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

**Сәмәрканд**

Ниһаять, 1935 елда карточка системасы бетерелде. Күрәсең, колхозлар ныгый барып, шәһәрләрне икмәк белән житәрлек тәэмин итә башлаганнардыр. Әхим гомерендә беренче тапкыр бер сум ун тиенгә кабарып торган ак икмәк сатып алды. Чиратта торганда укырмын дип Пушкинның «Дубровский» китабын да кыстырган иде. Тик инде чиратта торырга туры килмәде...

Ә менә кием-салым юнәтү кыенрак иде. Акча житмәгәнлектән, брезент ботинкасын ялан аякка гына киеп йөрсә дә, тормыш яхшыга үзгәрә барды. Хәер, тормыш кына түгел, Әхим үзе дә нык үзгәрде. Кыюсыз гына малайдан егет булып житеште, укуда да сынатмады. Урыс телен белү башка фәннәрне дә үзләштерергә булышты. Ни эшлисең, үз телендә укырга мөмкинлек булмагач, үзеңне көчләп булса да «олы абзыйның» телен өйрәнергә туры килде.

Группада укучыларны да кыл иләктән иләделәр. Кырык укучыдан нибары егерме ике укучы гына, иң чыдамнары, иң тырышлары, хезмәт сөючәннәре — кыскасы, иң яхшылары гына калды.

Беркөнне шулай Наманганга кайткач, канцелярия кибетенә сугылды Әхим. Анда кемне күрде, дисез? Хөснетдинне. Әйе, әйе, бергәләп Ферганәгә укырга барган Хөснетдинне.

— Бәй, — диде Әхим, — нинди кунак бу, каян килгән бу?

— Әйе, бирегә эшкә урнаштым, — диде Хөснетдин, уңайсызланып. Ул Әхимгә туры карарга читенсенеп читкә борылды.

— Син әйбәт кенә укып бара идең бит, башыңа нәрсә сукты синең? — диде Әхим.

— Туйдырды мине уку, Әхим, — диде Хөснетдин, — монда әйбәтрәк, дәрес хәзерлисе юк. Акчасы да бара. Хезмәт хакы начар түгел...

— Нәрсә, югары математиканы син шушының өчен укыдыңмени? Их син, Хөснетдин, бөке баш, укырга да күп калмаган иде бит инде... Күпкә

*Ахыры. Башы узган санда.*

түзгәнне, азга түзәргә ярамай идемени? Давай, бу эшенне ташла, киттек! Нәрсә, линейка сатар өчен укып интектенмени?

— Уйлап карармын әле, — диде Хөснетдин, Әхимнән котыласы килгәндәй. Әмма институтка ул кабат кайтмады.

Тиздән институтта педагогия практикасы тәгәлләнеп, Әхимнәр өченче курс имтиханын тоттылар. Тагын бер генә ел укыйсы калган иде. Нәкъ шулчак көтелмәгән хәл килеп чыкты. Җәйге каникулларда әйбәт кенә акча эшләп, ярыйсы гына киенеп, институтка килгәч җиткерделәр ана бу хәбәрне:

— Укулар химия бүлегендә башка булмаячак.

— Ничек, булмаячак?

— Югары оешмаларның карары белән химия бүлеге ябыла.

— Ә безгә нишләргә?

— Икенче, өченче курсны тәмамлаучыларны Сәмәрканд шәһәренә Үзбәк дәүләт университетына күчерәләр. Өченче курсны тәмамлаучылар өченчедә, ә өченче курска күчкәннәр икенчедә укыячаклар.

— Ә Сәмәркандка барырга теләмәсәң?

— Биредә каласың. Телисең икән, биология бүлегендә шул ук курста укый аласың.

Нишләргә? Әхим тиз генә әтисенә хат язып җибәрде. Ә үзе, озак уйлап тормыйча, университетка күчәргә кирәк, дигән карарга килде. Билгеле, әтисеннән җавап та озак көттермәде.

«Әй, улым, — дип язган иде әтисе хатында, — университет синең кебек яшь-җилкенчәк өчен бәхет ул. Мин,үд балаларымнан хет берсен генә булса да университетка урнаштыра алырмын дип, хыялланырга да курка идем. Үдең беләсең, университет тәмамлаган татар балалары бөтен татар дөньясына бармак белән генә санарлык». Кәрим абзый үзенең хатын үзенә бер горурлык хисе белән, «тырышып укы, улым, әйбәт укы», — дип тәмамлаган иде. Моны Әхим әтисенең изге хәер-фатихасы итеп кабул итте.

***

Икенче көнне химиклар Сәмәркандка — университетка юл тотты. Озатырга килүчеләр арасында таныш йөзләр: студент елларында инде шактый үсә төшкән «Төпчек» Турдыев, балагур Мостафин, «бөек хикәятче» Әбүбәкерев, акыл иясе Әдһәм Кокаев... Алар арасында Сәмәркандка китәргә теләмәгән химиклар да бар: Зина Гордеева, Таня Жеребцова, Таһир Касыймов...

Өч ел эчендә туганлашып беткән сабакташлардан аерылу җиңел түгел икән. Ничектер, җанынның бер кисәге теленеп калган кебек...

Поезд кузгалып киткәч, аерылышу хисләре бераз сүрелә төшкәч, кызлар бер-берсенә сөялешеп җыр сузды. Әхим исә, әле узган ел гына физматтан химикларга күчкән Петя Чернов янына елышты.

— Шулай итеп, Әхимчик, безне университет студенты дип санарга була. Шәп бит бу, шулаймы?!

— Син әйткәч, хак инде ул!

— Хагын хак та... Университетта укулары гына җиңел булмас. Миңа бигрәк тә... Ни генә дисәң дә, Ферганәдә чакта үз өебездә, әти янында яшәдем. Ә хәзер... тулай торак көтә.

— Ничава, яшәрсең! — диде Әхим, — без бит яшибез. Әти канаты астыннан киткәч, күшегермен, югалырмын дип куркасыңмы?

— Югалырмын димим мин, читен булыр, дим...

— Юлларында булып торсын икән киртәләр, — ди халык. Хәер, В.Гюго

нәрсә дигән? Ул да шулайрак дигән түгелме соң? Эчке каршылыклар аша үтү — җиңүгә зур бер адым! — дигән.

— Уку да пединституттагы кебек кенә булмаячак. Университет, туган, педвуз түгел инде. Син үзең хет университетның нәрсә икәнен беләсеңме?

— Беләм, — диде Әхим катгый гына, — шуңа күрә дә барам!

Нәкъ шулвакыт күрше ишек янындагы кызларның берсе әче итеп кычкырып җибәрде:

— Әй, кызлар! Туфлине... туфлине төшердем, — бу Анна Еврощенко иде. Озын гына буйлы, сылу кыз, беркеме дә юк, балалар йортында үскән. Хәер, үзенең сөйләвенә караганда, кайдадыр туганнан-туган апасы бар. Тик анда Анна кайгысы юк, үзенә унике баланы карарга, аларны туендырырга кирәк.

Кызлар шунда ук Анна янына җыелды, тегесе сөйләнүен белде:

— Кызлар, ә, егетләр?! Нәрсә эшләргә соң хәзер? Туфлисез кая барыйм?

Тегеләре исә, үз чиратларында Аннага ябырылды:

— Э-эх, син, ачык авыз!..

— Йокымсырап, «алтынланган» туфлиеңнән колак кактың менә!

— Пешмәгән! Хәзер ничек керәсең инде университетка?

«Алтынланган» туфли дигәне, дөресен әйткәндә, брезент белән җилемнән эшләнгән, ул да кызларныкы түгел, әлеге дә баягы шул тишелә башлаган малайлар туфлие иде. Бичараның яңасын сатып алырга акчасы юк. Кызларга, малайлар кебек, җәй айларында акча эшләп алу гадәте кермәгән. Хәер, җәен Анна үзенең тутәсендә була, балаларын карый. Шуңа күрә акча эшләргә вакыты да калмый иде...

Шул арада Аннаны коткару комиссиясе төзелде. Бераз гәпләшеп алганнан соң дөрес бер карарга килделәр: «Барчабыз исәбенә Аннага нинди дә булса йөрерлек аяк киеме сатып алырга». Поезд тукталышларда озаклап торырга күнеккән иде. Монысы ярап куйды. Урсатьев стансасына туктагач, егетләр акча җыйдылар да, Аннаны ияртеп, якындагы базарга йөгерделәр.

Менә ул аларга кирәк товар. Гомер буе юынмаган диярсең — кап-кара бер малай киелгән брезент туфлине кулында әйләндерә. Болар шул малай янына килделәр. Малай да боларны ерактан ук күреп алган икән.

— Пажалста, дарагуй, — дип башлады ул сүзен, — пустяк отдам, туфли харуш, лутчы сыравна не найдуш, — ул шунда ук Аннаның аягын эләктереп алды да, «туфлине» кигезеп тә куйды.

— Ах, какуй замечательный ножка, — дип дәвам итте ул мактауны, — подарил бы, да деньги немнужкы нужно!..

Үзе туфлине сыпырган булып кызның аягын иркәли:

— Немнушка күпме була соң ул? — диде Петя.

— Пустяк, голубчик, нибары полтора червонец.

— Шаяртма, — диде Әхим, бәхәскә кушылып һәм туфлине җентекләп карый башлады, — менә монда инде тишелә дә башлаган, табаны ташка үлчим, чак эләгеп тора... Ничек, Анна, аякны кысмыймы?

— Азрак кыса, — диде Анна, — шулай да, арзангарак бирсә, йөрергә була.

— Алайса, менә сиңа биш тәңкә, — диде Петя сатучы малайга, — товарыңа күрә бик житкән.

— Нәрсә сез, егетләр, шаяртасыз, што ли?! Туфли нибары ике тапкыр киелгән, яп-яңа бит...

— Алайса, менә сиңа алты сум, — диде Петя, бәяне арттыра барып, — бирәсенме? Юкса, китәбез.

— Юк, булдыра алмыйм, — диде сатучы малай һәм куркыпмы товарын җыя башлады.

Ләкин студентлар ашыкмады, сатулашуны дәвам иттеләр.

— Алайса, җиде. Канәгатьләндерәме?

Малай анысына да риза булмады. Сатулашу дәвам итте. Ниһаять, җиде сум сиксән тиен түләп туфлине алдылар. Шулай итеп егетләр Аннаны туфлиле иттеләр.

Икенче көнне иртә белән «химиклар» инде Сәмаркандта иделәр. Җимеш бакчалары, декоратив агачларга күмелеп утырган бу шәһәр монарчы Әхим күргән шәһәрләрдән зуррак та, матуррак та иде. Рәт-рәт булып тезелеп киткән, гасырлар буе яшәгән чинарлар гүя Аксак Тимер башкаласының борынгы серләрен саклый иде. Наманган һәм Ферганәгә караганда ул зуррак кына түгел, баерак та, истәлекләрәк тә кала. Биредә алты югары уку йорты, күпсанлы техникумнарның булуы аны, чынлап та, студентлар каласы итә. Университет белән рәттән тарихи истәлекләр... Әнә, борынгы корылмаларның берсе — сылу Регистан, Аксак Тимер мавзолее... Бу кала Әхимдә чиксез соклану хисләре уятты.

***

Ферганә һәм Бохара педагогия институтларының өч курсын тәмамлаучыларны ике группага аердылар: көчлеләрне өченче курска, йомшагракларны икенче курска кабул иттеләр. Әхим көчлеләр группасына эләкте. Монысында педагогия институтларыннан килгәннәрдән тыш, университетның икенче курсын тәмамлаучылар да укый иде. Шуңа күрә укуда да, программада да бу исәпкә алынды. Пединституттан килүчеләргә кичләрен өстәмә рәвештә математика, физика, органик химиядән дәресләр бирелде. Укуы ифрат та кыенлашты. Нәтиҗәдә, пединституттан килгән укучыларның шактый өлеше кабат өченче курста калдырылды. Бәхеткәме, тырышлыгын күреп алдылармы, Әхимне дүртенче курска күчерделәр.

Группада төрлечә укучы бар иде. Яхшылары да, яманнары да. Йомшак җәеп, катыга утыртучылар да. Хәвеф килгәч кенә акыл җыючылар да. Шуңа күрә укытучылар начар укучыларны көчлерәк студентларга беркеттеләр. Әхимгә органик химия буенча начар укучы Пеньковны бирделәр. Гадәттә, кеше үз фамилиясен аклый, диләр. Гүя, бу сүзләр Пеньковка атап әйтелгән иде. Пеньков тыгыз тәнле, утыз яшьләрендәге куәтле ир. Студенттан бигрәк укытучыга тартым иде ул. Төп дисәң дә төп инде.

Әхимгә «төп» белән шактый җәфаланырга туры килде. Аңа карап үзе дә аптырый ул, юк-бар белеме белән ничек итеп бу кеше өченче курска кадәр җиткән икән? Углеводородның төзелешен бит теләсә нинди мәктәп баласы белә. Ә университетның өченче курс студенты моны белми. Этан, пентан формулаларын да язарга өйрәтә алмады Әхим аны. Үзе бит оялмый да әле. Алай гынамы? Башкаларга өстән торып кына карый. Янәсе, менә ул кем, ул — партия әгъзасы!..

Әхимнең тырышлыгы аңа барыбер ярдәм итмәде. Ул химиядән нәрсә булса да аңларга сәләтле кеше түгел иде. Ниһаять, аны университеттан чыгардылар. Аңа карап югалып калмый тагын үзе. Аны бер авыл районына райком секретаре итеп җибәрәләр. Менә шул Пень...-ков 40-45 мең кешеле бөтен бер район белән җитәкчелек итәргә килә. Әй бәхетсез дә инде бу халык!..

***

Репрессияләр шаукымы университетны да читләтеп үтмәде. Бер үк көнне Үзбәкстанның Халык Комиссарлары Советы рәисе Фәйзулла Ходжаевны һәм Үзбәкстан Компартиясе Үзәк Комитетының беренче секретаре Аймаз Әкрәмовны кулга алдылар. Сәмәрканд университеты бу вакытта соңгысының исемен йөртә иде. Шуннан соң бер-бер артлы университетның ике ректоры кулга алынды. Укытучылар, галимнәр, кайбер студентлар бер-бер артлы эзсез югалды. Күбесе төнлә юкка чыкты... Теләсә кайсы төндә, теләсә кем юкка чыгарга мөмкин иде ул чакта...

Бу көннәрдә Әхим Ургут районында грамотасызлыкны бетерү кампаниясендә катнаша, призывникларны укырга-язарга өйрәтә иде. Биредә аны репрессия түгел, бизгәк авыруы эләктереп алды. Егетне район хастаханәсенә илттеләр. Анда авыру халык шыгрым тулы, күбесе бизгәктән интегә. Бу авыруны Әхим моңарчы белми иде, авырган кешене дә күргәне булмады. Яман да серле авыру булып чыкты ул. Өч атна хастаханәдә яткач, терелгән кебек булып, Сәмәркандка кайтты. Ә менә укулар башлангач, бу авыру бөтенләй башка ягы белән ачылды. Шулай лекция тыңлап утырганда Әхимне бөтен көченә калтырата башлады. Тышта эссе булса да, аңа суык, температурасы күтәрелде. Әхим тулай торакка кайтып, бүлмәдә нәрсә бар — һәммәсен дә өстенә өйде, түренде, ә барыбер җылына алмады. Ул бары тик кич белән генә тиргә батып, хәлсезләнеп урыныннан торды.

Икенче көнне бар да әйбәт, бер җир дә авыртмый. Әхим үз эшендә, лекция тыңлый... Ә бер көннән, нәкъ гадәттәге вакытта тагын калтырата башлады. Гел шулай кабатланып торды бу хәл. Тик 1938 елның җәендә генә котылды ул бизгәктән. Гомерлеккә котылды.

## Хәсрәт китергән хат

Барлык хәсрәтләрдән дә зуррагы килде. Әхим хат алды. Иң якын, иң кадерле кешесе — әтисе дөнья куйган иде. Наманган кабере Мөхәмммәткәрим Әхмәтҗан улының тормыш юлындагы соңгы тукталыш булды. Аңа әле 63 кенә яшь иде. Авыр еллар аның сәламәтлеген тәмам какшаткан иде. Михнәтләрне хәттин ашып күрмәсә, әле яшәр дә яшәр иде. Кем белә, бәлки, киләчәк михнәтләрне күрмәс өчен китеп баргандыр. Репрессияне... Коточкыч сугыш елларын... Ике улының, ике кияве һәм оныгының шул яуда ятып калуын... Сугыштан соңгы хәерчелекне... Боларны күрү аңа — инде кырык яра алган ата күңеленә — бәхет өстәмәс иде. Белеп, күңеле сизеп киткәндер. Урының оҗмахта булсын әткәем!

***

Ни дисәң дә, «әтием», «әнием» дип әйтер кешең булмагач, бигрәкләр дә авыр шул... Әхим әтисен соңгы юлга озатып килгәч, кая барып бәрелергә белми озак йөрде. Аннары ул урын таба алмыйча, ирексездән, тулай тораклагы озын залга үтте. Башка көннәрне бу вакытта шау-гөр килеп биергә өйрәнәләр иде. Ә бүген тынлык. Түгәрәк җитәкчеләре килгән, биергә өйрәнүчеләре дә... Тик рояльдә уйнаучы гына юк. Дәрес өзелү алдында.

Әхим әкрен генә рояль янына килеп утырды да, ул чагында бик популяр саналган танголы уйный башлады. Шулчак түгәрәк җитәкчесенең йөзе яктырып китте:

— Шулай, шулай, хөрмәтлем, дәвам итегез. Егетләр, әзерләнегез! Бер, ике, өч, дүрт... Бер, ике, өч, дүрт. Алга! Ике, өч, дүрт — унга! Ике, өч, дүрт... Егетем, сезнең менә дигән килеп чыга. Дәвам итегез! Игътибар! Башладык. Бер, ике, өч, дүрт!

Дәрестән соң түгәрәк житәкчесе Әхим янына килеп рәхмәт әйтте һәм киләсе шимбәдә дә шушы тирәдә булуын үтенде. Пианист килмәсә, алдагы атнада да Әхимгә уйнарга туры киләчәк иде.

Ул көнне түгәрәк дәресе беткәннән соң да Әхимне залдан чыгармадылар. Тагын да уйнавын сорадылар.

Танцы башланды. Ул озак дәвам итте. Егет, әле кичке ашны да ашамадым бит, дип качарга чамаласа да, файдасы булмады. Шунда ук аңа ике бутерброд белән бер стакан чәй китерделәр.

Әнә шул истәлекле көннән соң һәрчак рояльдә уйнавын сорый башладылар. Ә ул рәхәтләнеп, бирелеп уйный иде. Кайда гына булмасын, үзен барыбер эзләп табалар. Ул карышыбрак торса, егетләр аны күтәреп алалар да залга, рояль артына алып барып утырталар. Ә зал аны бердәм каршы ала: «Рәхмәт, Әхимчик!»

«Ничек чыга торгандыр бу кадәр көй?» — дип Әхим үзе дә кайчак аптырап куя иде, чөнки бер генә сәгать тә махсус музыкаль белем алган кеше түгел бит... Нәрсә ишетә — тиз генә отып алып шуны уйный... Әмма беркемнең дә аның кимчелеген күрсәткәне булмады. Ул уйный, болар бииләр. Менә шул.

Бер тын уйнаганнан соң аны, рояльдән бер төркем татар егетләре уратып алды:

— Әйдә, Әхим, татарчаны сыздырыйк!

Ул уйный, калганнары күтәреп алалар... Шулай бер-ике җыр җырлыйлар да тагын танцыга күчәләр. Барысы бии башлый. Барысы да канәгать.

Шулай ял итә-итә укый торгач, 1939 елның язы, чыгарылыш имтиханнары да якынлашты. Бу көннәрне Әхим күбрәк әрмән кызы Кнара Агапова белән бергә үткәрде. Инде өч ел буе дәресләрне бергә әзерли торгач, бер-берсенә ияләнеп тә беткәннәр иде алар. Кнара, чынлап та, егетләр күзе төшмәслек кыз түгел. Нык, сылу, шат күңелле кыз. Шул ук вакытта үзе житди дә, акыллы да, хезмәт сөючән дә. Бергә-бергә дәрес әзерләп үткән көннәр, билгеле, бушка узмый. Көн саен озаклап әзерләнсәләр дә, ятлау алар өчен ят нәрсә булды. Билгеле инде, күңелле итеп ял итүгә дә вакыт табыла иде.

Барлык дүрт имтиханны бу юлы да, гадәттәгечә, икесе дә бишкә генә бирделәр. Икесенә дә кызыл диплом тапшырылды. Әхимне университет китапханә белән бүләкләде, тик алырга гына насыйп булмады. Армиягә киткәндә аңа китапханә урынына акча бирделәр.

Уку белән мавыгып, университетны тәмамлагач нәрсә эшләргә, кая барырга, кая урнашырга икәнен уйлап та карамаганнар. Чыгарылыш кичәсендә диплом алып, тулай торакларга таралышканнан соң ул ничектер бушанып калды, нәрсә эшләргә, кая барырга да белмәде. Наманганга кайтыргамы? Кайтсаң да, анда нишлисең? Әтиләре үлгәч, Әсхәт укуын ташлап, әниләрен карарга дип әтисе йортына хуҗа булып кайтты. Хәер, кечкенә энеләре Фәиз белән Әдип тә инде шактый үсеп, ныгып киләләр иде.

Кайтыргамы, кайтмаскамы дип аптырап йөргәндә Әхимнең башына бер уй төште: «Бәлки, аспирантурага керергәдер?.. Моңа бит мин әзер диярлек, тагын бер кат кабатлап чыксам... Житмәсә, минем белгечлек буенча ике урын бар. Нәкъ вакыты! Өйләнергә әле иртәрәк. Белгәннәр истә чакта, онытылмас борын укырга, дәвам итәргә кирәк. Үзем дә тоям, галим булырга мөмкинлегем бар минем. Димәк, тәвәккәлләргә кирәк!»

Шундый уйлар белән ул тулай тораҡтан кафедрага таба атлады. Теләге булса да, эшне нидән башларга икәнен үзе дә белми иде әле. Шулчак аерылмас дусты Кнара очрады. Ул бирегә яши, Сәмарканд кызы. Балтасы

суга төшкән кеше шикелле, ул да Әхим кебек нәрсә эшләргә белмичә, кафедрага килгән иде.

— Әхим, карале, син хәзер нәрсә эшләргә уйлыйсың?

Егет башта иңнәрен җыерып кына куйды, аннары исә читләтеп кенә үзенең фикерен әйтте.

— Дөрес фикерлисең, Әхим. Мин дә — синең белән! Элеккечә, имтиханнарга бергәләп әзерләнербез. Безнең өй күне буе буш. Беркем дә булмый. Ике сеңлем дә лагерьда. Бездә әзерләнербез.

Шунысы да ачыкланды. Аспирантурадагы теге ике урынга инде теләүчеләр дә бар икән. Әхимнәр белән быел гына химфакны тәмамлаган Юлий Шваб белән Сара Рахлина.

— Аларга караганда безнең бер өстен ягыбыз бар: кызыл диплом! — диде Кнара Әхимне тынычландырып. — Артка чигенү юк!

Керү имтиханнарына бергәләп бер ай чамасы әзерләнгәч, эш туктап калды. Нәкъ шул вакыт Оборона халык комиссары К.Е. Ворошиловның приказы дөнья күрде. Анда аспирантурада укучыларга да армиягә алу срогын кичектерүнең бетерелүе хакында әйтелгән иде. Кемнең яше житкән, һәммәсе дә алыначак.

Шул көннән соң Әхим аспирантураны онытты. Үзенә генә күңелсез булды, күрәсең, Кнара да Әхим артыннан әзерләнүен ташлады. Шулай итеп, бу матур хыялларны тормышка ашыру насыйп булмады.

Июньдә кафедра бер ассистент урынына конкурс игълан итте. Әхим дә, Кнара да, тагын ике укытучы гариза яздылар. Июль ахырында бу урынга Әхимне алдылар.

Бу вазыйфа да теләгән кешегә фәнни карьераны үстереп җибәрү өчен мөмкинлек бирә. Иң мөһиме — ул кафедра коллективын, коллектив исә аны яхшы белә. Шуңа күрә Әхим яңа эшкә җиң сызганып тотынды, кафедраны яңа уку елына әзерләүдә кулыннан килгәннен барын да эшләде. Кнара да ерак китмәде — финанс-икътисад институтына ассистент булып урнашты.

Менә яңа уку елы да башланды. Әхимнең житәкчесе итеп профессор Штакельберг билгеләнде. Эшләр шулай җайланып кына киткәч, егетләрне армиягә ала башладылар. Әхим дә читтә калмады. Аны, комиссия үткәннән соң, Саратов өлкәсендәге Аткарск шәһәрендә урнашкан полкка җибәрделәр. Бик тә читен булды Әхимгә иң яхшы еллары үткән кафедра белән хушлашуы. Фән белән шөгыльләнү, галим булу кебек хыяллар барысы да челпәрәмә килде. Ә бит химиядә ул судагы балык кебек йөзә иде. Эх, озакка аерылырга туры килер, ахры. Гомерлеккә булмаса... Әнә, сугыш ил чикләренә якынайганнан-якыная. Сентябрьдә фашистлар Польшага бәреп керделәр һәм аны тиз арада, каршылыксыз диярлек тар-мар да иттеләр. СССР империясе дә читтә калмады: Литва, Латвия, Эстония, Бессарабияне басып алды. Көнбатыш Белоруссия һәм Көнбатыш Украина исәбенә ил чикләре шактый киңәйде.

## Сабакташлар — полкташлар

Полкка Сәмәркандтан барысы 25 егет килде. Үзбәк, таҗик, татар һәм урыслар, Алма-Атадан тагын унлап казакъ кушылды. Барысы да югары белемле. Нигә болай? Нигә барысы да югары белемле? Баксаң, репрессия елларыннан соң бөтен Урта Азия хәрби округында нибары бер югары белемле офицер калган да, максат — менә шул кытлыкны бетерү икән. Егетләрнең барысын да, сарык бәрәннәре сыман, полк мәктәбенә китереп куштылар. Берничә айдан Әхимнәр кече командир булып чыгарга тиеш иделәр.

Бу көннәрдә бер чиктән икенче чиккә ташлану ил күләмендә генә түгел, Кызыл Армиядә дә чагыла иде. Нәкъ шул чакта «матур киләчәк» өчен корбаннарның күпме булачагы исәпкә алынмый башлады. Кеше, солдат хокуклары икенче планга күчте. Моңарчы урамда 15 градустан салкынрак булса, курсантлар өйрәнүләрне бинада үткәрәләр иде. Ә хәзер рөхсәт юк. Тышта 46 градус суык, алар урамда... Карасаң, яңа закон чыккан икән: «Теләсә нинди шартларда да солдат бары тик урамда гына булырга тиеш».

Взвод командиры боларны елгадагы боз өстенә чыгарып бастыра да, үзе жылы урынга тая. Мескен егетләр исә иске чолгау гына урап кигән аяклары туңуга чыдый алмыйлар. Кайберләре бармаксыз кала. Мондый чакта нинди өйрәнү ди ул! Йөгерәләр, сикерәләр. Сикерергә хәле беткәне туктап кала да кайсы да булса бер жирен туңдыра...

Монысыннан да битәр көньяк егетләрен урысларның сөйләнүләре ярсытты. Болай карап торышка нормаль кеше ничек итеп үзенең сөйләмен иң кабахәт сүзләрдән генә оештырырга мөмкин?! Ничек итеп ул үз телен шулкадәр гарипләндереп, үзе шуннан канәгатьлек таба ала? Кеше түгелләр болар, кеше кыяфәтенә кергән азгын пәриләрдер!..

Урыс солдатларының сүгенүе бигрәк тә таҗик малайларын ярсытты. Беркөнне шулай таҗик егете Хәмит бәдрәфкә ялгызы гына китте. Аны анда икәү каршы алды:

— Әй, черномазый, пычагың бармы?

— Пычак йөртмим, — диде Хәмит тыныч кына һәм эчкә үтмәкче булды.

Шунда тегеләрнең берсе:

— Әгәр тапсак... беләсеңме нәрсә булырын? Е... мое... твое... — дип, егетнең анасын хурлап сүгенеп тә ташлады.

Хәмит кып-кызыл булды, муен тамырлары бүртте, күзенә кан йөгерде:

— Синме? Минем әнинеме?! Өрәк син, белдеңме!..

Урыслар күп бит алар, әллә каян тагын ике урыс солдаты килеп чыкты. Берсе:

— Возникаешь, да, мать твою!.. — дип, таҗикның чигәсенә китереп тә сукты. Хәмит пычрак бәдрәф идәненә егылды. Сугыш чукмарларының әле аның белән генә тынычлануда түгел иде исәпләре. Бичара егетне алмаш-тилмәш типкәләргә керештеләр. Шулвакыт үзенең ике иптәше белән Әхим килеп чыкмаса, эш нәрсә белән беткән булыр иде, билгесез...

— Нәрсә инде бу, егетләр?! — диде Әхим, — нигә аны болай кыйныйсыз? Капка төбендә чын сугыш сагалаганын абайлыйсызмы? Анда бергә керергә туры килер бит.

— Акыл сатма, «профессор»! — диде урыс солдатларының берсе, — безгә каршы торыр көч юк! Кирәк икән, изәбез, кирәк икән, ишәбез!..

Менә шушы бозык жаннар белән нишләмәк кирәк? Берәү, икәү генә түгел бит алар. Сиңа бер генә юл кала: кабахәт сүгенсә дә түзәргә, кул күтәрсә дә түзәргә. Шулай түзә-түзә арыслан кебек ажгырып торган көньяк егетләре сыгылып төште. Шулай итеп алар читкә кагылган, битараф, бернәрсәгә дә сәләтсез жан иясенә әвереләләр. Алардан начар, ә күп вакыт бер эшкә ярамаслык солдат формалаша. Ә бит алардан менә дигән кешеләр чыгар иде.

1940 елда жәйге хәрби лагерьда килеп чыкты бу хәл. Полк түрәләрен көньяк егетләре тирәсендәге төрле жәнжаллар туйдырды булса кирәк, аларның барын да бер взводка тупларга булдылар. Взводта үзбәк, таҗик, казакъ, азәрбайжан, әрмән һәм ике төрек егете дә бар иде. Әхимне взвод командирының ярдәмчесе итеп билгеләделәр. Гадәттәгечә, лейтенант взвод

белән житәкчелек итүне Әхимгә тапшыра да, үзе көн дә каядыр китеп югала торган булды. Кыскасы, взвод белән, нигездә, Әхим командалык итте бу көннәрдә. Ике-өч ай эчендә взвод ныгыды, башка подразделениеләрнең берсе алдында да сынатмый башлады. Моңарчы мораль яктан кимсетелгән, психикасы таушалган, өметләрен югалткан солдатлар, ниһаять, үзләрен кеше итеп сизә башладылар. Күңелләре күтәрелде.

Сәбәбе ни-нәрсәдә иде соң моның? Иң мөһиме — сүгенүне, бигрәк тә үзенә буйсынган бүлек командирларының кемгә дә булса сүгенү сүзе белән эндәшүен тыйды ул. Тагын бер сәбәбе — Әхим русча начар белүчеләрнең һәркайсына ана телләрендә эндәште, аңлатты, киңәште.

Әхимне ничек хөрмәт иткәннәрен белсәгез иде сез! Егетләр Әхим өчен утка да, суга да керергә әзерләр иде.

Әмма бу тәҗрибәнең бер теллелеккә омтылган урыс армиясендә һичкемгә дә кирәге юк иде. Киресенчә, шундый бердәм взводны, ниһаять, таркаттылар. Андагы солдатларны тагын төрле взводларга тараттылар.

Инде Әхимнең солдат срогын тутырып кайтыр вакыты да җиткән иде. Ничек кенә әйтсәң дә, армиядә хезмәт итү— ботка ашау түгел. Кайтыр көнен зарыгып көтте Әхим. Тик кайтырга насыйп булмады. Сугыш башланды.

***

Алар полкын да озакламый сугышка җибәрделәр. Полк Смоленск янындагы бәрелешләрдә катнашып, бер атна дигәндә тулысынча тар-мар ителде. Әхимне исә Пугачевскидагы запас полкта калдырганнар иде. Алар мобилизацияләнгән сугышчылардан янадан-яңа роталар формалаштырып, фронтка — хәрәкәттәге частьларга озата тордылар. Тиздән Әхимне хәрби училищега укырга җибәрделәр.

Биредә укыганда Әхим фронтны да күрә алмыйча, чак кына җан тәслим кылмады. Ул көннәрдә немецлар туктаусыз химик сугыш башлау белән куркытып тордылар. Шуңамы, училищеда да химик хәзерлек үтүгә нык әһәмият бирелә иде. Беркөнне шулай...

Әхимнәр ротасы иприт белән зарарланган участоктан үтәргә тиеш була. Әмма майор Яценко онытылып аңлата-аңлата солдатларны зарарланган линия каршында озак тота. Югыйсә, «сарымсак» исе борыннарны бәреп кераә, ә ул һаман кузгалырга исәпләми.

Сонарып булса да участокны үтә солдатлар, душ кабул итеп, йокларга яталар. Ә иртән торсалар, коточкыч хәл. Иприт парлары үз эшен эшләгән: берсе дә күзен ача алмый, ис кистерә генә, берсенең дә тавышы чыкмый, бугазлары зарарланган һәм барысы да негр кебек кап-кара булган — тире зарарланган. Солдатларны шуннан соң айдан артык дәваларга туры килде.

Уку вакытында Әхим взвод комадиры ярдәмчесе булды: башта кече лейтенант, аннан — лейтенант. Укулар тәмамлангач та, аңа взвод тапшырдылар һәм училищеда калырга тәкъдим иттеләр.

— Икенче ел сугыш бара, ә минем әле бер тапкыр да атып караганым юк, — диде Әхим. — Фронтка җибәрегез мине!

— Ул Сталинград фронтына эләкте.

## Сталинград фронтында

Сталинградка ул 1942 елның 18 августында килеп җитте. Шәһәр әле тыныч, йортлар төзек, җимерелгән урамнар күренми иде. Нәкъ өч көннән соң аны дүрт көн буе бомбага тоттылар. Аннары штурм башланды. Кала

күз алдында ишелә, җимерелә барды. Күрәсең, аны немецлар җир белән тигезләргә исәплиләр иде.

Әхимне штабта калдырдылар. Штаб Иделнең икенче ягында урнашкан. Менә шул штабтан Әхим оборонадагы частьларга боерык һәм пакетлар ташыды. Аннары аны паром командиры итеп билгеләделәр. Себер, Урал, Урта Азия, Идел буйларыннан җыелган яңа сугышчыларны ул уң як ярга, ә коточкыч сугышта яраланып исән калганнарны сул як ярга күчерә торды. Дөресен әйткәндә, тәмуг иде монда. Шәһәргә туктаусыз немец самолетлары һөҗүм итә. Идел өстен дә алар контрольдә тота. Кыскасы, күктә алар хуҗа. Паромнарны көненә берничә мәртәбә бомбага тоталар. Дүртенче көнне ярга якынлашып килгәндә генә бомба Әхимнең паромына да эләкте һәм ботарлап ташлады. Әхим аңын югалтып, суда бата башлады. Шул чакта аны бер солдат эләктереп алды да яр буена чыгарып куйды. Әхим аңына килгәндә, яр буенда инде беркем дә юк иде. Күпмесе баткан, күпмесе үлгән, күпмесе калган — ул хакта бернәрсә дә белә алмады һәм штабка юл тотты.

Шунысы аяныч, Әхимгә Үзбәкстаннан килгән егетләрне дә күчерергә насыйп булмады. Чөнки бомбага эләгеп, эшелон җимерелгәч, күп солдатлар һәлак була. Шуңа күрә исән калганнары берничә көнгә соңарып килә. Бу хәбәрне ишеткәч, Әхим якташлары янына ашыкты. Танышларны күрмәмме дип, барысын барлап чыкты. Менә таныш күзләр. Бәй, бу бит Наманганнан ерак түгел колхозда эшләгән хисапчы түгелме соң? Әйе, шул үзе...

— Исәнме, якташ! — дип, Әхим егеткә кул бирде. — Алла юк дип әйтеп кара син... Кайларда очрашырга язган бит, ә!..

Егет куанырга ашыкмады, аның күзләре моңлы иде.

— Әй, туган, — диде ул, — эшелонны бомбага тоткан чагында өч юлдашым һәлак булды. Синең абыең да...

— Әсхәтме? — диде Әхим, хисапчы егетне кочаклап. — Минем күп сөйләшми торган абыеммы?!

— Шул... Әле бомбага тотар алдыннан гына: «Очрашасы иде Әхим белән. Сталинград янында сугыша бит ул», — дигән иде. Менә миңа очрашу насыйп булды, ә аңа — юк! Ходай шулай язгандыр, күрәсең...

Күптән елаганы юк иде Әхимнең, күзләреннән яшь бәреп чыкты һәм ул якташын тагын да кысыбрак кочаклады.

— Тагын нәрсә, сөйлә, — диде ул. — Өйдәгеләр ничек яши икән?

— Өйдәгеләр ярыйсы. Менә Әсхәтнең хатыны гына нишләр? Шушы көннәрдә улымы, кызымы туарга тиеш. Әсхәтне әйтәм, кеме туганын да белә алмыйча китеп барды менә, мәрхүм. Урыны оҗмахта булсын инде, ни хәл итәсең бит. Күпме михнәтләр күрә-күрә яшәп, гомере шушы чит җирләр өчен өзелер дип башына да китермәгәндер...

— Акрын... — диде Әхим, — шымчылар хәзер дуслардан күбрәк. Аннары бит Әсхәт белән минем туган ягым Татарстанга, Казанга да күп калмый. Дөрес, Гитлер татарларга аерым дәүләт төзергә рөхсәт бирмәкче, ди. Тик, мин фашистларга ышанмыйм. Үз-үзебезне якламасак, татарны яклаучы табылырмы? Ярый, туган, тирәнгә кердек, ахры... Боларны тыныч елларга калдырыйк. Иң мөһиме — исән булыйк. Сау бул, туган!

— Хуш, Әхим! Җиңеп кайткач, очрашырбыз, Алла боерса!

***

Сталинград бәрелеше тәмамланганнан соң Әхимне К.Рокоссовский командалыгындагы Икенче танк армиясе составындагы 107нче танк бригадасына җибәрделәр. Ул чакта армия белән генерал-лейтенант Богданов, бригада белән полковник Теляков җитәкчелек итә, ә аның составындагы автоматчылар ротасы командиры Морозов иде.

...Дөньяга мәгълүм «Курск дугасы» бәрелешенең икенче көнендә 107нче танк бригадасын, немецлар атакасын кире кайтару максатында, Поныри авылы янына кертәләр. Бу — немецларның төп удар бирү юнәлешенә урнашкан. Бригада составында — өч танк һәм бер автоматчылар батальоны, артеллеристлар, саперлар...

Биредә совет танклары беренче мәртәбә «тигр»лар белән очраша. Тигезсез көрәш! Батальонның алтмыштан артык танкы сафтан чыга. Төнлә җыелу пунктына нибары өч танк, яндырылган Т-34 танкларының кайбер исән калган әгъзалары гына җыелып кайта. Исән калганнарга резервтан 20 танк өстәлә һәм бригада оборона тотуын дәвам итә. Бу участоктан немецлар, ничек кенә көчәнсәләр дә, үтә алмыйлар. Киресенчә, нәкъ унике көннән соң бригада дошманның үз тылына кимереп керә башлый. Соңгы бәрелеш барган төндә Әхим яралана, госпитальгә эләгә.

Нәкъ шушы вакытта Икенче танк армиясен тылга күчерәләр һәм ул кышка кадәр анда яраларын дәвалый, сафларын тулыландыра, ремонт эшләре башкара.

Дәваланганнан соң Әхим үзенең бригадасына әйләнеп кайта. Озакламый Икенче танк армиясе Киев янындагы Икенче Украина фронтына күчерелә. Нәкъ шул көннәрдә биредә коточкыч каты сугышлар башланып китә. Совет гаскәрләре Корсунь-Шевченко районында фашистларның йөз меңнән артык солдаты булган зур бер группасын чолгап алалар. Чолганышта калган группа никадәр генә ычкынырга талпынып караса да, булдыра алмый. Тиздән Гитлер аларны коткару максатында бирегә алты танк дивизиясен, шул исәптәп ике өр-яңа дивизияне җибәрә.

Көрәш искиткеч каты була. Өстәвенә, һава шартлары начар — карлы-бозлы су үзәкләргә үтә. Төне буе окопларда тездән карлы суда утыралар. Өскә юеш кар ява. Иртәнгә инде аяклар каткан, бөгелми дә, тураймый да. Таң аткач, тагын һөҗүм. Аннан контрһөҗүм. Төн тагын сулы окопта үтә...

***

Өченче көнне Әхимнәрнең автоматчылар батальоны якындагы Рядово авылына һөҗүм итте. Шул авылга оялаган немецлар өчен бу көтелмәгән хәл иде. Алар кинәт булган һөҗүмнән югалып калдылар, хәтта үлгән солдатларын гына түгел, ә төзек танк, һәм орудиеләрен дә калдырып качтылар.

Кич белән исә немецлар күпсанлы танклар ярдәмендә батальонны Татьяновка авылы янында чолгап алдылар.

Әхимнәрнең нибары өч танкы гына калган иде. Бригада командиры яралыларны танкларга төяргә һәм төн уртасы җиткәч, немец танклары арасыннан зур тизлектә чыгып китәргә боерды. Ә автоматчылар батальоны караңгылыктан файдаланып, тавыш-тынсыз гына икенче яктагы немец танклары арасыннан үтәргә тиеш... Әхим белән татар егете Зөфәров командирдан өч йөз метр чамасы алданрак баралар. Болар немец танкы янына килеп җиткәч, калганнар ятты. Фашистлар пулеметтан ата, яктырткыч ракеталар чөя башладылар. Бераздан барысы да тынып калды. Күрәсең, урыс солдатларын күрмәделәр алар. Шулай итеп, уйланган маневр уңышлы килеп чыкты. Юкса, шулкадәр көч батальонны җир белән тигезләргә мөмкин иде.

Ә болай батальон чолганыштан тулысынча исән-имин чыкты. Дөрес, бер Кривоногов фамилияле солдат югалган иде. Ул ике көннән соң гына батальонга үзе кайтты.

— Кайда булдың? — дип сорады аннан Әхим.

— Авылда, Татьяновкада.
— Ничек? Анда немецлар бит...
— Шул-шул! Башта немецлар иканен белмәдем. Базда уянып китсәм, өй эчендә немецча сөйләшкән тавышлар ишетелә. Беттем, мин әйтәм...
— Ничек безгә эләктең соң син? Нигә аерылып калдың? Командирның боерыгы сиңа нәрсә?
— Мин берни дә ишетмәдем. Авылны алгач, бер йортның базына төшкән идем. Анда шундый тәмле, куе каймак таптым. Туйганчы ашадым. Шуннан үзем дә сизмәстән йоклап киткәнмен. Күпме йоклаганмындыр, хәтерләмим. Мин уянганда, бүлмәдә немецча сөйләшәләр иде.
— Шуннан нишләдең?
— Нишлим, бер батальон немец белән берүзем сугыша алмыйм бит инде. Төн җиткәнне көтеп базда утырдым. Төн җитеп, тегеләр гырлаша башлагач, баздан чыктым да тайдым. Менә хәзер сезнең янда.

Бер тамагына хуҗа булмаган өчен командир үзен тиешенчә «пешермәкче» иде дә, тапкырлыгын күреп, кичерде.

Фашист танклары чолганышта калган группаны коткарырга омтылды. Максатка житәргә бары ике чакрым гына калган иде, ләкин ахырынача үтә алмадылар. Әхимнәр нык торды. Тиздән чолганыштагы немец группасы тулысынча юк ителде. Әһәмияте ягыннан бу бәрелешне соныннан «икенче Сталинград» дип йөрттеләр. Көрәш совет солдатлары өчен дә кыйммәткә төште: күпләр сугыш кырында ятып калды, исән калганнарның исә гомер буе аяк-куллары, буыннары сызлаудан җәфа чикте.

Әле ул чакта солдат буыннары сызлаудан зарланмый иде. Алар һаман немецларны үз өннәренә таба куууны дәвам иттеләр.

...1944 елның марты иде. Иртәнге көчле артиллерия хәзерлегеннән соң һөҗүм башланды. Бу һөҗүмгә өстән карасаң, ул өерманә хәтерләтә иде. Туктаусыз көнбатышка таба баралар да баралар. Немецлар һаман ушларын җыя алмый качалар да качалар. Күпләп-күпләп юлда техникаларын калдырып китәләр. Көндез Әхимнәр батальоны немецлар кулындагы авылга керде. Немецларның биредәге группасына оборона тотарга, бер генә урыс солдатын да үткәрмәскә боерылган икән. Тик, инде шактый бәрелешләрдә катнашып, коты алынган немец солдаты нык каршылык күрсәтергә сәләтле түгел иде. Шуңа күрә беренче бәрелештән соң ук качу ягын гына карадылар.

Батальондагы, Әхим белән теге көнне чолганыштан бергә чыккан татар егете Зөфәров, бу юлы шунда ук ике фашист солдатын юк итте. Өченчесе артыннан йөгерде. Тегесе, ярым шәрә килеш, бакыр баш, бер тавыкны эләктергән дә урам буйлап чаба гына бит. Үч иткәндәй, Зөфәровның автоматы буш иде, патроннары беткән. Әмма ул йөгерүдән туктамады. Куып житеп приклад белән сугып екты да, немецны әсир итеп алды. Бу батырлыгын һәм башка батырлыкларын да исәпкә алып, аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелде.

Шуннан соң бу җиңүле һөҗүм айдан артык дәвам итте. Днепрны кичеп, Молдавияне, Днестр, Прут елгаларын кичеп, Румыниянең бер өлешен азат иттеләр. Биредә табигатьнең бик матур чагы иде, бакчалар ап-ак чәчәккә күмелгән...

Әмма шуннан соң Икенче танк армиясен биредән алып, Жуков житәкчелегендәге Беренче Белоруссия фронтына күчерделәр. Бернечә көннән Әхимнәр батальоны Көнбатыш Украинадагы Ковель шәһәре янына урнашты. Озакламый биредә дә зур һөҗүм башланды. Люблин шәһәрен немецлардан азат иттеләр. Халык җиңүчеләрне шатланып каршы алды. Кемдер соклануын белдерде, кемдер шатлыктан елады, кемдер чәчәкләр

китерде, кемдер кин елмайды, кемдер солдатның кулын кысты, кемдер сигарет суздыᅟ... — болар барысы да фашист коллыгыннан котылган халыкның җиңүчеләргә җылы мөнәсәбәте иде.

***

Батальон алга атлады. Старшина солдатларны Люблинда кулга төшерелгән сыра белән сыйлый башлады. Көн эссе иде, эчәсе килә. Әмма сыра Әхимгә нәрсәсе беләндер ошамады, беразын эчкәч, ул сыраны түкте. Шуннан соң ул ике көн буе үзенә урын таба алмый йөрде. Ярый әле, шуның белән котылды. Сыраны күбрәк эчкән солдатлар кайсы сукырайды, ә кайсылары якты дөнья белән хушлашты. Тикшереп карагач, сырага агач (метил) спирты кушылганлыгы ачыкланды. Метил спиртының да исе, тәме шундый ук, ул да исертә. Әмма шул исерүдән айнуың гына икеле.

Инде солдатны туктатыр көч юк иде Уңышлы җиңүләр белән Әхим батальоны да Варшавага килеп җитте. Фронт сызыгы шунда 1945 елның башына кадәр тукталып торды. Әхим исә шул ара озак кына пан Ковацкий гаиләсендә яшәде. Өлкән буын поляклар, ягъни Польша Рәсәй империясе составында чакта ук яшәгән поляклар иске гадәт буенча азрак русча сукалыйлар иде. Ә аларның балалары Хелена, Владик һәм аларның дуслары Кинга өчен бу тел ят иде. Шуңа күрә Әхим башта алар белән аралаша алмый азапланды. Әмма акрынлап бер-берсен төшенә бардылар, хәтта сәяси бәхәсләргә дә кереп китә башладылар. Әхим ел ахырына инде полякча яхшы аңлый һәм сөйләшә башлаган иде.

Әхимне монда барыннан да бигрәк бер нәрсә кызыксындырды: ни өчен поляклар урысларны яратып бетермиләр? Ә бит үзләре минем белән әнә ничек яхшы мөгамәләдә, тыйнаклар. Болар да СССРның Көньяк халыклары кебек урысның үзен түгел, ә аның сөйләшүен, кыланышын, сүгенгәнен, тупаслыгын, бигрәк тә сөйләшкән вакытта кабахәт сүзләр белән сүгенүен яратмыйлар икән. Полякларны гына түгел, бу хәл Әхимнең үзен дә ярсыта иде. Шуна күрә ул егетләрчә поляклар белән уртак тел тапты, хәтта бер-берләрен яраталар да иде. Нәтиҗәсе шул: тегеләр бөтенләй ачылып китте.

— Без — полякларның — ике төп дошманы бар — урыслар һәм немецлар — диде Хелена беркөнне.

Ышанмый да мөмкин түгел, чөнки бала кеше күпчелек очракта дөресен сөйли.

***

Сугышның соңгы, йомгаклау этабы якынлашып килә иде инде. Әхимнәрнең 68нче танк полкы генерал Катуков җитәкчелегендәге беренче гвардия танк армиясе составында, ә Армия үзе маршал Жуков җитәкләгән Беренче Белоруссия фронты составында хәрәкәт итте.

Һөҗүм Варшавадан көньяктарак гыйнварның урталарында башланды. Тиздән Лодзь һәм Познань шәһәрләре азат ителде. Февральдә Одерны кичеп Франкфуртны алдылар. 16 апрельдә Одердан Берлинга куәтле һөҗүм башланды. Икенче майда дошман каршылык күрсәтүне туктаткач, Әхимне Рейхстаг районыннан Целиндорф шәһәре янына күчерделәр һәм алар бүтән сугышта катнашмадылар. Вак группировкаларны тынычландыру пехотага тапшырылды.

Сугыш тәмамлангач, күпчелек частьларны СССР территориясенә чыгару башланды. Ә менә Әхимнәрнең Беренче гвардия танк армиясе оккупацион гаскәрләр составында Германиядә калдырылды. Монысы инде Әхимне пошаманга салды. Аның инде бер генә көн дә хезмәт итәсе

килми иде. Шуңа күрә төрле инстанцияләргә демобилизацияләүне сорап рапортлар язарга керешге. Тик аны 1947 елның февралендә генә хезмәттән азат иттеләр.

***

Менә ул, ниһаять, иректә! Кая кайтырга? Үги әнисе янына Хакулабадкамы? Кайтыр иде, үги әнисен якын итте ул, хәтта сугыштан посылкаларны да ай саен диярлек җибәреп торды. Әнисе дә Әхимне бик якын күрә иде. Тик, анда кайтсаң, кайда яшәрсең? Улы Әдип белән үзләре дә балчык йортның кечкенә бер бүлмәсендә яшиләр бит. Әллә Казанга кайтыргамы? Их, берәр танышың булса, шунда кайтыр идең дә... Йөрәккә аннан да якынрак кала юктыр... Уйлый торгач, Мәдинә апасы янына кайтырга булды — Уфага. Авылдан киткән елны биредә бераз яшәп караган иде. Кирза ботинкалардан Мәдинә апасы йортына килеп кергәне әле дә исендә... Бу юлы да Мәдинә энесенең кайтуына куанып бетә алмады. Улы Наил сугыш беткәч тә кайткан була. Шунда алар өчәүләп яши башлыйлар.

Тиздән Әхим Уфада әле генә оешып килгән нефть фәнни-тикшеренү институтына эшкә урнашты. Хезмәт хакы «ташка үлчим» генә булса да, урнашты, химиясен сагынган иде шул егет. Аннары фәнни эшне дәвам итәргә дә биредә уңайлырак булачак, дип уйлады ул. Дөрес, соңгы вакытларда ул фәнни карьера турында уйламый да башлаган иде инде. Ни дисәң дә, утызда бит инде ул. Гомеренең иң дәртле, иң куәтле елларын сугыш кырында үткәрде, сугыш беткәч тә әнә ничә ел хезмәт итәргә туры килде. Әйдә, соң булса да уң булсын. Әнә Башкортстанда нефть чыгару, аны эшкәртү промышленносте ничек алга ыргылды! Шулай булгач, монда артык булмаячак ул...

## Саумы, Ленинград!

Ул көткән көн тагын өч айдан гына килде. Әхимгә Ленинградка аспирантурага барырга тәкъдим иттеләр. Геология, нефть һәм газ чыгару институтына иде бу чакыру. Көтүен дә көтте, теләге дә зур, тик менә геологиядән керү имтиханын ничек бирергә? Химия, тарих — алары проблема түгел. Ә монысы... Беркайчан да укыганы да, күргәне дә булмады аның. Нишләргә? Бу бит соңгы шанс булырга мөмкин. Ни әйтсәң дә, яшь бара. Бөтен көчен, бөтен энергиясен менә шуңа — геология фәнен өйрәнүгә багышлады ул. Көзгә кадәр әле шактый вакыт бар иде.

Берничә айдан исә Әхим геологияне су кебек эчә иде инде. Шулай итеп, яраткан химиясе янына геология дә килеп кушылды.

Әйе, тырышлык беркайчан да югалмый: Ленинградта ул керү имтиханнарын уңышлы тапшырды һәм ике айдан соң Мәскәүдән хәбәр дә килде, аны аспирантурага кабул итү карарын раслаганнар иде. Җитәкчесе дә билгеләнде. Ул нефть геохимиясе өлкәсендә иң кодрәтле галимнәрнең берсе Александр Добрянский иде. Нәкъ шул вакытта аның калын монографиясе дөнья күреп, тиз арада таралып та беткән иде. Бу китап Советлар илендә генә түгел, ә күп кенә башка ил галимнәренең дә өстәл китабына әверелде.

Әхимне нефть лабораториясенә беркеттеләр. Лаборатория мөдире Иван Иванович Богомолов гаять тә юан, кыска буйлы һәм бик тә тиз кызып китә торган булса да, ярыйсы кеше иде. Дөрес, Әхимгә аның хезмәткәрләренә туктаусыз бәйләнүе, артык төпченүе ошап бетми иде бетүен. Әмма торабара моның да серенә төшенде ул. Ә фәнни җитәкчесе, киресенчә, озын буйлы, чандыр, бик тә тыныч 62 яшьлек зат иде. Аның шундый холыклы булуы энергиягә экономия ясарга — берничә урында эшләргә мөмкинлек

бирә иде. Бер үк вакытта ул Ленинградның политехника институтында һәм университетта кафедра мөдире иде, аннары Эстония Фәннәр Академиясендә һәм Әхим укый торган Бөтендөнья геология, нефть һәм газ чыганакларын эзләү институтында консультант та иде. Үзе әйтмешли, Әхим аның унҗиденче аспиранты янында атнага бер тапкыр, анда да берничә сәгать кенә булып китә иде ул. Шулай да ул аннан канәгать иде. Алай гына да түгел, ул үзенең җитәкчесе белән горурлана да иде. Дикциясе дә булса, алыштыргысыз кеше. Чынлап та, Әхим аны башта аңлый алмыйча интекте. Хәтта, ияләшеп җиткәч тә, барысын да аңлау өчен профессорны бик тә бирелеп, игътибар белән тыңларга кирәк иде.

Институт Васильево утравындагы зур чиркәү бинасына урнашкан иде ул вакытта. Бигрәк тә Баулыда девон, Ромашкинода уникаль нефть чыганакларын үзләштерүдә роле зур булды бу институтның. Кыска гына вакыт эчендә СССР империясендә еллык нефть чыгару егерме тапкыр артып, 500-600 млн. тоннага, ә газ 600 млрд. кубометрга җитте. Бу чорда халыкның мәгълүм бер дәрәҗәдә яши алуы әнә шуның белән аңлатыла. Дөрес, бу үз чиратында яңадан-яңа нефть, газ чыганакларын һәм ятмаларын ачу һәм аларны үзләштерүне таләп итеп торды. Моңа исә генезис проблемасын дөрес хәл иткәндә генә ирешү мөмкин иде. Геохимия бүлеге, институтның күпчелек галимнәре үзләренең фәнни эшләрен, нигездә, шул проблеманы хәл итүгә юнәлтте. Әхимгә дә өлеш чыкты. Аңа «Икенче Баку» нефтенең ароматлы углеродлары» дигән теманы тәкъдим иттеләр. Шул көннән ул лаборатор-эксперименталь тикшерү эшенә чумды. Бигрәк тә күп уку, галимнәрнең элекке елларда яклаган диссертацияләре белән тирәнтен танышу, Гыйльми совет утырышларында йотылып тыңлау, күпьеллык отчетлар белән танышу галимнең фикерләү колачын киңәйтте, эзләнүләрне тизрәк һәм нәтиҗәлерәк алып бару мөмкинлеге тудырды. Болар исә Әхимгә нефть ятмаларының җирдә урнашу закончалыкларын гына үзләштереп калмыйча, геологик ятмаларның яшенә, нинди тирәнлектә ятуына, температурага карап төзелешен, аларның составын белергә, бигрәк тә бу ятмаларның җир тарихында ничек формалашуын ачыкларга ярдәм итте. Шулай итеп, үзенең дә язган отчетлары, мәкалә һәм брошюралары артканнан-арта барды.

***

Әхим, аспирант булу белән беррәттән, фәнни хезмәткәр эшен дә алып бара башлады. Бу эшне аңа лаборатория мөдире Богомолов тәкъдим итте. Шулай итеп, Әхимгә якты көнне күрмичә эшләргә мөмкинлек туды. Иртәнге сәгать 9дан кичке 10га кадәр лабораториядә эзләнүләр, тәҗрибәләр... Унөчәр сәгать эшләп лабораториядән чыкканда ниндидер җинелчә арыганлык сизелә. Кичке урам буйлап 4-5 чакрым юл үтә дә, берочтан бер кап пилмән эләктереп өенә керә. Ярты кило пилмән, уйлап карасаң, аспирант өчен начар түгел. Тамак ялгап алгач, тагын сугыш һәм сугыштан соңгы елларда югалткан кадерле вакытларын кире кайтармак булып эшкә чума...

— Күп эшлисез бит. Ничек вакытыгыз җитә? — дип кызыксынды шулай беркөнне лабораториядә эшләүче кызлар.

— Ялгыш уйлый күрмәгез, — диде Әхим. — Мин фанатик түгел. Аллам сакласын! Үземне бернәрсәдән дә мәхрүм итмим. Тик, фәнгә вакытны күбрәк бирәм. Шул гына.

Коллективта лаборатория мөдиреннән кала, барысы да хатын-кызлар иде. Билгеле, Әхим аларны кызыксындыра. Хәтта, җинелчә генә иркәләп тә җибәрәләр иде үзен Ленинград кызлары. Ни әйтсәң дә, алар арасында ул берүзе генә иде шул.

Ә менә мөдир белән хезмәткәрләр арасында хәл бөтенләй котелмәгәнчә, хәтта оригиналь була. Иван Иванович һәркөнне эшкә бик тә хөрти кәеф белән килә һәм лаборатория хатын-кызларының кайсына булса да бәйләнмичә калмый.

— Ник бу эшләнмәгән?

— Нигә болай киенеп килдең?

— Мин сезгә нәрсә әйттем?! Маймылны да өйрәтеп була, ә сез?..

Җәнҗал шулай үсә, куера бара. Үзе бәйләнгән кызның күзләреннән яшь ага башлагач кына ул лабораториядән тая, өске каттагы кабинетына кереп бикләнә һәм лабораториядә төшкә кадәр күренми. Ә төштән соң пешкән помидор кебек елмая, иркенләп сөйләшә, күнеле шат. Алыштырып куйганнар диярсең үзен.

Бу метаморфозаны хатын-кызлар бик гади аңлаталар. Димәк, Иван Иванович бик әйбәтләп, тәмләп төшке аш ашаган. Шулай ук һәр иртәне төшенке күңел белән усалланып килүе дә кызларга сер түгел иде.

— Иван Ивановичның хатыны ифрат та чибәр. Өйгә акча алган көнне генә кайта, — диделәр кызлар Әхимгә, — ә калган вакытын дингезчеләр белән үткәрә, бу калада бит аларның исәбе юк.

Чынлап та, получка алган көнне Әхим бу ханымның кассага чиратта торганын күрде. Ведомостька Иван Иванович кул куйды, ә акчаны хатыны алды. Акчаны алгач, почмакка барып санады да, шул минутта ук юк булды. Иван Иванович исә бер сүз дә дәшмәде, шулай да борчулы кыяфәт йөзенә чыккан иде.

Икенче көнне Иван Ивановичның кәефе ярыйсы гына иде, кызларга да бөтенләй бәйләнмәде.

— Һәрчак шулай ул, — диде Әхимгә Лида исемле кыз, — получка алганның беренче көнендә кәефе әйбәт була. Чөнки ул көнне хатыны өендә куна, күрәсең, тамагы да туя. Ә менә иртәгә ул башка кеше булачак. Чөнки хатыны тагын чыгып таячак һәм получка көне житмичә кайтмаячак.

Лиданың сүзләре хак иде. Лабораториягә кергәндә Иван Ивановичның бөтенләй кыяфәте юк иде, кием үтүкләнмәгән, кәефе кырылган, бәлки, бөтенләй ашамагандыр да. Бүген ул кызларга түгел, ни өчендер Әхимгә ташланды. Тик, кызлар белән була торганча, гадәттәге спектакль килеп чыкмады. Әхим чигенмәде дә, балавыз да сыкмады, киресенчә, бик кирәкле һәм дөрес итеп җавап бирде. Шуннан соң ул Әхимгә бүтән бәйләнмәде. Алар ярыйсы гына дуслар булып киттеләр.

Беркөнне Әхим кызларны күреп хәйран калды. Иртәнге җәнҗалга түзеп тора алмаганнар, бичаралар. Барысы берьюлы Иван Ивановичка ташланып аны аяктан егалар, ә икесе аның башына капчык кигезә. Шуннан... менә тотыналар болар профессорны тукмакларга... Түзеп кенә тор! Шуннан соң барысы берьюлы сикереп торалар да, бернәрсә булмагандай эш урыннарына барып утыралар. Иван Иванович та урыныннан тора да, беркемгә бер сүз әйтмичә, өске катка — үз бүлмәсенә менеп китә.

Шушы хәлдән соң Иван Иванович үзен бераз кулга ала башлый, усаллыгы да бераз кими төшә.

Ә көннәрдән бер көнне аның хатыны акча алырга да килмәде. Баксаң, ул Иван Ивановичны бөтенләйгә ялгыз калдырып, кем беләндер көньякка китеп барган икән. Профессор да каушап, аптырап калмый, тота да үзендә эшләгән лаборант кыз Лида Длиннохвостовага өйләнеп куя. Әйтергә кирәк, Лида белән начар яшәмиләр алар. Соңрак бер малай да үстерәләр. Иң мөһиме — лабораториядә җәнҗаллар бетеп, Иван Иванович гел елмаеп кына йөри башлады.

## Кызлар күңеле — тирән диңгез...

Әхимнең дә өйләнергә күптән исәбе бар иде. Уфада өч ел торып та бу бәхеткә ирешә алмаган иде әле ул. Сәбәбе — күзнең явын алырдай бер Уфа сылуына гашыйк булуында. Кызның исеме — Лилия. Әхим аңа өйләнү турында сүз башлап караган иде дә, тегесе аңа бу турыда авыз ачарга да ирек бирмәде:

— Нәрсә сөйлисез Сез, Әхим?! Нинди өйләнү ди ул? Әле болай дус булып йөргәнем өчен дә рәхмәт әйтегез.

— Рәхмәт инде... — диде Әхим кызарып һәм ул көнне алар үпкәләшеп аерылыштылар.

Шуннан соң Әхимгә укырга китәргә туры килде. Шулай Лилия бөтенләй онытылып, инде истән дә чыгып бара иде. Менә көтмәгәндә, шул кыздан открытка килеп төште, Әхимне ул Совет Армиясе көне белән котлаган. Инде барысы да онытылып барганда... »Юкка түгелдер бу...» — дип уйлады Әхим һәм озак уйлап тормыйча Уфа сылуына, үзе янына кунакка чакырып, хат юллады.

Фәрештәләрнең «Амин» дигән сәгатенә туры килдеме икән, беркөнне Әхим өенә кайтса, шаккатты, нишләргә белмәде: ишек төбендә Лилия басып тора. Әхим үз күзләренә үзе дә ышанмыйча кызга ташланды:

— Синме соң бу, Лилия? Килдеңмени? Рәхмәт сиңа...

— Әйе, килдем... — диде Лилия Әхимгә сыенып.

— Димәк, безнең очрашулар эзсез югалмаган...

— Эх, син, Әхим! Кызлар күңеленең тирән диңгез икәнен ник аңламыйсың? Мин бит ялындырмакчы гына булган идем. Дөресрәге, шаярткан идем...

— Кичер мине, Лилия!

...Ленинград һавасы килеште, күрәсең. Уфада еллар буе хәл ителмәгән мәсьәлә биредә үзенең чишелешен бик тиз тапты. Май аенда алар өйләнештеләр. Моңарчы Әхим ялгыз карчыклар яши торган фатирдан бер ятаклык урын гына алып тора иде. Ә хәзер алар икәү. Әхим кечкенә генә бер бүлмә алды. Бу бүлмәнең бердәнбер кечкенә генә тәрәзәсе булып, күршедәге йортның стенасына терәлеп диярлек тора иде. Яшь чак — дәртле чак, дигәндәй, ул чагында нигә ул якты тәрәзәләр? Лилиянең үзеннән бит яктылык бөркелеп тора. Чынлап та, ул лилия чәчәгенә охшаган. Ап-ак тәнле, шундый нәфис, табигатьнең нәкъ үзе кебек!

Әхим менә шул яраткан хатыны белән рәхәтләнеп гомер итә башлады. Билгеле, аралашучан, елгыр кыз Лилия өйдә кул кушырып утыра торганнардан түгел иде. Эшен дә тапты, урнашып эшли дә башлады. Аның яраткан эш урыны китапханә инде. Ул булса, аңа берни кирәкми.

Барысы да шулай әйбәт, шәп, тыныч кына бара иде. Әмма көннәрдән бер көнне гүзәл бер кызчык дөньяга килде. Аңа исемнең дә иң матурын сайлап — Гүзәл дип куштылар. Чынлап та, Гүзәл дөньяга килгәнче дөнья үзе дә гүзәл булган икән. Ә хәзер менә, эшләр бераз хөртиләнде. Балалы кешене фатирга кертергә якын да җибәрмиләр. Кертсәләр дә, шәп сорыйлар хакын. Яшьләргә андый акча каян килсен соң? Ярый әле, нәкъ шулчак Лилиянең әнисе Мәрьям килеп төште. Әйбәт кенә кунак булгач, Ленинград белән танышкач, ул Лилияне һәм бәләкәй кызчыкны да Уфага алып кайтып китте. Әхим китаплары арасында тагын япа-ялгызы калды.

## Тәүге ачышлар

Фәнни эзләнүләр буенча инде шактый материал туплаган иде Әхим. Иң кызыгы, иң тәэсирлесе — шуларны эшкәртү һәм системалаштыру башланды. Бу эшне Әхим химик, геохимик, математик ысуллар үткәрү ярдәмендә бер үк

вакытта алып барды. Системалаштыру бер яктан геохимик закончалыкларны ачыкларга ярдәм итсә, икенче яктан нинди яңа материал тупларга, нинди яңа экспериментлар үткәрергә икәнен күрсәтте, ә ароматлы углеводларны эксперименталь юл белән тирәнтен өйрәнүгә кагылышлы ачышка китерде. Беренчедән, Идел-Урал ятмаларындагы нефть составы турындагы ялган карашны юкка чыгарды, икенчедән, ароматлы углеводородлар бер-берсеннән аерылып торган ике катнашмадан: үз ароматлы углеводородлар һәм күкертле органик матдәләрдән гыйбарәт икәнен исбатлады. Димәк, утызынчы елларда Грозный нефть фәнни-тикшеренү институтында күкертле нефть өчен эшләнгән методика бездәге күкертле ятмалар өчен яраксыз. Дөресрәге, яшь галим Әхим составында 30-40 тапкыр күбрәк күкерт булган Идел-Урал нефтен анализлауда традицион методиканы куллануның ялгыш нәтиҗәгә китерүен исбатлады.

Бу ачыштан соң тагын да тирәнрәк экспериментлар үткәрә бару юлы белән Әхим нефтьнең бензин фракциясендә күкерт кушылмаларының күләмен төгәл билгеләү ысулын эшләде. Бу ачыш аеруча зур әһәмияткә ия. Беренчедән, ул фәнне үстерүгә житди өлеш булса, икенчедән, аны практикада, ягъни берничә миллиард тонна исәпләнгән Идел-Урал нефть запасының составын ачыклауда куллану чималны эшкәртү барышында гаять зур икътисадый эффект бирә; өченчедән, нефть генезисындагы, ягъни нефть катламының бүленүе һәм ятмаларының формалашуындагы закончалыкларны табарга мөмкинлек тудыра.

Бу ачыш — дөньяның барлык төбәкләрендә киң яклау тапты, ә Союзның барлык институтлары бу яңа ысулны кулланма итеп алдылар һәм фәнни эзләнүләр барышында кулландылар. Чөнки әлегә башка нәтиҗәлерәк ысул юк иде.

Үзенең бу ике ачышын тагын да тирәнәйтә барып, математик һәм график ысуллар куллану юлы белән Әхим нефть составына кагылышлы яңа закончалыкларны ачыклады. Әйтик, нефть составында күкерт никадәр күп булса, аннан җиңел, ягъни бензин фракцияләре азрак чыга һәм, киресенчә, асфальтен, сумала кебек авыр фракцияләр күбрәк була. Бу ачышлар соңрак фәнни эзләнүләрдә генә түгел, акрынлап житештерү сәнәгатенә дә үтеп керде, махсус күкертле нефтьне эшкәртү технологиясен тудырды, махсус предприятиеләр барлыкка килде...

***

Әхимнең бу еллардагы иң якын киңәшчесе, дусты, һичшиксез, Борис Тимофеев булгандыр. Шатлыкларын да, уңышсызлыкларын да ул аның белән уртаклаша иде. Алай гына да түгел, еш очрашалар, бәйрәмнәр дә бергә үтә. Фәндә дә бер-берсенә булышалар. Дөрес, Борис Васильевич — микропалеонтолог. Ул бик борынгы үсемлекләрнең серкә һәм спораларын өйрәнү, һәм шул нигездә тау токымнарының геологик яшен ачыклау белән мәшгуль. Беркөнне ул Әхимгә мөрәҗәгать итте:

— Дус итеп кенә әйтәм. Бер үтенечем бар, Әхим дус, сиңа...

— Тыңлап карыйк, Борис Васильевич.

— Нефть пробасыннан миңа шул үсемлек спораларын аерып алып, сыеклыкның каракучкыл элементларыннан чистарта алмыйсыңмы?

— Төгәл генә әйтүе читен, эшләп карармын. Аңлыйм, бу сиңа бик кирәк, шулай бит?

— Әйе, Әхим. Ул спораларны, аларның вак кисәкләрен микроскоптан карап өйрәнергә кирәк миңа. Шунсыз мөмкин түгел. Тау токымын тикшерү җиңелрәк, ә менә нефтьне өйрәнү алай җиңел түгел.

— Булыр кебек, Борис Васильевич. Уфа фәнни-тикшеренү институтында

хроматография белән өлешчә шөгыльләндем мин. Методикасы мәгълүм.

Әхим, шул методиканы кулланып, дустының проблемасын тиз хәл итте. Озакламый алар бергәләп уртак мәкалә әзерләделәр һәм академик журналда бастырып та чыгардылар. Шулай итеп, Әхимнең бу ысулын да шуңа охшаш фәнни тикшеренүләр барышында киң куллана башладылар. Борис Васильевич исә, үз өлкәсендә зур ачыш ясап, докторлык диссертациясе яклады һәм илгә танылып өлгерде.

***

Ә менә Әхимгә танылган галим булып китү өчен инде кандидатлык диссертациясе якларга вакыт иде. Югыйсә, бары да әзер, отчет та ясалган, ачышлар да җитәрлек. Дворянскийның хәер-фатихасы белән диссертациясе дә төгәлләнгән. Ә якларга һаман батырчылык итми. Сәбәбе — бу вакытта нефть генезисының органик теориясенә кагылышлы берничә гипотеза яши. Хәтта ул укый торган геологик эзләнү фәнни-тикшеренү институтында да бер-берсенә капма-каршы ике юнәлеш, ике мәктәп формалашкан. Аның берсен Әхимнең җитәкчесе Александр Дворянский, икенчесен Успенский һәм Радченко җитәкли. Бу ике агым арасында көрәш уйнап түгел, ә чынлап — көчәйгәннән-көчәя. Дөрес, Дворянский «Нефть геохимиясе» исемле монографиясен чыгарып, үз сүзен кистереп әйтте. Ә тегеләр исә уңайлы момент туган саен төрле утырышларда, язган мәкаләләрендә Дворянскийның билгеләмәләрен юкка чыгарырга, тәнкыйтьләргә тырышалар, ревизия ясыйлар. Дворянский яклылар исә, киресенчә, үзләренең эзләнүләрендә янадан-яна исбатламалар табып, тегеләрне «утка» тоталар...

Әхим бер якка да авышмады, җинел юл сайлап кемгә дә булса сукырларча иярмәде. Ә бит андыйлар күп. Үзенең ачышларына төзәтмә ясап, җил кайсы яктан иссә, шул якка авышучылар аз түгел. Әхимгә бу нәрсә чит иде, ул чынбарлыкны гына исбатларга тырышты. Чынлап та, ул геохимик һәм геологик мәгълүматларны бик күп туплады. Тик ул мәгълүматларның бер өлеше үзенең шефы Дворянский тәгълиматларын хупласа, икенче бер өлеше алардан аерыла иде. Дворянский гипотезасына каршы чыгучылар белән дә ул өлешчә каршылыкта. Кайбер билгеләмәләре аваздаш булса да, кайберләре капма-каршы килде.

Нәрсә эшләргә? Диссертацияне шушы килеш якласаң, теләгәндә ике якның да бик җинел батыруы ихтимал. Ничә еллар эшләгәнең юкка чыгачак, дөресрәге, нәтиҗәсез калачак.

«Ни генә булмасын, намусыма, үз-үземә каршы бара алмыйм, — дип уйлады Әхим, — бу һич тә мөмкин түгел. Ничек бар, материаллар ничек күрсәтә — шулай якларга кирәк.»

Монда Әхим һич тә ялгышмады, дөрес тактика сайлады. Шефы Александр Флавиатович Дворянский диссертациядә үз адресына, кайбер билгеләмәләренә һөҗүм булуын күрсә дә, вакланмады. Аннары үзенең шәкертенә каршы чыгу, тәгәрмәченә таяк тыгу олы галим өчен килешеп бетмәсен ул яхшы аңлый иде. Әхимнең төп ачышларын да ул башта ук уңай бәяләп өлгергән иде.

Успенский һәм Радченко яклылар да егетнең шефы кубызына гына биемәгәнен, үз сүзе, үз ачышы барын күреп, иң мөһиме, үзләренең дә гадел тәнкыйтьләнгәнен аңлап, Әхимгә каршы күтәрелмәделәр.

Бу 1954 елның истәлекле 15 гыйнвары иде. Әхим диссертация советы әгъзаларын таң калдырып, диссертациясен уңышлы яклады. Шулай итеп, аның күптәнге хыялы тормышка ашты — эшлекле тикшеренүләрдән соң Совет әгъзалары Әхимнең эшен бертавыштан хупладылар. Аңа химия фәннәре кандидаты дигән фәнни дәрәҗә бирелде. Соныннан совет

рәисе, институт директоры Иванчук диссертация яклау Советы әгъзалары исеменнән болай диде:

— Кәримовның аспирантурада уку срогын үз вакытында кандидатлык диссертациясе яклап тәгәлләве безнен күпьеллык тарихыбызда беренче очрак. Киләчәктә дә безгә шулай дәвам итәргә кирәк! — Аннары ул Әхим Кәримовка болай диде:

— Мин сезгә, иптәш Кәримов, институтта калырга тәкъдим итәм. Фатирны да озак көттермәбез. Ризамы?

— Тәкъдимегез өчен чиксез рәхмәтлемен. Тик вәгъдәмә хыянәт итә алмыйм. Мин бит үземне бирегә җибәргән Уфа фәнни-тикшеренү институтына кайтырга вәгъдә бирдем. Гафу итегез, минем урыным шунда дип уйлыйм.

***

Уфага Әхим апрель аенда кайтып төште. Кайтуына аңа яңа төзелгән йорттан Уфа фәнни-тикшеренү институты ике бүлмәле фатир калдырган иде. Җир йөзендә инде 36 ел яшәп, беренче тапкыр аның үз фатиры булды. Тиздән кадерлеләре Лилия һәм Гүзәлне алып Әхим яңа фатирга күчте.

Өлкән гыйльми хезмәткәр өчен институтта эш муеннан иде. Беренче чиратта барлык тупланган материалны системалаштырды, гомумиләштерде. Бер үк вакытта Татарстанда, Пермь, Самара, Оренбург, Саратов, Волгоград өлкәләрендә булып, яңадан-яңа материаллар туплады. Шул эзләнүләрнең тәүге нәтиҗәсе — «Башкортстан нефте» дигән китабы дөнья күрде.

Эзләнү барышында Әхим берсеннән-берсе кызыклырак детальләргә, закончалыкларга тап булды. Шуларның иң мөһиме — югарыда санап кителгән өлкә һәм республикалар территориясендә нефть составы һәм үзенчәлегенең горизонталь һәм вертикаль (яше буенча) үзгәрү закончалыгы. Бу закончалык нефтьнең тирән катламнардан (тирәнлекләрдән) территориянең өске катламнарына, әйтик, Әлмәт тирәсендәге Татар түбәсенә миграция хәрәкәтен ачыкларга мөмкинлек бирде. Менә шул грандиоз миграция процессы нәтиҗәсендә миллионнарча еллар эчендә углеводород геологик куышларда җыела барып, аларда эре һәм вак нефть ятмалары формалашкан.

Шулардан иң әһәмиятлесе — Татар җыелмасы запасының көньяк-көнбатыштагы Шпаков (Башкортстан) тармакчаларыннан башлап, аның Әлмәттәге (Татарстан) түбәсенә кадәрге территориядә урнашкан девон нефте чыганаклары. Шушы ук закончалыкка таянып, Әхим нефтьнең көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш миграциясе нәтиҗәсендә Саратов, Волгоград өлкәләре территориясендә дә нефть ятмалары булуын исбат итте. Соңрак нефть һәм газ катламнарының Каспий буе түбәнлегендә дә булу мөмкинлеген белдерә. Теоретик яктан дәлилләнгән бу фикерләрнең дөрес булуын тормыш үзе ачык күрсәтте.

## Кабат Үзбәкстанга галим булып

Язмышмы, ялгышмы дигәндәй, көннәрдән бер көнне Әхимгә Уфа белән хушлашырга туры килде. Конкурс буенча аны, Үзбәкстандагы әле яңа гына ачылып килгән геология һәм нефть, газ чыганакларын эзләү институтына (ИГПЕНИГМ), лаборатория мөдире итеп чакырдылар. Бу вакытта инде Үзбәкстанның күп кенә өлкәләренең нефть һәм газ ятмаларына бай булуы ачыкланып өлгергән була. Барыннан да бигрәк уникаль газ чыганагының ачылуы төп сәбәпче була моңа.

Ташкентка ул 1959 елның мартында килеп төште. Бу вакытта инде

институтның төп бинасы һәм торак йорты әзер. Беренче көннән үк Әхим коллективны туплауга, җиһазлар һәм приборлар, реактивлар алуга, өлкәләрнең неологик төзелешен өйрәнүгә, төрле-төрле тау токымнарын җыюга кереште.

Шулай да эш шома гына бармады. Институт директоры А.М.Әкрәмходжаев башта бу өлкәдә тыныч кына, тавышсыз гына җитәкчелек итә. Эш тә әйбәт кенә бара. Әмма тора-бара ул, үз тирәсенә үз туган-тумачаларын җыеп, үтеп керә алмаслык дивар кора. Өстәвенә, аның үзен җирле Фәннәр Академиясендә геология фәннәре бүлеге мөдире һәм геология журналы мөхәррире итеп билгеләләр. Аның рөхсәтеннән башка хәзер академиягә һәм институтка черки дә үтеп керә алмас була. Шулай итеп, ул фәндәге «мафия»нең башында тора. Үзен тулы канлы хуҗа, феодал итеп тоя... Мондый шартларда аның рөхсәтеннән башка беркем дә китап түгел, хәтта мәкалә дә чыгара алмый. Ә диссертация язу, аны яклау турында, хәтта уйларга да мөмкин түгел. Премия бирү, хезмәткәрләргә хезмәт хакын көйләү — аның кулында. Үзбәкстаннан читтәге галимнәр белән аралашырга ярамый, хәтта алар белән хәбәрләшеп тору да чикләнгән. Командировкаларга бару, эзләнүләрне кинәйтү, доклад һәм чыгышлар ясау, отпуск алу, аспирант белән җитәкчелек итүләр — барысы өчен дә аның рөхсәте, аның фатихасы кирәк. Кыскасы, Совет власте юк бирелә, диләр иде, чын икән. Ә үзе Мәскәү оешмалары, аерым галимнәр белән һәрчак элемтәдә тора, һәркайсы аны, аның эшен, диктаторлык, мафиозлык хәрәкәтләрен дә күрә торып — хуплыйлар иде. Күрәсең, Совет власте, җирле власть өчен кирәк булганда, үзәк бюрократик аппарат өчен отышлы булганда, аларны Ташкенттагы феодаль, колбиләүчелек кебек тәртипләр канәгатьләндергән...

Ул чакта Әхим әле боларны аңлап җиткерми иде. Шуңа күрә дә ул гаделлек эзләде, моның өстән-үзәктән килүен көтте. Билгеле, үзәктән кемнәргәдер ярдәм булды булуын, тик Әхимгә генә түгел...

Старобинц Илья Самойлович, ниһаять, беренче булып докторлык диссертациясе яклады. Бу институт өчен зур уныш иде. Дөрес, ул да бик актив, сәләтле галим. Тик, аңа яклауны тизләтүдә башка көчләр дә ярдәм итте. Мәскәүдәге «дуслар» үз кешеләрен кайда гына булса да күздән ычкындырмыйлар! Кирәк икән, булышалар, кирәк икән, тиешле кешеләр (феодалмы ул,мафиозмы) аша, кем булуына карамастан йогынты ясыйлар. Шуңа күрә, Әкрәмходжаев та аңа бөтен шартларны тудырды. Хәтта үзенә ярты еллык иҗади ял да бирде. Бу турыда башка докторантларга хыялланырга гына кала иде.

Бу вакытта инде Әхимнең дә докторлык диссертациясе формалашып килә иде. Өстәвенә, аның йөздән артык фәнни хезмәтләре басылган һәм фәнни җәмәгатьчелек үзен яхшы белә. Бу хакта ул институт директоры Әкрәмходжаевка да җиткерде. Тик, тегесе бу хәбәрне бик салкын, битараф кабул итте. «Ярый әле, Аллага шөкер, тыймады», — дип сөенде Әхим бу очрашудан соң.

Моңа карап Әхим күңелен төшермәде, диссертациясен соңгы таләпләргә җавап бирерлек итеп эшләргә, өстәмә материаллар тупларга кереште. Әмма төп эшне дә тулысынча алып баргач, язу авырга туры килде Әхимгә. Шулай да ул беркөнне барлык сабырлыгын, батырлыгын җыеп, Әкрәмходжаев янына керде һәм:

— Диссертациямне тулысынча тәртипкә китерү өчен өч ай иҗади отпуск рөхсәт итсәгез иде... — диде.

— Юк! — диде феодал. — Ашыгыч түгел бит. Эшли-эшли языгыз. Өлгерерсез.

— Болай да сонардым бит инде. Тиздән 50 яшь тула мина.

— Бер дә борчылмагыз. Докторлыкны 60 яшьтә дә яклаучылар аз түгел. Өлгерерсез.

Әхим жирле феодал белән башкача сүз куертып тормады. Әтиең үзбәк булмагач, йә яһүдтән тумагач, булмый инде булмагач...

Авыр көннәр иде бу. Житмәсә, Ташкент жир тетрәүдән жимерелде. Республика буенча җимергеч давыллар үтте. Гаиләдә дә барысы да ал да гөл түгел иде. Шулай да тырышты Әхим. Үзенә 50 яшь тулган көнне ул инде әзер диссертациясен Әкрәмходжаевка тапшырды. Әхимне ул ничек кабул иткән булса, аның диссертациясен дә шулай ук кабул итте. Хәзер инде барысы да аның кулында: якларга рөхсәт бирәме-юкмы — аның эше. Тели икән, ул юл бирә, тели икән — яндыра. Әйе, диссертациянең сыйфаты, эчтәлеге нинди булуга да карамастан! Кире какса да берни эшли алмыйсың. Каядыр бару, шикаять язу, яисә кемнәндер ярдәм сорау — бу очракта файдасыз иде. Ул ни дисә, шул булачак. Хәзер язмыш аның кулында.

Шулай көннәр үтә торды. Академик, су капкан кебек, берни дәшмәде. Бу арада Әхим СССРның иң эре шәһәрләрендә фәнни докладлар ясады, алар һәркайда унай яктан бәяләнде. Шулай үз эшен күп кенә галимнәргә күрсәтте ул, алардан язмача бәяләмәләр алды. Арадан рәсми оппонент булырга теләүчеләр дә табылды. Өч профессор, шул исәптән танылган геохимик К.Ф. Родионова унай бәя бирде. Кыскасы, шефтан шәфкатьлелек, рәхимлек көткән бер үк вакытта, үзе дә көрәшкә әзерләнә торды ул. Шефның нәрсә эшләсә дә кулыннан килә иде. Мәскәү аны тәмам узындырды, республика хөкүмәте дә... Шул арада инде тагын икәү, бу юлы инде үзбәкләр, докторлык диссертациясе якладылар. Әмма Әхимгә һаман да бер сүз әйтмәде шеф. Чөнки ул бу мәсьәләне хәл итү белән ашыгырга теләмәде, чөнки диссертация аның кулында чакта — Әхим бәйдә, аны күпме кирәк шуның хәтле эшләтергә, эксплуатацияләргә була бит. Вакыт шулай үтте дә, үтте... Бары тик 1969 елның мартында гына яклау көне билгеләнде. Ләкин әле сөенергә иртә иде. Ни әйтсәң дә, барысы да аның кулында — ул геология буенча берләштерелгән диссертация яклау Советы рәисе урынбасары иде. Әхим тикмәгә генә шикләнмәгән икән, яклауга аз гына вакыт калгач, шеф яклауны өзде.

— Нигә син, Әхим, башыңны имисең. Яклаганчы аның алдында түбәнрәк иярге кирәк иде башны... — диде аңа Совет рәисе.

— Минем болай да аңа каршы чыкканым, сүз катканым юк, ә билне болай да кызганмыйча бөгә алган кадәр бөгәм! — диде Әхим.

Ничек аңламасын ди, аңлый ул. Феодаль тәртипләр хөкем сөргәндә, ничек феодалга каршы чыгасың ди?! Акылсызлык булыр иде бу. Тик, Әхимнең әле аңлап житкермәгән өлкәсе дә юк дип булмый. Коры кашык авыз ертканын, юкса, күптән белергә кирәк иде. Хәер, белден дә ди, бүләкләргә байлыгың яки урланган малың булмагач, нихәл итәсең?.. Ярый әле, сабыр итте, тынын чыгармыйча көтә алды, йөрәге чыдады аның. Аз киттемени йомшак йөрәклеләр фәнгә кереп оялаган феодаллар аркасында?! Кешеләргә килгән бәхетсезлектән бу бәндәләр тәм табып яшәргә өйрәнгән.

...Тагын шактый айлар үтте. Яклауны туктатуның сәбәбе, юкса, күптән билгеле булган икән. Бер карасаң, аны сәбәп дип тә булмый. Хәер, үз башбаштаклыгын яклар өчен генә кирәк булган аңа сәбәп дигәне.

Ниһаять, болай да ачык мәсьәләне ачыклагач, яклау көне 1969 елның ноябренә билгеләнде. Совет әгъзалары диссертацияне бертавыштан яклады. Әхим Кәримовка «Геология фәннәре докторы» дигән гыйльми дәрәҗә бирелде! Менә шулай тәгәлләнде бу бик озакка сузылган тавышсыз тартышу. Ярый әле, әйткәнемчә, йөрәге нык булган диссертантның!

***

Профессор Кәримов Үзбәкстан өчен нәрсә бирде соң? Бала чагында үзен сыендырган, явызлары тотып кыйнаган, миһербанлылары үзен үлем тырнагыннан йолып калган Үзбәкстанга булган бурычын ул бише белән кайтарды, дисәк тә, хата булмас. Беренчедән, дуслары белән ул буш җирдә Ленинград һәм Мәскәүдәге лабораториядән һич кенә дә калышмаган фәнни-тикшеренү лабораторияләре оештырды, аларда киң колачлы геохимик эзләнүләр үткәрелде, яңа ачышлар ясалды. Дүрт провинцияне геохимик яктан тирәнтен өйрәнеп, аларда күпме нефть һәм газ ятмалары булуын ачыкладылар. Ниһаять, алар углеводород флюидларының төп миграцион юнәлешләрен билгеләп, аларның туплаган төп потенциал запасларын күрсәттеләр; алар никадәр Үзбәкстан геологларын геохимик кулланмалар белән эш итәргә өйрәттеләр; аларның утыздан артыгы, үзләренең геологик материалларыннан тыш геохимик материалларны да кулланып, фән кандидатлары булды. Үз чиратында геологлар да геохимикларга турыдан-туры булышты, шулай бер-берләрен үзара кирәкле белемнәр белән баеттылар; бер үк вакытта, эзлекле рәвештә Үзәк, Төрекмәнстан, Таҗикстан, Кыргызстан галимнәре белән аралашып, алар белән тикшеренү нәтиҗәләрен алмашып эшләделәр һәм иң ахыр чиктә табигый газ һәм нефть генезисы проблемасын тулысынча хәл итүдә катнаштылар. Бу фәнни эшләрнең практик нәтиҗәләре ничек булды соң? Сүз дә юк, гаять зур булды. Соңгы утыз елда әлеге территориядә гаҗәеп күп газ һәм нефть ятмалары ачылды, бигрәк тә Мангышлак-Көнбатыш Үзбәкстан, Төньяк-Көнчыгыш Төрекмәнстан кебек уникаль чыганаклар файдалануга тапшырылды. Болар барысы да, геохимия галимнәренең эшләнмәләрен газ һәм нефть ятмаларын эзләүдә — дөрес куллану нәтиҗәсе. Әле озак еллар буе ул эшләнмәләр янадан-яңа ятмаларны ачуга булышачак.

## Кан да тарта, җан да тарта!

Үзбәкстанда утырма тау токымнарын геохимик яктан өйрәнү, ул чор дәрәҗәсендә, нигездә, төгәлләнде. Аерым детальләрне инде Әхимнән башка да ачыкладылар. Аннары балалары да үсеп житте, аларны туган якларына алып кайтып урнаштырырга кирәк. Лилиясе дә соңгы вакытта Уфаны еш искә ала башлады. Аннары, Ташкентта милләтчелек хәрәкәте көннән-көн көчәя, ничектер мондый шартларда киләчәк көнеңә ышаныч кимеп бара...

Шул көннәрдә Уфа нефть институты органик химия кафедрасы профессоры урынына конкурс игълан итте. Нәкъ аның белгечлегенә туры килә. Күп уйлап тормыйча (хәер, Уфага кайту мәсьәләсе гаиләдә инде хәл ителгән иде), гариза бирде. 1975 елның августында Әхим гаиләсе белән кабат Уфага кайтып төште. Кан да тарткан, җан да тарткан аларны, күрәсең. Кайту белән үк, институт аңа фатир бирде. Әхим яңа көч белән укытуга — лекцияләр әзерләүгә керешге. Сүз дә юк, яңа эш өстәмә көч таләп итә иде, билгеле. Үзбәкләр дә бит «агач бер урында гына әйбәт үсә», — дип тикмәгә генә әйтмиләр. Билгеле, дәресләрне югары дәрәҗәдә, профессор дәрәҗәсендә аңлату җиңел бирелмәде Әхимгә. Шулай да ул Уфага кайтуының берданбер дөрес юл булуына кат-кат инанды. Бигрәк тә СССР таркалып, Үзбәкстан чит ил булып калгач, кайтуына куанып бетә алмады. Барысы да бирелә— туган якларында. Бәлки әле, теге чакта Ташкентка китү үзе хата булгандыр. Әгәр дә Уфада калган булса, яки Казанга күчсә, начар булыр идемени? Үз җирендә, үз туфрагында тамырын тагын да тирәнгәрәк җибәрә алмас идемени ул?

Әйе, үз гомерендә кайда гына булмады, ниләр генә күрмәде, кайда гына эшләмәде ул, кайда гына яшәмәде... Шулай да үзе өчен Татарстаннан да якынрак, кадерлерәк җирне тапмады. Эх, яшь чаклары булса, кайтыр иде Татарстанга, үз йортын корыр иде... Адым артыннан-адым ясап, такта артыннан такта сугып, барысыннан күркәмрәк йорт кору — үзе ни тора! Монысы тормышта иң дөрес, иң изге, иң гадел юл булачак. Тик хәзер болар сонлады шул инде. Шулай да күнеле белән ул һаман Татарстанда!

***

Уфа да матур икән, Уфа да якын икән. Икенче елны укыту да җиңеләя, яшәү дә матурая төште. Балалар да үсеп житте. Аскарны әнә Армиягә алдылар. Өйдә аннан нәфис сәнгать атрибутлары калды. Буш вакыты булдымы, Әхим улының бүлмәсенә керә дә, рәссам өчен кирәк булган әзер әйберләрдән файдаланып, рәсем ясарга тотына. Ә бит бала чакта рәсем ясарга бик тә ярата иде ул. Тик укытучысы гына йомшак булып чыкты. Хәер, бала чакта гынамы, җае чыкканда һәрчак рәсем ясый торган иде. Ә менә майлы буяу белән бүген беренче тапкыр ясавы. Рәсемнәрне күбрәк пыялага ясый иде ул.

Нәкъ шул елны нефть институтында үзешчән сәнгать әйберләре күргәзмәсе оештырылды. Әхим дә үзенен рәсемнәрен куйды анда. Шунысы кызык, дистәләрчә рәсем арасыннан Әхимнең эше беренче премиягә лаек булды.

Шуннан Әхим рәсем сәнгате белән, чын мәгънәсендә, мавыгып китте. Рәсемнәрен киндергә ясый башлады, зур күләмле эшләр башкарды ул. Акрынлап үзешчәннәрнең генә түгел, ә профессионалларның күргәзмәләрендә дә катнаша башлады. Уфада берничә тапкыр (моторлар төзү берләшмәсендә һәм педагогия институты бинасында) аның шәхси күргәзмәсен оештырдылар. Берничә тапкыр Мәскәүдә Бөтенсоюз күргәзмәләрендә катнашып, бер тапкыр беренче урынны алды һәм дүрт тапкыр лауреат дипломы белән бүләкләнде. Газета битләрендә, радио һәм телевидениедә аның әсәрләре турында җылы сүзләр, күп мактаулар әйтелде аңа. Бигрәк тә «Төнге Сталинград» картинасы аерым уңыш казанды. Ул анда үзе булган, үзе күргән, үзе сугышларда көрәшкән Сталинградны тулы гәүдәләндерергә тырыша һәм бу әсәре шаккаткыч уңышлы килеп чыга. Әйтергә кирәк, бу хыялына да ирешә ул.

Шулай бервакыт, көтмәгәндә Әхим эшли торган кафедраны физика кафедрасы белән берләштерделәр. Әхимгә исә институтның Салават филиалында махсус химия кафедрасы оештырырга тәкъдим ителде. Аның җитәкчелегендәге ул оештырган бу яңа кафедра уңышлы гына эшләп китте. Ләкин Әхимгә чит шәһәрдә яшәү ошап бетми, ни әйтсән дә, яшь чак түгел инде. Аңа Уфа педагогия институтында химия кафедрасы мөдире урынын тәкъдим иткәч, ул аңа риза булды. Кафедраның элекке мөдире Хәбибуллин ике елга докторантурага укырга китәргә тиеш икән. Озакламый Әхим бу кафедрага килде. Сүзне дә ул коллектив тормышыннан башлады. Янәсе, коллектив Әхимне кабул итәрме? Аларга өйрәнгән мөдирдән аерылу кыен булгандыр... дип уйлады ул. Шунда бер шаянрак доцент:

— Сезнең бер күрүдә тетрәндерә, калтырата торган кеше очратканыгыз бармы? — диде.

— Кичә генә очраттым, — диде Әхим берни уйламыйча.

— Кем ул?

— Билгеле теш табибы.

— Ялгышасыз, теш табибы безнең шеф янында чүп кенә ул!

Кафедрадагы хәлләрне таң калып тыңлады Әхим. Ленинградтагы

Богомолов лабораториясендә дип уйларсың үзеңне... Әмма Ленинград профессоры хезмәткәрләрен төшкә кадәр генә җәфалаган булса, бу көне буе әле берсен, әле икенчесен тинтерәтә, аларга кычкыра икән. Кыскасы, түзеп тора алмаслык атмосфера тудырган булган. Баксаң, өлкә комитетында ныклы таянычы булган икән мөдирнең. Диктатка да аңардан өйрәнгән, имеш.

Әхим бирегә кафедра мөдире булып килгәч, укытучылар «җиңел сулыш алдык, эшләве дә рәхәт», — дип ачыктан-ачык әйттеләр. Үзләре шундый әйбәтләр. Күркәм коллектив. Алар кемнеңдер күрсәтмәләренә мохтаҗ да түгелләр, үз эшләрен яхшы беләләр, аны җиренә җиткереп башкаралар. Үзләре үк Әхимгә ярдәм итәләр, дусларча киңәш бирәләр. Эшләве рәхәт, җиңел. Әйбәт көннәр тиз үтә шул ул...

***

Әхим хәләл җефете Лилия турында күп сөйләми. Әмма ул аның йөрәгендә, күңел түрендә. Ленинград, Уфа, Ташкент китапханәләрендә үткән аның хезмәт биографиясе, тормыш юлы. Эшләп тә, балалар тәрбияләп тә башта китапханә техникумын, аннары китапханә институтын тәмамлый ул. Эшен дә яратып башкара, гаиләсен дә кайгыртырга өлгерә.

— Аллаһы Тәгалә безгә сәламәт, шат күңелле кыз белән малай бүләк итеп искиткеч куандырды! — ди Әхим ага. — Безнең дәртле хыялларыбыз чынга ашты. Без аларның тормышындагы һәр уңышлы адымга бөтен гомеребез буе һәм һәр көн сөенеп, шатланып яшәдек һәм куанып яшибез. Алар безнең бәхетебезнең төп чыганагы булдылар һәм шулай булып калалар. Бу өчәү — минем тормышымдагы төп таяныч, төп юаныч!

***

Гүзәл ул — юл кызы. 1952 елда Ленинградта, әтисе аспирантурада укыган чакта дөньяга килә. Әхим белән Лилия өчен бу — берьяктан куанып туймаслык вакыйга булса, икенче яктан, Гүзәлнең тууы зур мәшәкать, кайбер уңайсызлыклар да алып килде. Бала белән фатирга кертүче юк. Өчәүләп бер фатирда яшәү инде бөтенләй мөмкин түгел иде, шуңа Лилия кызын — Гүзәлне алып Уфага — әниләре янына кайтып китә.

Аның каравы, аспирантураны тәмамлап Уфага кайткач, сөйкемле, яраткан кызын сөеп туя алмый Әхим. Ә кызлары Гүзәлгә җиде яшь тулганда алар гаиләсе инде тагын Ташкентта иде. Бирелә Гүзәл урта мәктәпне тәмамлады, бер үк вакытта музыка мәктәбен дә бетерде. Әле музыка мәктәбенең икенче сыйныфында укыган чакта ук ул:

— Үскәч мин музыка укытучысы булам! — дип кистереп куйды һәм шушы хыялына гомере буе тугры булып калды.

Ташкенттагы музыка училищесына укырга керергә талпыну нәтиҗәсез тәгәлләнде. Монда ул гаепле түгел иде. Тәҗрибәсез әти-әнисе игътибар биреп җиткермәде, ахры. Бирелдәге кануннарны төшенергә инде күптән вакыт булса да, Әхим әллә юри, әллә белмичә, аңларга теләмәде. Мәгълүм бер затларны алтынга коендырса, Гүзәл училищега керми калмый иде, әлбәттә. Әмма кыз чигенмәде. Ул Уфа музыка училищесына кереп, аны уңышлы тәмамлады һәм шунда музыка мәктәбендә эшкә дә урнашты. Аннары, ул Казан дәүләт педагогия институтының музыка факультетын әйбәт тәмамлады. Кияүгә дә ул төп хыялы, төп теләге тормышка ашкач кына чыкты. Соң булса да, уң булды. Ике матур кызы туды: Наилә белән Галия. Бүген Лилия ханым белән Әхим ага бу кечкенә кызларга карап куанып туя алмыйлар. «Баланың баласы балдан татлы» дип тикмәгә генә әйтмиләр икән шул халыкта. Хәтта, үз балаларыннан да ныграк ярата аларны Әхим ага. Тегеләре исә бабаларын «бишле»ләр белән сөендерәләр...

***

Улы Аскарның хәлләре башкачарак. Ул инде Уфада Әхимнен үз фатирында дөнья күрде. Бәхет өстенә бәхет, нур өстенә нур, дигәндәй, Аскарның тууы гаиләдә һәркем өчен бәхет иде. Бала нормаль шартларда үсте, урта мәктәпне тәмамлады, ә менә музыка мәктәбен дүрт сыйныф укыгач та ташлады. Аны укуын дәвам итәргә берничек тә күндереп булмады, җаны тартмый аның музыкага. Ул — рәсем сәнгатенә тартылды.

Ике ел армиядә хезмәт итеп кайтканнан соң, төзелеш институтын тәмамлап, йортлар төзүне проектлаштыра башлады. Әмма ул эшли торган оешма заказлар алмыйча, таркалды. Шул болгавыр вакыттан файдаланып, Аскар сәнгать мәктәбенең кичке бүлегенә укырга кереп, аны уңышлы тәмамлап чыкты һәм картиналар язу өстендә эшли башлады.

Әхим үзен рәсем сәнгатендә реалист дип саный иде. Шунамы, ул башта Аскарның рәсем серенә төшенә алмый азапланды.

— Ниндидер авангардизм чире йоккан сиңа... — диде ул аның рәсемнәрен карагач.— Нәрсә инде бу? Юкка кәгазь пычратасың бит. Их, бала!

— Әти, аларны аңлый белергә кирәк. Биредә һәр сызык — образ.

— Образ, образ... Ник кеше кебек ясамыйсың?

— Кайгырма, әти, аңларлар. Бу гасырда булмаса, киләчәк буын аңлар!

Аскарның рәсемнәре башта шулай Әхимнең кәефен нык кырса да, акрынлап ул үзе дә картиналарны аңлый, төшенә башлады.

— Хәзер аның картиналарын карыйм да, хәйран калам. Каян килә кешегә шундый фантазия?!

Чынлап та, Аскар рәсем сәнгате дөньясында танылганнан-таныла бара. Танылган рәссамнар аның эшләрен карап, чын мәгънәсендә сокланалар.

— Дөрес, — ди Әхим, — әле гади халык Аскарныкын түгел, минем рәсемнәрне реалистик якын күрә, ярата төшә. Әмма, Аскар талантлы!

Әйе, һәр солдат генерал булырга хыялланган кебек, һәр бала яшьтән үк олы, танылган кеше булырга хыяллана. Ата-ана исә, үзенең бәгырь кисәгендә һәрчак нинди дә булса талант иясе, даһи күрә. Бу төшенчә Әхимгә дә ят түгел, ул да улының бөек рәссам булуын тели, шул хакта хыяллана. Хыяллансын, хыяллану зыян итми. Моны аңлагандай, әнә Аскар да яңадан-яңа картиналар яза, илгә таныла бара. Иншалла, сүзләрем фәрештәләрнең «Амин» дигән сәгатенә туры килсен!

***

Әгәр дә кеше, чынлап та, намуслы, әдәпле, яхшы кеше икән, ул — үз Ватанына, туган халкына, милләтенә һәм диненә хезмәт итү, файда китерү турында хыялланмый калмый. Бу — закончалык! Әхим дә бу закончалыктан читтә калмады. Һәрчак аның уенда иде бу хыял.

Болай караганда, ул Олы Ватан хакына аз эшләмәде: аяусыз каты сугышларда катнашып изге җиребезне, илне илбасарлардан чистартуда күп батырлыклар күрсәтте, Берлинга хәтле барып житте; ярты гасырдан артык нефть ятмаларын ачуда бөек казанышлар казанды һәм аларны үзләштерүдә ул бөтен көчен кызганмады, тагын да гаҗәеп мөһим ачышлар ясады; үз үрнәгендә күпме (йөзләгән, меңләгән) яшь кадрлар әзерләде, шул исәптән, татар егетләре һәм кызлары арасыннан да...

Ләкин аның күңеле әле боларга гына канәгать булмады. «Ни өчен соң әле мин бары тик Олы Ватанга гына хезмәт итәм?.. Ә «кечкенә» Татарстаным — туган илем, туган җирем?! Ни өчен әле мин шундый югары әхлаклы, талантлы, гаҗәеп хезмәт сөючән, шул ук вакытта язмыш тарафыннан хәйран кыерсытылган туган татар халкыма тиешенчә хезмәт итә алмадым?! Ни өчен?.. Чөнки мине туган җиремнән аердылар. Безне шулай юк итмәкчеләр

иде, ә без югалмадык! Урта хәлле «крестиян» булу сәбәпле илдән китәргә мәҗбүр ителсәк тә, барыбер баш бирмәдек, күп сандагы авырлыкларны җиңеп кеше булып күтәрелдек. Тик миңа чит җирләрдә йөреп, туган халкымның бәхете өчен генә өлешемне кертә алмадым...

Әгәр дә мин бүген бер бай кеше булсам, бу гаебемне аклый алыр идем. Казанда бер хастаханә яисә мәдәният йорты корыр идем. Китапханә яисә зур бер мәчет, яисә Татарстанның мәдәният музееен ачар идем. Тик миңа, карт пенсионерга каян килсен ул кадәр акча? Булганын да Рәсәй саклык банкы йолкып алды бит. Хыялымны белгәннәрдер, мөртәтләр. Халкына файда итә алмасын әле, дигәннәрдер...

Ә хәзер нишләргә? Йөрәгемдәге хыялларга халкымны сүз белән генә ышандырып булмый бит!.. Тел сөяксез, ул нәрсә сөйләмәс, диярләр...»

Шунда Әхимнең күңеленә бер уй килде. Казанның Тукай урамында гүзәл бер бина — халкыбызның бөек, кабатланмас даһи улы Тукайның музее бар бит. Бу музей, һичшиксез, халкымның бөек милли мәктәбенә, магнитына, яраткан халкымны бер йодрыкка берләштерүче һәм аны үстерүче факторга әверелер. Әйе, әверелер! Әмма аны рухи яктан да, матди яктан да баетырга, үстерергә кирәк.

Әхим шулай уйлады да, Тукайның «Пар ат» шигыренә яңа бер картина ясарга утырды. Картинаның өске өлешенә алтынланган хәрефләр белән Тукай шигырендәге юлларны язды: «Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап...» Ә картинаның аскы өлешендәге почмагына: «И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан! — дип язып куйды.

Шуннан соң озакламый, ул хатыны Лилия ханым белән бу картинаны Казанга алып килеп Тукай музеена бүләк итте. Юк, бу классик рәссам картинасы түгел. Гадирәк. Әмма ул — бөек шагыйребез сүзләренә язылган. Бу үзенең даһи улын яратучы һәм хөрмәт итүче халыктан, халык күңеленнән килә. «Музейга бит күбрәк гади халык йөри, безнең балалар йөри, — ди Әхим, — алар картинаны да, мине дә аңларлар. Чит җирләрдә каңгырып йөргән татар галименең соңгы бүләге дип кабул итәрләр».

Ләкин бу картина, Әхимнең соңгы бүләге түгел иде әле. Үзе килә алмаса да, ул быел җәй Лилия ханым аша үзенең тагын берничә картинасын Казан мәдәни үзәгенә бүләк итте. Аның күптәнге хыялы —туган халкына, гүзәл Казанына бүләк калдыру хыялы чынга ашты. Аз булса да олы галимнең күңеле канәгатьлек тапты.

Рәхмәт Сезгә, Әхим ага! Татар халкы Сезнең изге хыялларыгызны һәрчак күңелендә саклар, ә картиналарыгыз туар буыннарга әче һәм олы язмыш кичергән йөзьяшәр татар галименең бер истәлеге булып сакланыр!..



Сирень
Якупова

# УЕМ – ТАМЧЫ, МОҢЫМ — ЧИШМӘ

***

**Дарухәнә саен керә киләм,**
**Тукранбаш дигән чәчкә-үлән**
**Кирәк миңа**
**Кан тамырын чистартырга.**
**Табиб әйтте,**
**Күзләремә сынап карап,**
**Кат-кат ул кисәтте.**

**Дарухәнә саен керә киләм,**
**Белә киләм, күрә киләм**
**Торган җирем бетереп мин эзләгән,**
**Туган жирдән иелеп мин өзмәгән**
**Ошбу үлән**
**Сатуда бит була икән сирәк!**
**Сатылмый ул, димәк...**
**Хәер, без дә сатылмадык,**
**Киттек үзебез теләп**
**Беркем берни вәгъдә итмәгән,**
**Беркем көтмәгән**
**Чит-ят жиргә.**
**Теләсәк тә кайталмадык аннан**
**Тукранбашлар үскән болыннарга...**
**Сагыну, сагыш, үкенүләр**
**Юшкын булып утыргандыр**
**Тамырларга, буыннарга...**
**Их, аларны бер юарга!**

**... Дару эзлим, дару кирәк.**
**Жан тамыры сызлый –**
**Түзәр микән йөрәк?!**

***

**Әрсез тамчы түгел шул мин,**
**Түбәдән тама торган.**
**Чишмә түгел, таш астыннан**
**Үз юлын таба торган.**

Сирень ЯКУПОВА – *шагыйрә; «Йолдызлы уйлар», «Яшәү сере», «Өстәгеләрдән дә өстә» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Җил дә түгел, киртәләрне
Актарып сала торган.
Гөл дә түгел, иркәләүне
Назланып ала торган.

Алай дисәм,
Уем — тамчы, моңым — чишмә,
Нәфрәтем — җил, сөюем — гөл
Түгелмени?!
Мең халәте күңелемнең
Табигатьнең үземени...

***

Акланып үтте гомерләр
Уйланмаган кара уйлар өчен,
Уйналмаган кызыл туйлар өчен,
Чынга ашмаган зәңгәр хыял өчен,
Дөнья яккан һәр төс—буяу өчен,
Акланып үтте гомерләр.
Булмады тик акланып,
Ак калып...

***

Җәйләрнең кыл уртасында,
Кылт итә дә кышлар искә төшә...
Нишләтәсең инде бу күңелне,
Үз канатын үзе, юләр, кисә.

Бәргәләнә аннан, өзгәләнә,
Оча алмыйм, аһ, мин мескен, диеп.
И әйтәсе килә: газаплан ла,
Үз канатың үзең кистең, диеп.

Тик тыелам. Күңел күбәләгем
Шундый хисле бит ул, шундый нечкә!
Беләм аның кышын очачагын,
Кылт итеп бер җәйләр искә төшсә.

***

Качышлы уйныйм үткәннәр белән,
Мең кат уйналган бик таныш уен.
Тик...
Качуы кыен, качуы кыен...

Табышлы уйныйм көткәннәр белән,
Бер уйналмаган бик серле уен.
Тик...
Табуы кыен, табуы кыен...

Кайчакта уйлыйм: нигә соң уйныйм?
Бүгенгемә, дим, йөрәгем, сыен!
Тик үткәннәрсез һәм көткәннәрсез
Яшәве кыен, яшәве кыен...

***

**Йөрәк мичем тартмый.**
**Моңлы төтен**
**Чыгар юлын тапмый,**
**Тын–сулышны каплый.**
**Күзләремә кереп,**
**Әрнеп, әчеттереп,**
**Тик зар булып саркый...**

**Йөрәк мичем тартмый.**
**Әллә димен**
**Яшәп карыйм якмый?**
**Һай, дөньялар суык...**
**Бер көн якмасам да,**
**Күңел өемдәге**
**Гөлләр үләр туңып.**

**Тартмый йөрәк мичем.**
**Әни, киңәш бирче?**
**Син бит мичче идең,**
**Син бит көчле идең,**
**Син бик хисле идең,**
**Гел күкләрне сөйдең...**

**Мин дә күккә багыйм?**
**Җан–морҗамны барлыйм?**

**Йә Ходаем! Кара!**
**Кайчандыр ак җанга**
**Оялаган карга!**

***

*Күңел тәрәзәмнең пәрдәсе юк...*

**Күңел тәрәзәмә пәрдә алдым,**
**Агын ак та... Элсәм,**
**Калыр микән шулай ап–ак килеш**
**Тән каралган чакта?**

**Күңел тәрәзәмә пәрдә алдым,**
**Киңен киң дә... Элсәм,**
**Тараймасмы күңел, ярыйм диеп,**
**Пәрдә киңлегенә?**

**Күңел тәрәзәмә пәрдә алдым,**
**Эләсеме? Әллә,**
**Ак сөлгеләр итеп бүләсе дә,**
**Өлге–өлге җырлар чигәсеме?**

**Уйга калдым...**

***

**Туйлар узды, туннар тузды дигән,**
**Уйлар килгән саен башыма,**
**Иске тунын әйләндереп киеп,**
**Дөнья чыга көлеп каршыма.**

**Шундый кызык, рәхәт булып китә,**
**Биеп китә күңел, очынып!**
**Ирексездән, ныграк кыса йөрәк**
**Гомер җепләренең очыннан...**



Гүзәл
Әдһәм

# НАЛАСА АВЫЛЫ КӨЕ

ХИКӘЯ

Баз капкачын ачып җибәрүгә, түбәннән күтәрелгән әллә нинди чирканыч ачы ис ни заманнан бирле җүнле ризык күрмәгән ашказанын ертып үтте дә бөтен эчен умырып алды. Хатын, укшып, җиргә чүкте. Бераздан кап-кара булып ырҗаеп торган баз авызына тагын башын сузды, тагын тыны буылды. Эшләр харап иде: берәмтекләп чүпләп, сайлап кына салынган унөч чиләк бәрәңге, череп, сасы тирескә әйләнгән.

Сәкинәнең бөтен тәнен вак калтыравык биләп алды. Ул бермәл, фикерләү сәләтен югалтып, һушын җыялмыйча торды. Кышкы озын төннәрдә, ябыгып шыр сөяккә калган Әнвәрен тән җылысына урап таңнар каршылаганда, аны шушы унөч чиләк бәрәңге барлыгы юатып килгән иде. Почмаклары дымланып карала башлаган шыксыз салкын өендә, казанда пешкән кабыклы кайнар бәрәңге турында хыялланып, күпме рәхәт минутлар кичерде ул. Баздагы бәрәңгенең һәр данәсе күңелдән кат-кат исәпләнгән, күп тапкырлар саналган иде инде. Яндагы бакчага утыртырга тиешле ун чиләктән арткан, түбәләмә өелгән тагын өч чиләк (өч чиләк бит, өч чиләк!) яна уңыш өлгергәнчегә кадәрге озын-озак айларны ялгап җибәрергә тиешле хәзинә булып, тәнгә җылы бөркеп тора иде.

«Бетте, барысы да бетте». Хатын, ыңгырашып, урыныннан кузгалды.

«Инде кышны үткәрдек, язын ничек тә түзәрбез, яшел үлән баш төрткәнче җан асрарга бәрәңгебез бар», — дип йөз-мең кат уйланган хыяллары чәлпәрәмә килде әнә.

— Үзем генә гаепле, үзем генә... Күзләр тидердем лә... Никләр генә шулай шатландым да, никләр ашкындым икән! Белә идем бит югыйсә, әни гомер буе әйтә килде: «Күзең бик каты. Артык куанма да, сокланма да. Чит күзләрдән Ходай үзе сакларммын дигән. Иң яманы — үз күзең тию...»

Арыш саламнарын шактый калын түшәп, бисмилласын әйтеп каплаган иде Сәкинә баз авызын. Дөрес, базны ачарга әлегә иртәрәк иде. Март кояшы көндезләрен шактый гына яктыртып алдаса да, төннәре һаман да салкын, хәтта өй эчендә дә өстән — бишмәт, аяктан киезката төшәргә өлгермәгән

---

Гүзәл ӘДҺӘМ (Шакирова Гүзәл Әдһәм кызы) (1957) *– язучы, КФУның Алабуга институты доценты, филология фәннәре кандидаты. «Асылмалы күпер» дигән пьесалар җыентыгы авторы. Алабугада яши.*

чак. Казан астына яккан коры-сарының гына җылылыгы күзәнәкләргә кереп оялаган суыкны куып тарата алмый шул.

Базны болай иртә ачуга улы Әнвәр сәбәпче булды. Бер чынаяк чәй эчим дип ашыга-кабалана фермасыннан өйгә сугылган чагы иде Сәкинәнең. Мәктәпкә киткән Әнвәрен укытучы Сания чанага утыртып тартып кайтты. Фронттан ире турында «кара пичәтле» хат килгәндә дә болай югалып калмаган хатын, буыннары йомшап, әздән генә җиргә төртелмәде, аннан, исенә килеп, улына ташланды.

— Әллә куркыттыммы, әни? Миңа берни дә булмады, бары тик башым гына бераз әйләнеп китте, — дип, гаепле сыман елмайды Әнвәре.

Зуп-зур башы белән чанада кайтуына оялса да, укытучы апасына каршы әйтергә базмавы булды, ахры, тыныч кына утыра бирде. Сәкинә, ашыга-кабалана, күгәрчендәй җиңел гәүдәле улын күтәреп алды, аның арык тәнен капшый-капшый, бар җиреңнең исәнлегенә ышангач кына җиңел сулап куйды.

Шулай да Сания шактый борчылган иде.

— Ярты сәгать буе аңсыз ятып котымны алды. Их, ипи-сөт муллан булса, егыла торган малаймени ул! Яхшырак ашатсаң, хәзер тернәкләнер иде дә... Ике-өч көн мәктәпкә җибәрми торырсың инде...

Әнә шулчак шатлыгыннан кычкырып җибәрде Сәкинә:

— Бар! Ачылмаган базымда башланмаган өч чиләк бәрәңгем бар!..

Бетте! Барысы да чәлпәрәмә килде!

Чарасызлыктан изелгән хәлсез тәнен өстерәп, хатын өйгә керде. Иске юрган ябынып сәкедә яткан улын уятмаска тырышып, тавыш-тынсыз гына мич буендагы эскәмиягә чүкте ул.

Дүрт ел буе барган рәхимсез сугыш өй эчендәге һәрнәрсәдә эзен калдырып өлгергән иде. Сугыш алдыннан гына салып кергән яна нарат йортның почмаклары да дымланып, күгәреп чыккан әнә. Сатарга мөмкин булган һәрнәрсә сатылып, азык-төлеккә алмаштырырлыгы күптән озатылып, диварлары шып-шыр калган өе хатынга бик кызганыч булып тоелды.

Менә бу карават янындагы стенада кайчандыр зур, затлы келәм эленеп тора иде. Утызынчы еллар ахырында Сәкинәне Мәскәүгә Колхозчылыр съездына делегат итеп сайлаганнар иде дә, келәмне ул шуннан алып кайтты. И-и-и, матур да иде соң! Шул келәмнең аллы-гөлле бизәкләрен күрергә дип Наласадагы берәр хатын кермичә калды микән аларга! Кичләрен ут алганда, Сәкинә үзе дә урам якка караган бер тәрәзә пәрдәсенең читен юри ачык калдыра башлады. «Әйдә, рәхәтләнеп карасыннар, сокланеыннар»...

Заем акчасын шул келәмне сатып түләргә туры килде. Бераздан үзе суккан, читләре матур чигешләр белән чуарланган ашъяулык, җәймә, кашагаларга да чират җитте. Кайчандыр кызыл башлы сөлгеләр белән шыплап тулы сандыгы да бушап, мескенләнеп, почмакта утыра әнә.

Хатын, аптыраудан гаҗиз калып, тагын шул сандыгына барып ябышты. Идән паласының читен күтәреп, яшерелгән урыннан ачкычын алып, бер-ике боруы булды, сандык капкачындагы йозак «келт» итеп ачылып та китте.

Кайчандыр сандык актару Сәкинәнең иң яраткан шөгыле иде. Ә хәзер...

Элекке мул тормышның хәбәрчесе булган сабын, хушбуй исләре катыш нафталин исе борынны ярып керде. Тын юлларын кытыклап, әллә кайларга кадәр үтте дә, күз яшенә әверелеп, сытылып та чыкты. Сандык капкачына беркетелгән «Грамота», открытка бизәкләре җанланып, биешеп алды.

...Менә бу кечкенә төргәк эчендә иренең фронттан язган хатлары һәм кайбер документлар саклана. Сәкинә аны кулына тотып, бер секунд кына уйланып торды. Юк, бүген аларны актарып, хатирәләргә бирелеп утырасы килми икән аның, төргәкне читкә этәрде.

Монысы — улының кечкенә чактагы кайбер киемнәре... Кыска җиңле ак күлмәк белән зәңгәр ыштаннарны ул үзе теккән иде. Юа-юа уңып, төсләрен җуя төшсәләр дә, әле барысы да шактый таза, нык күренгән бу киемнәрне, яшерен өмет-хисләр белән урап, әле сугышка кадәр үк сандык төбенә салган иде хатын. Әнвәренә иптәшкә тагын бер-ике бәбәй алып кайтырмын дип өметләнгән иде ул чакта...

Сәкинә иске генә баш яулыгына төрелгән тагын бер төргәккә үрелде.

Монысы — гармун иде... Әллә никадәр истәлекләр белән бәйле тальян гармун...

Ниндидер кыйммәткә ия, әлегәчә сатылмаган шушы бер тальян гармун гына калды өйдә. Баштарак Сәкинәнең аны сатарга кулы бармады. Бу вакытлыча гына дип саналган мохтаҗлык чорында юк бәягә генә җибәреп гармунны әрәм итәсе килмәгән иде. Менә-менә сугыш бетәр дә, ире дә кайтыр, тормышлар да көйләнеп китәр дип өметләнде. Шул өметне дүртенче кыш асрый хатын. Тик биелгысы иң-иң авыры булгандыр, мөгаен: кыш башында иренең кара кәгазе килсә, хәзер менә Әнвәре дә егылды. Сатам дисә дә, инде тирә-якта гармунга кызыгырдай кешесе дә калмады бугай...

...Ул чакта Сәкинә белән Хәйдәрнең яңа гына өйләнешкән мәлләре иде. Үзләренә аерым йорт салып, башка чыгарга иде исәпләре, язылып, Донбасс шахталарына китеп бардылар. Гаиләлеләрдән Хәйдәр белән Сәкинә генә иде. Бөтен булган җиһазы агач сәкеләрдән торган зур, озын баракта, иске такта кисәкләреннән укмаштырып, үз почмакларын булдырдылар да яшәп киттеләр. Ир-атлар иртүк эшкә таралгач, шыксыз барак көне буена буп-буш кала. Сәкинә баштарак үз «почмак»ларын көйләү, уңайлау белән мәшгуль булды. Тик иңгә-буйга өчәр адымнан артмаган ул бүлмәдә көннәр буе берүзе нишләп утырсын ди? Эч пошудан нишләргә белмичә бәргәләнеп туйгач, үзенә дә эш табуын үтенеп иренә ялварды. Хәйдәре исә аптырады да калды. Күмер шахталарында хатын-кызга яраклы эшне каян табарсың ди.

Барысы да көтмәгәндә хәл ителде дә куйды. Шахтер егетләрнең берсе Сәкинәләр бүлмәсенә өр-яңа чалбар күтәреп керде.

— Аптыраганнан сезгә кердем әле, Хәйдәр. Менә чалбар алдым...

— Шәп булган!Чүпрәге бик тотымлы, нык күренә.

— Анысы шулай да... Бераз зуррак шул.

Сәкинә егеткә чалбарын көйләп бирде. Андый эшләргә кулы ятып тора иде аның. Шуннан китте инде. Егермедән артык ир-егет яшәгән баракта вак-төяк хатын-кыз эше табылып кына торды. Сәкинә берсеннән дә тайчанмады. Кирәк икән, керен дә юды, ямавын да салды. Ә вакыт дигәнең һаман да калды: авылны сагынып, әти-әнине юксынырга да, моңланып җырлап алырга да җитте.

Шахтерлар арасында Галимҗан атлы бер гармунчы егет бар иде. Шунын сәке астындагы капчыктан тальянын алганын Сәкинә түземсезлек белән көтә торган булып китте. Матур уйный иде Галимҗан, үзәкләргә үтәрлек итеп өздерә иде.

Бервакыт, барак идәнен себергәндә, шул капчыкка юлыкты хатын. Куллары, үзеннән-үзе, төенләнгән бавын чиште, аннары бармаклары гармун телләренә кагылды. Бер басты, ике... Тагын басты... Аерыла алмыйча, сәгатьтән артык утыргандыр, имән бармагы белән «Әпипә»не шактый гына шома итеп ерып та чыкты. Күңеле күтәрелеп китеп, тагын, тагын баскалады... «Каз канаты» колакны иркәләде, түзәлмичә, көйләп тә җибәрде:

Каз канатларын санадым,
Очынып кагынганда,
Тулган айларга карадым
Өзелеп сагынганда...

Сәкинә шулай үзенә юаныч тапты, көн узып, кич житкәне сизелми дә башлады. Уйнады да уйнады... Бармаклары житезләнде, остарганнан остара барды, сизгер күнеле, инде эзләнмичә дә, гармунның кирәкле теленә басарга күнекте...

... — Ай-яй-яй! Кем шулай сыздыра дисәм!

Сәкинә корт чаккандай сикереп торды, оят эштә тотылгандай кызарынып, гармунын кая куярга белми бәргәләнде.

— Матур уйныйсың! Көнләшеп тә куйдым үзеңнән...

Хатын каушады. Авыз күтәреп жырлап, гармун уйнап утырганын башкалар белеп алса, көлә башласа? Әле Хәйдәре ни дияр бит?

— Зинһар, берәүгә дә әйтә күрмә! — дип, егеткә ялварды. Галимжан көлде генә. Шулай да серне берәүгә дә ачмады.

Күп тә үтмәде, гармунчы егетне шахта басты. Казып чыгарганда әле аңында булган, бөтен эче янып, шактый вакыт газапланган диделәр. Үлгәндә әйткән соңгы сүзен Сәкинәгә күпләр житкерде:

— Гармунымны Сәкинәгә бирегез, — дигән ул.

Нигә — Сәкинәгә? Берсе дә баш катырып уйлап тормады: «Мөгаен, түләнмәгән бурычы калгандыр», — дип, тальянны Сәкинәгә тоттырдылар...

... — Әни... Әни дим!

Сәкинә «дерт!» итте. Гармунны «ялт» кына сандык төбенә аударып, улы янына ашыкты.

— Хәлең ничек, балам? Башын әйләнмиме?

— Юк... Ашыйсым килә...

Хатын арык беләкләре белән малайны кочып алды.

— Хәзер, хәзер, балам, бераз гына түз...

Үз сүзенә үзе имәнеп китте.

«Бераз гына түз» дидемме? Их, түзеп кенә үзгәртеп булса икән хәлне!

Элек бу сүзне гел-гел кабатларга ярата иде ул: «Бераз түзегез, хәзер кыстыбыем өлгерә... Хәзер токмачым кабара... Хәзер бәлешем пешеп чыга...» И-и-и, булган да икән рәхәт чаклар!

Базда черегән бәрәңгесе исенә төшеп, тагын эсселе-суыклы булып китте. Симәнәгә дигән өлеше турында ул әлегә уйламаска тырышты. Менә бүгенгесе кыйммәт аның өчен. Хәзергесе!

«Ниләр генә ашатырга бу балага!»

...Мәликә күршесе белән элек-электән бер-берсенә ярдәм итешеп яшәделәр. Бары — бергә, югы — уртак дигәндәй...

Соңгы чиктә, бүген дә шуларга кереп егылды Сәкинә. Мәликәнең килене Нурания сугыш алдыннан гына бу йортка төшкән иде. Менә ул да нәкъ Сәкинә кебек тол хәзер. Сәкинә, ярый инде, сугыш чыкканчы алты ел ир белән яшәп калды, улы — Әнвәре — үсеп килә әнә. Ә Нурания соң, Нурания! Сәкинәнең йөрәге кысылып куйды: Нурияянең ирен туй табынынннан ук сугышка алганнар иде.

Көне нинди иде бит! Авылда Сабантуй гөр килә. Күршедә Шәләңгердән төшкән нечкә билле яшь килен туй кунакларын сыйлый. Уен сүз, шаян жыр, татар моңы белән бөтен ишегалды тулган. Киленнең энесе Шәләңгер Нури тальянда сиптерә генә. Уналтысын да тутырмаган үсмернең шулай оста уйнавы бөтен авылны шаккатырды ул көнне. Бармакларына күз дә иярми үзенең. Кем, нинди жыр башласа да, хәзер эләктереп кенә ала. Өздерә генә инде менә! Бөтен Сабантуй аның көенә биеде ул чакта... Күбесе шуннан, бии-бии, фронтка да китеп барды...

...Килен сулык-сулык яшь түкте:

— Энем Нурины госпитальдән кайтарганнар...

— Исән-саумы?

— Исәнен исән дә...

Килен тагын сулкылдады:

— Бер аягы, бер кулы... Төптән үк... Снаряд белән...

— Йа Раббым! Нинди егет иде бит! Нинди егет!

Сәкинә, кабалана-кабалана, киленне тынычландырырга ашыкты:

— Алай ук бетерешмә әле... Башы исән булсын диген. Бер кулы төзек кеше әллә ниләр майтара ул... Безнең авылның Гәрәй карт турында ишеткәнең бардыр бит. Элекке Герман сугышыннан ук кулсыз кайткан, ә анын кебек балта остасы бөтен Арчасында юк иде...

Озата чыккач, Нурания Сәкинәнең «тиләгрике» куенына эре-эре бәрәңгеләр тутырды:

— Ал, әйдә, ал, читенсенмә! Әнвәреңә ашатырсын... Аллага шөкер, Шәләңгердә былтыр бәрәңге бик уңган. Әни безне дә өлешсез калдырмады...

Сәкинә күршедән дәртләнеп чыкты, җитез генә казан астына төртеп җибәрде, кайнап өлгергән суга әрчемичә генә бәрәңгесен турап салды, саклап кына тоткан бер йомарлам каз мае бар иде, читен китеп, анысын шул шулпада эретте. Ымсындыргыч тәмле будан тәрәз пыялалары да парланып китте...

* * *

Шәләнгер авылына сәфәргә Сәкинә бик ныклап әзерләнде. Иртәнге савымны бөтен кешедән алданрак тәмамлап, иң элек Быкыртый Нәсимәсенең кул чанасын сорап алды. Ул чана үзенекеннән шактый зуррак тоелганга, ике капчык бәрәңге иркенләп сыярлык дип тапты. Шактый калын итеп түшәлгән салам өстенә Әнвәре дә чыгып утыргач, бисмилласын әйтеп, юлга кузгалды. Исәбе кичке савымга кайтып өлгерү иде.

Җәй көне булса, Шәләңгергә кадәрге биш-алты чакрымны болын сукмагы буйлап кына үткән булыр иде Сәкинә, тик март башында, әле язгы кояш бик кызганып, саран гына нурын чәчкән бер мәлдә, кар баскан болын буйлап юл салып барырга батырчылыгы җитмәде анын. «Алла сакласын, берәр чокырга төшеп, ерганакларда батып калуың бар. «Урау булса да, тигез юл яхшы» дигәнне хәтерләп, тагын Нурания сүзләрен дә истә тотып, Папа елгасы ярыннан Түбән Аты тавына күтәрелде: элеватордан симәнә ташучылар салган сукмакка шуннан турылап кына төшү иде исәбе. Ул сукмакның кат-кат тапталган, тыгыз һәм ышанычлы булуы күптән мәгълүм иде аңа.

Чанасы шактый «хутлы» булып чыкты. Сәкинә таудан түбән урыннарда шуып кына, тауга таба да әллә ни көч куймыйча, хәйран җиңел атлады.

— Әни, төшим инде... Мин бәбәй түгел бит! — дип киреләнеп маташкан Әнвәренә авыз ачарга да ирек куймады:

— Кире кайтканда чананы этешерсең. Әлегә утырып кына бар. Гармунны саклый күр. Төшеп-нитеп ватыла күрмәсен, — дип, җилдерде генә.

Әнвәрен өйдә калдырса да була иде. Әллә нигә үзе белән аласы итте: яна гына чирдән терелгән чагы, рәхәтләнеп язгы һаваны суласын да, март кояшында иркәләнсен әле диде, аякларын туңмасын дип шакмаклы калын шәленә кат-кат төрде.

Тау башына менеп житкәч, Сәкинә бер генә минутка дип хәл алырга тукталды. Туктады да, борылып, авылына күз салды.

Әнә ул — Наласа... Югары очтан алып зиратка кадәр сузылган озын-озын урамнары җемелдәвек кар астында тып-тын калган. Әнә ике катлы агач мәктәбе караеп басып тора да, аннан бераз гына арырак, мәчетне сүтеп төзегән клубы да кара күләгәдәй сузылып ята. Башка бик күпләр кебек Сәкинә дә ул клубка ияләшә алмый җәфаланды. Ата-бабаларың намазга дип чүгәләгән идәннәрне тыпырдатып биергә ничек җөрьәт итмәк кирәк!? Наласа имамы Сафа хәзрәт үзе бу хәлләргә ничек түзде икән? Казан төрмәсендә

соңгы сулышын алганда, университет белемле уллары Мөхәммәт белән Әхмәтнен янәшә камерада гына кыйналып-газапланып ятуларын сизде микән карт? Әллә яраткан кияве Хәлил мулланың ике сабые һәм кызы Хәдичә белән Себергә сөрелеп юкка чыгуы сабыр касәләренә тамган соңгы тамчы булганмы? Иске мәчетнең диварлары сәҗдәгә оеган картларның монсу карашларын үзенә сендергәндер дә, алары исә Ходай йортын басымчак итүчеләрне үпкә-рәнжешләре белән коендырадыр кебек тоелды аңа...

Авыл тып-тын. Аның, әйтерсең, йорт-җиреннән куылган Сәмигулла, Рәхим, Сабирҗаннар турындагы истәлекләре дә, матчага кыстырылган солдат хатлары да, яшь тамчылары белән чуарланган кара пичәтле кәгазьләре дә юк. Әйтерсең, ул, өмет-шатлыклары, юксыну-сагышлары һәм башка бик күп, бик күп вак-төяк мәшәкатьләре белән тыныч кына язны көтә...

Хатын чана читенә сөялде. Монарчы үзе дә сиземләмәгән, тоймаган ярсу дәртнең әллә кайдан, бик-бик тирәннән, ургылып-ярсып югары үрләвенә чыдый алмыйча, гармун төрелгән теге иске яулыкны тарткалап-йолыккалап сүтә башлады. Бармаклары әнә шул кайгы катыш өметләргә уралган илаһи аһәнне эзләгәндәй, тальян телләрен барлый-барлый, әле югарыга, әле түбәнгә шуышты, төртелде, абынды, тагын, тагын эзләнде...

Ниһаять, ул моң туды! Кар бөртекләрендә чагылып күккә чөелде дә, кояш нурлары белән үбешеп, киредән җиргә сибелде, җемелдәшкән кар чәчкәләрен иркәли-иркәли сыйпап үтеп, бөтен тирә-яктагы ап-ак серле дөньяны кочагына җыйды...

Өзде-е-е-реп га-а-армун уйныйла-а-р
На-а-ла-а-са-а авы-ы-ыл-ы-ы-нда...
Сагнул-а-а арым, сагышла-а-арым
Бу-у-у мо-о-оңлы-ы жы-ы-ырла-а-ары-ы-ымда...

Шакмаклы зур шәлгә төренеп утырган Әнвәр, бераз гына кымшанса яки хәрәкәтләнсә дә шул җырның өзелеп китүеннән курыккандай, әнисенә томырылып өнсез калды.

Ә Сәкинә җырлады да җырлады. Аның көенә, әйтерсең, Хәйдәре көйләгән моңнар да килеп кушылды, шуңа өстәп, тагын бик күп, бик күп Наласа егетләренең җырланмаган җырлары да үрелеп акты...

Хатын, авыз читендәге тозлы тәмне тойгач кына, буй булып сузылган яшьләрен кул аркасы белән житез генә сыпырып алды. Әнвәренә күз салса, анысының иреннәре калтырап, керфекләренә эленгән яшь тамчысы менә-менә тамарга тора икән.

— Ай-яй, кояшы шәп бүген! Күзне ничек чагылдыра! — дигән булды Сәкинә, күзен кыскалап. Үз йомшаклыгына җаны үртәлеп, кинәт кенә башын чөеп җибәрде дә, дәртле, шаян тавыш белән җырын дәвам итте:

Әй, Наласа, Наласа ла,
Наласаны су баса,
Наласаның кызларына
Кияү чыкмый лабаса...

...Сәкинәнең гармун уйнавын авылдагы бөтәннәр түгел, хәтта Хәйдәре дә белми, сизми калды. Бу шөгыль бары тик ир-егетләргә генә хас дип күңеленә беркеткән хатын тальянында гомер-бакый кача-поса гына уйнап килде. Хатын-кызга, бигрәк тә әни кешегә, гармун тартып җырлап утыру ниндидер оят бер эш кебек тоелып, бу һөнәре барлыгын сер итеп шактый озак саклады ул. Тик газиз баласы Әнвәрдән генә яшереп кала алмады.

...Кичен бәрәңге бакчасы аша уеннан кайтып килгән Әнвәр көтелмәгән

хәлдән каушады да калды ул чакта. Мунчадан көй агыла иде. Малайның коты очты. Кояш баегач, кара мунчада җырлап-биеп утырган җен-париләр турында аның әллә никадәр әкият ишеткәне бар иде. Мөгаен, шулардыр! Ул — җиргә сеңде. Буразналар арасына посып, мунчадан ишетелгән серле хикмәтне шактый озак тынлап ятты. Кара, кара! Җеннәр дә татар көйләрен белә икән бит! Әнисе җырларга яраткан «Баламишкин», «Арча»ларны сиптерәләр генә!

Куркуы бераз басыла төшкәч, бисмиллаларын укып, тәрәзәсеннән күз салырга да батырчылыгы җитте. Мунча эче кап-караңгы һәм берни дә күренми иде. Кинәт, көтмәгәндә, ишеге шыгырдап ачылды да, аннан ... әнисе килеп чыкмасынмы!? Җеннәрнең кеше кыяфәтенә кереп, зыян салып йөрүләре турындагы имеш-мимеш хәтерендә яңарып, малай чырылдап кычкырып җибәрде. «Җен» кисәк борылды да әнисе тавышы белән аңа дәште:

— Кайттыңмы, улым? Нигә шулай кычкырасың? Әйдә, ашатам үзеңне, карының ачкандыр, — дип, Әнвәргә таба атлады.

Малайның йөрәге бугазына ук килеп бөялде.

— Җеннәр... Мунчада... Бииләр... җырлыйлар... — дип, тотлыга-тотлыга сөйләнде дә сөйләнде.

Сәкинә төенчеген чишеп тальян гармунын күрсәткәч кенә малай тынычлана төште, аннан:

— Уйна! — дип анасына сарылды.

Буразналар арасыннан сак кына «Әнисә», «Әпипә»ләр агылды...

Ана белән баланың уртак сере барлыкка килде. Икәвесе генә аулакта калган чакларда, теге тальян да сандыктан чыгарылып, Сәкинә Әнвәрне гармун уйнарга өйрәтә башлады. Тик сугыш башлангач, бу шөгыль үзеннән-үзе онытылды.

Тальян гармун янә сандыкка бикләнде...

* * *

Шәләңгер дигәннәре илле-алтмыш йортлы кечкенә генә авыл икән. Иң башта Нурания ләр өенә сугылырга булдылар. Күрше килене әти-әнисенең хәл-әхвәлен белешүләрен бик үтенгән иде. Алар килгәч, өстәлгә самавыр менде, тирләп-пешеп бер-ике чынаяк кишер чәе чүмерделәр, мичкә тәгәрәткән бәрәңгеләре теленне йотарлык тәмле иде.

Почмак яктагы сәкедә ятучыга Әнвәр баштарак игътибар да итмәгән икән. Тегесе торып утыргач, сәер күренешкә аптырап, малай бөтенләй телсез калды. Аяксыз-кулсыз уң ягына авып китүдән курыккандай, сул кулы белән сәке читенә чытырдатып ябышкан егетне күргәч, Сәкинә үзе дә бермәл аптырап торды, тиз генә һушын җыеп, исәнләшергә ашыкты:

— Нихәл, Нури, терелә сеңме?

Егет ябык, ак чыраена бер дә туры килмәгән көр тавыш белән аңа җавабын бирде:

— Ә-ә-ә! Наласалар килгән икән! — дип, галәмәт олы, зур учын Әнвәргә сузды.

— Оһо-һо! Йә, егет, кызлар озата башладыңмы инде? — дип, аның аркасын шапылдатты.

Аннары сәке астыннан үрелеп таягын тартып чыгарды да, җитез генә күтәрелеп, әле чатанлап, әле тыраклап-титаклап ишеккә таба юнәлде. Тәрәзәдән күзләп торган Әнвәрне шаккатырган тагын бер хәл булды: Нури, ялт кына күлмәген салып атып, аркасын, күкрәген, битен, уч-уч кар алып, уа, ышкый башлады.

Юк, мескен түгел иде бу егет! Көч-куәте һаман да ташып торган яралы арысланнарга тиң ниндидер тыелгысыз күтәренке рухка, эчтән ургылып чыккан дәрт-дәрманга ия иде ул.

Ниһаять, чират гармунга да җитте. Аны тотып кайсы йортка барып

керергә, авылдагы кемнен бәрәңгегә алмаштыру мөмкинлеге булуы турында хуҗалар белән киңәшләшү киткәч, Нури никтер сүзсез торды, сонрак кыюсыз гына тамак кырып куйды.

Аннары:

— Әни, гармун мина калсын әле, — дип, өмет тулы сагышлы күзен әнисенә төбәде.

Бар да тып-тын калды. Әллә нинди унайсыз, читен бер тынлык иде бу.

...Ике капчык бәрәңге салынган чананы тартып Наласага таба атлаганда да шул җайсыз тынлыктан арына алмадылар алар. Әнвәр еш-еш борынын тартты, мыш-мыш килеп, дәшми-тынмый гына чананы этте дә этте.

Ана белән улны тоташтырып торган теге уртак сер дә иртәнге томандай таралды, эреде, юкка чыкты кебек ...

* * *

Көннәр, төннәр, айлар, еллар үтте дә китте...

Әнвәр үсте, башта — егет, аннан ир дә булды. Сугыш хатирәләре дә акрынлап онытыла, хәтердән җуела барды. Тик теге гармун, ике капчык бәрәңгегә алмашкан тальян гармун мәнге-мәңгегә күнел түрендә калды анын. Кызганыч иде ул, бик-бик кызганыч иде! Кулсыз солдатнын шүрлегендә ята-ята, мөгаен, әллә кайчан телләре күгәреп, тавышлары карлыгып беткәндер инде анын. Сәкинәнең чанага утырып уйнаган теге көе дә ул гармуннын ин сонгы җыры, соңгы сулышы булган, ахры.

Шунысы гаҗәп: әнисе бервакытта да тальянны исенә төшермәде, сагынып хәтергә дә алмады. Ничек шулай бик тиз онытты соң ул аны? Әллә, күңелен әрнетмәс өчен, уйламаска тырышуы гына булдымы?

Шулай да, авырып урын өстенә егылгач, ябыгып, бөрешеп беткән карчык Әнвәргә сонгы теләген җиткерде:

— Гармун уйныйсым килә!

Әнвәре сикереп торды.

— Хәзер табып китерәм, әни!..

Сәкинә, күзен йомып, хәлсез бармакларын хәрәкәтләндерә башлады, күңеле белән нииндидер көй бормаларын исенә төшерергә тырышты, тик бармаклары, кирәкле гармун телен таба алмагандай, һаман эзләнде, буталды, ялгышты, аннары бөтенләй хәрәкәтсез калды.

— Теге гармун булмагач... Кирәкмәс инде...

Әнвәр уянып киткәндәй булды.

Табарга! Табарга кирәк ул гармунны! Тальянга җан керсә, әнисе дә терелер дигән хыялый уйлар бөтен аңын биләп алды да аны юлга чыгарга этәрде.

...Күршедәге килен инде күптән калада яши иде, хәтта төс-кыяфәте дә хәтердән җуелып беткән. Әнвәр берәүдән дә сорашмады, җиенды да Шәләнгергә таба юл алды, андагы кайбер танышларын исенә төшерергә тырышып атлады да атлады.

...Наласа мәктәбенә, бишенче сыйныфтан башлап, ел саен бер-ике Шәләңгер укучысы өстәлеп килә иде ул чакта. Барысы да озын буйлы, көчле, таза малайлар иде. Физкультура дәресенә тезелгәндә, сафта беренче булып шулар торыр иде. (Шәләнгердә әллә кызлар бик сирәк туганмы, алары никтер юньләп хәтерендә дә калмаган анын.) Уку ягыннан әллә ни алдынгылардан булмасалар да, чаңгы-шахмат ярышларында Шәләнгерләрне җиңгән берәр кеше булды микән? Аз сүзле, сабыр, эшчән малайлар иде алар: Миндияр, Габдуллаҗан, Рафаэльләр...

Әнисе теге чакта гармун уйнаган урынга җиткәч, Әнвәр туган авылына борылып карады.

Әнә ул, Наласа! Куе яшеллек арасында калай түбәле төзек йортлары ничек

кукраеп утыра аның. Әнә, авылдан читтәрәк, Рәбига чишмәсе... Чәберкә елгасыннан башланып киткән Югароч урамнарындагы җанлылык моннан ук күренеп тора. Болайрак — Балтай чишмәсе, тагын да арырак — Аю тавы, аннан түбәнрәк — зират... Барысы да якын, бик-бик кадерле икән бит!

...Әмма Шәләнгерне тапмады ул. Бакчалары, җимеш агачлары исән, читтәрәк зираты шаулап утыра... Тик авыл — юк. Авыл таралган иде. Габдуллажан, Рафаэль, Миндиярларны таш шәһәр үзенә суырып алган...

Шәләнгер дигән авыл ерак-еракларгы үткәндә генә торып калган икән...

* * *

Гармун тавышы Әнвәрне урамга әйдәде.

Йа Хода! Мондагы җыр, шаян сүз, дәртле биюләр! Тальян тавышы бөтен Казанны әсир итеп, иң туң йөрәкләрне дә үзенә буйсындырып өлгергән икән бит. Ул, шул җыр-моңга кушылып йөзгән халык агымына ияреп, шәһәр үзәгенә дә килеп чыкты.

Кабан күле, Театр мәйданы янында гармун моңы тагын да үсте, тагын да көчәйде. Кинәт... бер мизгелгә генә дөнья тынып калды кебек...

Куәтле микрофон тавышы бөтен Казанга хуҗа әнә:

— «Уйнагыз, гармуннар!» дип исемләнгән халык талантлары концертын дәвам итәбез!

Әнвәр дә сәхнәгә якынрак килде. Шулчак милли киемдәге гармунчылар арасыннан күкрәге орден-медальләр белән тулган берәү аерылды да, шактый гына аксый төшеп, сәхнә уртасына чыкты. Конферансье егет аңа урындык тәкъдим итте, бик җитез кыланып, алдына гармунын да китереп куйды.

Кемнәрдер канәгатьсезлек белдереп пышылдашып алды: егет картка тальянны дөрес ягы белән тоттырмаган иде. Әнвәр дә борчылды.

— Телле ягы — унга, бакасы — сулга булырга тиеш! — дип, әздән генә кычкырып җибәрмәде.

Әмма карт тыныч иде. Ул ашыкмый-кабаланмый гына сул кулы белән уң җиңнән күренеп торган тимер башлы ниндидер ыргакны гармун каешына беркетеп куйды.

Әнвәр тынсыз калды — картның уң кулы юк иде.

Менә ул, шаян елмаеп халыкка карап күз кысты да, тальянын тартып җибәрде. Гармун күрекләре арасына сыеша алмыйча ташып чыккан иләһи, моңлы аһән, күзгә күренми торган ниндидер серле дулкыннарга уралып, әле күккә күтәрелде, әле кояш нурлары белән үбешеп, киредән җиргә сибелде:

Өздереп гармун уйныйлар
Наласа авылында-а-а,
Сагнуларым, сагышларым
Бу моңлы җырларымда...

Халык тантана итте, үзләре дә сизмичә, кулсыз гармунчының көенә кушылып җыр сузды:

Наласаның күлләрендә
Тезелеп йөзә аккошлар.
Үсеп җиткәч, чит җирләрдә
Йөртә безне язмышлар...

Мәйданда патшалык иткән шушы моң агышында әнисенең тавышы да яңгырап-яңгырап киткәндәй тоелды Әнвәргә...



Таһир
Шәмсуаров

# СИНЕҢ БАРЛЫК КИРӘК ДӨНЬЯДА

## Кеше язда җиргә якыная

**Кеше язда җиргә якыная,
Үзгәрә дә куя язларын.
Сандугачлы шомырт чәчәкләре
Сөйли аңа сөю, наз барын.**

**Кеше язда җиргә якыная,
Арына да кышкы киемнән.
Гөрләвекләр белән йөгерә ул,
Яланаяк чыгып өеннән.**

**Кеше язда җиргә якыная,
Язын көтү аны яшәтә.
Җирдән күтәрелгән яшәү пары
Тора салып аны яшәртә!**

**Елмаюны язлар бирә аңа,
Ул җыр көйли язга карата.
Йөзе нурлануга гаҗәпләнмә —
Ул тормышны шундый ярата!**

**Күзләр сөременнән арынырга
Ярдәм итә чыклы иртәләр.
Башын әйләндереп болыннарда
Күпме чәчәк җанын иркәләр.**

**Кеше язда җиргә якыная,
Бу чынбарлык күптән язылган.
Бәхет канатында очсын дисәң,
Аермагыз аны языннан...**

Таһир ШӘМСУАРОВ (1954) – *шагыйрь; җирле нәшриятларда чыккан берничә китап авторы. Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылында яши. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

## Бикләнмәсен иде капкалар

Күршеләргә бик еш керәлмисең,
Көне-төне бикле капкалар.
Кайда соң сез тәмле ризык керткән
Нурлы йөзле юмарт апалар?!

Утлы күмер эзләп йөгермибез —
Чормаларда күптән самовар.
Табасы да, агач кашыгы да
Үзебездә бүген — өйдә бар.

Печән алып кайтсак, сәнәк тотып
Йөгереп керми хәзер күршеләр.
Ак әбиләр бисмилласын әйтеп
Башыбыздан сыйпап үтмиләр.

Туган-тумачаның балаларын
Тик төсмерләп кенә таныйбыз.
Ни аяныч, байлык арткан саен,
Фәкыйрьләнә бара җаныбыз!

«Кайнар коймак авыз итегез!» — дип,
Балкып керсен юмарт апалар.
Күрше хакы — тәңре хакы икән —
Бикләнмәсен иде капкалар!..

## Август җыры

Күрәсеңме, август китеп бара,
Сары яфрак элеп таңына.
Ә мин менә сиңа кайтып барам,
Атап кайтам синең яныңа.

Үкенү дә, үтенү дә юктыр,
Үткән көннәр, әйдә, үтсеннәр.
Кем булсаң да, кайда яшәсәң дә,
Кайтуыңны синең көтсеннәр.

Арып-талып юллар гизгән чакта,
Кояштан да алда торганда —
Мин бәхетле, диеп әйтер өчен,
Синең барлык кирәк дөньяда!

Әйдә, малкай, кояш чыгар якка,
Тояк асларында чык кына.
Юк, без әле, соңармадык бугай,
Алларына басар чак кына.

Сизәсеңме, август китеп бара,
Сары яфрак элеп таңына.
Ат апкайта мине, атап кайтам
Китмәскә дип — синең яныңа!..

## Пар кабер

Кырык бердә ике җан дус
Унсигез яшькә җитте.
Сабан туе мәйданыннан
Илне сакларга китте.

Шул малайлар Яурупаны
Фашизмнан коткарды.
Бер уң аяк, бер сул аяк
Герман җирендә калды...

Сыңар аякта кайтсаң да
Ишек ача туган як.
Икесенә — ике аяк,
Култык астында — таяк.

Ике яшьти-көзен шулай,
Базарга бергә керде.
Бер пар итек. Берсе уңны,
Ә берсе сулны киде.

Бакый дөньяга күчсә дә
Онытылмый исемнәре,
Хуҗасы кигәнне көтә
Сагышлы итекләре.

Җиңү алып кайткан ирләр,
Тидеме сезгә кадер?!
Берсе-уңда, берсе-сулда,
Сыңар түгел — пар кабер!

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге документлар булу мәҗбүри:

1. Паспорт күчерелмәсе (титул, прописка бите).
2. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы күчерелмәсе.
3. ИНН күчерелмәсе.
4. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
5. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп).

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVII КОРЫЛТАЕ

2012 елның 18 маенда Татарстан язучыларының XVII корылтае булды. Әдипләр жыенына Татарстаннан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән 260 язучы делегат булып килгән иде. Язучылар корылтаенда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова, мәдәният министры Айрат Сабагатуллин, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Россия Язучылар берлеге рәисе урынбасары Владимир Бояринов, Башкортостан Язучылар берлеге рәисе Риф Тойгын һ.б. катнаштылар.




Татарстан язучылары корылтаен кереш сүз белән халык шагыйре Равил Фәйзуллин ачты. Язучылар берлеге идарәсенең ике корылтай арасында эшчәнлеге турында хисап белән Илфак Ибраһимов чыкты.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов корылтай делегатлары алдында чыгыш ясады. Соңыннан Президент Рәдиф Гаташка «Татарстан Республикасының халык шагыйре», Марсель Галиевка «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исемнәр бирү турында таныклыклар, танылган драматург Ризван Хәмидкә «Фидакарь хезмәт өчен» медален тапшырды.

Жыенда ревизия комиссиясе рәисе Фарсель Зыятдинов доклады тыңланды. Мәскәү кунагы В.Бояринов һәм Башкортостан язучылар делегациясе житәкчесе Р.Тойгын Татарстан язучылары корылтаен сәламләп чыгыш ясадылар.

Ике корылтай арасында әдәби процесс, аның үсеш-үзгәреше, табыш-югалтулары турында ике доклад тыңланды. Язучылар идарәсе каршында эшләп килүче шагыйрьләр остаханәсе житәкчесе Зиннур Мансуров татар шигъриятенең торышына бәя биреп, берлекнең әдәби консультанты Ркаил Зәйдулла хәзерге проза турында чыгыш ясадылар.

Докладлар буенча фикер алышуда катнаштылар: берлекнең рус әдәбияты һәм тәржемә остаханәсе житәкчесе Лилия Газизова, Марсель Галиев, тәнкыйть остаханәсе житәкчесе Равил Рахмани, Фоат Садриев, Айдар Хәлим, Газинур Морат, Рафис Корбан, Гәүһәр Хәсәнова, Язучыларның Чаллы оешмасы рәисе Вахит Имамов, Фәтхулла Абдуллин...

ТР Мәгариф һәм фән министры урынбасары Данил Мостафин чыгыш ясап, Язучылар берлегенең мәктәпләр, балалар бакчалары белән бәйләнешенә, татар әдәбиятын укыту, аның сыйфаты, программаларга камил эчтәлекле әсәрләрне

кертү һ.б. мәсьәләләргә игътибарны җәлеп итте. Башкортостаннан килгән әдәбият галиме Раиф Әмиров үзенең чыгышында татар әдәбиятының Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә яшәвенә, аларга игътибарлы булу, уртак әдәби процесс буларак тикшерү, өйрәнү кирәклегенә тукталды. Төркиядән килеп Татарстанны һәм татар әдәбиятын үз иткән Фатих Котлы байтак еллар инде татар әдәбияты үрнәкләрен төрек теленә тәрҗемә итеп, аның таралышына гамәли өлеш кертә. А.Гыйләҗевның Фатих әфәнде тәрҗемәсендә Төркиядә өч тапкыр басылып чыккан «Өч аршын җир» повестенең Евразия язучылар берлеге премиясенә лаек булуы — шуның уңышлы нәтиҗәсе.

Мәдәният министры А.Сибагатуллин язучыларның республика мәдәни тормышында зур роль уйнавын, халыкның рухи ихтыяҗларына уңышлы җавап биреп килүен билгеләде, киләчәктә дә үзара аңлашып, киңәшләшеп эшләргә чакырды. Соңыннан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г.Исхакый, Һ.Такташ, Ф.Хөсни, Ж.Вәлиди исемендәге әдәби бүләкләрен тапшырды.

Корылтай ТР Язучылар берлеге идарәсенең эшчәнлеген «канәгатьләнерлек» дип бәяләде. Җиде ел дәвамында берлек рәисе булып эшләгән Илфак Ибраһимов әдәби процессны тиешле дәрәҗәдә оештырып, әдипләрнең таркалмыйча, үзара аңлашып һәм максатчан эшләвенә ирешә. Илдәге кризиска бәйле, дәүләт тарафыннан матди ярдәмнең нык кимүенә карамастан, өлкәннәрнең көнкүрешенә ярдәм ителде. Яшь авторларны барлау, туплау, кызыксындыру, иҗатларына этәргеч бирү буенча җитди чаралар күрелде. Танылган шәхесләрнең юбилейларын, шулай ук әдәбият һәм сәнгать кичәләрен үткәрү планлы рәвештә алып барылды.



Корылтайда язучылар җитәкчесе итеп сайлануга дүрт кандидат күрсәтелеп, күпчелек тавыш белән Рафис Корбан ТР Язучылар берлеге рәисе итеп сайланды. 25 кешедән торган яңа идарә составы түбәндәгечә: Рәмис Аймәт, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Лилия Газизова, Марсель Галиев, Галимҗан Гыйльманов, Нәбирә Гыйматдинова, Ркаил Зәйдулла, Рөстәм Зәкуан, Вахит Имамов, Илсөяр Иксанова, Рафис Корбан, Ләбиб Лерон, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Рүзәл Мөхәммәтшин, Илүсә Нәбиуллина, Вакыйф Нуриев, Рифә Рахман, Гәрәй Рәхим, Данил Салихов, Равил Фәйзуллин, Зиннур Хөснияр, Ленар Шәех.

Фикер алышу барышында әйтелгән эшлекле тәкъдимнәр нигезендә корылтай резолюция кабул итте.

Бу санда корылтайда ясалган төп чыгыш-докладларның берничәсен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.



Равил
Фәйзуллин,
Татарстанның халык шагыйре

# КОРЫЛТАЙ АЧЫЛЫШЫНДА ЯСАЛГАН ЧЫГЫШ

Мөхтәрәм Президент!
Хөрмәтле каләмдәшләр — корылтай делегатлары!
Кадерле кунаклар!

Бүген безнең өчен, гомумән, җәмәгатьчелек өчен зур вакыйга. Ниһаять, без, күпмедер югалтулар аша булса да, бергә күмәк җыела алдык. Җыелганбыз икән, күп съезд-корылтайлар күргән өлкәннәр дә, әдәбиятка яңа аяк баскан яшьләр дә нәрсәгәдер өмет белән, киләчәктә яхшыга үзгәрешләр булуын теләп килде бу залга. Әмма, күреп торабыз, дөнья яшәеше, тормышыбыз шактый катлаулы, хәтта әйтер идем, кайбер хәлләребез шактый ук аянычлы. Халкыбызның милләт буларак саклану мәсьәләсе, телебез һәм мәгариф язмышы, яңа буыннарның иман-әхлагы һәм, ниһаять, үзебезнең тереклек итү шартлары, матди мөмкинлекләребез... Үзегез беләсез, дөньяның көйсезлеге иң әүвәл гади халыкны, бигрәк тә нечкә күңелле җаннарны — талантларны яралый... Бүгенге көндә намуслы язучы булу — үзенә күрә бер батырлык ул.

Әмма без бирегә зарланыр өчен түгел, булдыра алган кадәр киләчәк өчен игелекле гамәлләр кылырга ниятләнеп җыйналдык. Аның өчен безнең ихтыярыбыз да, көчебез дә, нигезебез дә бар.

Без Россия күләмендә үрнәк итеп куярлык иҗат союзыбызны, берлегебезне бүлгәләнмичә, бердәм булып саклап кала алдык. Китаплар чыгару буенча да күрше-тирә халыклар белән чагыштырганда алда барабыз. Интернет челтәрендә «Татар әдәбияты китапханәсе»н гамәлгә кую да бер зур эш булды. Тәрҗемә эшен җанландыру буенча байтак эшлекле чаралар үтте. Һәм, ниһаять, бүген капиталь ремонттан соң гаҗәеп затлы бинабызны ачтык. Болар, әлбәттә, республика җитәкчелегенең булышлыгы, теләктәшлеге белән тормышка ашырылды. Иҗат эше никадәр генә индивидуаль булса да, эш нәтиҗәләре буенча барыбер күмәклеккә, ягъни, укучыларга, киң җәмәгатьчелеккә барып тоташа. Укучыларың булмаса, язуның мәгънәсе дә калмас. Язучы һәм укучы арасындагы бәйләнешне ныгыту иң мөһим мәсьәләләрнең берсе бүген.

Хөрмәтле каләмдәшләр!

Без бүген соңгы еллардагы эшләргә хисап бирү белән бергә, киләчәккә бару юлларын да ачыкларга тиешбез. Докладлар, чыгышлар булыр. Яңа идарә сайланыр. Без бу җыенда, зур максат куеп, вакланмыйча, зур тарихлы әдәбиятның лаеклы варислары булып, әдипләрчә эш алып барырбыз дип уйлыйм. Хәерле сәгатьтә!

Татарстан Язучыларының XVII корылтаен ачык дип игълан итәм.



Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Республикасы Президенты

# «ТӨП СЫЙФАТ — ТАЛАНТ ҺӘМ ҺӨНӘРИ ОСТАЛЫК»

Хәерле көн, хөрмәтле язучыларыбыз! Бүген бик җаваплы көн. Татарстан язучылары съезды республика тормышында зур вакыйга. Бүгенге көнне без яхшы эшләрдән башладык: ниһаять, сезнең үтенечегез канәгатьләндерелде — иртән без янартылган Язучылар йортын карап чыктык. Әлбәттә, бу үзгәрешләр киләчәктә язучылар иҗатына уңай тәэсир итәр дип уйлыйм.

Хөрмәтле язучылар, сез бүген эшегезгә нәтиҗәләр ясыйсыз, үз алдыгызга бурычлар куясыз. Белгәнебезчә, дөнья глобальләшүгә таба бара. Әмма рухи кыйбла җәмгыять өчен төп ориентир булды һәм шулай булып калырга тиеш. Бу мәсьәләдә әдәбият җитди роль уйный: аның иң мөһим бурычы — туган телне, рухи кыйммәтләрне саклау, мәгърифәт-белем тарату. Минем уйлавымча, мәгълүмати җәмгыять шартларында да язучы сүзенең абруе элеккечә бик югары булып кала. Хәзер мәгълүматны тапшыруның зур мөмкинлекләре бар. Иң мөһиме — мәгълүматның эчтәлеге тиешле югарылыкта булуы кирәк. Заманча технологияләр безгә әдәбиятыбызны башка регионнарга, халыкара мәйданга чыгарырга мөмкинлек бирә.

Аңлашыла ки, язучы кеше үзе дә билгеле бер таләпләргә җавап бирергә тиеш. Үрнәк алырдай кешеләр бездә һәрвакыт булды һәм бар. Күптән түгел арабыздан киткән хөрмәтле Туфан ага Миңнуллин шундыйлардан иде. Андый кешеләр безнең өчен нигез, терәк булып тора.

Безгә җитди рәвештә яңа эш алымнарын барларга, әйтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алырга кирәк. Бүгенге фикер алышуда республика җитәкчелегенә дә теләкләр җиткерелер, дип уйлыйм. Тормыш тормыш инде. Гади кешегә кагылган мәсьәләләр язучыга да кагыла. Бөек төшенчәләр хакында фикер алышканда да без тормыштан аерылмаска, язучыларыбыз турында кайгыртырга тиешбез. Вакыт-вакыт үз фикерләрегезне безгә ирештереп торсагыз, бик дөрес булыр.

Әйткәнемчә, бүген әдәбиятны үстерү, пропагандалау өчен заманча технологияләр, глобаль челтәрләр бар. Беренчедән, басма әдәбият булса, икенчедән, электрон әдәбият формалаша. Минем уйлавымча, һәр икесенең дә үз урыны бар. Басма әдәбият һәрвакыт булган һәм булачак, ә электрон форма безгә алга үсәргә җирлек тудыра. Дөнья барыбер үзгәрә. Яшь буын электрон мәгълүмат чараларын бик актив куллана, һәм без аларга булышырга тиешбез. Татарстанда «Электрон китап» проекты бар, Татарстан китап фонды да электрон версияне хәрәкәткә китерергә тиеш. Китап басу — ул зур чыгымнар, дигән сүз, ә электрон форма чыгымнарны киметергә һәм яңа әсәрләрне укучыга җиткерергә мөмкинлек бирә. Минем уйлавымча, без электрон версия ярдәмендә иң беренче чиратта басылырга тиешле, иң күп укыла торган әсәрләрне дә билгели алачакбыз. Заманча мөмкинлекләрне файдаланырга кирәк, дип саныйм.

Мин сезнең игътибарны чит ил һәм Россия язучылары тәҗрибәсенә юнәлтергә телим. Алар сайтлар, блоглар булдыра. Үзеңне пропагандалау, тәкъдим итү өчен бу форма бик кирәк. Мин ышанам, шушы формада эшләү үзен аклар һәм сезне күпләр белә башлар.

Электрон форма барлыкка килү белән авторларга гонорар түләү мәсьәләсе туа. Монда да яна методлар, янача якын килү булачак. Электрон китап чыгаручы да авторлык гонорары алырга тиеш, шуңа күрә бүгенге корылтай кысаларында без «Татмедиа» агентлыгына, Мәгълүматлаштыру һәм элемтә, Мәдәният министрлыкларына түләү системасы механизмын эшләргә йөкләмә бирербез. Тагын бер кат искәртәм: бу яңалыклар китап бастыруга берничек тә тәэсир итмәскә тиеш. Бу өлкәдә дә яна технологияләр бар, алар да эштә кулланыла.

Бу урында тагын берничә мәсьәләгә киңрәк тукталып үтәсем килә. Аның беренчесе — әдәби әсәрләрне тәрҗемә итү. Әлеге эш системалы рәвештә башкарылырга тиеш. Безнең республика киңрәк танылa бара, безгә бик күп кунаклар килә. Татарстан һәм татар халкы турындагы, шулай ук икътисадка, тарихка багышланган әсәрләрне тәрҗемә итүне тиешле югарылыкка куярга кирәк.

Икенчесе — китапка мәхәббәт тәрбияләүне гаиләдән, балалар бакчасыннан башларга иде. Соңгы елларда без «Бәләкәч», «Киләчәк» программаларына зур игътибар бирәбез, мәктәпне реформалаштыру бара. Китаплар кызыклы һәм бай эчтәлекле булырга тиеш. Бу, әлбәттә, язучылар эше генә түгел, бу — хөкүмәтнең дә бурычы. Без бергә эшләргә тиешбез. Яңа барлыкка килгән «Татар иле» порталы, «ТНВ-Планета» каналы — алар һәммәсе әдәби иҗатның дәрәҗәсен күтәрүгә хезмәт итәргә һәм Татарстанда чыккан яңа әсәрләрне укучыларга, Интернет кулланучыларга житкереп барырга тиеш.

Бүген бик күп көндәлек матбугат, китаплар басылып килә. Боларның кайсысы файдалырак, югарырак икәнен билгеләүдә тәнкыйтьчеләрнең роле зур булырга тиеш. Алар гади укучыга өстенлекләрне билгеләргә ярдәм итәчәк. Профессиональ тәнкыйтьче барыннан да бигрәк укучыга кирәк.

Бүген язучыларның сафы ишәюе турында әйтелде. Язучы кешенең дә төп сыйфаты — талант һәм һөнәри осталык. Бу критерийлар сакланырга тиеш. Сезнең арага кабул ителгән яшьләр шул таләпләр югарылыгында тәрбияләнсә, яхшы булачак. Татарстан Язучылар берлегенең Россия Язучылар берлеге составына керү-кермәү мәсьәләсен каләм ияләре үзләре хәл итәргә тиеш, дип уйлыйм. Әмма элемтәләр булырга тиеш. Эрерәк оешмага керү — ул яңа бурычлар алу дигән сүз. Бәлки, бергә эшләүнең башка формаларын табаргадыр. Мин фәкать барлык иҗат берлекләре белән дә хезмәттәшлек итәргә кирәклеген генә әйттем. Россия күләмендә грантлар бар. Алар безнең Татарстанда да булырга тиеш. Ул — талантлыларга ярдәм итү формасы.

Корылтай ул һәрвакыт күпмедер хисап бирүне күздә тота. Уйлавымча, биредә тәнкыйть тә, тәкъдимнәр дә булыр. Республика Президенты буларак та, мин сезгә рәхмәтле. Безнең мәдәниятебезгә, тарихыбызга мөнәсәбәт, җәмгыятьтәге урыныбыз сезнең әсәрләрегез тәэсирендә дә формалаша. Сезгә хезмәтегез өчен ихлас рәхмәтемне житкерәм. Безнең арада тыгыз элемтә булырга тиеш. Безгә — сезне, сезгә безне ишетү кирәк. Киләчәктә дә республикабыз яңа уңышларга ирешсен өчен, бергәләп эшләргә насыйп булсын.



Илфак Ибраһимов,
Татарстан Язучылар берлеге рәисе

# МӘДӘНИ ҮСЕШКӘ ЙӨЗ ТОТЫП...

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ИКЕ КОРЫЛТАЙ АРАСЫНДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА ХИСАП ДОКЛАДЫ

Хөрмәтле каләмдәшләр, корылтаебыз кунаклары!

Республикабыз Язучылар берлегенең XVI корылтаеннан соң нәкъ 4 ел узып китте. Дүрт ел дәвамында без башкарган барлык дөньяви эшләр тарихка-хәтергә күчте, ә һәркайсыбыз язган әдәби әсәрләр китап укучыларга һәм вакыт хөкеменә тапшырылды.

Узган чор халкыбыз тормышында, ил-көндә истәлекле вакыйгаларга бай булды: Бөек Җиңүнең 65 еллыгы, Язучылар берлеге төзелүгә 75 ел, Татарстан Автономияле Республика буларак төзелүгә 90 ел; Россия күләмендә халык санын барлау һ.б. Татар халкы, төрки халыклар бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуны Евразия киңлекләрендә билгеләп үттеләр. Тукайның олуг юбилее татар халкын барлау, ана телебезне зурлау, әдәбият үсешенә көчле рухи этәргеч биргән вакыйга булды. Әлеге чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә Татарстан Язучылар берлеге, киң җәмәгатьчелек актив катнашты.

Хөрмәтле каләмдәшләр! Бүгенге җыенныбыз ике корылтай арасындагы эшләребезгә анализ ясау гына түгел, ә XXI гасырның, өченче меңьеллыкның беренче ун елында әдәбиятыбыз-мәдәниятебез үсешенә дә билгеле бер дәрәҗәдә йомгак ясау, киләчәгебезне күзаллау, кичекмәстән хәл итәсе мәсьәләләрне һәм, гомумән, ил-көнебез, милли мәдәниятебез язмышы хакында тирәнтен фикерләшү дә булыр дигән нияттә торабыз.

Язучылар берлеге идарәсе, бүгенге корылтайга хисап докладларын әзерләү мәсьәләсен караганда, аны дүрт өлештән торган мәгълүмат формасында тәкъдим итәргә булды. Әдәби иҗат процессының торышы хакында: татар поэзиясе, татар прозасы, рус телендәге әдәби иҗат турында аерым өч доклад һәм Язучылар берлеге рәисенең идарә эшчәнлеген оештыру буенча хисабы. Бу чыгышларны бербөтен итеп кабул итүегезне сорыйбыз.

Ике корылтай арасында Язучылар берлеге идарәсе, киң әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан үткәрелгән барлык чаралар хакында махсус җыентык чыгарылып, һәркайсыгызга тапшырылды. Алар хакында һәм әдәбиятыбызны пропагандалау буенча үткәрелгән барлык чаралар, шул исәптән дистәләрчә юбилейлар турында сөйләүнең хаҗәте юктыр. Алар барысы да узган корылтаебызда кабул ителгән резолюция таләпләреннән чыгып оештырылды. Язучыларны үзебезнең һөнәри оешма тирәсенә туплау-берләштерүдә әлеге чаралар мөһим урын алып торып, берләшмәбезнең нигезен ныгытырга ярдәм иттеләр.

Хисап жанры таләп иткәнлектән, узган корылтайда кабул ителгән карарларның аерым бүлекләре үтәлешенә, идарә һәм аның рәисе тарафыннан башкарылган аеруча мөһим эшләргә тукталырга бурычлымын. Иҗат берлегенең нигезен

нычыту дигән жөмләне турыдан-туры аңлау да кирәктер. Авария хәлендәге Язучылар бинасын төзү-төзекләндерү мәсьәләсе корылтайдан корылтайга иң югары дәрәҗәдә күтәрелүгә карамастан — хәл ителмәде. Алай гына да түгел, узган корылтаебыздагы киеренкелеккә төп сәбәпче булып, барыбызның да кәефен жибәргән иде... 2008—2010 кризис елларында ремонт эше бөтенләй тукталды. 2010 елда Республикабыз Президентына Язучылар берлегенең бинасын төзекләндерүне генә түгел, гомумән, бөтен проблемаларны күрсәтеп, бигрәк тә язучыларның каләм хакы — гонорарларының түбән булуын, китап бастыру һәм тарату буенча үзебезнең теләк-тәкъдимнәребез белән мөрәҗәгать иттек. Рөстәм Нургали улы безнең мөрәҗәгатебезгә бик игътибарлы һәм җаваплы карады. Бик тиз арада Мәдәният министрлыгына, Финанс министрлыгына, Төзелеш-торак, комуналь хуҗалык министрлыгына, «Татмедиа» агентлыгына, нәшриятларга мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән мәсьәләләрне уңай хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләргә күрсәтмә бирде.

Бөтен эш процессларын сөйләп-әйтеп тормыйм, Илбашыбыз безнең барлык сорауларыбызны уңай хәл итте. Беренче чиратта, аның күрсәтмәсе белән 2011 елдан дәүләт нәшриятында басылган китаплар, әдәби журналларда басылган әсәрләр өчен гонорарлар түләү 150% күтәрелде. Китаплар бастыру өчен өстәмә рәвештә 26 миллион сум күләмендә акча бүлеп бирелде. 2012 елда исә узган елдагы өстәмәләр күләмендәге акча бюджетка ук кертелде. 2011 елдан башлап, дәүләт китап нәшриятында басылган һәр китапның 85 % күләмендәге тиражы турыдан-туры дәүләт китапханәләренә җибәрелә башлады. Шулай итеп, болай да түбән гонорарларны китаплата-натуралата түләү кебек кимсетүле гамәл бетерелде.

Бу көннәрдә озак еллар ремонт күрмәгән бинабызда реставрация-төзекләндерү эшләре төгәлләнеп килә. Президентыбыз ярдәме белән моның өчен 98 миллион күләмендә акча бүлеп бирелде. Ремонт эшләренең баруын шәхсән үз контролендә тотты. Язучылар берлеге бинасында элек Габдулла Тукай исемендәге клуб бар иде. Яңа бинада әлеге клуб өчен 180 урынлы зал булдырылды. Г.Тукай клубы, барлык эш бүлмәләре өчен 4 миллион сумга өр-яңа җиһазлар, тавыш аппаратлары, мебельләр сатып алынды. Язучылар берлеге бинасының язучыларга булачагында бүген бернинди дә шик калмады.

Татарстан Язучылар берлеге бинасын шундый зур чыгымнар бәрабәренә ремонтлау-реставрацияләү — ул тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне, биналарны саклау буенча Республикабыз җитәкчелеге үткәргән яңа сәясәтнең беренче күркәм нәтиҗәсе! Әлбәттә, шундый таләпләр 2-3 ел алданрак булса, Тукаебызның куышы булган «Болгар» номерлары җимерелмәгән булыр иде.

Хөрмәтле Рөстәм Нургалиевич, барлык язучылар, иҗат интеллигенциясе Сезнең тарихи һәм милли мәдәни һәйкәлләребезне саклау буенча үткәргән сәясәтегезне тулысынча яклыйбыз. Без Сезнең милли Республикабызның бөтен матбугаты, мәгарифе, язма мәдәнияте үсешенең бер гасыр дәвамында үзәге булган, Казанның Бауман урамындагы атаклы Матбугат йорты бинасын төзекләндерү турындагы күрсәтмәгезне дә хуплыйбыз. Әлеге бина татар китабы йорты булып, аның беренче катындагы китап кибете татар язучысының, татар әдәбиятының йөзен билгели иде. Сезнең ихтыяр белән һәм турыдан-туры катнашуыгызда ул яңадан милләтебезгә кайтарылыр дигән ышанычта һәм өметтә яшибез. Бауман урамындагы матбугат йорты — милли китап нәшрияты булып та, милли китап кибете булып та хезмәт итәр иде. Без шулай ук Республикабыз милли китапханәсенең яңа бинасы төзелешен дә Сезнең исем белән бәйлибез.

Язучылар берлегенең яңа бинасы республикабызның милли әдәби-мәдәни үзәге булып хезмәт итсен өчен, безгә үзебезнең һәм иҗади, һәм иҗтимагый активлыгыбызны бермә-бер арттыру сорала. Моннан 4-5 ел элек Язучылар берлеге каршында әдәбият-сәнгать өлкәсендә эшләүчеләрнең сәясәтчеләр, милли байлар, дин әһелләре һәм башкалар белән аралашу-фикерләшү урыны буларак «Зыялылар клубы»н оештыру теләге белән йөргән идек. Хәзер моның өчен бөтен шартлар да бар һәм бу эшкә кичекмәстән алыну кирәктер.

Узган корылтайда ук «Яшь әдәбиятчылар клубы»ын төзү хакында әйткән идем. Яшь иҗатчыларны барлый алдык, байтагын Язучылар берлегенә хакыйкый әгъзалар

итеп кабул иттек, инде 30 яшькә каләрге 30га якын яшь язучыбыз һәм галимебез бар. Алар да бу бинада үзләренең чараларын үткәрә алачаклар. Югыйсә, кем өчен төзедек тә, кем өчен җиһазладык соң аны — яшьләребез өчен түгелмени?! Язучылар берлеге бинасы өр-яңадан тернәкләнеп килүче республикабызның Әдәби фондын да үз түбәсе астына кертергә тиеш.

Билгеле булганча, Язучылар берлеге бинасында безнең әдәби басмаларыбыз булган «Идел», «Салават күпере» журналлары редакцияләре урнашкан иде. Аларга «Татмедиа» агентлыгы уңай шартлар тудыру буенча эшлекле чаралар күрә. Без үз бинабызда иҗат секцияләре өчен мәйданнарны киңәйтә алачакбыз. Язучылар берлеге бинасы үзе үк, архитектура һәйкәле һәм мәдәни мирас буларак, безнең милли әдәбиятыбыз тарихын чагылдыручы музей хезмәтен дә үтәргә тиештер. Ә Габдулла Тукай исемендәге клуб һәм залыбыз әдәбиятыбызны пропагандалау мәйданы, трибунасы ролен үтәр дип ышанабыз.

Бинабыз Мәдәният министрлыгының тарихи һәйкәлләрне саклау идарәсе тарафыннан безгә килешү буенча тапшырыла. Ул — республика милке. Аны киләчәктә Мәдәният министрлыгының дәүләт учреждениесе статусына күтәреп, карап тору, эксплуатацияләү өчен махсус штатлар билгеләүне сорау дөрес булыр. Язучылар йорты буларак дәүләт учреждениесе дә булып теркәлсә, анда эшләү өчен штатлар бирелсә, бу язучыларга өстәмә эш урыны да булыр иде...

Хөрмәтле каләмдәшләр! Язучы һәм җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләр язма әдәбият мәйданга чыккан вакытта ук барлыкка килгәндер, мөгаен. Ул бер генә яклы түгел. Бер яктан, язучы, үзенең язма иҗаты белән иҗтимагый фикер әйтеп, җәмгыятькә мөнәсәбәт белдерсә, икенче яктан, җәмгыять исеменнән хакимият үзе язучыдан шул идарә системасы өчен яраклы һәм кирәкле фикер әйтүне теләгәндер. Борын-борыннан бу мөнәсәбәтләрнең меннәрчә төрдәге чагылыш үрнәкләре бар: тоталитар җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләр, демократия чикләнгән җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләр, тулы демократия урнашкан илдәге мөнәсәбәтләр. Милли әдәбиятыбыз тарихы да әнә шул мөнәсәбәтләрнең тарихи тупламасы дисәк, хакыйкатьтән китү булмастыр.

XXI гасырда демократик мөнәсәбәтләр һәм гражданлык җәмгыяте төзелүгә юнәлеш алган безнең илдә милли әдәбиятыбызның гражданлык активлыгы үз югарылыгында калды дип әйтергә бихисап күп мисалларыбыз бар. Ике корылтай арасындагы иҗтимагый вәзгыятькә мөнәсәбәт белдергән дистәләгән публицистик язмалар, шигырь һәм поэмалар, эссе һәм романнар язылды. Милли мәктәпләребезне саклау, ана телебезне үстерү турында булсынмы, хак тарихыбызны яктырткан фәнни-әдәби иҗат булсынмы, халыкара террорчылыкның сәбәпләренә карата булсынмы, милли мирасыбыз, тарихи һәйкәлләрне саклау турында булсынмы, «Болгар» номерлары, «Булгария» теплоходы фаҗигаләре хакында булсынмы — барысы хакында да татар язучысының иҗтимагый активлыгын чагылдыручы мисаллар күп булды. Дөрес, бер-беребезне иҗтимагый пассивлыкта, куркаклыкта, яраклашуда тәнкыйтьләвебезне дәвам итәбез. Бу үзе дә иҗтимагый активлыкның капма-каршылыктан гыйбарәт бер күренеше.

Иҗтимагый активлык, дәүләтне һәм җәмгыятьне тәнкыйтьләүгә багышланган публицистика гына түгел, ә бәлки шул җәмгыятьтә яшәүче кешеләрнең язмышлары, тирән кичерешләре, рухи-психологик киеренкелек шартларында кылган гамәлләре, ягъни табышлары, югалтулары, фаҗигаләре аша чагыла. Бу очракта һәр язучы — миссионер. Ул үз максатына үз ысулы, стиле, иҗади осталыгы, акылы, яшәү тәҗрибәсе белән ирешә. Иҗтимагый активлык әдипләрнең иҗатын барлаучы, анализлаучы тәнкыйтьчеләр һәм галимнәр иҗатына да шул югарылыкта ук таләп ителә.

Әдәби процессны оештыру Язучылар берлегенең төп вазифасы булган дәверләрне өлкән язучыларыбыз әле дә булса сагынып искә алалар. Күрәсең, бер яктан, иҗат иреге чикләнү, көчле цензура шартларында, икенче яктан, әдәби иҗатны үстерүгә тулысы белән дәүләт кайгыртуы гарантияләнгән шартларда язучыларыбыз үз максатларына ирешү юлларын-ысулларын тапканнар. Дәүләт идеологиясе тәкъдим иткән, мөһим дип күрсәткән дистәләрчә темаларны үз итеп, иҗат ихтыяҗларына

һәм мәсләкләренә якын итеп алып хезмәт куйганнар... Әлбәттә, милли язучыларның төп мәсләге дәүләт заказын үтәүдән бигрәк, ана телебезне саклау-үстерү, туган халкыбызның әдәбиятка, әдәпле сүзгә булган, үз халкының олы тарихын дөрес чагылдырган әдәби әсәрләргә ихтыяҗын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән иде. Шуна күрә дә без милли әдәбиятыбызның киләчәге ничек булыр дигәндә, үзенең гасырлар дәвамында формалашкан традицияләренә нигезләнеп үсәргә тиеш дип белдерәбез. Милли әдәбиятыбызның үсеш процессы дөнья әдәбияты һәм мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә барырга тиеш дип беләбез. Бердәм әдәби мохитне булдыру иҗат берлегенең бүгенге һәм иртәгәсе көндәге беренче дәрәҗәдәге бурычы да.

Ике корылтай арасында Язучылар берлеге идарәсе, Фәннәр академиясе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре белән берлектә, «XXI гасыр татар әдәбияты, татар әдәби теленең сакланышы һәм үсеше тенденцияләре»; «Яшь язучылар иҗаты»; «Балалар әдәбияты: бүгенгесе һәм үсеш перспективалары» дигән темаларга фәнни-гамәли конференцияләр уздырды. Әлеге конференцияләр максатчан рәвештә язучыларыбыз өчен һәм күпчелек әдипләр катнашында 2009, 2010, 2011 — әдәби ел йомгаклары кысаларында үткәрелде. Конференциядә ясалган докладлар, чыгышлар аерым җыентыклар булып бастырып чыгарылды һәм алар безнең каләмдәшләребезгә, бигрәк тә яшь язучыларга кулланма булып та хезмәт итәр дип уйлыйбыз. 2008 елда Әлмәттә «Милли драматургиянең бүгенгесе һәм киләчәге» дигән темага барлык драматурглар, театр режиссерлары һәм директорлары катнашында семинар булып узды.



*ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов Татарстан Язучылар берлегенең яңартылган бинасында. 2012 ел, 18 май.*

Әдәби процессны оештыруда, бигрәк тә яшь каләм ияләрен барлауда иҗат фестивальләре хәрәкәтенең мөмкинлекләре зур. Отчет чорында Язучылар берлеге идарәсе алдагы чорларда ук «Идел» яшьләр иҗат үзәге тарафыннан гамәлгә куелган «Иделем акчарлагы», Татнефть ачык акционерлык җәмгыятенең «Рухият» Янарыш фонды белән эшли башлаган Сажидә Сөләйманова исемендәге яшь иҗатчылар фестивальләрен оештыруга турыдан-туры катнашты. Яшь язучыларның әсәрләрен рецензияләү, редакцияләү һәм бастырып чыгаруга безнең тәҗрибәле язучыларыбыз һәм галимнәребез дә актив алынды. 2009 елда Казан дәүләт гуманитар педагогика университеты, хәзерге Идел буе федераль университетының Филология һәм сәнгать институты, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты һәм Язучылар берлеге идарәсе тарафыннан өченче зур иҗат фестивале —«Илһамлы каләм» — гамәлгә куелды.

Әйткәнемчә, фестиваль хәрәкәтенең мөмкинлекләре зур. Ул моңа кадәр эшләп килүче әдәби берләшмәләрнең эшчәнлеген дә активлаштыра, бер максатка, юнәлешкә туплый. Фестивальләр әдәби көчләрне барлау һәм, гомумән, бөтен әдәби процессны тулаем күзалларга мөмкинлек бирә. Отчет чорында Язучылар берлегенә алынган барлык яшьләребезнең санап үткән фестивальләрдә чыныгып, олы иҗатка юллама алганнарын барыбыз да беләбез. Киләчәктә бу хәрәкәткә тагы да оешкан төс биреп, аның матди чыгымнарын да кайгырту кирәк булачак.

Әдәби иҗат процессы нәшрияттән аерым була алмый. Республика китап

нәшрияты «Мәгариф» нәшрияты белән берләштерелде һәм бердәнбер дәүләт нәшрияты булып калды. Финанс кризисы ин тәэсирле 2009-2010 елларда язучыларның китапларын бастыру бермә-бер кимеде. Шөкер, 2010, 2011 елларда исә янәдән темпланнар кабул итеп, язучыларыбызның җыентыкларын бастыра алдык. Нәшрият дирекциясе һәм Язучылар берлеге идарәсенең килешүе буенча Яшь язучыларның беренче китапларын бастыру, берлек әгъзаларының юбилей басмаларын эшләү гамәлгә керде. Нәшрият дирекциясенә Бөек Җиңүнең 65 еллыгы уңаеннан фронтта һәлак булган язучыларыбызга багышланган «Каһарман каләме» җыентыгын, Г.Тукайның 125 еллыгына багышлап, Мәскәү әдипләре башкарган өр-яңа тәрҗемәләрдән төзелгән «Тукайның язгы фаэтоны»н, Идел буе халыкларының алты телендә Г.Тукайның шигырьләр җыентыгын бастыруда ярдәм иткәне, шулай ук Төркия һәм Төрекмәнстан кебек илләрдә, Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Пермь кебек шәһәрләрдә «Татарстан мәдәнияте, әдәбияты көннәре»н үткәрүдә китап күргәзмәләре белән катнашып, татар әдәбиятын пропагандалауда зур өлеш кертүләре өчен рәхмәтебезне җиткерәбез. Китап нәшрияты Халык язучылары һәм Халык шагыйрьләренең күптомлыкларын бастырып чыгаруын яңартты.

Көндәлек әдәби процесс безнең әдәби басмаларыбызда бара. «Татмедиа» агентлыгы карамагындагы «Казан утлары», «Идел», «Мәдәни җомга», «Мәйдан», «Салават күпере», «Сөембикә», «Ялкын», «Казан», «Казан альманахы» журналлары, кризис киеренкелеге булуга карамастан, үзләренең тиражларын һәм даими укучыларын саклап калды. Отчет чорында Чаллы каласында рус телендә «Аргамак» журналы гамәлгә куелды. Быелның май аеннан өр-яңа фәнни-популяр, әдәби-нәфис «Мирас» журналы нәшер ителә башлаячак. Бер сүз белән әйткәндә, республикабыздагы әдәби басмаларның санап үткән үрнәкләре гамәлдә булуы — безнең казанышыбыз, дәүләтебезнең олы кайгыртуы дип тану фарыз. Ә журналларның сыйфаты, әдәби зәвыклылыгы, затлылыгы, үз укучыларын табуы — болар барысы да редакцияләрнең җаваплы хезмәткәрләреннән һәм безнең һәркайсыбыздан тора.

Һәр ни-нәрсә вакыт сынавына дучар. Дүрт ел элек корылтайда яңа дәвердә милли әдәбиятыбызны үстерү, яшь әдәбиятчыларны барлау, гомумән, иҗат процессын тәэмин итүгә юнәлтелгән резолюция-карарлар да җитди сынауга хөкем ителгән икән. Ни дәрәҗәдә реаль чынбарлыкка нигезләнгән булган ул?.. Юкса, һәр пункты уйланып, киләчәкне күзаллап язылган иде.

Узган корылтайның резолюциясендә Казан дәүләт университетының татар теле факультеты базасында татар әдәбиятчыларын, тәрҗемәчеләрен әзерләү буенча махсус төркем ачарга тәкъдим ителгән иде. Тормыш безнең хыялларга үз төзәтмәсен керткән булып чыкты. Идел буе федераль университеты статусына кадәр күтәрелгән югары уку йортында татар теле һәм әдәбияты тарихы факультеты бөтенләй ябылып, федераль университет составына кергән Филология һәм сәнгать институты кысаларында гына калды безнең булачак язучыларыбызны тәрбияләргә тиешле факультетыбыз! Ни кызганыч, Мәдәният министрлыгы белән фаразланган яшь язучылар өчен стипендияләр булдыру да хыял гына булып чыкты. Дөрес, без отчет чорында хөкүмәтнең 2 грантын — узган ел Г.Тукай әкиятләре буенча аннимацион фильмнар төшерү һәм быел яшь язучыларыбызның әсәрләрен бастырып чыгару буенча — оттык. Бүген сезнең кулларга тапшырылган яшь язучыларның антологиясе — шуның нәтиҗәсе.

Алдагы корылтайда Мәскәүдәге Әдәбият институтына өметле яшь язучыларыбызны дәүләт стипендиатлары итеп җибәрү мәсьәләсе дә куелган иде. Анда укуга юллама алып урнашкан ике язучыбыз, финанс кризисы сәбәпле дип әйтик, укуларын калдырып кайттылар. Киләчәктә бу эшне өр-яңадан башлыйсы булыр.

Соңгы ике елда «Тюрксой» халыкара оешмасы һәм Мәдәният министрлыгының юлламасы буенча ике яшь язучыбызны Төркиягә әдәби тәрҗемәчеләр әзерләүче курсларга җибәрә алдык.

Әдәби тәрҗемә — иҗат процессының мөһим бер тармагы. Киләчәктә милли әдәбиятыбызны яңа киңлекләргә чыгару, әдәби багланышларны киңәйтү фәкать әдәби тәрҗемә аша гына мөмкин булуына беркемнең дә шиге юктыр. Ни кызганыч, узган корылтайда дәүләт китап нәшриятында махсус әдәби тәрҗемә бүлеге булдыру,

аны финанслау һәм тәрҗемә әдәбиятны дәүләт заказлары тәртибендә алып бару билгеләнгән булса да, ул тормышка ашмады. Шулай ук алдагы елларда хөкүмәтнең «Дәүләт телләрен үстерү» программасы буенча безгә бүлеп бирелә торган акча да, күп тапкыр мөрәҗәгать итүгә карамастан, безгә 4 ел дәвамында бер тапкыр да бирелмәде. Шуна да карамастан, әдәби тәрҗемә буенча безнең Язучылар берлегенең иҗади мөмкинлекләре әлегәчә сакланды. Яна сайланган идарә һәм аның рәисенең бу юнәлештә максатчанрак эшләве сорала.

Әдәби иҗат процессын оештыру юнәлешенә шулай ассызыклап тукталуыбыз, киләчәктә Язучылар берлегенең төп игътибары әлеге мәсьәләләргә юнәлтелергә тиешлегеннән, әлбәттә! Иҗат берлеге иҗатлы булырга тиеш. Һәрбер каләм иясе үзенең иң шаһ әсәрләрен язуны билгесез ераклыкка күчермичә, бүген-иртәгә язу өчен үзен әзерләргә, иҗат итәргә тиеш!

Әдәби иҗат процессы әдәби иҗатны стимуллаштыруга да бәйле. Язучылар берлеге идарәсе тарафыннан озак еллар дәвамында бу эшнең билгеле бер системасы, механизмы булдырылды: әдәби иҗат елына йомгак ясау, әдәби иҗатның төрле жанрлары буенча әдәби премияләр тапшыру, язучыларның иҗат кичәләрен уздыру, аларны дәүләт бүләкләренә тәкъдим итү һ.б. Отчет чорында, моңарчы гамәлдә булган Державин исемендәге премия бөтен Россия күләмендәге премия статусына күтәрелде. Узган ел Язучылар берлеге һәм Актаныш муниципаль район хакимиятенең Гамил Афзал исемендәге премиясе гамәлгә куелды. Әдәби иҗатны стимуллаштыру, иң югары дәүләт бүләге, Г.Тукай исемендәге бүләктән мәхрүм ителүне исәпкә алмаганда, нәтиҗәле файдаланылды һәм берлекнең иҗат потенциалын үстерде дип әйтә алабыз.

Яшәешебезгә үтеп кергән электрон куллану техникасы казанышлары басма китапларга, матбугат басмаларына карата булган мөнәсәбәтләрне дә үзгәртә. Интернет, виртуаль аралашу чаралары инде һәркайсыбызның көндәлек кулланылышына үтеп керде. Отчет чорында республикабызда «Электрон китапханә»гә нигез салына башлады. Без моңа төрлебез төрлечә мөнәсәбәт белдерсәк тә, киләчәк көннәребездә әдәби иҗат процессын электрон китаплардан башка күзаллап булмастыр. Бу юнәлештә хәл итәсе бердәнбер мәсьәлә — авторлык хокукларын саклауның гарантияләнүе һәм һәр язучының электрон китаплар чыгаруга шәхси теләге булу-булмау исәпкә алынырга тиешлеге... Электрон китапханә, нигездә, моңарчы традицион ысулда басылган китаплардан төзелә. Бу очракта да авторлык хокукы буларак, язучыга бер тапкыр каләм хакы түләүне хәл итү зарур. Ул традицион китап бастыру тарифларыннан кимрәк тә булырга мөмкин. Бер сүз белән әйткәндә, яна сайланган идарәгә бу мәсьәләне беренче планга куюны тормыш үзе үк таләп итәчәк.

Язучылар һәрчак халык белән очрашу ихтыяҗын кичерәләр. Аларга трибунлык хас. Соңгы елларда республикабыз радио-телевидениесендә язучылар катнашында күп кенә тапшырулар оештырылды. Язучыларыбызның иҗат, юбилей кичәләренең язмалары даими күрсәтелде. Әмма радио, телевидениедә әдип сүзе, язучы мөнбәре булырдай тапшырулар программасын оештыра алганыбыз юк. Бу максатта берничә еллар элек ТНВ житәкчелегенә язмача мөрәҗәгать итүебездән соң, «Шигърият», «Шигъри тәлгәшләр» һәм «Мәдәният дөньясында» тапшыру программасы кысаларында «Әдәбият дөньясында» тапшырулары гамәлгә куелды. Безне бигрәк тә «Яна гасыр» телерадиокомпаниясенең, «Болгар» радиосы һәм «Татар радиосы»ның талымсызлыгы, зәвыксызлыгы борчый. Турыдан-туры эфирда бозык тел белән примитив юморга корылган уеннар, табышмаклар, бернинди әдәби кануннарга сыешмаган сүзләрдән төзелгән җырлар белән эфирны пычрату һаман дәвам итә. Радиода әдәби тапшыруларга урын бирү өчен эфир вакытын табып булыр иде югыйсә.

Язучылар берлегенең янартылган бинасында «Яшел камин»нар, «Шигъри мизгел»ләр, «Әдәби кич утыру»лар, «Түгәрәк өстәл»ләр һәм башка исемдәге яна цикллар ачып, телевидение, радио аша халкыбызга милли әдәбиятыбыз, ана телебез, халык иҗаты җәүһәрләрен, нәфис сүз сәнгате үрнәкләрен житкерә алыр идек. Бу — язучыларга яна эш урыны да булыр иде.

Узган корылтайда мәктәпләр өчен яна әдәбият дәреслекләре әзерләү, хрестоматияләрне янарту тәкъдимнәре булган иде. Бу максатта хөкүмәтебезнен дә аерым карары булып, шөкер, Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан бу эш башланып китте. Язучылар берлегенен тәнкыйть, проза, поэзия һәм балалар әдәбияты остаханәләре яна дәреслекләргә язучыларыбызнын әсәрләрен кертү буенча тәкъдимнәрен әзерләде. Безнең язучыларыбыз, галимнәребез дәреслекләр төзү буенча эшче группаларга тартылды. Уртак эшләребез нәтиҗәсен якын арада күребез дигән ышанычта торабыз.

Хөрмәтле каләмдәшләр! Ике корылтай арасында Язучылар берлеге идарәсе тарафыннан әдәби багланышларны җәелдерү буенча да күп кенә чаралар күрелде. Элеккеге СССР Язучылар берлегенен дәвамчысы буларак оешкан Халыкара язучылар оешмалары берләшмәсе, Россия Әдәбият фонды, Мәскәү язучылар оешмасы, «Дружба народов», «Наш современник» журналлары, «Литературная газета» әдәби басмалары, Башкортостан, Удмуртия, Чувашия, Якутия, Пермь өлкәсе, Ульян өлкәсе язучылар берлекләре, Төркиянен Евразия язучылар берлеге һәм «Кардәш әдәбиятлар» журналлары белән иҗади элемтәләр урнаштырып, алар белән бердәм чаралар үткәрелде. Язучыларыбызнын тәржемә әсәрләрен санап үткән газета-журналларда бастырып чыгару оештырылды. Шулай ук Бөтендөнья татар Конгрессы Башкарма Комитеты белән берлектә Россия төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребез өчен әдәби-мәдәни чаралар оештыруда язучыларыбызнын катнашуына ирештек. Төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезгә йөзләрчә данәдә китапларыбызны туплап бүләк иттек. Язучылар берлеге идарәсе 2010 елда Рәсәй күләмендә үткәрелгән халык санын алу уңаеннан Татарстан язучыларынын бөтен татар халкына мөрәҗәгатен кабул итеп, аны милли-мөхтәриятләр һәм 46 төбәккә 64 язучы-шагыйрьләребезне иҗади командировкага җибәрү аша халыкка юлладык. Отчет чорында бу чараларны үткәрүдә Мәскәү, Ижау, Ульяновск, Чиләбе шәһәрләрендә яшәп иҗат итүче язучыларыбызнын да иҗтимагый активлыкларын билгеләп үтәр идем.

Әдәби багланышлар, алдагы чорда да Язучылар берлегенен төп эш юнәлешләренең берсе булачак. Бу мәсьәләдә безгә, телибезме-теләмибезме, Россия Язучылар берлеге белән хезмәттәшлек итү юлларын табасы булыр. Ике корылтай арасында, Россия Язучылар берлегеннән аларның чираттагы съездына чакыру килгәч, дөресрәге делегатлар сайлап җибәрүләрен сорап мөрәҗәгать иткәч, без бу мәсьәләне өч тапкыр идарә утырышында тикшердек. Россия Язучылар берлеге съездында Туфан ага белән мин фәкыйрегез кунак буларак катнашып чыгыш та ясадык. Без үз позициябезне — әгәр киләчәктә илдә бердәм иҗат берлеге төзелсә, Татарстан Язучылар берлеге аны оештыручы буларак, анa кирәчәк дигән фикеребезне җиткердек. Бүгенге көндә Татарстан Язучылар берлеге — Россия Язучылар берлеге составында булмаган бердәнбер оешма. Әмма бу — безнен өстенлегебез, табышыбыз димәс идем. Россия Язучылар оешмасы вертикаль структурада оешкан булса да, нинди дә катгый вертикаль идарә урнаштырмый. Шул ук вакытта үз оешмаларына, бүлекчәләренә Россия хөкүмәте билгеләгән төрле грантлар, фондлар аша матди ярдәм күрсәтүдә ул шактый эшләр башкара. Без, Россиягә налог түләүчеләр буларак, ул грантларга хокукыбыз булуга карамастан, алардан әлегә үзебезне-үзебез мәхрүм итәбез.

Язучылар һәм җәмгыять, шул исәптән хакимият арасындагы мөнәсәбәтләрнен иң мөһиме — язучынын социаль статусы, аның гражданлык һәм авторлык хокукларынын сакланышы. Ни кызганыч, Рәсәй күләмендә әлегәчә бу мөнәсәбәтләр иҗат кешеләрен канәгатьләндерми. Иҗат берлекләре — җәмәгать оешмасы статусында, ул үз эшен шуңа нисбәтле законга нигезләп оештыра. Шуңа күрә, бүген язучы хезмәтенә үзешчән хезмәт, хобби дип карау күзәтелә. Хоббины дәүләт тарафыннан үстермәскә дә мөмкин бит. Ә бит иҗади хезмәт нәтиҗәсе — китап — ул шул ук дару, шул ук азык, шул ук дәреслек, шул ук фән, шул ук сәнгать. Алар барысы да үзешчән иҗат белән түгел, ә эш сәгатьләре чикләнмәгән хезмәт нәтиҗәсе. Язучынын хезмәт хакы — аның хезмәтенә тәңгәл булырга тиеш. Безнең хезмәт хакы — кулланучылар кулында. Радио-телевидениедә, интернетта язучыларнын публицистик чыгышларына, лекцияләренә түләүләр тарифы кертелсә, язучы үзе

дәүләткә тагы да күбрәк налог түләр иде. Республикабыз хөкүмәтеннән һәм Дәүләт Советыннан бу максатта Россиянең закон кабул итү органнарына тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итүләрен сорыйбыз. Без үз тәкъдимнәребезне 2006 елда ук әзерләп биргән идек, киләчәктә дә тәкъдимнәребезне бирә алабыз.

Ни кызганыч, безнең күз алдыбызда ил күләмендәге бердәм әдәби процесс, бердәм мохит таралып, югалып бетеп бара. Әлбәттә, ил җитәкчелегенең мәдәнияткә булган мөнәсәбәте үзгәрмичә, ил буенча «Мәдәният турында», «Иҗат оешмалары турында» өр-яңа законнар кабул ителмичә, бердәм Язучылар берлеге төзү озак вакытлар билгесезлектә калачак. Аерым була торып, без ул законнарны эшләү, үз тәкъдимнәребезне әйтү хокукыннан да мәхрүм әлегә. Моннан егерме еллар элек үзара ниндидер килешү булган икән, ул кайсыдыр як тарафыннан үтәлми икән, аның егәре-көче шулай гына булган дигән сүз. Димәк, килешүнең, хезмәттәшлекнең яңа юлларын эзләү кирәк. Бу мәскәүләрдән бигрәк, безнең өчен аеруча кирәк дип уйлыйм һәм бу хакта да фикерләшү кирәктер бүгенге корылтайда.

Отчет чорында вафат булган каләмдәшләребезнең исемнәрен мәңгеләштерү, аларның иҗади мирасларын саклау, кабер ташларын урнаштыру буенча да шактый эшләр башкарылды. Бөек Тукаебызның Яңа Бистә татар зиратындагы ташы-һәйкәле өр-яңадан корылды. Ул чын мәгънәсендә тарихи һәйкәл, һәйкәлләрнең һәйкәле. Президентыбызның матди ярдәме белән Мөдәррис Әгъләмов, Рафаэль Мостафин, Шәүкәт Галиев, Рөстәм Кутуй, Роберт Әхмәтҗанов, Фәнис Яруллин, Равил Бохараевларның кабер ташларын, һәйкәлләрен куюны быелның җәендә тулысынча хәл итәчәкбез.

Безнең алда чорыбызның күренекле шәхесе, олуг язучыбыз Туфан ага Миңнуллинның исемен мәңгеләштерү бурычы тора. Ул, әлбәттә, Татарстан Хөкүмәтенең карары белән тормышка ашырылыр дип уйлыйбыз. Вафат булган язучыларыбызның әдәби мирасын — архивларын Татарстан Республикасы Дәүләт архивына тапшыру, аларның сакланышына һәм киләчәктә чын-чынлап әдәби мирас булып файдаланачагына гарантия бирәчәк.

Әлбәттә, ике корылтай арасында эшләнеп бетмәгән эшләребез дә күп булды. Ел ярым үз бинабыздан читтә, уңайсыз шартларда эшләвебез дә, ике ел авыр кризис булуы да комачаулагандыр. Әмма бу житешсезлекләрдә мин беркемне дә гаепләргә җыенмыйм. Үзебез дә булсын дип йөрдек. Һәр идарә әгъзасына бергә күйган хезмәтләребез өчен рәхмәт сүзләрен житкерәсем килә. Дүрт ел дәвамында идарә әгъзасы булмаган бик күп каләмдәшләребезнең, галимнәребезнең Язучылар берлеге үткәргән чараларда рыясыз ярдәмнәрен күрдек — аларның барчасына да зур рәхмәт.

Отчет чорында Мәдәният министрлыгы, «Татмедиа» агентлыгы, «Татнефть» җәмгыятенең «Рухият» фонды, Татарстан китап нәшрияты, «Мәгариф» нәшрияты, «Идел-Пресс» коллективы, ТР Фәннәр Академиясе, Г.Ибраһимов ис. ТӘСИ коллективы, Республикабызның Милли китапханәсе, театрлар һәм музейлар белән тыгыз элемтәдә булып, ярдәмләшеп эшләдек.

Мин Язучылар берлеге рәисе буларак, Хөкүмәтебез, Дәүләт Советы җитәкчелегеннән, бигрәк тә Президентыбыз Р.Н.Миңнехановтан үземнең мөрәҗәгатьләремә һәрчак уңай җавап алдым. Аларның ярдәмен тойдым, зур рәхмәт аларга.

Хөрмәтле каләмдәшләр! Язучылар берлеге идарәсе бөтен эшчәнлеген Устав һәм алдагы корылтайда билгеләнгән юнәлешләр нигезендә алып барды. Идарә еллык эш планы регламентында эшләде. Һәр ай саен идарә утырышлары үткәрү тәртибе тайпылышсыз сакланды. Докладта бәян ителгәнчә, отчет чорында иң олы игътибар әдәби иҗат процессын оештыру, яшь иҗатчыларны барлау, язучыларыбызга социаль-көнкүреш мәсьәләләрендә ярдәм итү, әдәбиятыбызны пропагандалау, әдәби багланышларны оештыруга багышланды. Берлегебезнең Чаллы, Әлмәт бүлекчәләрендә дә эшне бергәләп оештырдык. Аларның һәркайсының үзләренә тапшырылган вазифаны үтәүгә җаваплы каравын билгеләп үтәр идем.

Хөрмәтле каләмдәшләр! Ил күләмендәге вәзгыять, дөньядагы глобальләшү күренеше һәр милләт алдына үз-үзен саклап калу иммунитетын югалтмау бурычын

куя. Күпмилләтле дәүләт кысаларында яшәргә дучар булган халыклар өчен андый чыдамлылык икеләтә таләп ителә. Бүген милләтебез алдында милли мәктәбебезне, ана телебезне, милли мәдәниятебезне саклап калу, халкыбызның рухи төшенкелеккә бирелүенә киртә булырдай гамәлләр кылу сорала. Гомумән, һәр халыкның рухи үсешен билгеләп, гасырлардан гасырларга өзлексез дәвам итә торган мәдәни үсеш программасы булырга тиеш. Ул программаны эшләүдә иҗат интеллигенциясе үзенең өлешен кертергә бурычлы. Беренче чиратта, талантлы, кыю һәм житди фикерле, әхлакый кыйммәтләргә ия әдәби әсәрләр язып! Халкыбызның рухын күтәрә торган гимн, җырлар, шигырьләр язып... Тарихыбызны әдәби иҗатыбыз аша халкыбызга аңлатып, милли геройларыбызны байрак итеп күтәреп, халкыбызның күркәм йолаларын, традицияләрен саклап, үзара һәм барлык халыклар белән дустанә, гадел яшәп, аек, сау-сәламәт һәм иманлы булып.



Зиннур Мансуров,
Татарстанның Г.Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты

## ШИГЪРИЯТ РУХЫН ГАМЬ ЯШӘТӘ

Иҗат белән шөгыльләнүче һәрбер буын заман алдына үзенчә сораулар куя. Җавап таләп иткән мәсьәләләр исә аерым чорларда әледән-әле кабатланып тора. Сораулар төрлечә яңгырый. Әйтик, классик шагыйребез Габделҗәббар Кандалыйның түбәндәге шигъри юллары килеп туган чарасызлык тәэсирендә үз-үзенә эндәшүне хәтерләтә:

*Языйм микән, җитәр микән?*
*Язу файда итәр микән?*
(«Иляһи, бу асыл кошны...»)

Күрәбез, шагыйрь әле XIX гасыр ахырында менә шундый гаҗизлек кысаларында калган. Дөрес, аның шул рәвешле үзалдына мөрәҗәгать итүендә шәхси тормышына бәйле мотивлар да тоемлана. Ничек кенә булмасын, безгә килеп ирешкән әлеге шигырьдә кодрәтле каләмнең мөмкинлекләренә шик белдерелә. Ә бит бүгенге заман шагыйре дә бу сорауны сүзмә-сүз кабатлый алыр иде: «Языйм микән, җитәр микән? Язу файда итәр микән?».

Чыннан да, мондый икеләнүле ниятне белдерер өчен хәзер байтак сәбәпләр күренеп тора. Соңгы берничә дистә ел эчендә алар бөтен кискенлеге белән калыкты. Һәммәбез дә шаһит: сәнгать төре буларак, әдәбиятның гомум дәрәҗәсе төште, иң күп укый торган илдә китап кадерсез тауарга әйләнеп калды, язганнарны басма итеп чыгару, аларны халыкка ирештерү авырлашты... Санауны дәвам итәргә мөмкин. Яңа вакыт сынаулары шигъриятькә аеруча зур зыян салды — аның элек-электән килгән гаммәвилек чикләре елдан-ел кысыла килә. Меңләгән шигырь сөючеләрне бергә җыйган Лужники спорт фанатикларының сугышу урынына әйләнеп бара. Атнаның һәрбер җомгасында сәхнәсен шагыйрьләргә биргән Габдулла Тукай клубы

инде тарихка күчте, башкала халкын үзенә тартып торган «Казан язы» кичәләре сагынып сөйләргә генә калды.

Менә шундый югалтулар аша күзалланган вәзгыять язучының җәмгыять алдындагы ролен тарайтуга китерде. Рухи кыйммәтләрне аңлы рәвештә диярлек инфляциягә дучар итүнең нинди күңелсез хәлләргә алып баруы инде күпләргә мәгълүм. Күңел киштәләрендә Һади Такташ кебек шагыйрьләрнең китаплары сирәгәя барган саен, мәхкәмәләрдә «Һади Такташ» сыман оештырылган җинаятьчелек төркемнәренең «эш-томнар»ы ишәя тора.

Гыйбрәтле заманда яшибез. Кызганыч ки, тормыш пәйгамбәрләр телендә сөйләшүче шагыйрьләр билгеләгән юлдан гына бармый. Әмма гаҗәпләндергәне шул: «Язу файда итәр микән?» ише шөбһәле гамь бимазаласа да, зур әдәбиятыбызның чишмә башы саналган шигърият рухы һәрвакыттагыча исән-аман! Алай гына түгел, безнең халыкта шигырь язу омтылышы күзгә күренеп көчәя генә бара. Хәзер балалар да, урта яшьтәгеләр дә, өлкәннәр дә, картлар да үзләренең уй-кичерешләрен тырышып-тырышып тезмә калыбына салырга талпына. Татар күңеленең шулай түгелүе, мөгаен, безнең төрки традицияләрдән киләдер. Әнә, илле Кырым ханының утызы шигырь һәм көйләр иҗат иткән. Піродокска охшаган әлеге күренешкә карата бүгенге шагыйрьләребез дә мөнәсәбәтләрен белдерә. «Һәр икенең берсе шигырь яза, шигырь белән дөнья туп-тулы», — дип искәртә Фәйрүзә Мөслимова «Һәр икенең берсе» исемле әсәрендә. Ә Салават Рәхмәтулла үзенчә сагайтып куя:

*Китап укучы аз булу —*
*Һич түгел каза!*
*Каза —*
*Китап укымаучылар*
*Үзләре... китап яза?!.*
(«Китап укучы аз булу...»)

Кайвакыт шикләнеп куясың, киң колач алган әлеге шаукым ахыр заман билгесе түгелдер бит?! Әлбәттә, табигый рәвештә туган ошбу «шигырь бумы»нда нииндидер сыйфат күтәрелешенә исәп тотып булмый. Кирәк тә түгел. Гомумән алганда, гаммәви төстә иҗатка тартылу югары зәвыклылыкка зыян салса да, күңелдәгесен ак кәгазьгә күчерергә омтылучыларның кулына үчләнеп сугарга ярамый. Хәтерлим, нәкъ менә шундый охшаш хәлләр җәһәтеннән язучы Ованес Туманян мактанып алуны кулай күргән: «Һәрбер грузин — шагыйрь, — дигән ул. — Ә шагыйрь-грузин — икеләтә шагыйрь». Безнең татар шигырь белән күбрәк җенләнәдер. Әйе, күпләр каләмгә тартыла. Әгәр олы шигърияттә сәнгатьлелек дәрәҗәсе беркадәр төшә бара икән, моның өчен беренче чиратта профессиональ иҗат әһелләре гаепле.

Юк, безнең шигърият талчыктыргыч ыгы-зыгылы чынбарлыктан качып тору урыны түгел, ул халыкның рухи үсешендә үзен һәрдаим җаваплы итеп тоя. Кайчак җыр-биюгә авышып киткән гавамның күңелен ачып яшәү аның өчен бик тар мәгънәдәге максат булыр иде. Сентименталь җаннарда ләззәтле матурлык хисен генә уяту татар шигъриятендә элек-электән беренчел бурыч рәвешендә куелмаган. Безнең күпчелек әсәрләребез кешенең рухын формалаштыруга, җәмгыятьнең әхлак табигатен яхшыртуга турыдан-туры хезмәт итә. Ә моның өчен каләмгә тугрылык саклау, үзеңне сүз сәнгатенә тулысынча багышлау сорала.

Шапырынмыйча гына әйткәндә, шагыйрьләребез соңгы елларда да шушы олуг максатларны күзаллап, халкыбызның үткәне белән бүгенгесенә киләчәк югарылыгыннан карап иҗат итте. Барлык шигъри жанрларның әдәби барышта үзләрен үсештәге организм итеп тоюы да, гәзит-журнал битләрендә тезмә әсәрләрнең тулы яңгырашта мәйдан тотуы да, китап нәшриятларында төрледән-төрле мәҗмугаларыбызның күпләп чыгуы да шуны раслап торадыр. Әйтик, язучыларның ике корылтае арасында Татарстан китап нәшрияты гына да төрле буын шагыйрьләренең 80гә якын җыентыгын укучылар хөкеменә тапшырды.

Алар арасында Габдулла Тукай, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Рәдиф Гаташ, Клара Булатованың күптомлыклары, Мәжит Гафури, Дәрдемәнд, Сибгат Хәким, Әнвәр Давыдов, Марс Шабаев, Фәнис Яруллинның сайланма әсәрләреннән торган җыентыклары да бар. Ә «Идел-Пресс» нәшриятында Марсель Галиевнең алты, «Илһам» нәшриятында Гәрәй Рәхимнең биш томлыклары дөнья күрде. Аларның икешәр томын тезмә әсәрләр тәшкил итә.

Дөрес, әле генә санап үтелгән шагыйрьләр иҗаты төрле чорларга карый, кайберләренең язганнарын соңгы еллар казанышы итеп санап та булмыйдыр. Әмма алар китап продукциясе буларак тулаем бүгенге гамәлләребез исәбенә керә. Гомумән, күтеп алынган һәртөрле күптомлыклар әдәбият сөючеләрнең гомерендә тулы бер чорны тәшкил итә, һәм алар әле язу барлыкка килгәнче борынлаган шигъриятебезнең зурлыгын да күрсәтеп тора. Бу җәһәттән Ренат Харис, Разил Вәлиев, Лена Шагыйрьҗан, Айдар Хәлим, Мөхәммәт Мирза, Илдус Гыйләҗев, Госман Садә, Җәүдәт Сөләйман, Резеда Вәлиева, Нурия Измайлова, Нәҗибә Сафина, Әнәс Исхаков, Ирек Сабиров, Фәйрүзә Мөслимова, Таһир Шәмсуаров, Шәмсия Җиһангирова, Илсөяр Иксанова, Әнәс Хәсәнов, Мансур Сафин, Вазыйх Фатыйхов, Хәнәфи Бәдигый, Фәүзия Солтан, Әлфия Ситдыйкова, Раушания Арсланова, Сирень Якупова, Рәсимә Гарифуллина, Рөстәм Зәкуан, Сания Әхмәтҗанованың нәшриятта дөнья күргән аерым җыентыкларын да шигъриятебезнең соңгы еллардагы казанышларын үзенчә кристаллаштырган басмалар рәтенә куярга мөмкин. Шулай ук Роберт Миннуллин, Мөхәммәт Мирза, Рашат Низами, Факил Әмәк, Илдус Гыйләҗев, Рифат Җамал, Рөстәм Зәкуан, Розалина Шаһиева, Шәүкәт Гаделша һ.б.ларның төрле нәшриятларда шигъри китаплары басылып чыкты. Тулылыкны дәгъва итмәгән әлеге исемлектә аеруча уңышлы җыентыклар байтак булды, һәм аларның һәркайсы хакында көндәлек матбугатта этрафлы бәяләмәләр дә күренгәләп торды.

Һәммәбез дә яхшы белә, хәзерге «прозаик заман»да шигырь арты шигырь язып, купшы метафора тапканга куанып кына яшәргә ярамый. Лирик дөньяны беркадәр артка чигендергән чор аңлы рәвештә реалист булуны таләп итә. Мондый шартларда халык тормышы белән яшәүче каләм иясенең көндәлек мәшәкатьләр ягына авыша төшүе, аеруча шагыйрьләрнең җәмгыятьтәге теге яки бу мәсьәлә уңаеннан үз мөнәсәбәтен белдереп баруы бик табигый. Ә безнең әдипләргә шулкадәр вазифа йөкләнгән ки, аларны борчыган мәсьәләләрне санап та бетереп булмыйдыр. Күреп торабыз, күпне колачлаган рухи экология киләчәккә атлаган саен кискенрәк төс ала. Милли яшәешнең отыры тармакланып торган катлаулы проблемаларын ничекләр итеп «тар шигырьләр үлчәве»нә сыйдырмак кирәк!

Таный белик, мондый мөһим юнәлештәге эшчәнлектә дә шагыйрьләребез зур активлык күрсәтте, көндәлек матбугатта публицист буларак чыгыш ясап, көнүзәк мәсьәләләргә багышланган мәкаләләрен җыентык итеп чыгарырга да өлгерде. Ошбу раславымда мин иң беренче чиратта Равил Фәйзуллинның «Илбагар уйлар», Разил Вәлиевнең «Дөнья гаме», «Җанга уелган уйлар», Марсель Галиевнең «Талисман», Әхмәт Рәшитнең «Һәркемнең... үз хакыйкате», Ркаил Зәйдулланың «Ташка ордым башны» исемле чын мәгънәсендә саллы китапларын күз алдында тотам. Безнең шагыйрьләребез китапка бәйле башка игелекле гамәлләр, әйтик, аерым махсус басмалар төзеп чыгаруда да катнаша. Шуларның берсен генә искә төшереп узыйм. «Нажар Нәҗми. Милли җаным» дигән әлеге уникаль китап Роберт Миңнуллинның шәхси тырышлыгы нәтиҗәсендә укучы кулына тапшырылды. Үзебезнең мәшһүр шагыйрьләребез мирасын шулай ташта теркәп калдыру исә татар шигърияте тарихы елъязмасын киләчәккә карап дәвам итүебезне күрсәтә.

Татар шигъриятенең дәрәҗәсе шигъри китапларда гына түгел, башка төрле басмаларда да шактый ачык чагыла. Бу җәһәттән шуларның икесенә генә аерым игътибар юнәлтеп үтәсем килә. Болар — Тәлгат Галиуллинның «Яктылык» һәм Нурмөхәммәт Хисамовның «Татар шагыйрьләре» китаплары. Гадәти булмаган әлеге басмалар Татарстан китап нәшриятында 2011 һәм 2012 елларда дөнья күрде. Безнең шигъриятне классик нигездә өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәрнең бу

китаплары үзләре дә әдәби тәнкыйтьнең соңгы елларда ирешкән казанышлары рәвешендә бәяләнергә лаек.

Көн кебек ачык, сүз сәнгате казанышларын чагыштырмача кыска вакыт эчендә кин җәмәгатьчелеккә җиткереп баруда, теге яки бу жанрны үстерүдә, яңа әсәрләрне сайланыш иләге аша үткәрүдә көндәлек матбугат зур роль уйный. Әле кайчан гына каләм уйнатыр мәйданның кинлегенә шөкер кыла идек. Гаҗәпләндерә, соңгы елларда шигъриятне читкә тибәрүче басмалар да күренгәли башлады. Иң яхшы иҗат үрнәкләрен укучыларга тәкъдим итүдә, әлбәттә, «Казан утлары» төп профессиональ журнал булып кала. Тезмә әсәрләрне сайлап бастыруда «Мәйдан», «Идел» журналлары, «Мәдәни җомга» гәзите дә зур таләпчәнлек күрсәтә. Бирелеш формалары да төрләнәнеп бара. Бу уңайдан «Мәйдан» журналының эзләнүләрен билгеләп үтәргә кирәк. Кем ничек кабул итәдер, журналның аерым шагыйрьләр иҗатына багышлап чыгарылган саннары мина тулы бер энциклопедик басмалар кебек тоела. Мәсәлән, һәртөрле мәгълүматка тартылучы укучылар «Мәйдан»ның ике корылтай арасында чыккан саннарыннан Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Айдар Хәлим, Резеда Вәлиева, Гарифҗан Мөхәммәтшин, Рәшит Бәшәр, Рашат Низами, Җәүдәт Дәрзаман, Нәҗибә Сафина, Мөхәммәт Мирза, Факил Сафин, Флера Тарханова, Газинур Морат, Ләбиб Лерон, Шәмсия Җиһангирова, Фәйрүзә Мөслимова, Фирүзә Җамалетдинова һ.б. шагыйрьләребезнең өстәмә мәгълүматлар белән бирелгән үзенчәлекле «сайланма әсәрләр»ен яратып кабул иткәндер. Соңгы елларда шагыйрьләребез Мәскәүдә чыга торган гәзит-журналларда да һәм хәтта Интернетта да чагыштырмача ешрак күренә башлады. Кыскасы, безнең әдәби хәрәкәттә катнашуыбыз шундыйрак гамәлләребез аша күзаллана.

Күргәнебезчә, шигъриятнең хәле алай ук зарланырлык түгел — безнең күнелләрдәге шигырь уты элеккечә исән-сау. Ул чынбарлыкка карата мөстәкыйль рәвештә үтемле сүзен әйтә ала һәм үзенең укучыларына да шундый ук мөстәкыйльлекне тәрбия кыла. Әлбәттә, һәрвакыт яхшы исәптә торган шигърият күбрәккә дә өмет итә аладыр. Һәр житешсезлек артында объектив сәбәпләр ята. Аларның иң житдиләреннән берсе «кадрлар мәсьәләсе»нә, ачыграк әйткәндә, чын-затлы шагыйрьләребезнең чагыштырмача азаеп калуына бәйледер. Һәрбер әдәбиятның биеклеген барыбер шәхесләр билгели.

«Безнең белән ул-бу була калса...» Әдәби алмаш мәсьәләләренә багышланган бер мәкаләсендә Сибгат ага Хәким шулай язган иде. Безнең белән ул-бу була калса... Шактый шомландыргыч сүзләр. Шигъриятә көчләрнең кимиячәген, әйтерсең, аксакал алдан сиземләгән. Менә шундый тәкъдири фаразлаудан соң никадәр алтын баганабыз киселде. Соңгы дистә ел дәвамында гына да без күпме асыл шагыйрьләребезне мәңгелеккә озаттык: Илдар Юзеев, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗан, Харрас Әюп, Шәүкәт Галиев... Яшәү белән үлем арасында иҗат итәргә дучар ителгән Фәнис Яруллинның китүе дә күктән бирелгән кабатланмас талантлар сафына китереп суккан зур югалтуга бәрабәр иде. Миллионнарның уй-гамьнәрен күкрәгендә йөрткән шушы гаҗиз зат, гәрчә сәламәтлеккә туймаса да, үз әсәрләре аша күпләргә яшәү дәрте өләште. Алай гына да түгел, ул безгә яшәүнең мәгънәсен һәм бәһасен аңларга ярдәм итте. «Сары тап»ны кояшка әверелдерә алучы оптимист иҗатчы мораль укымады, үзенең идея-фикерләрен укучыга үҗәтләрчә көчләп такмады, җәмгыятьтә туып торган социаль күренешләргә коры кимәлдә анализ ясамады — ул образлы телдә сурәтләде генә. Юк, аның әсәрләрендә авторның үкенечле тәкъдир сынаулары бүлтәеп чыкмады, киресенчә, күнел яктысы белән өртелгән халык язмышы үзәккә алынды. Нәкъ менә шушы асыл сыйфатлар шагыйрь иҗатының әһәмиятен дә билгели. Гомерлек урын хастасы булган Фәнис Яруллинның күптомлыгын күздән кичергәндә Габдулла Тукайның җан авазыдай яңгыраган мондый сүзләре хәтергә килә: «Милләт хәлен тетрәгән куллар белән язып бирү бу...» Ул да шулай әйтә алыр иде. Аның тау кадәр хезмәте калды. Шунысы да сокландыра, Фәнис Яруллин Шигърият әнкәбез белән дә чын шагыйрьләрчә хушлашып китәргә көч тапты. «Мәдәни җомга» гәзитендә чыккан соңгы шәлкеме хәзер инде бәхилләшү буларак кабул ителә.

*Сау бул, шигырь, күпме мөмкин инде*
*Туктамыйча алга барырга?*
(«Сау бул, шигырь»)
*Каләм очындагы ут сүнгәнче*
*Яшь алсам — калмас үкенеч.*
*Болай да мин артык күп яшәдем,*
*Дөньяга юк үпкәм, юк бер үч.*
(«Каләм очындагы шигъри утым...»)

**Әле ярый, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташлар буыны зур шигъриятебез казанышларын баетуда төпкә җигелеп тартучы шагыйрьләр булып кала бирә. Тәҗрибәле өлкәннәр хаклы: һәр югары зәвыклы талант көчле фикер-хис юнәлешенә кертелсә, гадәттә, андыйлар үзләренең эзләнүчән иҗатында бик күп нәтиҗәләргә ирешә.**

*Ак кәгазьнең эчке чиксезлеген*
*кем ишетә, ә кем күрә дә...*
*Әллә кая барып юк эзлисе —*
*кәгазь эчендә ул, тирәндә.*
(«Ак кәгазь сонеты»)

Ак кәгазьгә могҗиза чыганагы итеп карый белгән Ренат Харис әлеге юлларны үзенең һәрбер буындашы исеменнән белдерә кебек тоела. Чыннан да, милли әдәбиятыбыз тарихына атаклы «алтмышынчы елгылар» буларак кергән әлеге плеяда вәкилләре татар шигъриятенең иксез-чиксез тирәнлегеннән талант көче белән нинди генә җәүһәрләр чыгармады икән?! Әйткәнемчә, алар әлегәчә иярдә. Соңгы елларда Ренат Харис үзе драматургия өлкәсендә бик нәтиҗәле эшләп алды, шулай ук шигырьләр, сонетлар, поэмалар һәм кызыклы мәкаләләр язарга да



*Президент Рөстәм Миңнеханов съездда Рәдиф Гаташка «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исемнең билгесен тапшыра.*

өлгерде. Шулай ук Равил Фәйзуллин да әдәбиятыбызга армый-талмый хезмәт итте: шагыйрь буларак та, мөхәррир вазифасында да, җәмәгать эшендә дә... Ә Гәрәй Рәхим үзенең күптомлыгын нәшриятка әзерләү белән бергә, байтак кына затлы басмалар төзеп чыгаруга зур көч салды. Каләмдәшләре иҗатына һәрвакыт игътибарлылык күрсәткән Рәдиф Гаташның да татар шигърияте турында мәкаләләр язуда активлашуы сокландыра. Көтмәгәндә язмыш сынавына дучар булган шагыйребез Рөстәм Мингалимнең дә яхшы мәгънәдәге иҗади үҗәтлеген күрмичә мөмкин түгел. Югарыда телгә алынган буын хакында уйланганда күңелдә йөргән мәгълүм хакыйкать калкынып куя: сүз сәнгатендә милләт хадиме дәрәҗәсенә күтәрелү өчен, әлбәттә, әүвәл үзең яшәгән чорның мәдәни биеклеген яулау, бүгенгенең торышына бәйле үткәннәр тарихын тирәнтен белү, шул рәвешле милли рух культурасына ирешү зарур. Ә аларның өзлексез җимешләнеп торган иҗаты әлеге олуг таләпкә тулысынча җавап бирә.

Әгәр мондый мәртәбәле җыенда «Шигъри иҗаттагы нәтиҗәлелек» номинациясе буенча бәяләү җитди санала икән, мин хисап чорында аеруча активлык күрсәткән берничә каләмдәшемне атап үтәргә җөрьәт итәр идем. Аларның берсе — Илдус Гыйләҗев. Көндәлек матбугат басмаларында даими рәвештә дөнья күреп килгән саллы тупламаларында шагыйрьнең тагын да киңрәк офыкларны колачлавы,

тирәнрәк катламнарга үтеп керүе, зуррак гомумиләштерүләргә ирешүе сизелеп тора. Шигъри теле тыгыз, сурәтле һәм музыкаль. Һәрбер әсәре милләт гаме белән сугарылган. Аның буш юллары бөтенләй юк диярлек. Каләме өлгер. Безнең бүгенге съездга да ул ике яна китап белән килде. Бик артык кинәеп китмичә, шуны гына искәртәсе килә: Азнакай районында яшәп иҗат итүче Илдус Гыйләҗев язганнары белән әдәби җәмәгатьчелекнең зуррак игътибарына лаек. Бездә андый каләм ияләре күп түгел. «Көндәш тә юк ичмасам...» исемле шигырендә исә ул хәл-халәтен үзе дә аңлатып үтә кебек:

*Авылларның шагыйрьләре*
*Шәһәргә күчеп киткән.*
*...Беткән саланы язарга*
*Мин үзем дә бик җиткән...*

Күз тимәсен, шагыйрә Флера Гыйззәтуллинаның әдәби хезмәт җитештерүчәнлеге күпләрдә соклану хисе тудырадыр дип уйлыйм. Соңгы дүрт ел дәвамында гына да ул «Казан утлары»нда «Ватан көзгесе» исемле шигъри дастан, «Яңу дәверләрендә» дигән роман-поэмадан өзекләр, «Мәдәни җомга»да ике поэма бастырып чыгарды. Көндәлек матбугатта аның шигъри тупланмалары да, шулай ук мәкаләләре дә дөнья күрде. Кыскасы, Флера Гыйззәтуллина илһамлы иҗат аша сулыш алып яши, дөньясын онытып дигәндәй, көннәр, атналар, айлар буена өзлексез бер тында халык «яшәешен дәваларлык» әсәрләрен кәгазь битләренә төшерергә ашыга.

Иҗат өлгерлеге хакында фикер йөрткән чакта тагын бер исемне атап үтәсем килә: ул — Мөхәммәт Мирза. Шәхси тәҗрибәмнән чыгып әйтәм, Язучылар берлегендә җаваплы вазифа башкарган шагыйрьгә үзенең иҗатын югарылыкта тоту гаять кыен. Барысына да җитешергә кирәк. Ә Илфак Ибраһимов оештыру эшчәнлеген дә көйле-эзлекле итеп алып барды, бүгенге катлаулы заманда язучыларыбыз һәм, гомумән, мәдәниятебез өчен дә байтак игелекле гамәлләр кылды, үз иҗатын да әдәби җәмәгатьчелек алдында калкытып куюга иреште. Гадел булыйк, аның активлыгын күпләребез таный. Шагыйрьнең «Адәм баласына» исеме астында бирелеп килгән бишьюллыклары эчтәлек һәм форма җәһәтеннән аеруча зур кызыксыну уятты. Татар рухиятенең бихисап якларын галәми киңлектә яктыртып күрсәткән әлеге проект, күп кенә әдәбият белгечләре раславынча, эзләнүләрдән туктамаган милли шигъриятебезнең соңгы чордагы казанышлары рәтеннән саналырга хаклы.

Рухи яссылыктан караганда, шагыйрьләрдә иммунитет дигән нәрсә гомумән булмыйдыр — алар милләтнең һәрбер авыру-сызлануларын, гадәттә, үзләренең җаннарына кабул итеп алучан. Менә шундый олы хис-кичерешләрнең бихисап төсмерләрен без Әхсән Баян, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Айдар Хәлим, Әхмәт Рәшит, Эльмира Шәрифуллина, Шамил Маннапов, Нур Әхмәдиев, Әхмәт Гадел, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Флера Тарханова, Рифә Рахман, Шаһинур Мостафин, Рафис Корбан, Гөлзадә Бәйрәмова, Луиза Янсуар, Гөлнур Корбанова, Рамис Аймәтнең шигъри әсәрләрендә әледән-әле күреп торабыз. Күп кенә каләм ияләренең югары шигырь культурасы биеклегендә торуы, иң әһәмиятлесе, шушы биеклектән милли тамырларыбыз тирәнлегенә төшә алуы һәркемне сөендерәдер. Башкортостанда яшәп иҗат итүче Фәрит Габдерәхим, Рим Идиятуллин, Марис Нәзиров, Халисә Мөдәррисова, Дилә Булгаковаңы, Ижаудан Ринат Баттал, Ибраһим Биектаулы, Гөлфия Исхакова, Гыймран Сафинны, Мәскәүдән Әхмәт Саттарны, Чиләбедән Ирек Сабировны, Ульяннан Иделбикәне, Пермьнән Һидият Әшировны, АКШтан Нурия Измайлованы, Төркиядән Чулпан Зарифны, Англиядән Рөстәм Сүлтине ничек инде милләт өчен җан аткан шагыйрьләр җөмләсенә кертмисең?!

*Ишеттем күкләрдән вәхи:*
*— Тәкъдирең шундый, бала!*
*Хезмәт, Газап, Ләззәт өчен,*

*Шигъри юллар тезмәк өчен*
*Яратты сине Алла.*
*Тәкъдирең шундый, бала!..*

Хәрәкәтле тынгысыз гомерендә төрлесен күрергә өлгергән шагыйрәбез Салисә Гәрәева хаклы — аның «Вәхи» исемле әлеге шигырендә үткәрелгән фикер белән күпләр килешер: гүзәл затлар гына түгел, шулай ук ир-егетләр дә. Ошбу юлларда безнең олуг миссиябез дә, газаплы иҗат хасияте дә ачык чагыла. Мен михнәткә бер рәхәт, дигәндәй, әҗер-мәртәбә күтәреп кенә килә. Бу җәһәттән әйдәп баручы шагыйрьләребезнең берсе Лена Шагыйрьҗанга әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге иң югары бүләк — Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелү үз хөкемен ашыкмыйча ирештерүче Гаделлекнең «Афәрин!» дип әйтүенә бәрабәр иде.

Әдәбият белеме классиклары искәрткәнчә, сүз сәнгате форма-жанрлар төрлелегендә генә үзенең олуг максатларына ирешә ала. Бу унайдан соңгы елларда яхшы мәгънәсендәге чуарлык күзгә ташлана, ягъни шагыйрьләребез иҗатында шигъри сурәтләүнең һәрбер төре гәүдәләнеш таба: поэма да, баллада да, сонет та, робагый да... Алыйк поэма жанрын гына. Исегезгә төшерәм, әгәр әдәбиятыбыз тарихына күз салсак, без анда иң элек зур күләмле шигъри әсәрләрнең — дастан, кыйсса, поэмаларның аерым биеклекләр булып торуын күрербез. Гасырдан гасырга шулай дәвам итә. Шагыйрь шәхесенең зурлык перспективасын аеруча ачык күрсәтүче поэма жанры бүгенге заманда иҗтимагый яңгыраш мөмкинлекләрен эзлекле рәвештә кинәйтә төште. Көндәлек матбугат басмаларында соңгы дүрт ел дәвамында гына да дистәдән артык зур полотнолы шигъри әсәр дөнья күрде. Болар — Рәсимә Гарифуллинаның «Кем көчлерәк?», Җәүдәт Дәрзаманның «Тормыш — сәхнә», «Ап-ак карлар ява», Рашат Низаминың «Яшәүгә гимн», Ренат Харисның «Татар «Титанигы», «Урам» поэмалары, Флера Гыйззәтуллинаның «Ватан көзгесе» шигъри дастаны, «Яну дәверләрендә» шигъри трилогиясе, Җәүдәт Сөләйманның «Кыйбла», «Болгар җиле» дастаннары... Шулай ук Рәниф Шәриповның «Соңгы сәлам» исемле монологларын да зур күләмле шигъри әсәрләр исәбенә кертергә мөмкин дип уйлыйм. Бу җәһәттән Сания Әхмәтҗанованың «Татар кызлары» дип аталган тарихи циклы да бер мөбарәк тәсбихка тезелгән асыл геройлары белән лиро-эпик жанрга якын тора. Андый мөһим теманың барлыгын күптән белеп, шуның сәнгатьчә гәүдәләнешен көтеп яши идем. Ниһаять, күнелдә йөргән гамәлгә ашты... Санап үтелгән әлеге әсәрләрнең күпчелеге безнең игътибарны халкыбызның үткәненә юнәлтә. Табигый ки, милли үзаң уяу заманда тарихка ихтыяҗ нык арта.

Яшьләрнең эзләнүле иҗаты, куанып әйтәм, күнелдә ышаныч уята. Татар шигъриятенең үзгә бер феноменаль күренеш рәвешендә кинәт яшәреп китүенә туксанынчы еллар милли күтәрелеше балаларының үсеп җитүе дә йогынты ясагандыр. Бездә яшь талантлар тәрбияләү мәктәбе дә әлегәчә көчле булып кала бирә. Әлбәттә, озак еллар дәвамында зур тәҗрибә туплауга ирешкән әлеге мәктәпнең эшчәнлеген Татарстан Язучылар берлегенең координацион роленнән башка күз алдына китереп булмый. Дөресен әйтик, соңгы дистә елда яшьләргә кайгыртучанлык чагыштырмача күбрәк күрсәтелде. Шунысы да сөенderә: «Казан утлары», «Идел», «Мәйдан» журналлары, «Мәдәни җомга» газете дә яшь каләм ияләре иҗатын даими төстә хәерхаһлык үзәгендә тота. Татарстан китап нәшрияты да әдәби алмаш мәсьәләсенә игътибарлы. Безнең төп нәшрият ике съезд арасында гына да Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Рүзәл Мөхәммәтшин, Айдар Җамал, Лилия Гыйбадуллина, Йолдыз Миннуллина һ.б.ларның җыентыкларын бастырып чыгарды.

Шөкер, яшь шагыйрьләребез дә иҗтиһат итә. Аларга мактау муллан әлегә. Әмма таләпчән мөнәсәбәт белдерү дә яшьләр өчен артык булмас кебек. Әнә, Рифә Рахман әлеге буынның сәхнәдән күмәкләшеп чыгыш ясавын да, язган шигырьләрен дә тәнкыйди күзлектән бәяләп үтәргә кирәк саный. «Кызы да, егете дә аңлаешсыз җирлектә туган образлар белән чуарланган әсәрләрен, үчле кысылган тешләреннән, күтәртеп куелган тамак төбеннән сытып, имгәтеп чыгарып, каядыр еракка, томанлы офыкларга карап, уртак бер яңгырашка китерелгән тавыш белән укый, — дип яза

ул «Бөек мәгънә эзли юкса шагыйрь» исемле мәкаләсендә. — Кирәгеннән артыграк күкләргә чөелгән бер төркем яшьләребезнең уртак рухта, уртак темаларга шактый охшаш стильдә иҗат ителгән сумбур әсәрләрен игезәк интонация белән укыганнарын ишеткәндә үз яшьтәшләремне уйлыйм...» («Казан утлары», №1, 2012).

Хикмәти Хода, яшьләр кайда да бертөрле бугай. Күптән түгел Казанда «Дружба народов» журналы редакциясенең күчмә сессиясе үткәрелгән иде. Анда Россия, Әзәрбайҗан, Беларусь, Казакъстан, Кыргызстан, Украина, Эстония вәкилләре беравыздан диярлек шулай кабатлады: «Яшьләр күбрәк фэнтези яки постмодернизм өслүбендә иҗат итә... Алар бүгенге катлаулы чынбарлыкны тасвирлаудан читләшүне хуп күрә... Яшь каләм ияләренең үз-үзләре белән артык хозурлануы күзгә бәрелеп тора... Лаеклы дәвамчылар булырга тиешле буын өлкән әдипләрне тиешенчә хөрмәтли белми... Язган әсәрләре аша яшь авторның милләтен ачыклау шактый кыен...»

Электән шулай булган: һәрбер яңа алмаш әдәбиятны үзенчә яулый. Кайчак яшьләрнең без ошатып бетермәгән яклары да тора-бара үзенчәлек рәвешендә кабул ителергә мөмкин ләбаса. Шигъриятебезгә алтмышынчы еллар буыны килгәндә дә әдәби җәмәгатьчелектә төрлечә канәгатьсезлек белдерүләр күзәтелде. Үз шигырьләрен «үчле кысылган тешләреннән» сытып чыгару Белла Әхмәдуллина кебек мәшһүрләргә дә хас иде. Әмма Рифә Рахман сүзләрендә дә хак бәяләү бар дип уйлыйм, шулай ук «Дружба народов» сессиясендә катнашучыларның күзәтүендә дә дөреслек чагыла. Безнең бүгенге кайбер яшьләребезгә образлы фикерләү ачыклыгы, башкалардан аерылып торган тел-өслүп җителеге җитеп бетми. Чәчәк тузанында гына казынып ятарга ярамый. Купшы киенгән сумбурлык бушлыкка атуны хәтерләтә. Бу җәһәттән хәзерге яшьләр безгә мирас кылынган «общественный деятель»лектә дә тынгы белмәүче шагыйрьләргә төс игелекле гамәлләр башкарырга ашкынып торсын иде. Ә моның өчен сүзләрне тезмә калыпка салучы гына түгел, бер үк вакытта чын фикер иясе булу да шарт.

Бу мөһим теманы дәвам итәсе килә. Гомумән, соңгы елларда шигъриятнең профессиональ дәрәҗәсе сизелерлек төстә төшә башлады. Сәбәпнең иң зурысы каләмдәшләребезнең сәнгатьлелеккә игътибар биреп житкермәвенә, төгәлрәк әйткәндә, поэтика кануннарын тирәнтен аңлап эш итмәвенә кайтып каладыр. Гадирәк итеп аңлатканда, безнең ташка басылган бик күп әсәрләребез сәнгатьчә оешып житмәгән, алар төрле образлылыктагы сүзләр җыелмасыннан торган ниндидер «полуфабрикат»ны хәтерләтә. Нәтиҗәдә, ритмга игътибар чамасыз кимеде. Алама рифмаларның үрчүе тезмәнең тәмен җибәрде. Шигырьнең әүвәлге юлларын бер үлчәмдә башлап, аннары икенче төрле иҗек санына күчеп, өченче үлчәмдә төгәлләү гадәти күренешкә әйләнде. Поэма дип тәкъдим ителгән байтак әсәрләр эт эчәгесе кебек сузыла, аларда лиро-эпик жанр элементларын үзара сәнгатьчә беркеткән композиция бөтенләй сизелми. Сүз сәнгатенең иң мәһабәт формасы булган шигъриятне күрәләтә ниндидер коры карикатурага авыштыра баручылар бермә-бер ишәйде. Без иң нәзакәтле тезмә кысасына, көчли-көчли, ниләр генә кертергә маташмыйбыз икән?! Гап-гади публицист каләме белән күтәрелергә тиешле темага да лирик жанрлардан саналган ода кулмәген кидермәкче булабыз. Шигырь тукымасына хәтта мәкаләләрдә дә сирәк кулланыла торган, тәнне чымырдатып куйган әллә нинди сүз-кәлимәләр кереп китә. Тезмәдә милләт гамен калкытып күрсәтү өчен каләм иясеннән зур талант көче сорала. Әйтик, аеруча мөһим иҗтимагый-сәяси теманы шигырь калыбына керткәндә Дәрдемәнднең «Кораб»ы безгә үрнәк булып торырга тиеш. Югыйсә камиллектән ерак торган әсәрләр хәзер кемгә кирәк, аларны укыр өчен озын чиратка тезелгәннәр дип уйлыйсызмы?

Иң аянычы, шигъриятебезнең гомуми дәрәҗәсен төшерүгә китергән мондый хәлләр хәтта абруй казанган шагыйрьләр иҗатында да күзәтелгәли. Вазифам буенча байтак вакыт кульязмалар белән эшләвемнән чыгып әйтәм, үзләренең язганнарын сәнгатьлелек ягыннан мөкәммәллек дәрәҗәсенә житкерә алмаучылар, аерым редактор ярдәменә мохтаҗ каләм ияләре арттаннан-арта бара. Күпләргә кат-кат төзәтү сабырлыгы житми. Лампа эчендә май кимегәндәй, андыйлар гелән каядыр ашыга. Житмәсә арабызда көнгә 5-6 шигырь язам, дип, үзләренчә мактанып алырга

яратучылар да очраштыргалый. Әнә, һинд шагыйре Шри Чимной 1975 елда бер көндә 843 шигырь язган. Аңардан үрнәк алыргамы? Саннын сыйфатка сугуын күргәндә, үзалдына көрсенеп куйгандай итәсен: мәдәни үсешкә китергән сәнгать әсәрләрен, юк, конвейер алымы белән ишәйтеп булмый.

Санап үтелгән әлеге житешсезлекләрнен барысы да, минемчә, бер асыл башлангычка кайтып кала: бу — каләм әһеленен иң беренче чиратта телгә бәйле булуы. Телгә бәйлелек дәрәжәсе турыдан-туры анын әдиплек дәрәжәсен билгели. Әгәр без язучылык сәнгате стиль белән билгеләнә, дибез икән, стиль үзе барыннан да элек телгә бәйле рәвештә күзаллана. Менә шушы хакыйкатьне тирәнтен аңлап иҗат иткәндә, иманым камил, безнең әсәрләребезнең сәнгатьчә дәрәҗәсе һәрвакыт югары булачак. Әйе, татар теле — шагыйрьләр теле. Әгәр шулай икән, әдәби иҗатнын үзәгендә торган тел-өслүп мәсьәләсендә дә иң беренче чиратта шагыйрьләребез үрнәк күрсәтергә тиештер. Гайре очракта без Изге Китаптагы шигъри аһәнгә хыянәт иткән булып саналырбыз, яшәү рәвешендәге мөкатдәс шигъри рух гаять куркыныч дәрәҗәдә көчсезләнә барачак, газиз Әнкәбез Туган тел безгә рәнжү белән караячак.

Шушы урында элгәрге шагыйребез Габделҗәббар Кандалыйның мәгълүм шигъри юллары янәдән хәтергә килә:

*Языйм микән, җитәр микән?*
*Язу файда итәр микән?*

Гәрчә каләмнең яшәеше өчен шартлар җинеләюгә бармаса да, әлеге сорауга җавап бары бер генә булырга мөмкин: «Язарга!» Шигърияткә биниһая зур бурычлар йөкләнгән. Хәтта ЮНЕСКОның 30 нчы сессиясендә дә (октябрь-ноябрь, 1999 ел) бу мәсьәләнең мөһимлеге турында ассызыклап әйтелде. «Шигърият бүгенге кешенең иң кискен һәм тирән рухи сорауларына җавап була ала, — диелә әлеге халыкара оешма кабул кылган мөрәҗәгатьтә. — Әмма моның өчен киң җәмәгатьчелекнең мөмкин кадәр күбрәк игътибарын җәлеп итәргә кирәк».



Ркаил
Зәйдулла,
Татарстанның Г.Тукай исемендәге
Дәүләт премиясе лауреаты

## КИЛӘЧӘККӘ ЫШАНСАК КЫНА...

Күптән түгел бер район үзәгендә китапханәгә кергән идем. Әлбәттә, татар китаплары белән кызыксындым: «Яңа китаплар киләме? Нинди ләре килә?» Китапханәче ханым мине татар китаплары тулы киштә янына алып килде. «Үзегез укыйсызмы соң? Безнең китаплар укырга кызыкмы?» — дип сорадым мин китапханәчедән. Ул балкып елмайды... «Кулга кергән һәр китапны укып барам», — диде. Һәм китапларны берәм-берәм кулына алып, аларга бәя бирергә кереште: «Менә монысы яшьләр проблемасы турында, монысы хатын-кызлар проблемасын чагылдыра, монысында эчкечелек проблемасы күтәрелгән...» Безнең язучылар

кагылмаган бер генә проблема да калмаган икән. «Бер генә проблема да булмаган әсәр юкмыни соң арада?» — дип сорадым мин аптыраганнан.

Мина калса, бу бик гыйбрәтле сөйләшү булды. Әдәби әсәр турында сүз чыкса, гадәттә, «нәрсә турында?» — дип сорау бирәләр. Элегрәк тәнкыйтьчеләр һәм әдәбият чиновниклары язучыдан ниндидер бер теманы яктыртуны таләп итә иде бит. Шуның нәтиҗәсендә нефтьчеләр турында күпме әсәр язылды, КамАЗ турында... Совет заманының соңгы елларында безнең әдәбиятта Татар АЭСына да игътибар зур булды. Үзгәртеп кору елларында АЭС төзүне туктаттылар, әмма аның кирәклеген раслаган роман һәм күпсанлы мәкаләләр әдәбият чүплегендә әле дә саклана.

Һәркемнең үз зәвыгы, әлбәттә, ләкин мина бүгенге көн проблемаларына хадимлек итмәгән әсәрләр якынрак. Дөресрәге, әдәби әсәрдә, публицистикадан аермалы буларак, проблема күзгә бәрелеп тормаска тиеш. Ләкин бездә соңгы ике дистә елда жанрлар шулкадәр буталды, кайбер әсәрне укып чыккач шактый озак аптырап утырасың: ни булды бу — публицистикамы? тарихтан компиляцияме? фантастикамы? истәлекме? Тик шунысы хак, авторларның байтагы әсәрен роман итеп күрәсе килә. Нинди генә романнар пәйда булмады бездә! Роман-эпопея, роман-хатирә, роман-эссе, роман-фарс... Мина аерата охшаганы «интеллектуаль бәян» дип билгеләүләре булды. Ә кайбер әсәрнең жанры бөтенләй билгеләнми: мәсәлән, соңгы елларда чыккан романнардан Марат Кәбировның структурасы, бербөтенлеге, сәнгатьчә югарылыгы, символик әһәмияте белән аерылып торган «Бердәнбер һәм кабатланмас» әсәре «Казан утлары»нда жанр җәһәтеннән берниңди билгеләмәсез чыкты. Хәлбуки, романның төрләрен ачыклау юлына бассак, мин аны роман-фантасмогория дип билгеләр идем.

Леонид Андреевның Горькийга язган бер хатында мондый юллар бар: «Һәр атның тумыштан килгән үзенчәлекләре була, милләтнең дә шулай ук, — дип яза ул. — Барлык юллардан да кабакка борыла торган атлар бар, — безнең ватан да үзенә якын булган ноктага борылды, һәм ул, чыгарып ташланганчы, сәрхушләнеп янә озак яшәр».

Л.Андреев шулай үз ватанына, үз милләтенә бәя бирә, аның төп үзенчәлеген билгеләргә омтыла. Ә без кем? Татар халкы нинди бүген? Безнең милли үзенчәлегебез калдымы? Чөнки үзенә генә хас сыйфатлары булмаса, милләт үзе дә юк дигән сүз. Әдәби әсәрләрдә шул сыйфатлар, үзенчәлекләр, милли гамь, әгәр алар булса, чагылырга тиеш бит. Язучы сюжет кысаларында характерлар тудыра, һәм аларда без үзебезне төсмерләми кала алмыйбыз.

Бу җәһәттән Айдар Хәлимнең «Хунвейбин» әсәренә кагылмыйча үтү килешмәс. Әсәрнең композициясе бик отышлы: Шәркый Төркестанда туган Иркен ага Казанга килеп төшә һәм татар яшәгән төбәкләрдә йөри. Әлеге алым авторга халкыбызның төрле катламнарын, төркемнәрен сурәтләргә ярдәм итә. Әсәр проблемалар белән дыңгычлап тутырылган. Казанда милли чәйханәләр булмавыннан алып татар дөньясындагы бер генә проблема да әдипнең күз уңыннан читтә калмаган. Әсәрне укыганда гел әрнисең, гел гарьләнәсең: нигә без шундый хәлгә калдык соң? Кем гаепле? Инде нишләргә? Һәркем бу сорауларга үз вөҗданы кимәлендә җавап эзләр, әлбәттә. Шунысын да әйтергә кирәк, романны сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе язуы күренеп тора, кайчакта нәфисе сәнаигъка хилафлык китереп публицистика алга төртеп чыга. Хәер, бу безнең күп әсәрләргә хас сыйфат. Мондый күләмле, колачлы әсәрләрдә башкача булмый да торгандыр. Ләкин бу сүзләрем белән мин Айдар Хәлимнең художниклык куәсен һич тә кимсетергә теләмим. Сурәтләү чараларының байлыгы, персонажларның үзенчәлекле сөйләме авторның шагыйрь икәнлеген күрсәтеп тора. Кайбер урыннарда, А.Платоновның «Котлован» әсәрен укыгандагы кебек, сәер хисләр дә кичерәсең. Әйтерсең лә, Иркен ага бүтән яссылыкта, бүтән вакыт үлчәвендә яшәп ятучыларның планетасына килеп эләккән дә ниндидер сәер төш томанында тирбәлә. Гүяки иң асыл татар булып дөнья йөзләрендә бер ул гына калган. Ул һәм автор, әлбәттә.

Никадәр пессимистик рухта һәм кара тоннарда язылса да, әдәби әсәр укучыда киләчәккә өмет калдырырга тиеш, минемчә. Милли яшәеш җәһәтеннән мондый өмет һәм көрәш дәрте уяту бүген безгә аерата кирәк. Бүтән әсәрләр янында Ринат Мөхәммәдиевнең «Кыргый атауга сәяхәт» дип аталган хикәясе бу яктан аерылып

тора. Аның нон-фикшн шәкелендә, ягъни булган хәл дип язылуы да ышандыру көчен арттыра. Автор бер урыс шагыйре белән Яна Зеландиягә барып чыга. Аннан аларны нәни генә бер утрауга алып китәләр. Баксаң, әлеге утрауда туган илебездәге бандитлардан, алардан да бигрәк алйот чиновниклардан качкан Айрат исемле татар егете үзе бер нәни Татарстан булып яшәп ята икән. Татар кешесенең һичкайда югалып калмавына, гомумиләштереп әйткәндә, милләтнең үлемсезлегенә бер шәһадәтнамә түгелмени бу әсәр?

Югары сәнгать әсәренең төп үзенчәлеге — кеше ышанмастай нәрсәләр турында язып та укучыны сискәндерә, тетрәндерә алуда. Бу яктан хәзерге татар әдәбиятында Марат Кәбировка тиңнәр юк, минемчә. «Бердәнбер һәм кабатланмас» романында ул халкыбызның бүгенге аянычлы хәлен аллегория алымнары белән желеккә утәрлек итеп тасвирлап бирә алган. Кыскача гына эчтәлеге болай: Фатыйма әби ире белән авылда дүрт ир бала үстерә. Хәлил югары уку йортына керәм дип чыгып китә дә Америкага барып төпләнә. Хәмит маржага өйләнә, маржасы үләч, яна хатынының авылына — Башкортостанга барып урнаша. Малик, Сургутка эшкә китә, анда нахакка кеше үтерүдә гаепләнеп төрмәгә эләгә, биредә исә килеп йөргән поптан христиан динен кабул итеп, азат ителгәч, үзе дә поп була. Исемен Михаил дип үзгәртә, Анна исемле маржа белән гаилә кора. Өчесе дә әти-әниләренә бер кәлимә хәбәр җибәрми, алардан ваз кичә. Ул арада әтиләре вафат була. Шәһәргә киткән төпчек Радик алкашка әверелә. Фатыйма әби аның янына килеп тулай торакка урнаша, хәер теләнеп шунда җан асрый башлый. Менә шул вәзгыятьтә дөньякүләм танылган бай язучы Искәндәр әлеге дүрт ирне төрле юллар белән Балтыйк дингезендәге бер серле утрауга җыя. Ул аларны ата-анадан, туган туфрактан ваз кичкәннәре өчен җәзаларга, сабак бирергә ниятли. Ягъни үзенә Аллаһы Тәгалә вазифасын ала. «Үзе хакында халык югары фикердә булырга тиеш. Ә безнекеләр үзенең мескенлегенә җуелмас ышаныч белән рәхәтләнеп яши бирә», — ди кодрәтле язучы. «Бу нәфрәтме?» — дип сорый әңгәмәдәше. «Юк. Әрнү, — дип җавап бирә ул. — Фатыйма карчык турында белгәч, шушы әрнү кабат кузгалды. Татарның да бит бер өлеше чит илләрдә, бер өлеше Башкортостанда, бер өлеше чит диннәрдә. Ә ата йортын сакларга тиешлесе — исерек. Юк, хәмердән генә түгел. Белмим нәрсәдән икәнен дә. Тик ул — исерек. Ул, айнык кеше кебек, алдын-артын карап, иртәгәсен уйлап гамәл итми».

Искәндәрнең, биредә Марат Кәбировның дисәң дә ярыйдыр, эксперименты аянычлы тәмамлана. Утраудагы дүрт бертуган ир эзсез юкка чыга, авторның кинаясенә ышансаң, алар, мөгаен, бер-берсен татарча ашап бетергән булса кирәк. Аларга ярдәмгә ашыккан Фатыйма юл һәлакәтенә очрап, үзенең ниндидер яман энергиясен — улларын ул соңгы сулышында да кичерми! — уйнашчы хатын Ләйләгә калдырып дөньядан китә. Соныннан язучыны да әлеге юкка чыккан ирләрнең варислары үтерә.

Әйтерсең лә, милләтебезне суырып яткан упкынга күз салган Марат Кәбиров. Ләкин әйтем бар: упкынга озак карап торсаң, упкын үзе сиңа күзәтә башлый. Бер генә дә өмет юкмыни икән соң? Юк! Менә бу өзекне сезгә кабатламый булдыра алмыйм: «Фатыйманың җыры, тулай торак бүлмәсенең түшәмнәре аша үзып, югарыга күтәрелде һәм, далаларга киткән балаларны эзләп табарга теләгәндәй, җир шары буйлап таралды. Биек-биек йортлар, кара урманнар, очсыз-кырыйсыз далалар, шаулы дингезләр аша урап кайтты да, хәле бетеп тынган давыл сыман, кабат тулай торак бүлмәсенә ауды. Далаларга киткән балаларны ана моңы гына таба алмый икән. Монда инде тыелгысыз дәрт тә, өмет тә, киләчәктән көткән яктылык чаткылары да юк иде, монда тик ятимлек ачысы гына сулкылдады.»

Әсәр ризасызлык хисе уята, ниндидер кысаларны җимереп атасы, татар тормышын үзгәртеп корасы килә башлый. Романның көче шундадыр да, бәлки. Ләкин ничек? Ни рәвешле? Әйткәнемчә, үзе кузгаткан сорауларга җавап бирү авторның вазифасына керми.

Шунысы гыйбрәтле: авторлары шагыйрь булган проза әсәрләрендә сурәтләнгән баш каһарман, гадәттә, фани дөньяга сыя алмый, гел каршылыкларга очрый, каршылыклар булмаса, аларны үзе уйлап таба. Шәхес һәм җәмгыять, шәхес һәм дәүләт каршылыгы. Бу җәһәттән Нур Әхмәдиевнең «Мөнирстан» әсәре кызыклы.

Теле камил, сурәтләү чараларына бай әсәр, озынрак булса да, җыйнак: сюжет сызыгыннан чыгып арткан, бүселгән өлешләр юк диярлек. Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, дигәндәй, әсәр каһарманы гел сынаулар аша уза, ул бу җәмгыятьнең торышыннан риза түгел, әмма аны үзгәртергә дә чарасыз. Н.Әхмәдиев хәзерге татар әдәбиятында үзенчәлекле «артык» кеше образын тудыра алган. Мөнирнең бәхетсезлекләренә җәмгыять гаепләме? Әллә үзенең дә гаебе бармы? Яраклаша белмәү гаеп була аламы?

Бүгенгең аянычлы, киләчәгең томанлы икән, яктылыкны үткәннәрдән эзләү табигый хәл. Ә нигә әле бүгенге хәлебез аянычлы, дип кистереп әйтәсең, диярсез. Равил Фәйзуллинның яңа шигырьләреннән берсе белән җавап бирәм:

*Чагыштырам. Тик кызганыч:*
*Күп нәрсә истән чыккан.*
*Бүгене кызык булса да,*
*Үткәне өскә чыга.*

*Толерантлык, дия-дия*
*Күп нәрсә эштән чыккан.*
*Ил-тел хәлен уйлыйсың да,*
*Үткәне өскә чыга.*

Марат Әмирханов соңгы дүрт елда өч тарихи әсәр язып дөньяга чыгарды: «Урбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг». Боларга төрлечә бәя бирергә мөмкин. Кайбер терминнарны дөрес кулланмауда, тарихи төгәлсезлекләрдә гаепләргә дә була. Ләкин тарихыбызда һәмишә сай йөзгән яки бөтенләй хәбәрсез укучыда данлы да, кызганыч та үткәнебезгә карата кызыксыну уяту җәһәтеннән мондый әсәрләрнең әһәмияте бәхәссез. Шушы кыйммәтле сыйфатын икърар иткән хәлдә, «Әлвидаг» әсәренә бераз тукталып үтсәм, зыян булмастыр. Әсәрдә тарихка кагылышлы бүлекләр белән бүгенге заманны тасвирлаган өлешләр аралаштырып язылган. Бу, әлбәттә, яңалык түгел. Хәзерге заман белән үткәндәгесен чагыштырып нәтиҗәләр ясар өчен әлеге алимның үз өстенлекләре бар. Әсәр сәер генә башланып китә. Йоклап яткан Сөембикәне юрганына төреп урларга маташалар. Һәм урлаган да булырлар иде, тик ире Сафагәрәй ханның тавышы ишетелә: «Ханбикәне азат итегез!» Баксаң, бу чынлап урлау түгел, хан тарафыннан хатынының иминлеген сынар өчен үткәрелгән бер «учение» икән. Әлбәттә, керештә үк мондый көлке нәрсәләрне язу укучыда әсәргә ышанмау хисе тудыра. Шунысы да бераздан ачыклана: тарихка кагылышлы бүлекләр безгә билгеле чыганакларның компиляциясе генә икән. Шулай да аларда фәкать безнең көннәргә генә хас булган сүзләрне, төшенчәләрне кулланудан тыелырга иде. Бүгенге көнгә багышланган бүлекләрнең күбесе исә газетадагы репортажлар өслүбендә язылган. Мәсәлән, Париждан килеп Сөембикә эзләреннән йөрүче Татли дигән француз хатыны (үзе кайсыдыр татар морзасының токымы да икән әле) мондагы безләргә болай акыл өйрәтә: «Глобализация күп халыкларга, күп телләргә яный. Ассимиляция инде бүген үк бугаздан алды. Тик өметсез шайтан гына, ди. Татар зур тарихлы халык. Милләт агачының үзәге таза, тамырлары тирәндә. Шуна күрә яфраклары саргаеп, ботаклары зәгыйфьләнеп киткән очракта да шытым бирергә сәләтле. Әлбәттә, табигатьтәгечә тәрбияләнү, ашлау, сугару зарур. Монысы инде субъектив фактор: һәр буын өстенә бердәй дәрәҗәдә төшә торган гомум бурыч кына түгел, көндәлек вазифа. Татар кебек дәүләтчелеген югалткан этнос өчен субъектив фактор аеруча мөһим». Мин инде моңа берни өсти алмыйм.

Ә Камил Кәримовның «Игезәкләр йолдызлыгы» әсәрен укыганда үзебезнең, ягъни хәзерге заман татарларының тарихка күчә баруын тоясың. Әсәргә җентекләп тукталырга мөмкинлегем юк, киләсе елга Тукай премиясенә тәкъдим ителгәч, анын турында әле күп язарлар. Мин Дияр картның кызыл сандык ясатып (һәлакәткә дучар булган очкычларның «кара тартма» дигәннәре кызыл төстә икән), аңа икешәрданә «Әлифба», «Туган тел» китаплары, Илһам Шакиров, Фәридә Кудашева пластинкалары, чүпләмле сөлгеләр, чигелгән яулыклар салып җиргә күмүенә генә

игътибарны җәлеп итәсем килә. Дияр карт кыямәттән соң да Татарның янадан тернәкләнеп күтәрелүенә ышана. Бу коры ышанычтыр, баксаң, ләкин ул бүген барыбызга да кирәк. Кыяматкә өметләнеп тормыйча, бүген татар булып яшәү өчен кирәк.

Бүгенге дөньяда милләтнең урынын билгеләгәндә, иң беренче нәүбәттә, аның асыл шәхесләрен барлау зарур. Инде тарихта калганнарын да, бүгенгеләрен дә... Үз арабызда булып татар дәүләтчелегенә, татар мәдәниятенә хезмәт иткәнме ул, әллә татар исемен югары күтәреп дөнья сәхнәсенә менгәнме — алар барысы да безнең өчен кадерле булырга тиеш. Равил Вәлиевнең Рудольф Нуриев тормышына һәм иҗат эшчәнлегенә багышланган «Канатлы татар» әсәре шул юнәлештә бер адым булды. Күптән түгел Батулланың да әлеге атаклы шәхес турында романы дөнья күрде. Зәки Зәйнуллинның «Кави Нәҗми дигән язучы» әсәре исә әлеге каршылыклы шәхеснең биографиясенә яна штрихлар өсти.

Былтыр Татарстан китап нәшриятында Роза Туфитуллованың «Бәйлисе бар йөрәкне» дигән китабы дөнья күрде. Ул Хәсән Туфан тормышындагы гүзәл мизгелләрне үз эченә алган. Һәм бер үк вакытта бөек шагыйрьгә җан җылысы биргән, кайчакта үлем куркынычын да җиңәргә ярдәм иткән ханымнар, туташлар турында да әлеге китап. Анда әдәби эшләнгән кисәкләр белән шәхси хатирәләр, кичерешләр, документаль чыганаклар, әсәр каһарманнарының истәлекләре нәүбәтләшеп, бер-берсен баетып килә. Нәтиҗәдә үзенчәлекле форматка ия булган бербөтен әсәр дөньяга туган.

Мондый әсәрләр рәтенә мин Тәлгат Галиуллинның «Мөхәммәт Мәһдиев йолдызлыгы» дигән роман-эссесын да кертер идем. Дөрес, аның жанрын «истәлекләр» дип кенә дә билгеләп була. Ләкин автор белән бу җәһәттән бәхәскә керәсем килми. Гоголь «Үле җаннар» әсәрен поэма дип атаган бит әле, һәм аңа беркем дә дәгъва белдерми. Иң мөһиме, Тәлгат ага М.Мәһдиевне һәйкәлгә әверелдерми, төрле гамьнәр, вак борчулар, нәни сөенечләр һәм олы әрнү белән яшәүче гап-гади кеше итеп сурәтли. Һәм безнең күз алдында мәшһүр язучының олпатлылыгы, зурлыгы арта гына төшә. Олы язмышлы шәхесләр турындагы әсәр үзе үк бу авыш-тәвеш заманда һәрберебезгә терәк була ала.

Ләкин милләт язмышында булсын, аерым кешенең шәхси тормышында булсын — иң төп терәк, әлбәттә, Аллаһ Тәгалә. Аңарга ышану, ягъни Иман. Нәбирә Гыйматдинованың «Эзләмәгез җирдән» бәянен укыгач, әлеге хакыйкатьне хәтердә яңартмый мөмкин түгел. Кайчандыр күренекле рәссам булган Зөлфия Солтанова алга таба юл таба алмаудан гаҗиз булып, тәмам кешелектән чыга, эчкечелеккә бирелә. Әмма Аллаһ Тәгалә ташламаса, кеше барыбер кыйбласын таба. Автор, психологик төсмерләрдән саран гына файдаланып, шушы мәңгелек фәлсәфәне алга сөрә.

Тарих чоңгылларыннан исән-имин үтеп, милләт буларак үз йөзенне җуймау һәр көн туктаусыз көрәш, көчәнеш таләп итә. Шул көчнең чыганагы нидә? Хатын-кызда! Нәбирәнең һәр әсәрендә хатын-кызның алгы планга чыгуы, минемчә, шуның белән бәйле. Монысы да безнең борынгы риваятьләрдән, әкиятләрдән килә. Тарих төпкелендә чакта ук безне Ашина коткарып калган! Хатын-кыз йорттагы учакны саклап, аңа утын өстәүче генә түгел, ир-егетләре йә кырылып, йә хатыншага әйләнеп беткәндә, көрәш кылычын үз кулына алып юлбашчыга әверелүче дә...

Бүген хатын-кыз язучыларның алгы сафка чыга баруын шушы хәл белән дә аңлатып була. Бу уңайдан иң беренче итеп Фәүзия Бәйрәмова исемен атарга кирәк, әлбәттә. Аның романнары, хәтта юлъязмалары (мин аларны документаль проза буларак кабул итәм) бүгенге әдәбиятыбызның офыкларын киңәйтеп җибәрде. Аларны укыганда мәңгелек әрнү, рәнҗү тойгылары белән бергә йөрәктә горурлык хисе дә уяна, җилкәләр язылып китә.

Биредә өлкән язучыларыбыздан Мәдинә Маликованың «Юкә чәчәк аткан чак иде» романын, Гөлчәчәк Галиеваның «Газзәбану»ын, яшьрәкләрдән Рәмзия Габделхакованың «Тау артында кояш бар», Фирүзә Җамалетдинованың «Исемнәре Искәндәр», Айгөл Әхмәтгалиеваның «Өзелгән гөл» әсәрләрен билгеләп үтәр идем. Халисә Мөдәррисованың «Соңгы сер» бәяне исә миңа аерата тәэсир итте. Җыйнак

кына әсәр җиңүчеләргә дә, җиңелүчеләргә дә бәхетсезлекләр китергән сугышка ләгънәт булып яңгырый. Хәер, авторның үзеннән дә үтемлерәк әйтеп булмас: «Тарихта булып үткән яки булачак бөтен сугышларга каһәр укып, аталыдан атасыз булган баласын күкрәгенә кысып, чәчләрен җилгә чәчеп, эшелон артыннан бер хатын йөгерә.

Милләте кем аның, сәясәткә мөнәсәбәте бармы, нинди телдә сөйләшә ул, дине нинди аның? Кем генә булса да, ул сугышка каршы, ул бары тик имин илдә, тыныч, тулы гаиләдә, ир хатыны булып яшәп, дөнья киләчәген дәвам иттерергә теләүче гади хатын гына.

Сугышка ләгънәт укып, перроннан, сугыш эшелоны артыннан Мәңгелек хатын йөгерә».

Сүземнең ахырында шуны әйтәсем килә: без күп вакытта татар прозасының торышына канәгатьсезлек белдерәбез, укымаган килеш бәя бирергә ашыгабыз. Хәлбуки, бездә игътибарны җәлеп итәрлек әсәрләр бар. Кайберләре татар игътибарын гына түгел, бүтән халыкларның да игътибарын яуларлык. Шуңа күрә аларны, аерып алып, бүтән телләргә, аерата урыс һәм төрек телләренә тәрҗемә итү эшен гамәлгә куясы иде. Чөнки кин дөньяга чыккан һәр яхшы әсәр татар халкының да, Республикабызның да дәрәҗәсен күтәрәчәк. Урыс теленә күпмедер әсәр тәрҗемә ителә, ләкин бу авторларның энтузиазмына һәм кесәсенә генә бәйле. Татар әдәбиятын дөньяга чыгару мәсьәләсендә Мәдәният министрлыгы белән Язучылар берлегенең аерым программасы булырга тиештер. Шунысын гына әйтәсем килә, Төркия нәшриятлары, каләм хакы түләмәү шарты белән, татарчадан тәрҗемә китапларын нәшер итәргә әзер. Шундый мөмкинлекләр булса да, без беркемнән дә әсәрләрне бушлай тәрҗемә иттерә алмыйбыз. Тәрҗемә бик күп көч һәм, әлбәттә, сәләт сорый торган гамәл. Гомумән, мөстәкыйль дәүләтләрдә үз әдәбиятларын чит илләрдә пропагандалау белән тышкы эшләр министрлыгы, илчелекләр шөгыльләнә. Без өмет тулы карашыбызны бары тик Мәдәният министрлыгына гына төби алабыз.

Киләчәгебезгә ышаныйк! Үз язмышына ышанып алга барган халыкларга Тәнре мәрхәмәтле була.

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XVII КОРЫЛТАЕ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

Татарстан Язучылар берлеге – Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында иң зур иҗат оешмаларының берсе. Аның 2008 елдан алып 2012 елга кадәр булган ике корылтае арасындагы эшчәнлеге Язучылар берлеге Уставына нигезләнеп һәм Татарстан Президенты указлары, хөкүмәтебез карарларына таянып алып барылды. Шул ук вакытта бу чорда республикабыз һәм бөтен халкыбыз тормышында булып үткән әһәмиятле вакыйгалар да язучылар иҗатына, Язучылар берлеге эшчәнлегенә җитди йогынты ясады. Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Дәрдемәнд, Муса Җәлил, Һади Такташ, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал, Хәсән Туфан, Сәгыйть Рәмиев, Гомәр Бәширов, Сибгать Хәким, Әмирхан Еники, Габдрахман Әпсәләмов һәм башка күренекле шәхесләребез юбилейларын бөтенхалык бәйрәме дәрәҗәсендә уздыру чараларында һәрвакыттагыча Язучылар берлеге һәм әдипләребез турыдан-туры һәм актив катнаштылар.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе И.М.Ибраһимовның отчет докладында, әдәби жанрлар буенча ясалган докладларда, язучылар чыгышларында идарәнең отчет чорындагы эшчәнлеге төрле яклап яктыртылды.

Бу чорда Татарстан каләм ияләре актив иҗат иттеләр, милли әдәбиятыбызны поэзия, проза, публицистика, драма, шулай ук балалар өчен язылган әсәрләрдә укучы таләбенә җавап бирерлек камил, югары дәрәҗәдәге сүз сәнгате әсәрләре белән баеттылар. Рус телендә иҗат итүче әдипләр дә отчет чорында нәтиҗәле эш алып барды. Аларның әдәби тәрҗемә өлкәсенә актив тартылуы игътибарга лаек.

Нәтиҗәдә ике корылтай арасында Татарстан язучыларының 500гә якын әдәби китабы укучыга барып житте. Ул китаплар Татарстаннан тыш Мәскәүдәге үзәк нәшриятларда, Уфада, Ижау, Төмәндә, Самарада, Россиянең башка төбәкләрендә, Төркия, Англия, Әзәрбайҗан һәм башка чит илләрдә дөнья күрде.

Ике корылтай арасында әдипләребезнең иҗатын стимуллаштыру максатында әһәмиятле чаралар күрелде. Г.Исхакый, Ф.Хөсни, Һ.Такташ, А.Алиш, Ж.Вәлиди исемендәге әдәби премияләр Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлеге бүләге статусында даими бирелеп барылды. «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте белән Язучылар берлегенең Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләрен һәм яшь иҗат көчләре өчен стипендияләрен бирү дәвам иттерелде. Юмор һәм сатираны үстерү максатында Татарстан Язучылар берлегенең һәм Актаныш муниципаль районы хакимиятенең Гамил Афзал исемендәге премиясе булдырылды.



*Корылтайдан бер күренеш.*

Язучыларның иҗатын пропагандалау, укучыларның каләм ияләре белән элемтәсен ныгыту максатында күпкырлы һәм нәтиҗәле эш алып барылды. Башкортостан, Чувашия, Удмуртия, Мордовия республикаларында, Пермь, Чиләбе, Ульяновск, Самара, Төмән өлкәләрендә, республикабызның дистәләрчә районында татар әдәбияты көннәре, юбилейлары унаеннан йөзгә якын язучының иҗат һәм искә алу кичәләре үткәрелде.

Язучыларыбызның иҗат эшчәнлекләре, республиканың рухи-мәдәни тормышында актив катнашулары дәүләт органнары тарафыннан югары бәяләнде. Ике корылтай арасында Татарстан Язучылар берлеге үтенече нигезендә 126 язучы Татарстанның һәм Россиянең мактаулы исемнәренә һәм төрле бүләкләргә лаек булды.

Татарстан язучыларының XVII корылтае Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең 2008-2012 еллардагы эшчәнлеген «канәгатьләнерлек» дип бәяли.

Шул ук вакытта матбугат чараларындагы язмалардан, съездагы докладлардан, чыгышлардан күренгәнчә, хәл итәсе мәсьәләләр дә байтак әле. Аерым авторларның шәхси уңышларына карамастан, республикабыз каләм ияләренең иҗат активлыгы бердәй югары дип әйтеп булмый. Әдәби әсәрләрдә туган телебезгә, халкыбызның рухи байлыкларына карата булган таләпчәнлекне арттырырга кирәк. Поэзиябездә югары зәвыклылык, прозада эпиклык һәм колачлылык, драматургиябездә миллилек җитенкерәми. Татар әдәбиятын рус теленә тәрҗемә итүдә профессиональлекне үстерү, сәләтле тәрҗемәчеләрне дәүләт китап нәшриятларында даими эш белән тәэмин итү зарур.

Балаларга белем бирүдә милли-төбәк компонентын юкка чыгарып, Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни, шул исәптән әдәбиятының үсешен чикли торган федераль закон кабул ителү барыбызны да борчый.

Ике корылтай арасында дәүләт нәшриятларының, «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте карамагындагы әдәби басмалар редакцияләренең китап чыгару, тарату, авторларның хезмәтенә тәңгәл гонорар түләү эшендә күзгә күренерлек уңай үзгәрешләр булса да, телерадиокомпанияләрнең бу өлкәдә активлык күрсәтүләре җитенкерәми.

корылтай Язучылар берлегенең җәмгыятебезгә кирәклеген, халкыбызның мәдәни-рухи тормышында тарихи әһәмиятен тагын бер кат искәртә.

Татарстан язучыларының XVII корылтае язучылар җәмәгатьчелегенең киләчәктәге һәр гамәле, беренче чиратта, республикабыз тормышын һәръяклап кайгыртырга, туган халкыбызның милли идеясен раслауга һәм үстерүгә хезмәт итәргә тиеш дип

саный. Корылтай Язучылар берлеге киләчәктә республикабызның дәүләт, җәмәгать һәм башка төр оешмалары белән берлектә түбәндәге чараларны тормышка ашыруны максатка ярашлы дип таба:

– Татарстан Республикасы хөкүмәте белән берлектә әдәбиятны һәм сәнгатьне үстерүгә юнәлдерелгән озак вакытка исәпләнгән дәүләт финанславындагы Республика Программасын төзү.

– Татарстан Язучылар берлегенең дәүләт тарафыннан төзекләндерелгән-реставрацияләнгән бинасын әдәбиятны пропагандалау, төрле чаралар үткәрү, иҗат мөмкинлекләре тудыру, үзара аралашу, ял итү максатында нәтиҗәле файдалану.

– Татарстан Республикасы хөкүмәте белән берлектә, атаклы әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең исемен мәңгеләштерү максатында, озак вакытка исәпләнгән план төзү һәм аны дәүләт чыгымнары, хәйриячелек нигезендә тормышка ашыру.

– Татар әдәбиятын пропагандалау максатында һәр шәһәрдә, район үзәгендә, зур торак пунктларында китап кибетләре ачу, китапханәләрдә китап сәүдәсе оештыру, аларның фондларын дәүләт заказы белән басылган китаплар исәбенә баету.

– Татар әдәбияты классикларының, халык язучыларының күптомлы сайланма әсәрләрен дәүләт исәбенә бастырып чыгаруны дәвам итү.

– Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән берлектә татар язучылары әсәрләрен рус һәм башка телләргә тәрҗемәдә нәшер итүнең 5 еллык планын төзү.

– Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә мәктәпләрдә, махсус урта һәм югары уку йортларында файдалану, чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләргә куллану өчен татар язучылары әсәрләренең аудио-китапларын чыгаруның еллык планын төзү.

– Татар әдәбиятын үстерүдә, аның төп юнәлешләрен билгеләүдә әдәбият фәненең, әдәби тәнкыйтьнең ролен көчәйтү.

– Әдәбиятның киләчәген кайгырту, яшь каләм ияләренең активлыгын үстерү, иҗатларын стимуллаштыру максатында җирле әдәби берләшмәләр эшчәнлегенә игътибарны арттыру, республика күләмендә үткәрелә торган әдәби конкурсларны тагын да масштаблырак итү һәм аларны финанслауда дәүләт һәм иганәчеләр ярдәмен арттыруга ирешү.

– Мәктәп дәреслекләрен классик әдәбиятның һәм бүгенге заман язучылары иҗатының иң яхшы үрнәкләре белән камилләштерү.

– Татарстан язучыларының торак шартларын яхшырту максатыннан, Татарстан социаль ипотекасы программасы кысаларында, Язучылар берлеге әгъзалары өчен льготалар билгеләүне тормышка ашыру.

– «Васильево» шифаханәсендәге «Иҗат йорты»нда язучыларның ташламалы юлламалар белән ял итүен дәүләт гарантиясенә алу.

# ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА

24 март көнне (2012 ел) минем өчен көтелмәгәнрәк хәл булды: Казан милли-мәдәни үзәгендә Россия татар авыллары эшмәкәрләренең җыенында Фәүзия Бәйрәмова мина «Ачылмаган татар тарихы» исемле китабын бүләк итте. Дөрес, башта ул китапны автограф-фәлән язмыйча гына биргән иде. «Язып бир», — дигәч, титул битенә шундый сүзләр язылган китапны сузды. «Хөрмәтле Туфан абыйга! Милләтебез бөек һәм фаҗигале юл үтте, ул бәхеткә дә, бәхетсезлеккә дә лаек. Сез бөтен гомерегезне татар халкын бәхетле итүгә багышладыгыз. Милләтебезнең азат булган көннәрен күрергә насыйп итсен иде. Без башлаган эшне балаларыбыз дәвам итсен иде!» Язылганның ихласлыгына ышандым: Фәүзиянең холкы, ялгышмасам, ак белән карадан гына тора — сүзнең матурын да, матур булмаганын да бәреп әйтә, әллә нинди бормалы-сырмалы, икеле-микеле җөмләләр эзләми. Мактау сүзе, әлбәттә инде, анардан сирәгрәк чыга.

Автограф турында шулай озын итеп язуымның сәбәбе — озак еллар ул мина кырынрак карап йөри. Кайчакларда сәлам дә бирми узып китә. Сәбәпләре бардыр инде — төрле фаразлар кылып үткәннәрдә казынасым килми. Мин үзем дә бит сер бирүчеләрдән түгел, «не хочешь, как хочешь» принцибы белән яшим. Бигрәк тә хатын-кызларга карата. Хатын-кыз белән бәхәскә керүне мәгънәсез эш дип саныйм. Чөнки хатын-кыз беркайчан да сүзен бирми, мин ялгышамдыр, бәлки, дигән сүзне үтерсәң дә әйтми. Бер гаишникның әйткәне искә төште: «Ир-ат шоферлар юл кагыйдәләрен бозганнарын танырлар, ә бер генә хатын-кызның да таныганы юк», — дигән иде ул. Максималист, «экстремист» хатыннардан шүрлим дә әле: алар үзләренең хаклылыгын раслар өчен сүз сайлап тормыйлар — ишетмәгәненне ишетәсең. Фәүзия дә хатын-кыз. Нихәтле генә талантлы, ничаклы гына акыллы, белемле булса да, хатын-кыз. Горурлыгы тәкәбберлек янәшәсендә торган мөстәкыйль фикерле татар хатыны. Аның ара-тирә «ычкынып китеп» әйтеп ташлаган кайбер сүзләре мине һәрвакыт сагайтты, аның татар милләте өчен аяусыз көрәшүенә соклансам да, анардан читтәрәк торуны хәерлерәк санадым. Мин генә түгел, бүтән милләтпәрвәрләр дә ана бигүк якын килмиләр. Хәер, Фәүзия үзе дә якынаерга тырышмый бугай. Хәтеремдә әле, Бөтендөнья татар конгрессының бер җыелышында Фәүзия трибунадан залга күз ташлады да: «Бу залда милләт турында кайгыртучы берәү дә юк», — диде. Җыелышны алып баручы Разил Вәлиев тапкыр кеше: «Нишләп булмасын, Фәүзия ханым, сез бар бит», — диде.

Фәүзия Бәйрәмованың холкына кагылышлы тагын бер вакыйганы әйтәм дә, төп сүзгә күчәм. Моннан утыз ничәдер еллар элек мәрхүм Илдар Юзеев белән Бауман урамындагы Матбугат йортының коридорыннан барабыз — каршыбызга кәс-кәс басып бер кыз килә. Безнең каршыбызга туктады бу: «Сез үзегезне бөек драматургларга санныйсыз инде, менә мин язып күрсәтәм әле сезгә пьесаның нинди булырга тиешлеген», — диде дә, кәс-кәс атлап китеп тә барды. «Кем булды бу?» — дип сорадым Илдардан. Илдарның ни әйткәнен инде хәтерләмим, көлгәнебез хәтердә. Менә шундый холык Фәүзияне гомер буе озата бара. Ләкин аның холкын кабул итмәсәләр дә, татар язмышы өчен борчылучылар аны читкә тибәрмәделәр. Бүген дә ул Бөтендөнья Татар конгрессының башкарма комитеты әгъзасы. Мин шәхсән Фәүзиянең холкын өнәмәсәм дә, аны хурларга теләүчеләр ягына бер карыш та аяк басмадым, аны якларга тырыштым. Язучылар берлеге идарәсе утырышларында берничә тапкыр аны Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим иттем, ләкин аның кандидатурасы яшерен тавыш биргәндә төшеп кала торды. Фәүзия, горур шәхес буларак, андый бойкотларга исе китми, ялынып-вакланып йөрми — эшлисен эшли, язасын яза бирә. Мин аның язганнарын даими укып барам. (Даими укып барган язучыларым биш-алтыдан узмый). Язганнарына бәям югары. Талантлы кызыбыз, чын көрәшче шәхес, кыйбласы төгәл билгеләнгән. Кайвакыт язганнарына хөрмәтемне үзенә әйтергә теләгәнем дә бар, ләкин тукталып калам. Чәнечкеле берәр сүз

ташлар да, ачуымны чыгарып дип дәшми калам. Мин бит әле, ачуым да бер килмәгәе, аңардан күп яшькә өлкәнрәк тә. Шулай йөри бирәм,ниндидер тәкәббер кызыйга мәхәббәтен белдереп вакланырга теләмәгән егет шикелле.

Эшмәкәрләр жыенында Фәүзия искиткеч төпле, акыллы чыгыш ясады. Бу юлы мин аңа мактау сүзләремне әйтмичә булдыра алмадым, Фәүзия елмайды. Карале, елмайганда бигрәк чибәр икән бу ханым — йөзенә туры караганым юк иде.

Инде бүләк ителгән китапка күчик. Андагы сәяхәтнамәләрнең барысы белән дә диярлек, әйткәнемчә, таныш булсам да, китапны тулаем укып чыктым. Сәяхәтнамәләрен автор үзе фәнни-популяр язмалар дип атый. Әлбәттә, шулай. Ләкин алар Фәүзиянең татар дөньясы буйлап сәяхәт кылуларының нәтиҗәсе. Сөбханалла, кайларга гына барып чыкмаган ул. Әгәр дә Галимҗан Ибраһимов исән булса, теге заманда язган «Татар хатыны ниләр күрми» хикәясен ертып ташлар да, бүгенге татар хатынының күргәннәрен исе китеп, сокланып язар иде. Мин үзем дә йөрим татар арасында, мин дә күрәм Фәүзия күргәннәрне, мин дә сөенәм, мин дә көенәм, ләкин язганнарым фәнни дәрәҗәгә күтәрелә алмый, күрәсең, мин тарихчы галим түгел. Фәүзия Бәйрәмова татар тормышын бүгенгесе һәм үткәне белән бәйләп карый, еш кына ул тарихка, тормышка галимнәр карашыннан күз сала. Бу аның күп укуын, тирән мәгълүматлы булуын раслый торган факт. Әлләни калын булмаган китапта Россиядә татарны юк итү сәясәтенең ничәмә гасыр буе эзлекле рәвештә баруы дәлилләп, күп санлы мисаллар белән күрсәтелә. Әйе, бу илдә җәмгыяви формацияләр үзгәреп тора (феодализм, капитализм, империализм, социализм, тагын капитализм) ә руслаштыру сәясәте үзгәрми; патшалар, генсеклар, президентлар алышына, рустан башка милләтләрне юк итү планы гына алышынмый. Фәүзия галим-публицист буларак боларны анализлый. Моңа бер генә шовинист галим дә каршы чыгып, Фәүзияне милләтләр арасында низаг тудыруда гаепли алмый һәм алмаячак. Моннан ике-өч ел элек «Комсомольская правда» газетасында сатирик Михаил Задорнов Россиянең тарихын аллы-гөлле итеп сурәтләгән иде. Анда, имеш, колониализм да, инквизиция дә булмаган. Мин аңа җавап язарга алындым. Элеккеге союздаш республикаларның асылда колонияләр булуын яздым да, инквизициянең булганын раслау өчен мисаллар эзләргә тотындым. Фәүзия мәкаләсеннән таптым мин аны. Урал ягында көчләп чукындырылган бер мөселман татар хатынының янадан үз диненә кайтканы өчен Россия патшасы указы нигезендә яндырып үтерелгәнен Фәүзия язып чыккан иде. Шуны да кабатлап, «Звезда Поволжья»дә мәкалә бастырып, аны «Комсомольская правда»га җибәрдем. Дәшмәделәр. Ялганнары тотылганын аңладылар. Фәүзиягә тикшерү оешмаларыннан туктаусыз бәйләнеп торалар, ләкин гаепләрлек фактлар таба алмыйлар, чөнки аның һәр җөмләсе, һәр сүзе фактлар белән исбатланган була.

Китапның «Мишәрләр иле» дигән бүлеге миңа аеруча тәэсир итте. Белмим икән ләбаса мин татарның бу кавемен. Аннан-моннан ишеткән белән генә йөргәнмен. Бигрәк тә мишәрләрнең борынгы бортас кабиләсенә барып тоташуы кызыклы булды һәм бу ышанырлык итеп дәлилләп язылган. Безнең Тау ягында (Кама Тамагы, Апас районнары) Бортас исемле авыллар бар. Без бит мишәрләр күпләп яшәгән якларга якынрак. Димәк, бәйләнеш бар. Фәүзиянең тарихчы гына түгел, публицист та булуы, мишәр кавеменең татар тарихындагы урыннарын бүгенге халәтләре белән бәйләве бигрәк тә отышлы. Мин автор белән тулысынча килешәм — ул көчле, унган, булган, үҗәт кавемнең гомумтатар яшәешендә роле бик зур, гомеребез озын булсын дисәк, бергәлекне тагын да ныгытырга, кыйблабызның бер юнәлештә булуын сакларга кирәк.

Китапның «Татар Уралы» өлеше дә тарихи чыганакларга таянып Фәүзиячә язылган. Нух пәйгамбәр темасы минем өчен бераз сәеррәк, әлбәттә. Автор арттырыбрак җибәрмәде микән дип тә уйлап куйдым. Ләкин тарихтан надан башым белән бәхәсләшергә алынмыйм. Әмма ул якларның борын-борыннан төрки-татар җирләре булуы (һәрхәлдә, урысныкы түгел) бәхәссез. Аның өчен әллә кая барырга кирәкми, безнең төбәктән алып Тын океанга хәтле араның топонимикасына гына игътибар итәргә кирәк. Безне кыргый даладан чыккан кыргый халык дип язганнарына җен ачуым чыга иде. Юк шул, Фәүзия әйткәнчә, без тау кешеләре. (Хәер, дала халкы булсак, ни начарлыгы бар?). Заманында шуны дәлилләргә тырышып бер мәкалә дә язган идем. Безнең халык тауның образын

кешегә охшатып сурәтләгән: Тау башы, тау төбәсе, тау бите, тау күзе, тау муены, тау күкрәге, тау биле, тау итәге, тау сырты... Әле тагын мин ишетмәгәннәре дә бардыр. Белмим, тагы кайсы халыкта бар тауны кеше итеп сурәтләү?

Мин Урал төбәгендә татарларның татарлыгы шактый ук яхшы сакланган дип уйлый идем, бактың исә анда милләтебезнең хәле нык уйландырырлык икән. Әйе, нәрсәнең ни икәнен үз күзең белән күргәч кенә аңлыйсың шул. Фәүзияне укыгач, шактый ук шомлы уйлар килде. Элегрәк тә Фәүзиянең аерым мәкаләләрен укып, шул як кешеләре белән очрашып хәл-әхвәл белешеп, кайбер авылларда үзем дә булып Урал төбәге татарлары тормышыннан, тарихыннан азмы-күпме хәбәрдар идем. Хәлләребез монда да бигүк әйбәттән түгел икән. Милләтнең үз-үзен саклау иммунитеты ярыйсы ук какшаган. Әлбәттә, моның сәбәпләре бар — ничәмә-ничә гасыр буе изелеп, мыскыл ителеп килгән татар көрәштән арып аянычлы язмышына буйсынган, киләчәгенә кул селтәгән. Күп кенә татарларга татар булуның кирәге юк, ана кем булса да инде барыбер. Урыс дип язсалар да барыбер, башкорт дип язсалар да барыбер, диннән ваз кичсә дә барыбер. Иманы да инде тотрыксыз. Мондый татарны ничек хак юлга чыгарырга? Чын көрәшче Фәүзия Бәйрәмова да «Бу сорауларга мин дә җавап таба алмыйм...» — ди. Бердәнбер өмет Фәүзия һәм без күргән көчле рухлы, динле, иманлы татар авылларында татарның башбирмәс егетләре-кызларында. Алар, Аллага шөкер, бар әле. Кыскасы, гыйбрәт алырга да, үрнәк алырга да мисаллар күп.

Фәүзиянең әлеге һәм аңа чаклы чыккан китапларында бары тик бер генә максат — татар халкын югалтудан саклап калу. Аның өчен бәйсезлеккә ирешү. Бу бөтен милләтпәрвәрләрнең дә максаты. Ләкин ул бәйсезлеккә ничек ирешергә? Фәүзия язуынча, Идел — Урал легионнарын җитәкләүче татарлар да ул турыда уйланганнар. Легионнарда җанын саклап калырга теләүчеләр белән бергә, әлбәттә, Германия ярдәме белән татарның мөстәкыйль дәүләтле чорын кире кайтарырга хыялланучылар да булган. Андыйларны Фәүзия хөкем итәргә ашыкмый. Мин бәхәскә кермичә генә шуны әйтә алам — бәйсезлек яулап алуның мондый юлы — наивлык. Безгә Германия дә, Америка, Кытай, шул исәптән Россия дә бәйсезлек бирмәячәк. Жириновский әйтмешли, «Надо было в свое время защищать свое государство, сейчас нечего рыпаться». Бу сүзләрне ул 1990 елда, Мәскәүдә, Съездлар сарае фойесында журналистларга әйткән иде. Дәүләтчелегебезне кайтару өчен безгә бер генә юл — иң элек рухыбыз ирегенә, рух бәйсезлегенә ирешү. Җаны бәйсез булган милләт кенә үзен саклап кала алачак. Фәүзия дә шуның өчен көрәшә, иманга кайтырга чакыра. Моның өчен аны берәүнең дә гаепләргә хакы юк.

Бу уңайдан Фәүзия Бәйрәмованың 2010 елда Чаллы шәһәр судында ясаган чыгышы татар тарихына аерым сәхифә итеп теркәп куярлык факт. Анда көрәшче кызыбыз дөньякүләм әһәмияткә ия чыгыш ясаган, үзен бөек сәясәтче итеп күрсәткән, аны хөкем итәргә алынучыларның мескенлеген раслаган. Ул чыгышны китабына кертеп Фәүзия бик тә дөрес эшләгән. Аны укыгач, минем күз алдымда Фәүзия тагын да үсеп китте.

Фәүзиягә бер генә теләк: ул (сәбәпләре дә бардыр) язучы каләмдәшләреннән бераз читләшә. Татар язучылары арасында төрлесе бар, әмма безнең барыбызны милләт язмышы берләштерә. Монда, минемчә, битарафлар юк. Бергәрәк булыйк, фикерләр уртаклашыйк, аңлашыйк, рухыбызның бөтенлеген ныгытыйк. Милләтебез алдында без барыбыз да җаваплы. Бер чыгышымда мин фашистлар Мәскәү янына килеп җиткәч политрук Крючковның «Отступать некуда, позади Москва» дигән сүзләрен бүгенге хәләтебезгә туры китереп «Чигенергә урыныбыз юк, артыбызда милләт язмышы» дигән идем. Фәүзиянең ачынып (куанып та) язганнары шуны раслый.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**
*3 апрель*

**Редакциядән.** Бу мәкаләне Туфан ага вафатына бер ай кала язган. 26 апрельдә, шигырь бәйрәмендә, ул аны безгә китерә, дип вәгъдәләшкән идек. Китереп җиткерә алмады... Ләкин, шөкер, укучыларыбызга барып ирешә ул.



*Азнакай районында очрашулар истәлеге. Сулдан уңга – Шәүкәт Галиев (1928-2011), композитор Заһид Хәбибуллин (1910-1983), Ләбибә Ихсанова (1923-1900), Илдар Юзеев (1933-2004), Мәхмүт Хәсәнов (1927-1990). 1970 елда төшерелгән фото.*



*Шагыйрь Мәхмүт Хөсәен һәм Магнитогорск Татар иҗтимагый үзәге җитәкчеләре Фәнзаман Баттал фатирында кунакта. 1992 ел.*



*Татарстан Язучылар берлегендә очрашу. Уңнан сулга: Чыңгыз Айтматов, Олжас Сөләйманов, Равил Фәйзуллин, Харрас Әюп, Марат Әмирханов, Солтан Шәмси. 2000 ел.*



*Университет тәмамланган, зур шагыйрь булырга ниятләр зурдан! Рөстәм Мингалимов, Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим). 1969 ел.*



*"Казан утлары" журналы редакциясендә. Сулдан уңга: Факил Сафин, Флүс Латыйфи, Марс Шабаев. 2004 ел.*

# ТАТАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ТАРИХ ПРОФЕССОРЫ

ГАЗИЗ ГОБӘЙДУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Газиз Гобәйдуллинның тарих фәненнән татарлар арасында беренче профессор, 1920-30 елларда татар әдәбияты тарихының мөстәкыйль фән булып формалашуын тәэмин итүче, Казанда Шәрык академиясен нигезләүчеләрнең берсе буларак татар мәдәниятендә мәртәбәле урыны бар. Дөрестән дә, фаҗигале шәхес культы казасына эләккәнче, XX гасырның беренче чирегендә, ул күп төрле һәм гаять әһәмиятле фәнни, иҗтимагый-мәдәни эшчәнлек алып бара: төрки дөньяда аерым гыйльми юнәлешләрне нигезли, әдәби һәм фәнни кыйммәте бәһаләп бетергесез хезмәтләр һәм әдәби әсәрләр яза, югары уку йортларында профессор гына түгел, җитәкче вазифалар башкара... Бу урында шуны да билгеләп үтик, Г.Гобәйдуллинның мәдәниятнең алтын чоры буларак кабул ителгән XX гасыр башында башкарган хезмәтләре үзләренең әһәмияте ягыннан һич тә 1917 елдан соңгы чор эшчәнлегеннән калышмый. Бәлки әле милли мәдәни күтәрелешне башлап йөрүе, аның төрле сукмакларда киңәеп үсүе белән бәйле адымнары мөһимрәктер дә. Һәрхәлдә әлеге күтәрелешне, милли үсешне XX йөз башында мәйданга чыккан әзерлекле яшьләр, милләт язмышын үз язмышы итеп кабул иткән кешеләр әйдәп барганлыгы бүген инде шик уятмый. Г.Исхакый, Ф. Әмирхан, Г.Тукай, Г.Ибраһимов һ.б. белән янәшә бу процесста Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхимнәр дә бар. Шәхсән мин аны шушы буынның, фикердәшләрнең берсе буларак күзаллыйм. Документлар да шул хакта сөйли.



Г.Гобәйдуллин 1887 елның 15 июнендә Казанда танылу алган гаиләдә дөньяга килә. Бабасы Сабит Гобәйдуллин (1821-1870) — 2нче гильдия Казан сәүдәгәре, шәһәребездә үз мануфактурасын оештыра. Әтисе Салих (1862-1935) — Ш.Мәрҗани шәкерте, 1нче гильдия Казан сәүдәгәре. Ф.Әмирхан аны үз драмаларында «аталар» лагерена кертеп сәхнәгә менгерсә дә («Яшьләр», «Тигезсезләр»), өлкән Гобәйдуллинның балалары оештырган әдәби-музыкаль кичәләргә дә, асылда җитәкчесе Ф. Әмирхан булган «Әл-ислах» газетасын чыгаруга да, башка чараларга да һәрчак матди ярдәм күрсәтүе билгеле. Ш.Мәрҗанинең 100 еллык юбилеена багышланган җыентык та аның катнашы белән нәшер ителә. Әти кеше дини гаиләдә, дин нигезләрен мәдрәсәдә үзләштереп үскән балаларына яхшы сыйфатлы дөньяви белем бирүне дә кайгырта. Г.Гобәйдуллинның Казан университетына кергәндә имтихан эше итеп язган «Автобиография»сендә *(Эхо веков. 1997. № 1/2. С.121 — 122)* бу моментлар ачык чагылыш таба һәм әлеге буын зыялыларның әзерлек баскычларын күз алдына китерә.

Балачак тәрбиясен Г.Гобәйдуллин «фанатик татар ясап чыгару» дип бәяли. 7 яшьтән «Халидия» мәдрәсәсенә бирүләре, монда 8 ел укуы (мәдрәсәне 1904 елны тәмамлый), биредә Коръән текстларына нигезләнеп гарәп телен өйрәнүе, төрле дәреслекләрдән грамматика һәм синтаксис, логика һ.б. үзләштерүе аның тарафыннан

шулай кабул ителә. Гарәпчә китаплар арасында «юнан философларынын тәрҗемәләре бар иде, Платон һәм Аристотельгә аерым игътибар бирелде», мәдрәсәдә бәхәсләр даими оештырылып, «еш кына Алланын, фәрештәләр һәм шайтанның булу-булмавы хакында бәхәсләшә идек» дигән сүзләр исә дөньявилыкка тартылуны китереп чыгарган факторлар кебек тәкъдим ителә.

Шәхес буларак формалашуында Газиз өстәмә укунын әһәмиятен билгели. Мәдрәсәдә укудан тыш, әтисенең «бер татарга фарсы телен өйрәнергә бирүен», үзенең фарсы әдәбияты, бигрәк тә Сәгъди һәм Фирдәүси иҗаты белән кызыксынып китүен, бишенче ел укыганда төрек китаплары белән танышуын, шушы телнең Европа әдәбиятына тәрәзә ачуын күрсәтә. Жюль Верн һәм Фламмарион, Вольтер һәм Руссо китапларын төрек тәрҗемәләрендә уку аша егет Европа әдәбиятына якыная, аңарда рус теле һәм әдәбиятын өйрәнү теләге уяна. Башта әтисе яллаган укытучыдан рус телен өйрәнгән Г.Гобәйдуллин, сигез сыйныфлы гимназия курсын тәмамлап, аттестат ала.

Барлык имтиханнарын «бик яхшы» билгеләренә тапшыргач, 1909 елны Казан университетының юридик факультетына кабул ителеп, бер елдан үз теләге белән тарих-филология факультетына күчкән Г.Гобәйдуллинның зур гыйльми мирас калдырачак олы галим булып житешүе — гомумбилгеле факт. Безнең өчен яшь кешенең һәм Шәрык, һәм Европа мәдәниятен белерлек гыйлем алуы, дин нигезләрен һәм дөньяви әдәбиятны, фән нигезләрен үзләштерү ярдәмендә киң карашлы, үз фикерле шәхес булып каләмгә тотынуын ачыклау мөһим. Аның белән иңгә-ин торып татар мәдәниятенә хезмәт иткән күп кенә фикердәшләре шулай ук Европа телләрен (аеруча алман) өйрәнәләр, үзләре дә татарчага тәрҗемәләр эшлиләр. Бу турыда филология фәнендә күп мәгълүматлар табарга була *(Кара: Нигматуллин Э.Г. Татарская литература начала XX века в ее отношении к западноевропейской литературе и эстетической мысли: Дисс. ... канд.филол.наук. Казань, 1972; Гилазев З.З. Татарская литература начала XX века в книжных изданиях. Казань, 2005 һ.б.).*

Студент вакытында ук Г.Гобәйдуллин үзен актив тормыш позициясе булган кеше итеп таныта. Гомумән, аның кызу канлы, житез булуы мәгълүм: бу хакта гаиләдә аңа бирелгән «Тыр-тыр Вафа» дигән кушамат та сөйләп тора. Ул татар яшьләре белән бергәләп күп кенә яңалыкларга юл яра: шәкертләрнең «әл-Ислах» хәрәкәтендә, «Шимбә» театр түгәрәгендә оештыручыларның берсе булып катнаша. Университетның соңгы курсларында белем алганда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих фәнен укыта башлый.

Әле шәкерт чагында ук Газиз каләм сынап карый: беренче өйрәнчек «Чын төш» хикәясе 1907 елның 6 апрелендә «Казан мөхбире» газетасында басылып чыга. Шулай да студент егетнең чынлап әдәбиятка аяк басуы танылган «Аң» журналы һәм аның редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәни шәхесе белән бәйләнгән. XX йөз башы мәдәни тормышында иң күренекле урын тоткан «Гасыр» нәшриятынын хуҗасы, үз заманын күпкә узып киткән «Аң» журналын чыгаручы, язучы, драматург, тәрҗемәче Г.Тукайның, Ф.Әмирханның, Г.Кәрәмнең, Г.Гобәйдуллинның, Г.Рәхимнең, Г.Ибраһимовның дусты, мәсләктәше, фикердәше була. Ә.Хәсәни рус мәдәниятендәге «Весы», «Золотое руно» тибындагы, үз укучысын заман сәнгате белән таныштыруны, шулай гакълый–мәдәни яктан камилләштерүне максат итеп куйган журнал оештыру идеясен күп еллар күңелендә йөртә. 1912 елның 15 декабреннән 1918 елның мартына кадәр айга ике тапкыр басыла килеп, 123 сан тәшкил иткән «Әдәби, фәнни, сәяси вә иҗтимагый рәсемле журнал» татар халкы өчен мөһим идеологик, рухи, мәдәни проблемаларны күтәрә, яңалыкларны мәйданга чыгаручы гына булмыйча, бәлки әдәбиятта тәҗрибәләр ясаучы үзәккә әйләнә. «Аң» исеменә тугры калып, журнал татар кешесенең аңын, дөньяга карашын үзгәртүгә хезмәт итә. Яшь иҗатчылар өчен ул каләм сынау мәйданы ролен үти. Журналның еллык саннарына күз салсак, 1907-1908 еллар аралыгында татар матбугатында ел саен берәр язма белән катнашып килгән Г.Гобәйдуллин 1913 елны — 11 тәнкыйть мәкаләсе, 4 хикәя, 1914 елны — 6 тәнкыйть мәкаләсе, 2 хикәя, 1915 елны — үтәли саннарда 4 фәнни мәкалә, 10 хикәя, 1916 елда 8 хикәя, 1917 елда 3 фәнни мәкалә, 5 хикәя бастырып чыгара *(Әхмәтгәрәй Хәсәни: Фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2011. 349-395 б.).*

«Аң» битләрендә милләтнең иртәгесе, киләчәге турында сөйләшү башлана, иҗтимагый-мәдәни янарышның милли үсеш-үзгәреш ихтыяҗына буйсындырылырга тиешлеге ачыклана. Г.Гобәйдуллин мәдрәсәләрдә логика, тарих кебек фәннәрне укыту, сәяси мәсьәләләр, тарихка кагылышлы язмалар әзерли. Ләкин ул иң күп мәрәҗәгать иткән өлкә — милләт мәсьәләсе. Милләтне үстерүнең теоретик нигезләрен барлауда Г.Гобәйдуллинның роле зур була. 1913 елны ул журнал укучыларын милләт турында сөйләшүгә чакыра. Автор «милләт, миллият» сүзләренең әдәбиятка мөнәсәбәтле кулланыла башлавына игътибар итә *(Газиз Г. Милләтне ничек тәгъриф кылырга? // Аң. 1913. № 8.137-138 б.)*, 1911 еллардан башлап, рухи бердәмлек кебек аңлануын билгели. «Милләтнең асылы тарихи ганганәләргә (традицияләргә), хатирәләргә теркәлгән була, ягъни бер милләттән булган кешеләр бер-берсенең якынлыгын хис итәләр, һәркайсының бабасының бабалары вә нәселләре бер дошманга — дошман, бер дуска — дус; бер җирдә торганга яисә бергә көчеп йөргәнгә халык тарихын җырлар кыяфәтендә күңелдә саклыйлар. Шулай итеп, бер милләткә хазир рухи бер тәгъриф бирәбез: милләт — тарихи ганганәләре бер булып, берлек хис иткән адәмнәрнең җыеныдыр». Һәм шушы берлекне — милләтне — Европа дәрәҗәсенә күтәрү мөмкинлекләре хакында сөйли.

1913-1914 елларда «Аң» журналы «Милләтне ничек аңлыйсыз?» дигән анкета уздыра, шуның җавапларында Г.Газизнең (бу исемне әдәби-фәнни тәхәллүс буларак куллана) милләткә билгеләмәсе тагын да төгәлләшә: «Милләт — тарихи ганганәләре бер булып, үз араларында берлек хис кылынган, бер юл тарткан — бергә хәрәкәт иткән һәм бер даирәдәрәк яшәгән яисә тарихта күп вакыт бергә торган, асыл—телләре бер булган ифрат адәмнәрнең җәмгыятедер» *(Аң. 1913. № 22. 396 б.)*. Милләтнең киләчәгенә ышану «һәрвакытта сәнгать нәфисә кыяфәтендә заһир итәдер» *(Аң. 1914. № 2. 37 б.)* дию белән, автор иртәгәге юлны эзләү эше әдәбиятка йөкләнгәнне дә ачык әйтә.

Г.Газиз язмалары милләт мәсьәләсенең татар әдәбиятында ничек куелышына зур тәэсир ясый. Аннан соң анкетага җавап бирүчеләр, нигездә, шушы ук позицияне яклый. Мәсәлән, Җан Шәрәф тә (Галимҗан Шәрәф) «дәүләтләрнең күтәрелү вә төшүләре күп вакытта миллият хисенең күтәрелү вә төшүеннән килгән» дип белдерә һәм, милләтне «тел якынлыгы», «нәсел якынлыгы», «тарихи кардәшлек» барлыкка китерә дигәндә, Г.Газиз кебек үк, милли рух, «милли вөҗдан» — үзенне милләтнең бер кисәге итеп хис итү, милләтнең гомуми күтәрелү вә төшүен үз шәхси күтәрелү вә төшүеннән артыграк итеп» (Аң. 1914. № 2. 40 б.) хис итүдән гыйбарәт, дип өсти. Шулай итеп, милли хис, миллилек мәгънәсендә «миллият» сүзе урнаша. Матбугат битләрендә «миллиятле милләт дөньядан югалмый» (Кадыйри З. Миллият агымнары // Тормыш. 1914. 12 февр.) дигән караш ныгый. Г.Гобәйдуллин үзе бу мәсьәләгә кабат 1917 елны әйләнеп кайта. Аның «Милләтчелекнең бәгъзе әсаслары», «Миллият өчен көрәшнең бәгъзе фәнни әсасларе» хезмәтләре башта шулай ук «Аң» битләрендә укучыга тәкъдим ителә. Галимнең 1917 елдан соң 20 ел эчендә әзерләнгән төрки-татар тарихы һәм мәдәнияте буенча күпсанлы фундаменталь хезмәтләре шушы нигезгә утыртыла.

«Аң»ны булдыручы иҗади төркем яна татар әдәбиятын тудыру максаты куя. Яна тип әдәбият тормышта гармониягә, бәхеткә ирешү мөмкинлекләрен, яшәүнең мәгънәсен эзләүдән башлана. Бер үк вакытта каләм тибрәтүчеләр гармонияне кешенең күңел төпкелләрендә, аң һәм фикерләү, хис-кичереш, теләк-омтылыш, хыял-күзаллау катламнарында, рухи өлкәдә табарга омтылалар. Шушы төркемдә Г.Гобәйдуллин язучы буларак чыгыш ясый. Шәрык һәм Гареп традицияләренең тоташуы, икесенең ике төрле ассоциацияләр уятуы, укучыны төрлечә шәрехләүгә көйләве бу иҗатны серле һәм мавыктыргыч ясый. Кызганыч, язучының әдәби иҗаты да, гыйльми мирасы кебек үк, аз билгеле. Берничә мисал китерик.

Г.Газизнең 1913 елны басылып чыккан беренче әдәби әсәре — «Бер хыял» *(Г.Сәлман. Бер хыял // Аң. 1913. № 18. 305-306 б.)* фәлсәфи хикәясенең сюжеты традицион татар әдәбияты өчен ят тоела. Хикәяләү «җир йөзендә мәңгелек тынычлык, дуслык падишаһлык» сөргән вакыттан башлана. «Сарыклар бүреләр белән йөриләр, карчыгалар күгәрченнәр белән бер агачка оя ясыйлар иде». Ләкин

көннәрдән бер көнне хәл үзгәрә: «...бер арыслан бер сарыкны ялаганда, сарыкның тәне кызарганын күреп, кабып алды, ике егет һәммә яктан хөр булган бер хатын өчен кычкырыштылар, хәтта үтерештеләр, бер сыер, Алланың бирә торган мәшәкатьсез ризыгы белән генә канәгать итмичә, матур чәчәкле бер матур үләнне кабып чәйнәде, түмгәкләре өстеннән үтеп бара торган кортны кырмыскалар өстерәп ояларына алып кереп үтерделәр...». Шулай, автор әйткәнчә, «олуг канун, солых, рәхәтлек кануны» югала, жимерелә, жир гөнаһка бата, жәһәннәм дәрли башлый. Моның сәбәбе — үлем, үтереш. «Кешеләр тагын, бер-берсен саклар өчен, төрле-төрле өемнәргә бүленделәр, кораллandылар, зәгыйфьләрне кыстылар, төрле мәжбүри кануннар ясадылар...». Без яши торган тормыш — менә шушы гөнаһлы, ирексез, пычрак, тынычсыз дөнья дип, автор әсәрен мондый сүзләр белән тәмамлый: «...Ләкин бу рәхәтне, бу заманны теләү хәзергә кадәр аз адәмнәрнең күнелләрендә сузылган үтның кечкенә генә чаткысы кебек калды... Калды, әмма фәкыйрь хыял булып калды».

Дини тәгълимат буенча, кайчандыр гөнаһ эшләнгән, кешелек дөньясы түбән тәгәрәгән. Ләкин кеше бу түбәнлектән чыгарга тиеш. Яшәештә газап чигү һәм явызлыкның булуы мәжбүри түгел, алардан котылырга була. Моның юлы — инволюция, рухи чисталык һәм илаһи башлангычның материальләшүе. Шушы фикерне житкерү өчен, автор яшәешне ике чиккә бүлә. Беренчесе — кайчандыр булган тормыш: «Дөнья бөтенләй бер бакчалык, бөтенләй бер рәхәтлек йортына әйләнгән иде...» Табигать, кеше — бар да гармониядә: «Хәзер рәхәт, хәзер бер дуслык дөньясы хөкем сөрә иде... Адәмнәр әүвәлге кабахәтлекләрен онытканнар иде инде...» Канун бозылганнан соң, тормыш кан елгалары, суеш-үтерешләр, төрмәләр аша күрсәтелә. Тормышның авырлыгы кешеләргә бирелгән жәза кебек шәрехләнә.

Әсәр жентекләп, детальләп сурәтләүгә корылган. Чиктән тыш арттыру алымы киң кулланыла. Хикәяләүче пәйгамбәрлек сыйфатына ия, ләкин башкаларны үзгәртә алмаячагын аңлаган акыл иясе кебек күзаллана. Аның хыялы — тормышка ашмаячак утопия: азат, тыныч-рәхәт яшәү. Шушы хикәяләүче ярдәмендә язучы яшәешнең мәгънәсезлеге, тормышның караңгылыгы һәм явызлыгы өчен жаваплылыкны кеше жилкәсенә сала, аны «көчленеке замана» кануны белән яшәгән табигатьнең бер вәкиле итеп күрсәтә. Гаепләнне ачыклаган герой бу хәлдән чыгу юлын, яшәештәге төп кыйммәтне дә тапкан: явызлык кылмаска гына кирәк. «Изгелек эшләп яшәү» формуласы чарасызлыктан котылу мөмкинлеге кебек тәкъдим ителә. Изгелек мәңгелек кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрелә.

Татар әдәбияты өчен шулай ук ят, яңа мотив — иманны югалту, Алланы югалту мотивы Г.Газизнең «Юлдаш эзләгәндә» *(Ан. 1916. № 18. 282-283 б.)* хикәясендә (ул фәлсәфи трактат жанрына карый) кызыклы фәлсәфи нәтиҗәләргә алып килә. Әсәрнең герое — «югалган Аллалы» Ильяс — үткәндә Аллага ышаныч белән яшәгән, ун ел элек шул ышанычны жуйган: «Аның өчен олы хәсрәт ул — югалган кыйбла... Ун елдан бирле рәхәт бирми ана югалткан Алласы... Ул югалганнан бирле аның күңелендә сөю, рәхәт, жирдә һәм күктә бәхет югалды...». Яшәү мәгънәсен эзләп китапларга, мәшһүр философларның әсәрләренә мөрәҗәгать иткәннән соң, Ильяс әлеге мәсьәләне һәр кеше «бары үзе генә, һәрбер кеше үзе өчен генә хәл итәчәген» аңлый. Алай гына да түгел, бәхетсезлегендә шул китапларны гаепли: «Рәхәтемне югалттыгыз, күңелемә бер шөбһә ташы ыргыттыгыз, үзегез бернәрсә дә бирмәдегез». Аныңча, китаплар аны «булган юлдаштан» да аерганнар.

Ильяс элеккеге юлдашына болай мөрәҗәгать итә: «Кая син, кая син? Кая киттең син, әүвәл заманнарда йокламаганда йокы биргән, үлемнән курыкканда тынычлык биргән йомшак аһәң?» Икенче мөрәҗәгать «аһәң» төшенчәсен төгәлләштерә: «Кая син, минем мөкатдәс Тәңрем? — диде ул... — Кая син, бабаларымның рухы белән буташып, Чыңгыз рухына манылып, безне катле чигеннән Адриатикка кадәр илткән Тәңре? Кая син, кодсиятнең (изгелекнең) зурлыгының, мәрхәмәтнең мөбһәм (билгесез) бер кисәге булып, безне дошманнар ыргылганда куркытмаган, гайрәт биргән мәгъбуд (табына торган зат)? Кая син, ташлар эченә кереп, безнең рухыбызга дәва биргән мәгъбуд?» Аһәң Алла, табынган, ышанган илаһи көч кебек тәкъдим ителә. Шул рәвешле, хикәя җәмгыятьтәге секуляризация (ижтимагый һәм шәхси тормыштагы барлык сфераларның дин контроленнән котылуы) процессы

алып килгән каршылыклы халәтне тасвирлый. Бу очракта әлеге процесс үткән белән хәзерге арасындагы сызык, чик ролен башкара.

Әсәрдә кеше (вакытлы, фани) һәм яшәеш (мәңгелек, бакый) капма-каршы куела. Күктәге «каз юлы», тартарлар кычкыруы, ярга бәрелгән дулкыннар, шыгырдаган вак ташлар, сандугач сайравы, атылган йолдыз, каен шыбырдавы Ильяска яшәешнең хикмәтен беләләр күк тоела. Кеше — вакытлы гына яшәүче, табигать тавышын аңламаучы җан иясе шушы гүзәллек һәм хәрәкәт уртасында ялгыз, көчсез, бәхетсез, үзенә Алла — рухи кыйбла эзләүче. Андый кыйбла, яшәүнең мәгънәсе юк дигән нәтиҗә әсәрне буеннан-буена сызып үтә. Аллага ышанычын җуйган, хәрабә хәлендәге кеше — газаплanучы, хәсрәтле, кайгылы. Әсәр идеясе Ф.Ницшенең нигилизмны аңлатуына, бу чор мәдәниятендә мәгълүм фикеренә: Аллага ышанычны җуйганнан соң гына азатлыкка ирешергә мөмкин дигән концепциягә каршы чыга. Татар дөньясына заман алып килгән проблемаларны ачыктан-ачык, тирәннән ачып бирә.

Г.Газизнең 1914 елны «Аң»да басылган «Әкиятләрдән берсе» *(Аң. 1914. № 21. 375-377 б.)* хикәясе шәрык әкияте, риваять кебек яңгырый. Ялгыз дәрвиш, рәссам Габдулла чүл уртасында гыйбадәт кылып, Коръән укып һәм тамагын туйдырыр өчен китап күчереп көн итә. Бер көнне таң алдыннан кыз сурәтен күреп ала: «Бөтен матурлык шул сурәтнең эченә кергән дә беткән, бөтен изгелек шуның эчендә камырга сеңгән су кебек сеңгән шикелле иде...» Әле югала, әле пәйда була торган кыз сурәте Габдулланың хыялымы яки саташуымы — билгесез. Ләкин дәрвиш аны матурлык символы итеп күрә: «мин синең матурлыгыңа гына гашыйкмын, нәкъ, әнә, бәгъзан җилнең матур сызгыруы, дөяләрнең муеннарына таккан шөлдерләренең ачык һавалы чүлдә төннәрен дә чылтыраган тавышы кебек кенә яратам», ди. Һәм шушы матурлыкны тирегә төшерә башлый. Сурәт ясала, Габдулланың: «Син илаһимы, шайтанимы» дигән соравына, «бу — матурлыкның синең күңелдәге хакыйкый һәйкәле», дигән җавап килә... Шулай итеп, автор Матурлыкның кеше күңелендә яшәвен раслый, аның идеалы җир кызы — чибәр хатын-кызга мәхәббәтнең иҗатка этәргеч, илһам чыганагы икәнлеге әйтелә.

Журнал битләрендә Г.Гобәйдуллин көлке остасы булып җитешә. Язучының юмористик-сатирик әсәрләрендә дә «икенче план» — фәлсәфи эчтәлек күренеп тора. Әсәрләрнең кыйммәтен билгеләүче сыйфатларның берсе дә шул. Әйтик, «Җомга көн» *(Аң. 1913. № 6. 95-97 б.)* хикәясендә сюжет, әйтик, Галим хаҗиның үлгән хатыны каберенә баруы, аны оҗмахта итеп күзаллавы һәм күрше кабергә күмелгән үлектән көнли башлавы, бер яктан, ирнең хыялыйлыгыннан көлү тәэсире тудыра. Ләкин монда мәхәббәтнең көченә дә ишарә бар.

Г.Газизнең «Алмагачы чәчәк атканда» *(Аң. 1916. № 16/17. 266 б.)* хикәясендә җылы юмор Хәмдебикә карчык һәм Галимҗан картка карата кулланыла. 40 ел бергә гомер иткән картлар үткән тормышларыннан канәгать. Аларның сүзләре дә, хис-кичерешләре дә ике чик арасында тирбәлә: үлемнән курку һәм бәхиллек сорау. Авыр, чарасыз курку хисен ике кеше күңелендәге ярату яктыртып җибәрә. Автор әсәр исеменә үк чыгарган «чәчәк атучы алмагач», «үзенең таза, сулы исен шул җил белән бөтен бакчага чәчкән», «утыручыларның өсләренә югарыдан елмаеп карап, агарып, кызарып, мөлдерәп, бизәнеп-төзәнеп утырган карт алмагачы», әйтерсең, Хәмдебикә белән Галимҗан күңелендә сакланган самими хисне символлаштыра. Яшь вакытларында бергә утырткан агач кебек, беренче мәхәббәтләре үлем чигенә килеп җиткәндә дә «чәчәк ата», үлем куркуын моң белән алыштыра. Бу моң һәр кеше гомеренең чиклелеге, Яшәешнең шушы гаделсезлеге хакында уйлануга этәрә.

Г.Гобәйдуллинның 1913 еллардан башлап әдәби процессны бәяләү эшендә юл күрсәтүчегә әйләнүен дә әйтергә кирәк. Беренче тәнкыйть мәкаләсе — «Ике йөз елдан соң инкыйраз» *(Олуг кешеләр һәм аларның әсәрләре. Казан: Үрнәк, 1911. 3-24 б.)* Г.Исхакый героен татарчылык символы буларак аңлатуы белән («Әмма мин монда Җәгъфәрне күрмим, мин аны бер кеше дип атамыйм...Мин аны бары кристаллга әйләнгән, ташка, матдәгә әйләнгән татарлык, аның вөҗданы, дим...Чөнки андый бер коры вөҗдан, хис белән тулган шәхес нәфселәмердә булу ихтималы юк...») башка язмалардан аерылып тора. «Сәгыйть Рәмиев шигырьләре

турысында» *(Ан. 1913. № 5. 80-82 б.)* мәкаләсендә татар әдәби тәнкыйтендә беренче тапкыр шагыйрь иҗаты гыйсъянчылык ноктасыннан тулы һәм шигырьләргә анализ ясап бәяләнә. «Яшь әдәбиятымызда — «Яшь йөрәкләр» *(Ан. 1913. № 11. 189-194 б.)* — Г.Ибраһимовның шул исемдәге романына иң тирән һәм төпле анализ ясаган хезмәтләрдән булып, романны әдәбиятыбызда аваз салган романтизм юнәлешендә карарга кирәклеген искәртә. Әсәр үзе, аның геройлары, андагы иҗтимагый, фәлсәфи, милли мәсьәләләр алга таба татар әдәбияты тарихында нәкъ менә Г.Гобәйдуллин нигезләгәнчә тикшерелә. Гомумән, Г.Гобәйдуллинның тирән белемле булуы тәнкыйть мәкаләләрендә әсәрләрне шәркый һәм гарби фәлсәфә, әдәбият фонында карарга мөмкинлек бирә. Әйтик, Г.Колахмәтовның шул исемдәге әсәренә рецензия кебек эшләнгән «Ник уйгандым?» мәкаләсендә *(Вакыт. 1911. № 746. 3 б.)* автор ахирәтне (тәмугны) тасвирлауны Дантеның «Илаһи комедия»се, Исмәгыйль Хаккый әсәре, «Мөхәммәдия», «Тәкый гаҗәп»ләр белән чагыштыра.

Әлбәттә, Газиз Гобәйдуллинның фәнни һәм әдәби мирасы хакында күп сөйләргә мөмкин. Аның 120 фәнни хезмәте, 40 тан артык әдәби әсәре булуы мәгълүм. Бу исемлектә татар милләтенең мәдәни тарихын беренче тапкыр Орхон-Енисей ташъязмаларыннан алып тикшерә башлаган, Гали Рәхим белән берлектә язылган фундаменталь «Татар әдәбияты тарихы. 1нче җилд: Борынгы дәвер» (1922, 240 б.), «Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. XVII, XVIII һәм XIX гасырларда иске әдәбият. 1нче җилд» (1922, 184 б.), «Татар әдәбияты тарихы: Борынгы дәвер. 2 бүл. 1нче җилд» (1922, 240 б.), «Татар әдәбияты тарихы: Феодализм дәвере» (1925, 31 б.), төрки-татар тарихына караган «Татар тарихы» (1925, 290 б.), «Борынгы богарлар» (1924, 27 б.), «Татарларның килеп чыгышы һәм Алтын Урда» (1924, 15 б.), Урта Азиядә һәм Азәрбайҗанда, башка төбәкләрдә төрки халыкларның тарихы һәм мәдәниятенә караган күпсанлы хезмәтләре бар. Шунысына аерым игътибар итәргә кирәк: бу хезмәтләр бүгенге фән өчен әһәмиятен җуймаган, алар кабат милли гыйльми хәзинәгә кайтаруны көтеп яталар.

Г.Гобәйдуллинның тормышы фаҗигале, шәхес культы тәмугында өзелүе аның мирасы язмышына да тискәре йогынты ясый. Галим тапкан, тикшергән, анализлаган материаллар совет чорында, чыганагы күрсәтелмичә, башкалар тарафыннан кин файдаланыла. Аның хезмәтләрен һәм әсәрләрен кайтару омтылышлары бары тик 1958 елда һәм 1990 еллардан соң гына ясала. Бүгенге көнгә кадәр Гобәйдуллин хезмәтләре XX йөз башы фикер ияләре арасында да иң аз фәнни әйләнешкә кертелгәннәр исәбендә кала килә.

Шушы көннәрдә татар һәм төрки халыкларның горурлыгы булган Газиз Гобәйдуллин тууга 125 ел тула. Юбилей уңае белән аның хезмәтләрен барлау да милли-мәдәни мирасыбызны кайтару өчен махсус дәүләт программасы булдыру кирәклеген кабат исебезгә төшерә. Әгәр без бу эшне XXI гасырның беренче яртысында башкара алмасак, бу шәхеснең тууына 150, 200 ел тулган вакытларга инде аның хакында истәлекләр калырмы — бу сорауга җавап ачык түгел.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*Татарстан фәннәр академиясенең*
*баш гыйльми сәркатибе, академик*

## Чыңгыз үләне

Сез тагын дөньяны яулаган Чыңгызхан хакында яза дип уйлый күрмәгез. Бусы — Әгерҗе Чыңгызы...

Авыл шагыйренең сәерлегенә шаккатмалы! Алар үзләренчә шулай яшәргә, көн итәргә күнеккән. Күпне күрәләр, күпне беләләр Чыңгызхан токымнары. Җәйнең кыл уртасында, көн белән төн минуты-секундына кадәр тигезләнгән бер мәлдә Әгерҗе Чыңгызы урман-кырларга, әрәмәле болыннарга юнәлә — тайганың шифалы хәзинәсен җыярга, иҗатына илһам алырга.

Аңлашылсын өчен, бер мисал китерәм. Сугыш елларында, авыр тормышта ачлы-туклы яшәгән кечкенә Чыңгыз үпкә чире йоктыра. Егет булып җиткәч тә шуның белән интегә. Бигрәк тә буылып-буылып ютәлләгәндә кызлардан ояла. Күрше авылдагы бер удмурт карчыгы аңа үлән белән дәваланырга киңәш итә. Үләннең исемен дә атый, халык телендә «Эт тигәнәге» (урысчасы «Репушка») дип атала икән. Аның да нәкъ менә Иж, Чаж, Көрекмәс буйларында үскәне файдалы ди. Чыңгыз шулай эшли дә. Үзләренең Мырдыбый авылы аша агып яткан Чаж елгасының югарыгы өлешеннән җыеп кайта эт тигәнәген. Шуның төнәтмәсен эчеп дәвалана. Бер ай дигәндә, син күр дә мин күр, чир юкка чыга. Моңарчы исәптә торган хастаханәгә баргач, табиблар шакката. Мондый хәл булырга мөмкинме?! Тагын нинди әмәлләр кулландың, дип тинтерәтәләр элеккеге чирләшкәне. Халык ярдәм сорап Чыңгыз янына килә башлый. «Эт тигәнәге» дигәне бөтенләй онытыла, аны «Чыңгыз үләне» дип йөртә башлыйлар. Менә шундый хәлләр, малай!..

Сүзем бит тайга шагыйре Чыңгыз Мусинның иҗаты турында. Ул, әйткәнемчә, 1934 елда Тирсәдә туса да, Мырдыбый (урысчасы Мордва — Мордва халкына һич катнашы юк) авылында яши. Зур сала Тирсәне онытмый. Машина-трактор станциясендә (МТС) башта шофер, автослесарь, токарь булып эшли, аннары автомеханик, инженер дәрәҗәсенә күтәрелә.

Уңган кеше — гел уңган инде! Ч.Мусин Чаж елгасының иң матур җирендә, яшел болынлык читендәге куе өянкеләр арасында ике катлы гүрнәчә җиткерә, алма бакчасының бер почмагында, Чаж суы гына җитмәгәнме, унбишкә — биш метр зурлыгында тирән итеп күл казыта, анда балык үрчетә. Абзар тулы терлек-туар асрый. Чын шагыйрь буласыгыз килсә, сулы, урман-болынлы салага китегез сез, егетләр! Илһамны да, бәхетне дә шунда табарсыз!..

Инде иҗатка да җиттек. Хәзер балыкка йөрисе юк, шагыйрь көндез алган тәэсирләрен төнлә яки иртән иртүк торып, кәгазь битләренә төшерә. Авыл тормышын белеп, халык мәнфәгатьләрен кайгыртып яши, аларның уй-фикерләрен шигъри калыпка салып бирә белә. Үткен телле, усал телле, сатира-юморга бай телле әдип ул Чыңгыз Мусин. Автор сатирасыннан башка «Чаян» журналын күз алдына китереп тә булмый. Аның Татарстан китап нәшриятында бер-бер артлы «Язмышым үзәннәрендә», «Тамырлар», «Кадер кичендә» дигән китаплары басылып чыкты. Шигырьләре тирән мәгънәле, поэтик яктан җитешле, халык тарафыннан яратып укыла.

Татарстан Язучылар берлеге безне, идарәбез рәисе урынбасары Вакыйф Нуриевны, эзтабар язучы Шаһинур Мостафинны һәм без фәкыйрегезне Чыңгыз Мусинны 75 яшьлек юбилее белән котларга җибәрде. Ни аяныч, Әгерҗе белән нык бәйләнештә булган тәнкыйтьче-язучыбыз, профессор Фоат Галимуллин, бригадабыз башында торса да, безнең белән бара алмады, дәүләт эше буенча җибәрелгән командировкасыннан кайтып өлгермәде. Аның каравы, район хакимияте башлыгы,

минем хажидашым — Фәрит Габбасов көндез дә, кичен дә гел безнең белән булды. Алай гынамы, шагыйрь Чыңгыз Мусинның шигырьләрен яттан укыды. Аларның иң яхшыларын, күңеленә хуш килгәннәрен, блокнотына күчереп алган икән, шуларны бәян кылды.

Димәк, шагыйрьнең гомере заяга узмаган! Ә Чыңгыз тәнәтмәләре белән сыйланасыгыз килсә, Мырдыбыйга барыгыз! Без анда бер кат хушландык инде. Кәттә генә килеп чыкты...

## Нәкышче Нәккаш

Биргән икән Аллаһ талантны! Әлеге шәхес рухи бәхеткә күмелеп бүген безнең арабызда яши. Һәр бөртегенә тиклем ялтырап торган тубал чәчле, сиңа нинди игелек кылыйм дип гел нур бөркегән күзләре аны тагын да сөйкемлерәк итә, үзенә якынрак тарта. Бу безнең мөхтәрәм галимебез, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе нәкышче Нәҗип Исмәгыйлев-Нәккаш...

Танышасызмы? Мамадыш районының Усали (әүвәлге исеме Өчиле) авылында туып-үсә ул. Борынгы, тарихи сала. Нәҗип урта мәктәпне тәмамлагач, уку алдынгысы буларак, үз мәктәбендә калдырыла, остазлары белән бер сафка басып, җиде ел буе балалар укыта. Тәмам ныгып житкәч, Казан дәүләт университетына барып керә. Әйтерсең, аның киләчәктә кем буласы вәхи белән индерелгән?! Дипломлы егетне Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына эшкә чакырып алалар. Өлкән гыйльми хезмәткәр вазифасын башкара. Борынгы әдәбиятыбыз үрнәкләре белән кызыксына, нигездә гарәп имлялы кульъязмаларны һәм китапларны өйрәнә, аларны бүгенгегә күчерә. Төгәлрәк әйтсәк, мирасыбызның нәфис прозасын текстологик яктан эшкәртеп, китап итеп бастыра. Ул инде шундый дүрт басма нәшер кылды. Бишенче китабы да типографиягә тапшыру өчен әзер. Басмаларның кыйммәте шунда: алар моңа кадәр галимнәребезгә аз мәгълүм булган әсәрләр.

Без Нәҗип Нәккашне бәһаләп бетергесез шәмаилчы дип беләбез. Бу шулай да. Мең еллык тарихлы, әмма соңрак онытылып барган матур язу — коллеграфия сәнгате остасы ул. Шәмаилләр буенча үткәрелгән 25ләп гомуми күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре саны да бер ярым дистәдән артып китә.

Инде шәмаилләренең эчтәлегенә күз салыйк. Аларда Коръән аятьләре, Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисләре. Кол Шәриф мәчетендә төсле пыялаларга язылган биш шәмаиле Аллаһ йортының диварларын бизәп тора. Лениногорск шәһәре һәм Зәй районындагы Шәңгәлче мәчетләре бизәлешен күреп тә күпләр соклана. Тугра жанры элек-электән татарларда шактый киң таралган була. Башлыча югары катлам арасында. Мөселман патшалары указ-фәрманнарына үз туграларын (мөһер, печатьләрен) суга торган булганнар. Татар гаиләләрендә тугра буыннан-буынга күчеп барган. Нәҗип әфәнденең киң күңеллелеге белән бүген татар зыялыларының, язучыларның, рәссамнарның, композиторларның, артистларның һәм башкаларның үз тамгалары эшләнгән. Жөмләдән, без фәкыйрегезне дә сөендерде.

Тукай мәйданына чыгыгыз да карагыз: андагы сәнгать әсәре исәпләнерлек шәһәр сәгатенең саннары сүзләр белән язылган. Уйлап тапкан бит рәссам! Бүген Нәҗип әфәнде «Алмаз-Холдинг» ювелир компаниясе белән хезмәттәшлек итә. Затлы металлдан — алтын-көмештән коелган йөзек, балдак, беләзек, муенса кебек бизәнү әйберләренә милли орнамент, догалык эскизларын эшләп бирә. Универсиадага болар бик нәзакәтле истәлек-бүләк булачак!

Бердәнбер нәкышче Нәккаш булу бик рәхәттер ул!? Булып карыйсы килә!..

**Госман ГОМӘР**

Гарифҗан
Мөхәммәтшин

# БАЛАЧАКТА КАЛАЧАК

## Мотыйгулла хәзрәт

Мотыйгулла хәзрәт авылыбызның иң соңгы указлы имамы иде. Ул озын-озак гомер яшәп, 1967 елның җәендә генә вафат булды.

1911 елда Иж-Буби мәдрәсәсе вакыйгаларыннан соң авылыбызның имамы, үзенең алдынгы карашлары белән танылган Әхмәтгәрәй ахун Зарифов репрессияләнеп, имамлыгыннан мәхрүм ителгәч, чарасыз калган авыл картлары күрше Түнтәр авылы мәдрәсәсенә барып, берәр шәкертне имам итеп җибәрүне сораганнар. Мәдрәсәнең мөдәррисе Ишмөхәммәт хәзрәт үзенең иң яраткан, иң булдыклы шәкертен — Мотыйгулла Зыятдиновны Мөнингәр авылына имам итеп җибәргән. Менә шушы көннән башлап гомеренең ахырына кадәр иң имансыз чорларда да бернинди хилафлык китермичә ул үзенең имамлык вазифаларын башкарган.

Үзебезнең орынып торган күршебездә генә яшәгәнгәме, миңа аны еш күрергә, сабый чагымнан аның тормышының шаһите булырга насыйп итте. Аның гомере үтә имансыз чорга туры килде. Кыйбласыз совет чорындагы власть тарафыннан бик күп рәнҗетүләр, кимсетүләр, кысрыклаулар кичерде ул. Әти белән әнинең шомланып: «Бүген төнлә хәзрәтне тагын алып киткәннәр икән, кайтыр микән инде?» дип аһ-зарлап йөргәннәрен әле дә булса хәтерлим. Әмма ул бервакытта да зарланмады, төшенкелеккә бирелмәде, аның йөзеннән бервакытта да серле, ягымлы, үзенә тарта, җанга җылы бирә торган елмаю китмәде.Ул очраган һәркемнең сәламен җылы итеп кабул итә, хәл-әхвәлен белә, олымы-кечеме, һәркем белән сөйләшергә ягымлы сүз таба. Аның мәһабәт гәүдәсенә, ыспай сакал-мыеклы йөзенә ап-ак чалмасы, шактый таушалган, әмма төсен җуймаган яшел чапаны, ялтыравыклы читеге, кулындагы бик тә оста итеп кырып эшләнгән нәфис таягы үтә дә килешеп тора.

«Алып киткән» жиреннән кайткан көнне үк ул әнә шулай киенеп, җәмәгатькә күренеп урамнан уза, үзенең исәнлеген, бирешмәгәнлеген белдерә. Күрәсең, бу аның әнә шул гаделсезлекләргә каршы протесты да булгандыр.

Хәзрәтнең җиргә яртылаш казып эшләнгән кечкенә генә өендә булганда андагы чисталыкка, пөхтәлеккә таң кала идем мин. Өйнең әнә шул җиргә баткан өлеше сары такта белән төрелгән, өсте шүрлек рәвешендә эшләнгән. Мине әнә шул шүрлек өстенә тезелгән бихисап күп китаплар, чип-чиста агач савытларда үсеп утыручы әллә нинди челтәрле-чуар яфраклы гөлләр җәлеп итә иде. Ул гөлләр мина хыял ирешмәс ерак шәрык илләрен хәтерләтә, күнелемдә бер кечкенә кошчыкка әверелеп әнә шул җылы, чәчәк-гөлләргә күмелгән хыялый илләргә очу теләге уяна. Әлеге китапларда без белмәгән, без анламаган тирән-тирән серләр бардыр кебек тоела, йотылып шуларны укыйсы, бу ач-ялангач хәсрәтле дөньядан аерылып, әнә шул китаплар, алардагы могҗизалар-серләр дөньясына чумасы килә. Чибәр Кәримә абыстай чәчәкле күлмәгенең тирән кесәсеннән алып биргән тәмле конфет яки прәннек әлеге кичерешләрне чынбарлыкка якынайтып, тәмләндереп җибәрә. Әй сабый чакның беркатлы онытылмас кичерешләре...

Борынгы китапларны жыю, аларны тәртипләп төпләү, кече яшьтән үк аларны укырга өйрәнү дә әнә шул кичерешләремнең нәтиҗәсе булгандыр, күрәсең. Ул китаплар арасында Мотыйгулла хәзрәт китапханәсеннән кергәннәре дә бар. Мин бүген дә еш мөрәҗәгать итәм әле аларга.

Күршедә булып, еш очрашкангадыр, хәзрәт мине үтә дә үз итә, якын күрә. Гомумән, ул бик тә бала җанлы иде. Үсеп житеп, инде студент булгач та сирәк кенә әти-әниләр янына кайткалаганда мин башта әти-әниләрем белән күрешәм дә, аларга керәм, аларның хәлен беләм. Киткәндә дә башта хәзрәт белән хушлашып чыгам, аннан соң әти-әнием белән саубуллашып юлга кузгалам. Инде картайган, йөзендәге мөлаем елмаюына тирән фәлсәфи уйчанлык өстәлгән хәзрәт мона бик тә сөенә, минем хәл-әхвәлем, яшәешем белән кызыксына, ничек-нәрсә укуымны белешә, үзенең хәер-фатихасын бирә:

— Әйбәт укы, гомеренне бушка уздырма. Күбрәк белергә тырыш. Шулай итсәң, тормышында ак белән караны, яхшы белән яманны җиңел аерырсың — бу дөньяда югалмас өчен әнә шул кирәк, балам.

Миңа да күпләр шикелле үк гомеремдә күп авырлыклар-кыенлыклар, аянычлы югалтулар кичерергә, авыр хәлләрдә калырга туры килде. Иң авыр чакларда минем күз алдымда җылы елмаеп ак чалмалы, яшел чапанлы, изге җанлы, нык иманлы Мотыйгулла хәзрәт пәйда була һәм күземә карап: «Яхшы белән яманны аерырга өйрәндеңме инде?» дип сорый, авыр хәлдән чыгу юлын күрсәтә иде.

Хәзер дә шулай.

## Каеннар җыры

Ул көнне әти мине йокыдан бик иртә уятты. «Әйдә, улым, икәү бергә каеннарның яфрак ярганын тыңлап кайтыйк әле!» — диде ул.

Иртәнге татлы йокыдан айнып бетмәгән килеш мин башта игътибар итмәгән, «Каеннарның яфрак ярганын тыңлап кайтыйк әле» дигән сүзләр бераздан миңа бик тә сәер тоелды — ничек инде каеннарның яфрак ярганын тыңларга мөмкин? Әмма әтине сорау биреп йөдәтмәдем. Ул колхозда агротехник булып эшли, көннәре тулысынча басуда уза. Җир эшкәртү, чәчү, уру — барысы өчен дә ул җаваплы. Илнең кыр ышыклау урман полосалары утыртып җенләнгән чоры бу. Анысы өчен дә әти җаваплы. Ул еш кына мине дә үзе белән ала, мине агачлар, үсемлекләр белән таныштыра. Әти хәтта кечкенә бөҗәкләрнең дә гамен белә, аларның файдалары, зарарлары турында кызыклы итеп сөйли. Авыл тирәсендәге чишмә-инешләр турында ул әллә нинди риваятьләр белә, туктап су эчкәндә яки әлсерәгән битләребезне юганда әнә шуларны сөйли. Без аның белән табигатьтәге могҗизаларны күзәтәбез. Болар барысы да миңа кызык, мавыктыргыч — мин аларны йотлыгып-онытылып тыңлыйм, күзәтәм, күңелемә сала барам. Беренче мәртәбә әти белән арыш серкәләнгәнен, ажаган уйнаганын карап торганыбыз хәтеремдә. Басу буйлап ап-ак булып, болыт кебек бөтерелә-бөтерелә арыш серкәсе йөзгәнен мәңге онытасым юк. Гомеремдә мин аны соңыннан күп мәртәбәләр күзәттем. Илаһи күренеш! Күргән саен табигатьнең нинди дер интим, үтә дә серле мизгеленә юлыкканыңны аңлап сөенәсең, хисләнеп, комачауламыйм дип тын каласың. Ә энгер-меңгердә ажаган уйнавын күзәтү шомлану-тетрәнү хисләре уята миндә, гомернең фанилыгын искәртә.

Сорау биреп йөдәтмәдем, вакыты житкәч әти үзе аңлатыр әле, дидем.

Кашкарны җигеп дрожкага менеп кунакладык та, юлга кузгалдык. Әни миңа дип кечкенә шешәгә тутырылган сыек сөт, юка ипи телеме төрелгән төенчекне биреп, безне озатып калды.

Әти белән дрожкада утырып бару үзе бер рәхәтлек. Ул тәмәкесен кабыза, әкрен генә шуны суырып уйланып бара, ара-тирә ягымлы карашы белән миңа

карап ала. Басу юлына чыккач, Кашкар юрта башлый. Юл тигезсезлекләрендә дружка әкрен генә деркелдәп бара. Әти, уйчан карашын җиргә текәп, йомшак кына тавыш белән моңлы бер көйгә җырлап җибәрә:

Агыйделне тирән диләр,
Кемнәр үлчәгән икән,
Сагыш дигән дәрья суын
Кемнәр эчмәгән икән.

Арба дерелдәве әтинең җырына әллә нинди бер кабатланмас үзгә моң, серлелек бирә. Нәрсә турында уйлый, нигә шулай моңлана икән ул? Еллар үткәч кенә белдем — тугыз яшендә өч сеңлесе белән тома ятим калган бит ул! Үскән, җирдә үз урынын тапкан, яшәгән, яши. Сеңелләрен дә аякка бастырган. Сагыш дигән дәрья суын мул эчәргә туры килгән шул аңа. Әнә шулар моң булып үрелгәндер аның күңеленә.

Мин әнә шул моңнарны күңелемә сеңдереп, тирә-якны күзәтеп барам. И матур да инде безнең авылның табигате. Артышлы урләре, тыйнак чишмәләре, чуар урманнары, басынкы инешләре... Кай ягына карама — хозурлык. Күккә эленеп калган тургайларның кинәнеп сайравын күр син!

Басу түрендәге Ерак каенлыкка килеп җитәбез. Әти Кашкарны тугарып, дилбегәсе белән дружкага бәйләп, утларга җибәрә. Әй сөенә малкай мондый вакытта, ни генә кыйланмый. Аның кыйланышларын күреп мин көлеп җибәрәм, ул яңгыравыклы кешнәве белән минем көлүемә кушыла. Мондый чакта ул минем белән бергәләп көлгән кебек тоела.

Урманның бу ягында яшь каеннар үсә. Алар куе да түгел, араларында инде тыйнак урман чәчәкләре күренә. Сирәк була торган җылы, парлы май иртәсе. Язгы назлы кояшның җылысы күлмәк аша да үтеп тәнгә рәхәтлек бирә. Без әти белән каеннар арасына узабыз.

— Тыңла, улым, — ди әти — каеннар менә шушындый назлы көнне җырлый-җырлый, ярыша-ярыша яфрак яралар. Аларның бүген иң бәхетле көне...

Мин әтидән аерылып эчкәрәк узам, туктап калам. Тып-тын каенлык эченә күктән ниндидер зыңлау тавышы иңә. Аңа дистәләгән кошларның ярышып сайравы өстәлә. Шуларга серле черкелдәү, пышылдау, йомшак кына үзара сөйләшкән кебек авазлар кушыла. Чатнап ачылган бөре кабырчыклары кыштырдап җиргә коела. Болар бөтенесе бергәләп тантаналы бер моңга, музыкага әверелә. Бераздан мин аларда таныш аһәңнәр, таныш ритмнар тоеп алам, сихерле моң дөньясына чумам, онытылам. Каеннар җырлый... Урманда тантана... Яшьлек, яшәү, яшәрү тантанасы! Никадәрле ярсу, ашкыну, өмет, шатлык бар бу аһәңнәрдә! Каеннарның бүген иң бәхетле көне! Иң бәхетле көне!

Әти басып калган якка борылам — аның йөзендә шатлыклы елмаю. Сизгән ул минем каеннар җырын аңлаганымны, ул канәгать.

Соңыннан басуларны әйләнгәндә дә, яшел чирәмгә утырып әни җибәргән сөт белән ипине ашаганда да, кайтыр юлга кузгалгач та минем колак төбемдә каеннарның тантаналы җыры тынмады. Мин хәтта, җинелчә генә сызгырып аларны кабатларга да тырышып карадым.

— Әти, тагын барырбыз әле каеннарның яфрак ярганын тыңларга, — дидем мин әтигә борылып.

— Юк инде, улым, андый могҗиза бер генә көн була, гел кабатланмый. Менә быелгы кебек матур яз килсә, киләсе елга барырбыз. Насыйп булса, — диде ул.

Әмма алдагы елда безгә каеннарны тыңларга насыйп булмады. Борчулы-газаплы ел булды ул безнең өчен. Шулай да, үсеп житкәч берничә мәртәбә

тыңлау бәхетенә ирештем мин каеннарның яфрак яруын. Ул минутларның бәхетен уртаклашырга әти генә юк иде янымда.

Күп еллардан соң, композитор Рөстәм ага Яхин белән бергәләп язган «Керим әле урманнарга» җырының көен фортепьянода уйнаганда тоемладым мин каеннарның серле, тантаналы моңын. Бәлки, ул да балачагында каеннарның яфрак ярганын тыңлаган булгандыр. Кем белә...

## Патефон

1952 елда булса кирәк, авылыбызга бөтенләй уйламаган, көтелмәгән кунаклар килеп төште. Нефть эзләүчеләр килгән, безнең авыл тирәсеннән нефть эзләячәкләр! Шушы вакыйга авылыбызның гадәти салмак бер көйгә ага торган тормышын әллә ничек җанландырып, кымырҗытып җибәрде. Олыларның да, яшьләрнең дә авызында моңарчы колак ишетмәгән сәер бер сүз — нефть. Авылның фантазиягә бай тел осталары кичләрен җыелышкан вакытларда әллә нинди әкиятләр сөйлиләр. Имештер, безнең авыл астында зур диңгез кадәрле нефть ятмалары бар, тиздән аны суырып чыгара башлаячаклар, безнең авыл зур шәһәргә әвереләчәк; имеш, инде Шәмәрдәннән безнең авылга таба тимер юл төзи башлаганнар... Бу җәһәттән әлеге дә баягы Навил барысын да уздыра — килсә килә бит форсат кешегә!

Безнең әле сабый чак. Ач-ялангач авыл малайлары шул әкиятләрне тыңлап, шуларны үзебезнең сабый күңелебездән кичереп, хыялланып йөрибез.

Нефть эзләүчеләрнең берничәсе безнең күршедәге Фатих абзыйларда урнашты. Шуларның берсе Хәмит абыйның бик тә усал гадәте бар иде — колакны борырга ярата. Үзе болай әйбәт кенә кеше, безнең белән әүмәкләшүдән дә читләшми. Әле баш кадәрле туп алып чыгып безнең белән футбол уйный, әле беребезнең биленә кызыл, икенчебезнекенә — зәңгәр чүпрәк бәйләп көрәш оештырып җибәрә. Үзе кечкенә генә сыбызгысын сызгыртып көрәшне иң кызык җирендә туктата да, безгә киңәшләр бирергә тотына. Әле безне түгәрәкләп тирә-ягына утырта да, әллә нинди без ишетмәгән нәрсәләр турында сөйли башлый — аның белмәгәне юк. Нефтьнең кара булса да алтын икәнен, аннан әллә ниләр ясап булганын, нефтьтән башка кешелекнең киләчәге юклыгын да без Хәмит абыйдан ишетеп белдек.Тик шунысы бар — эләктерсә, колакны каты бора инде, күздән яшьләрне чыгара. Безне ул «кирәкле кишер яфраклары» дип атый. Сәер кеше. Үзе яшь, борын астындагы куе кара мыегы булмаса, әле яңа егет булып килүче бер үсмер дияр идең. Күрәсең, ул нефть яки геология институты студенты булгандыр, монда практика үткәндер. Соңрак без аның кичке уеннардан соң укытучы Былбыл апаны озата кайтуларын, аның белән мәктәп бакчасында озаклап сөйләшеп утыруларын да белдек.

Тиздән әлеге серле абыйлар безнең тыкрык башында, инеш буенда, Мещан урманы кырыендагы каланчадан да биек вышка төзеп, җирне бораулый башладылар. Безнең өчен хикмәт тулы көннәр башланды — мөмкин кадәр якынрак килергә тырышып шул тирәдә кайнашабыз. Әлеге дә баягы шул Хәмит абыйның усал кулы булмаса...

Беркөнне кич белән Фатих абзыйлар каршындагы чирәмлеккә җыйналган малайлар янына чыккач: «Бер могҗиза күрсәтимме үзегезгә?» диде Хәмит абый. Без сагаеп калдык — колак борудан тыш тагын нинди могҗизасы бар икән инде моның?

Ул өйдән бер зәңгәр тартма күтәреп чыкты. Шуны капка төбендәге өч аяклы эскәмиягә куеп ачты, нәрсәсендер борды-борды да, урталагы тәлинкәсе өстенә нинди дер йодрык кадәрле ялтыравыклы әйберне

әйләндереп салды. Әллә нинди кыштырдау тавышлары ишетелде һәм шул тартманың кай җиреннәндер җыр янгырый башлады. Безнең күзләребез мангайга менде — менә бу могҗиза ичмасам!

Хәмит абый безгә әлеге тартманың патефон икәнлеген, аның тәлинкәсенә иң бөек җырчыларның җырлары язылганлыгын, әлеге матур җырны Гөлсем Сөләйманова исемле җырчы башкаруын аңлатты.

— Менә шулай, кирәкле кишер яфраклары! — дип йомгаклады ул сүзен.

Кичке уеннарда авыл егетләренең һәм кызларының җырлап-биеп уйнауларын гына күреп-ишетеп үскән безләргә шушы тартмадан агылган җырлар кеше ышанмаслык бер серле хәл иде, билгеле.

Менә тартмадан ир-ат җырлаганы ишетелде.

— Ә бусы инде Рәшит Ваһапов исемле җырчы абыегыз булыр, белеп торыгыз, кирәкле кишер яфраклары! — дип таныштырды Хәмит абый.

Җәйге кич. Тып-тын авыл һавасын тибрәндереп җыр янгырый. Аның моңы күңелләрне актарып ташлый. Күз алдыма әллә нинди илаһи күренешләр килә. Каен сиртмәгә эленгән кайры бишектәге кечкенә игезәк энеләремне моңлы җыр көйләп тирбәтүче әнием, басу юлларыннан юртып баручы атка җигелгән арба деңгердәвенә кушылып тын гына җыр көйләп баручы әти ... Күземә ирексездән яшь тула.

Без җәй буе кичләрен Фатих абзыйлар капка төбенә җыйналабыз. Тиздән анда авылның өлкәннәре дә килергә гадәтләнде. Үзенә күрә бер бәйрәм була иде ул кичләр.

Көзен нефть эзләүчеләр вышкаларын сүтеп алып китеп бардылар. Авыл моңаеп, боегып калды. Шөкер, безнең якларда нефть табылмады. Дистә еллар үткәч тә кабат килеп бораулап эзләп карадылар югыйсә. Нефть чыкмады. Әмма Хәмит абыйлар бораулаган урыннан ургып чишмә чыгып калды. Мул һәм бик тә тәмле, йомшак сулы иде ул. Халык аңа «Нефтьчеләр чишмәсе» дип исем бирде. Якында гына безнең якта үсә торган нинди хуш исле үлән бар — барысы да билдән булып үсә торган болын, шул болын буйлап кыеклап бара торган чишмә сукмагы. Әнигә булышыйм дип яланаяклап, иңемә көянтә-чиләк элеп әнә шул сукмак буйлап мин үзем дә суны күп ташыдым. Ярата идем мин анда суга барырга...

Алтмышынчы еллардан соң әлеге болында сыер, дуңгыз абзарлары төзелде, болын тирескә күмелде. Якында гына силос салу өчен чокырлар, траншеялар казылды. Яратмады әлеге гамәлләрне чишмә — кинәт кенә юкка чыкты. Чуар болын да югалды. Студент чагымда каникулга кайткач әнә шул урында юксынып озак басып торганнарым хәтердә.

Мин гомерем буе халкыбыз җырларын тыныч кына тыңлый алмадым. Аларны тыңлаганда күңел сафлана, хисләр актарыла, хәтер яңара. «Кара урман», «Зөләйха», «Сандугач», «Сакмар», «Уел», «Рәйхан» — бу җырларны ишеткәндә мин әле бүген дә, инде күпме еллар үткәч тә, әнә шул ерак балачактагы моң тулы кичләрне искә төшерәм. Шул тиңсез кичләрне кайтарасым, әнә шул могҗизаны безгә бүләк иткән, туган җирне, туган халкыбызны яратырга, аның фаҗигале тарихын белергә һәм изге итеп сакларга өйрәткән Хәмит абыйны күрәсем, хәтта бер генә мәртәбә булса да аңа колагымны бордырасым килә.

## Әлкич абый

Әлкич абый безнең күршедәге мари авылыннан. Аның чын исеме Алексей. Әмма безнең авыл кешеләре өчен ул Әлкич. Үзе дә шушы исемне үз иткән инде.

Озак еллар безнең авылның терлекләрен көтте Әлкич абый. Үтә йомшак күңелле, ягымлы, итагатьле зат иде ул. Авылыбызның һәммә кешесе — олысы

да, кечесе дә — ярата аны, үз итә. Сарыгыннан алып ябык сыерына кадәр һәр терлекнең гадәтләрен белә, аларда ниндидер үзгәреш булса, авырып-сырхаулап китсә, хуҗаларына бик тәфсилләп аңлата, үзенең кинәшләрен бирә, дәва ысулларын тәкъдим итә. Шул терлекләрнең телен белә диярсең.

Әлкич абый татарча татардан да матур итеп сөйләшә. Ул «ж» белән «ң» авазларын шулкадәр җиренә җиткереп «җиңги» дип эндәшкәндә авыл апалары, күңелләре булып, елмаеп ук җибәрәләр иде. Ихлас менә!

Әлкич абый һәрвакыт шат күңелле, җор була. Әмма тормышы бик тә авыр, михнәтле иде аның. Өе тулы берсеннән-берсе кечкенә бала-чага, аларны туйдырырга, киендерергә кирәк. Өе дә бик кечкенә — җиргә сеңеп беткән бер алачык кына. Әнә шул тормыш авырлыгы, тормыш михнәте аның йөзендә дә бөтен барлыгы белән чагыла, хәтта көлгәндә дә моңсу уйчанлыгы югалмый. Хәер, ул елларда кайсы авыл кешесенең тормышы җиңел булды икән.

Без — тиктормас ыбыр-чыбыр авыл малайлары — еш кына Әлкич абый көтү көткән җиргә барабыз. Әллә кайда, ерак басу түрендә булганда да югалып калмыйбыз. Ул безгә үзенең башыннан үткән бетмәс-төкәнмәс вакыйгаларны сөйли. Әй күпне күргән-кичергән дә инде Әлкич абый, кайларда гына булмаган, кайларда гына йөрмәгән. Кая инде безгә андый хәлләрне күрү!

Безгә аның бигрәк тә сугышта күргәннәрен сөйләве ошый. Ул һәрбер сөйләгәнен оста артистларча хәрәкәтләр белән күрсәтеп бара. Каян килә икән аңа шундый елгырлык? Әлкич абый әле егылып чирәмдә тәгәрәп китә, әле сикереп торып йөгереп ала, әле сузылып ятып, ике аягын ике якка җәеп, сыңар күзен йомып автоматтан «ата» башлый. Ул берәм-берәм безнең күзгә карап сөйли, үзенең күзендә ниндидер хәйләкәрлек чалымнары да чагылып китә — ышандырдыммы сез ачык авызларны, янәсе. Әмма безгә ул олылап «егетләр», «агайне» дип эндәшә. Күзгә карап шулай эндәшкәндә без ничектер үсебрәк тә китәбез әле. Шулай булмыйни, Әлкич абый кадәр Әлкич абый «агайне» дип атасын әле үзеңне!

— Ятабыз шулай, егетләр, окопта җомарланып. Ятып кара син көнетөне әнә шулай. Немецләрнең безнең өскә килергә кузгалганын көтәбез. Тамашаларын кырабыз инде күтәрелсәләр. Тегеләр дә безнең күтәрелгәнне көтә бугай. Кузгалмыйлар, агайне. Түзмәде йөрәк, башны күтәреп үрелеп тегеләр ягына карадым. Әй, мин сиңайтим, егетләр, немецләрнең әллә бөтен автомат-пулеметлары тыкылдап ата башлады (Әлкич абый атып күрсәтә). Чумдым окопка (Әлкич абый чумып күрсәтә). Баш янына гына сайрый-сайрый пулялар килеп кадала...

Без күптән инде сугыш эчендә, авыз ачып, Әлкич абыйга омтылып тыңлыйбыз.

— Әлкич абый, берсе дә тимәдемени? — дип түземсезләнеп сорап куя тиктормас Гадил.

— Тимәде шул, агайне, — ди Әлкич абый. Аннан карлыкканрак тавыш белән өстәп куя:

— Тигән булса бу михнәтләрне күрмәгән булыр идем дә...

Ул авыр сулап сугышта берничә бармагын югалткан кулы белән Гадилнең башыннан сыйпап алды һәм уйчан-моңсу карашын әллә кая, ерак билгесезлеккә төбәп уйга чумды. Соңгы сүзләрен ул безгә түгел, үз-үзенә әйтте бугай

Без дә бу минутта аның авыр уйларын бүлмәдек, кесәсеннән янчыгын алып тәмәке төргәнен, тәмәкесен кабызып, тирән итеп суыра-суыра тарта башлаганын карап тынып калдык.

# САРА АПА ДӘРЕСЛӘРЕ

Яңа 2012 ел башында олуг әдәби журналыбыз «Казан утлары»нда аның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин «Өмет» атлы язмасын бастырып чыгарды. Анда автор журналның киләчәген кайгыртып, хәзерге көндә бик мөһим булган мәсьәләне күрсәткән. Бу - журналның укучылар санын арттыру. Журналның яшәү-яшәмәве дә шуңа бәйләнгән. Мәсьәләне уңай һәм оптималь рәвештә хәл кылу юлы да күрсәтелгән кебек. Минемчә, аны төптәнрәк эзләргә кирәк. Агачның очында түгел, тамырларында булырга тиештер ул. Шул хакта уйлана торгач, Сара апаның миңа биргән дәресләре искә төште.

Сара апа Казандагы 13нче тулы булмаган (җиде сыйныфлы) татар урта мәктәбенең китапханә мөдире иде. Беренче сыйныфта укый башлау вакытым 1944 елга туры килде.

Минем өченче сыйныфта укыган ел. Дәресләр арасындагы тәнәфес барышында Сара апа мине мәктәп коридорында кулымнан эләктереп алды. Аның шулай коридорда йөргәнен, анда аерым бер укучы бала белән сөйләшеп торганын күргәли идем үзе. Коридорда иптәшләрем белән уйнашып-йөгерешеп йөри идек. Апабыз, кулымны җибәрмичә, ягымлы гына миңа карап, сүзен болай дип башлады: «Мансур, энем, син 4-5кә укыйсың икән. Димәк, син ударник саналасың». Салпы якка салам кыстыру булды бугай бу. Узган чирекләр ахырында үземә «өчле» билгесе дә чыккалый иде юкса. Сара апа үзенең «дәресен» дәвам итте: «Мин ударникларны гына язам китапханәгә. Әйдә, энем, минем янга керик әле». Шулай үсендергәч, бер дә каршы килмичә аның артыннан кереп киттем инде. Сара апа миңа укучы формулярын язып тутырды, аны теркәү санын ятларга кушты һәм шунда ук киштәдән китабын да сайлап алып бирде. Ахырдан болай дип тә әйтте әле: «Яшь китап сөюче (мин инде «китап сөючегә» дә әйләндем!) укыган һәрбер китапның исемен һәм авторын аерым бер дәфтәргә теркәп барырга тиеш һәм китапның кыскача эчтәлеген, бер-ике җөмлә белән генә булса да, язып куярга кирәк. Кара аны, мин бу дәфтәреңне тикшерермен». Аның менә бу сүзләре дә истән чыкмаган әле: «Шуны бел, энем, китап уку кешенең акылын тирәнәйтә, дөньяда булган кызыклы тарихларга аның күзен ача, алга,тормышны дөрес аңлау бөеклегенә, алып бара». Хөрмәтле укучым! Югарыда язылганнар Сара апаның миңа биргән беренче дәресе булды.

Шулай итеп, апабызның җиңел кулы белән матур әдәбият дөньясына кереп киттем. Миңа китап «җене» тиде! Мәктәптәге елларда ана телемдә бик күп китап укыдым. Кайвакытта, китаптан аерыла алмыйча, төннәр буе укый торган идем. Рәхмәт әти-әнигә, китапка булган омтылышымны бер дә чикләмәделәр. Әти хәтта акча да бирә иде әле, кибеттән китап сатып алырга дип.

Мәктәп китапханәсенә язылган елны укылган кайбер китапларны күрсәтеп китим әле: «Рөстәм мажаралары» (Гадел Кутуй), «Разведчик язмалары» (Фатих Кәрим), «Маякчы кызы» (Гариф Гобәй), «Ак төннәр» (Габдрахман Әпсәләмов), «Сиваш» (Гомәр Разин, соңрак – Бәширов), «Батырлар китабы» (төрле авторлар язган җыентык). «Батырлар китабы» мине тәмам тетрәндерде. Бу китап 1947 елда зур форматта чыкты, үзе кызыл тышлы, тышлыгына «Алтын йолдыз» медале сурәте төшерелгән. Китап кибетендә күргәч тә бу китапны үзем сатып алдым. Бөек Ватан сугышы кырларында үзләренең аеруча зур батырлыкларын күрсәткән 50дән артык Советлар Союзы Герое, татар халкының каһарман уллары турында язмалар тупланган бу китапта. Белсәгез иде минем никадәр дулкынлануымны укыганда.

Мин, өченче сыйныф баласы, Татарстаннан сугышка алынган абыйларның немецларга каршы көрәштә күрсәткән батырлыкларын шуннан укып белдем. Сыйныфымда беренче булып белдем Александр Матросов батырлыгын кабатлаган Газинур Гафиятуллиныбыз бар икәнен. Мәхмүд Максудның татар очучысы Фәрит Фәткуллин батырлыгы турындагы язмасын, шулай ук Сталинград сугышында иң күп санда немец генералларын әсир итеп алган укчы дивизия командиры, 38 яшьлек полковник Гани Сафиуллин турындагы язманы шаклар катып укыдым.

Рәхмәт Сара апага, аның икенче дәресе дә бар бит әле. Апабыз гел эзләүдә булган безне, башлангыч сыйныф укучыларын, китап дөньясына кертү юлында. Ул безне, үзенең китап сөюче активын, вакыты-вакыты белән дәресләрдән соң татар язучылары белән очрашуларга да алып бара иде. Мондый очрашулар университетның Актлар залында, Тукай клубында, район китапханәләрендә узды. Китап язучы абыйлар зур акыл иясе булып күренәләр иде мина. Матур сурәтләү алымнары белән һәм тирән эчтәлекле итеп язылган китапларны уку ул замандагы мәктәп яшендәге балаларга дөньяга карашларын кинәйтүдә, гомумән, безнең белемнәребезне арттыруда бик тә ярдәм иткән. Очрашуларда күрешкән язучыларның күбесе тере классиклар булган дип уйлыйм хәзерге аңлавым белән. Аларны искә алып, кайберләрен бу язмамда күрсәтим әле: Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов, Афзал Шамов, Мәхмүд Максуд, Гариф Гобәй... Очрашуларда без, мәктәп укучылары, аларга каршы утырган хәлдә башта үзебезнең сорауларыбызны бирергә тартына идек. Очрашуга килгән язучыларыбыз сүзләрен үзләре башлыйлар иде. Батырлык кирә башлагач, без дә сорауларыбызны бирә башладык. Шулай итеп, безнең өчен тормыш юлында маяклар күрсәтеп, олуг язучыларыбыз белән сөйләшү-фикер алышулар башлана иде.

Мин башлангыч мәктәптә укыган еллар күнелемдә онытылмаслык мизгелләр булып сакланып калдылар. Без дә, Сара ападан дәресләр алган аның китап сөюче шәкертләре, Казанның 12нче татар урта мәктәбенә 8нче сыйныфка күчтек...

Озын сүзнең кыскасы, бу язмада китерелгән алымны, ягъни Сара апа дәресләрен, мәктәп коллективларында татар әдәбияты укытучылары белән бергәләп күздән кичерергә кирәк. Аның хикмәтен шәһәр һәм республикабызның мәгърифәт идарәләре житәкчеләренә дә житкерергә иде. Бу тәжрибәне мәктәпләрдә тарату өчен Сара апа кебек оештыру сәләтенә ия китапханә эшчәннәрен ишәйтергә, булганнарының эшен стимуллаштырырга иде. Сара апа киләчәк өчен тырышкан бит – ул игътибарын татар телендә китап укучылар тәрбияләү мәсьәләсенең тамырына юллаган. Шул нияттән чыгып, ул изге эшен 3нче сыйныф укучыларыннан ук башлаган. Дөрес эшләгән апабыз, ни өчен дисәгез, 6-7нче сыйныфларда укучы баланы инде китапка җәлеп итеп булмаячак.

Форсаттан файдаланып әйтәм, «Өмет» атлы мәкаләсе өчен рәхмәт Равил әфәндегә! Мин, гади укучы буларак, хәзерге көндә ул күтәреп чыккан мәсьәләләр турында уйлаучы кеше бар микән дип кайгырып йөри идем. Баш мөхәррир үзе күтәреп чыккач, журналның укучылар саны артачагына ышаныч бар. Бу изге эшегездә Сара апа дәресләрен дә онытмаска иде.

**Мансур ҖӘЛӘЛИЕВ**
*Казан*

# БАРЫБЕР КАЙТТЫҢ СИН...

Бухгалтерия бүлмәсендәге эшлекле тынлыкны сискәндереп, кисәк кенә телефон чылтырады.

— Ие, Салих Сабитович. Ә-ә, ни, Гөлмәрьям юк шул. Алар иртәнге якта ук Мөнир Кадыйрович белән районга киттеләр бит. Нәрсәгә дип, белмим шул. Миңа отчет бирмәделәр. Эш белән киткәннәрдер инде, ие, эш белән.

Кассир Нәзирә, телефон трубкасын урынына куйды да, сораулы күзләре белән бүлмәдәшләренә карады. Башкалар да, эшләрен ташлап, аңа төбәлгәннәр иде. Нәзирә арада өлкәнрәк, житди, ихтирамга лаеклы хатын. Аңардан узып авыз чайкау килешмәс. Гадәтенчә, бу юлы да артык сүз ычкындырмады Нәзирә.

— Нәрсә әйтергә дә аптыраган инде, кызлар. Нужә-әли-и?! — дию белән чикләнде. Һә-әй, авыл жирендә кешедән нәрсәне дә булса яшерермен димә. Жир астыннан йөргән еланны да сизә бит ул авыл кешесе!

Хужалыкның партоешма секретаре иде Мөнир. Авыл халкы өчен һәр сүзе үтемле булды. Югарырак оешмаларга эшләре төшкән кешеләр дә, суд юлын таптарга туры килгәннәр дә аның белән киңәш-табыш итешмичә эшкә тотынмыйлар иде. Гаиләсе дә һәркемгә үрнәк итеп куярлык: укытучы булып эшләүче хатыны Гадилә белән алты бала — өч егет, өч кыз үстерәләр. Олы кызлары инде буй тартып килә. Матур, тату гаилә: ир белән хатынның бер-берсен хөрмәт итеп яшәүләре һәркем сокланырлык иде югыйсә. Кем уйлаган?!... Кем уйлаган һәр сүзен үлчәп сөйләшкән, һәр адымын уйлап атлаган Мөнир дә ялгышыр, бу гаиләгә дә хыянәт салкыны бәреп керер дип?!

Гөлмәрьям авылга яшь килен булып килде. Ире, шофер Кәбир белән, Мөнирләрдән урам аша гына буш торган йортны сатып алып, башка чыгып яши башладылар. Ямь өстенә ямь булып, башта уллары, аннары кызлары туды. Бәхетле иде яшь гаилә, бик бәхетле кебек иде. Хисапчы Гөлмәрьям эштә дә, аннан да бигрәк өй арасында алабыр гына киенеп, жыйнаксыз гына йөрсә дә, бәйрәмнәрдә сәхнә күрке булды: концерт-кичәләр куйсалар, өздереп жырлады, теттереп биеде; спектакльләр оештырсалар, төп рольләрдә уйнады. Башкалар белән беррәттән Кәбир дә хатынына сокланып туя алмады, аның өчен жаны фида иде.

Әмма язмыш дигәнең барысын да үзенчә хәл итте! Кем, ни өчен шулай усал шаярды соң алар белән?! Ни өчен мәхәббәт фәрештәсе Амур үзенең угын инде иллегә якынлашып килүче, алты бала атасы булган ирнең йөрәгенә төбәп атты да, икенче угын әле утызга да житмәгән, ике бала анасы булган хатынның йөрәгенә кадады?!..

Кайчан, кайсы мизгелдә күзләр очрашканын икесе дә бик яхшы хәтерли алар. Яңа ел кичәсе иде ул көнне. Гөлмәрьям сәхнәдә «Гөлшаһидә жыры»н башкарды. Гадәттәгечә, кат-кат чакырып жырлаттылар үзен. Мөнир, беренче кат гашыйк булган үсмер шикелле, бүген аңардан күзен дә ала алмады: карәле, булса да булыр икән бу хәтле дә илаһи гүзәллек, шушы кадәр моң... Исемнәре генә дә ни тора бит! Гөл — мәрья-ям!... Илһам Шакиров

әллә шушы Гөлмәрьям турында жырлады микән ул? Көтү чираты көнне болында күреп, «ах» иткәндер дә... «Болыннарда көтү куды Гөлмәрьям, гөлләр жыйды бер бәйләм, Гөлмәрьям»... Әмма, гафу, Илһам дус, көтүче булыр өчен яралган жан түгел бу! Юк-к, мондый хатын жигелеп авыл тормышы тартырга да тиеш түгел. Югары катлам кешесе булырга тиеш ул! Әгәр дә жаннын куәүе дөрес булса, аксөякләр нәселеннән булган кызның жаны күчкәндер аңа!

Партоешма секретаре аксөяк нәселләрен зурларга тиешле кеше булмаса да, бу минутта Мөнир нәкъ менә шулай уйлады. Үзенә төбәлгән утлы карашны Гөлмәрьям дә сизде... Сизде һәм залга баш игән арада, күзләре белән генә, халык арасыннан шул күзләрнең иясен эзләп тапты. Парторг Мөнир абы-ы-й?!...

Бер генә мизгелгә очрашты лабаса күзләр... Әмма дөньяның астын өскә әйләндерергә шул бер мизгел дә житә икән.

Әгәр дә Мөнир белән Гөлмәрьям шушы кичәдән соң жиңел генә йөреп киткәннәр икән дип уйласагыз, нык ялгышырсыз. Мондый хәлне икесенең берсе дә күз алдына да китерә алмый иде әле. Инде күптән акыл утырткан, сөйләшкәндә жиңел юмор кушып сөйләшергә яратса да, һәр эшкә житди карый иде Мөнир. Ике арадагы кайнар мәхәббәт хисләрен күптән инде бер-беренә ияләнү, жайлашу алыштырса да, аның гомер иткән, менә дигән хатыны бар! Алтын баганалары — балалары бар! Гадиләсе белән бергәләп булдырган житеш йорт-жире, жиңел машиналары бар. Менә дигән эше, авыл кешесе алдында еллар буена бөртекләп тупланган абруе бар! Әгәр дә очраклы рәвештә генә бер күрәзәчегә тап булып, ул күрәзәче: «Берзаман син бар булдырган бу тормышыңны бер яшь хатынның мәхәббәте хакына ташлап китәрсең», — дисә, Мөнир башта эче катып көләр, аннары, кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә, дип, күрәзәчегә тамчы да ышанмавын әйтер иде. Дөрес,үзеннән биш яшькә олы булган Гадиләсенә карата хисләр күптән сүрелгән сүрелүен. «Күңел урыс, маржа сорый» дигәндәй, кайдадыр тирәндә назга, кайнар хисләргә булган сусау яши. Әмма кем гомер буе сөешеп кенә яши соң?! Гомер итә-итә яшәү мәгънәсен икенче кыйммәтләр алыштыра башлый. Моның шулай икәнен чуала башлаган кайбер яшь гаиләләргә дә төшендереп бирүче кеше бит әле ул Мөнир. Тик менә, Гөлмәрьям атлы яшь хатын, үзе дә сизмәстән, аның ип вә тәртипкә салынган һәммә уй-фикерен чуалтты да куйды. Яңа ел кичәсеннән соң, Гөлмәрьямнең күркәмлеге, чибәрлеге, сөйкемлелеге — Мөнир күзенә арифметик кына түгел, геометрик прогрессия белән арта барган кебек тоелды. Йомышы булмаса да, бухгалтериядән бер әйләнеп чыгарга гадәтләнеп китте. Гөлмәрьямгә бер генә күз салса да, жаннарына сихәтле бәлзәм коелгандай була иде. Үзенә аерым игътибар тойган яшь хатын да эшкә килешле итеп киенеп, матур итеп бизәнеп йөри башлады. Чәч кистереп, жиңелчә химия дә ясатып кайткач, бигрәкләр дә чибәрләнеп китте.

Гөлмәрьям дә гаилә тормышында үзен бәхетле санаучы, ирен яратып яшәүче хатын иде югыйсә. Әгәр дә берәр күрәзәче аңа да фал ачып, Кәбиреңне үзеңнән егерме яшькә олырак иргә алыштырырсың, дисә, «әстагъфирулла, тузга язмаганны», — дип кенә куйган булыр иде. Дөрес, парторг Мөнир абыйсы кеше буларак бик ошый иде аңа. Һәрчак итагатьле, ярдәмчел ул Мөнир абый, интеллигент. Һәрвакыт затлы, пөхтә киенгән булыр. Буе-сыны, үз-үзен тотышы, сөйләшүләре белән әллә каян аерылып тора. Авылдагы башка ирләргә бөтенләй дә охшамаган. Авылга кунакка гына кайтып төшкән шәһәр түрәсе кебек дип әйтер идең, шәһәр түрәсе болай мөлаем булмас! Мөнир абыйсының теге көнге утлы карашыннан соң, Гөлмәрьям аны очраткан саен «дерт» итеп китә торганга әйләнде. Мондый

йомшаклыгы өчен үз-үзен орышып, сүгеп тә карады. Ләкин бар да файдасыз иде. Эчтән корган бөтен крепость-баррикадалары Мөнир абыйсының бер күз карашыннан ишелеп төшә барды...

Бер ел вакыт шулай үтеп китте. Тик Мөнир күнелендә нәкъ бер ел элек бөреләнгән хис һич тә сүрелмәде. Киресенчә, көннән-көн көчәя генә барды; ул инде хыялында Гөлмәрьямне шашып-шашып сөя, бөтен җирләрен үбеп чыга, кочагында кысып «үтерә» яза иде. Кайсы төннәрдә, хыялындагы шушы дәрт белән, Гадиләсен дә кайнарланып яратып ала. Мондый назларны инде онытып бетерә язган хатыны читенсенеп тә, сөенеп тә куя. Ни хикмәт булыр бу?!... Их, Гадилә, Гадилә! Гафу ит! Иреңнең назлары сиңа аталмаган! Алар сиңа кул астындагы кеше буларак кына тәтеде.

Быелгы Яңа ел кичәсендә Гөлмәрьям Кар кызы булды. Аңардан да гүзәлрәк Кар кызының булганы юк иде әле моңарчы. Яшь кызларың әнә теге читтәрәк торып торсын. Тукаебыз да әйткән бит: әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну, дип. Шушы тәмле хисне кадерләп кенә күңел түрләрендә саклап йөртүгә ни житәр иде дә соң! Бу хакта беркем дә сизенмәгән дә булыр иде. Әйе, шулай дөрес булыр иде ул!

Кайда егыласыңны белсәң, мендәр салып куяр идең, ди мәкаль. Адәм баласы гел туры юллардан гына йөреп бетерә алмый бу дөньяда, вакыты белән кыек-мыек, сикәлтәле юлларга да кереп китә... Хәер, кем белә, Галиҗәнап очрак булышмаса, тормышларын үзгәртергә тәвәккәлләмәгән дә булырлар иде, бәлки?!

Яңа ел бәйрәмнәре үткәч, эш буенча бергә башкалага командировкага барырга туры килде аларга. Икесенең дә куна барырдай туганнары булса да, кунакханәдә тукталдылар. Шушы көнне икесе дә эчтән генә өзелеп көткән сөйләшү булды; җүләр йөрәкләр, шашынып тибә-тибә, үзләренең акылдан өстенрәк икәнен исбатлады. Сулышы ешайган, кайнарланган ирнең көчле куллары яшь хатынның нәфис күлмәге буйлап шуышты.

— Юк, Мөнир абый, юк! Ярамый безгә!! — дисә дә, Гөлмәрьям үзе дә инде шашкын хисләр кочагында, карышырга хәле дә, теләге дә юк иде. Куллары ирексездән ирнең йөзеннән, чәченнән сыйпап үттеләр. Иреннәр очрашып, бер-беренә суырылдылар. Шушы көннән Мөнир белән Гөлмәрьямнең мәхәббәт тарихы башланды!...

Яшерен очрашулар белән янә бер ел үтте. Аларның мәхәббәтләре сүрелмәде. Җае чыккан саен командировкаларга бергә чыгып киттеләр. Йортлары да кара-каршы гына булгач, хәбәрләшергә шартлы сигналлар уйлап таптылар. Кәбир күп нәрсәне күрми, ишетми, вакланмый торган кеше булганнан файдаланып, күбрәк Гөлмәрьямнәрнең мунчаларында очрашалар иде. Очрашасы кичне хатын мунчаны алдан әзерләп куя: яхшылап юып чыгара, тәмле исләр килеп торсын өчен, мәтрүшкә, бөтнек, карлыган яфракларын кечкенә ләгәнгә салып, кайнар су белән пешекли, киң ләүкәгә урын җәеп куя. Ашау ягын да онытмыйлар: гадәттә Мөнир берәр яхшы шәраб, затлы кабымлыклар алып килә. Гөлмәрьям ул яраткан камыр ризыгы пешерә, термос белән тәмле чәен алып керә. Әзерлек эшләре тәмам булгач, алай-болай йомышы төшеп, Кәбир кереп күрмәсен тагы дип мунчаны бикләп, ачкычын кесәсендә йөртә. Билгеләнгән сәгатьтә Мөнир арт яклап кына бакча капкасына килә. Хатын аны инде көтеп тора, капка келәсен акрын гына күтәреп, эчкә үткәрә дә, җитәкләп, карлыган куаклары арасыннан гына мунчага алып китә. Ишек эчтән бикләнүгә, бер-берсенең кочагына атылып, шашып яратышалар. Аннары, тәрәзәгә одеял элеп, шәм кабызып, көлешеп сөйләшә-сөйләшә, бер сыйланып алалар. Тагын үбешәләр, сөешәләр...

Аларның кичләрен югалгалап торуларын гаиләләрендә башта сизмәделәр. Мөнир кирәк чакта төн уртасында да чыгып китә торган кеше. Эшенең

сәгате юк. Гөлмәрьям берәрсенә кич утырырга барам дип кул эше тотып чыгып киткән була. Әмма без капчыкта ятмый шул. Кеше арасында чыш-пыш сүз дә китте. Алга таба болай дәвам итә алмый, нәрсәнедер үзгәртергә кирәк иде! Аерылыргамы?! Юк, яратышуларының иң тәмле мәлендә монысы мөмкин түгел! Кушылыргамы?! Ә балалар?! Алар нишләр?!

Элегрәк Мөнир янына, дөресрәге, парторг янына, өсләреннән йөргән ирләренә чара күрүне сорап, яшь хатыннар килгәли иде.

— Синең белән бөтенләй йокламыймени? — дип сорый Мөнир. Яшь хатынның битенә ут каба.

— Йоклы-ый... — ди ул, күзен яшереп. — Хикмәт анда түгел.

— Юк, сенелем, хикмәт шунда. Син дөньяны аңлап бетермисең әле. Әгәр ирең бераз аш төрләндереп ала икән, моның бер куркынычы да юк. Гадәттә, андыйлар гаиләдән китми. Зәргә борчылып, нервыңны бетереп йөрмә. Әгәр дә инде берәрсенә чынлап гашыйк булса, монысы куркыныч! Шуңа күрә син аны гел үзеңә гашыйк итеп яшәргә тырыш!

Кеше хәлен кеше белми үз башына төшмәсә, диләрме? Кинәш бирүе җиңел ул. Үз башына төшкәч, читен икән. Гадилә, ни сабыр хатын булса да, ире Яңа ел төнендә тагы чыгып китәргә җыенгач, түзмәде. Ел буена җыелып килгән бөтен үпкә-рәнҗешләрен, балалар алдында дип тә тормыйча, иренең йөзенә бәреп әйтеп бетерде. Мөнир,ниләрдер әйтеп, акланмакчы булды, әмма аны тыңларга теләмәделәр:

— Бөтен авыл белә инде моны, әти. Сөйләшеп торма. Чыгып китегез, ичмасам. Әни бу кадәр газапланмас иде! Урамда кеше күзенә күренергә оят бит!

Унтугыз яшьлек Гүзәленең бу сүзенә Мөнир шаккатты. Карәле, өйдәгеләр берни белми, сизми дип йөри иде бит ул! Мәхәббәттән исереп, үзе берни дә сизмәгән икән. Кызы ни арада үсеп җиткән соң әле? Инде олыларча фикер йөртә башлаган. Алай да атасына болай итеп тел күтәрергә?! Моңарчы усаллык белән хатынының, балаларының өстеннән тормаса да, өйдә хуҗа кеше ул, Мөнир иде! Бар да ул дигәнчә булды. Хатыны «Мөнир» дип, «әтисе» дип, балалары «әти» дип күзенә генә карап тордылар. Нишләргә соң инде? Житмәсә, тегендә хәзер Гөлмәрьям, коты алынып, берүзе мунчада аны көтеп утыра торгандыр. Ирен, балаларын йоклаткач, Яңа елны сөйгәне кочагында каршыларга хыялланган иде ул.

Мөнир, кызының сүзләренә бер җавап та кайтармыйча, өйдән чыгып китте. Куркуыннан калтырана башлаган Гөлмәрьям ишекне ачуга аның муенына сарылды, битләреннән үбә-үбә кайнар пышылдады:

— Килдеңме, Мөнирем! Ә мин монда куркып беттем. Яңа еллар белән сине, матурым! Җимешем минем! Үлеп яратам үзеңне, яратам, яратам!

Уйлана-сөйләшә торгач, бер фикергә килеп, икәүләп чыгып китәргә булдылар. Яңа елдан яңа тормыш башларга, сөеп-сөешеп кенә яшәргә иде исәпләре. Кая барып урнашасын да хәл иттеләр. Икесе дә, яшертен генә, китүгә әзерләнде.

Башкалада яшәүче дуслары ярдәмендә әйбәт кенә эшен дә, кереп торырга фатирын да тапты Мөнир. Аны ремонтлатты, йорт җиһазларын юнәтте. Машинасы булу ярады: өйдән дә кирәк-яракны, кием-салымын шактый ташыды. Гөлмәрьям дә алып китәсе киемнәрен, башка кирәкләрен, төйнәп-төйнәп, караңгы төшкәч билгеле бер урынга яшереп куя да, Мөнир аны төнгә багажнигына тутырып калдырып, иртәдән башкала тарафларына чыгып китә иде. Балалар мәсьәләсендә дә бар да хәл ителгән: Мөнирнекеләр инде мәктәп яшендә, Гүзәле студентка. Алар, әлбәттә, әниләре янында кала. Мөнир аларны ташламас, булышып торыр. Гөлмәрьям улын ирендә калдырырга, дүрт яшьлек кызын үзе белән алырга булды.

Билгеләнгән көнне, кунакка барабыз дип, кызын житәкләп, кулына жиңел бер сумка гына тотып, өеннән чыгып китте Гөлмәрьям. Ире белән улы берни белми калдылар. Эшеннән расчет алып та, пропискалардан төшеп тә тормады. Әллә кешегә күренеп йөрисе килмәде, әллә китәсенә ышанып бетмәде. Боларын, соңыннан кайтып, Мөнир эш итеп китте.

Шул китүдән берничә ел күренмәде алар. Мөнирнең гаиләсенә булган ярдәме күпмедер акча салып торудан узмады. Гөлмәрьям дә «улым» дип бер кайтып килмәде. Авылга имеш-мимешләр ишетелеп торды анысы. Уртак кызлары туган икән, исемен Мөнирә дип кушканнар, имеш. Монда кайтмасалар да, Гөлмәрьямнәр авылына кайтып йөриләр икән. Үзенең бәрәңге бакчасына чыгып та карамаган Мөнир анда тәпке тотып бәрәңге төбе өя икән, имеш...

Әмма соңгы вакытларда килеп ирешкән хәбәрләр икенчерәк рухта иде. Инде укуын тәмамлап, Казанда эшли башлаган кызын, Гүзәлен эзләп килгән:

— Бик сагындым сезне, балам! Шушы Яңа елларга кайтырмын, ахры, — дигән имеш Мөнир. Бу хәбәр уңаеннан Гадиләнең дә кылын тартып карадылар:

— Кайтса, кертерсеңме, Гадилә?!

— Әлбәттә! — диде Гадилә, һич икеләнүсез. — Ни генә булмасын, балаларымның атасы бит ул!

Акыллы хатын барысын да аңлаган. Кешегә сиздермәскә, сер бирмәскә тырышса да, эченнән генә өзелеп көтте ул Мөнирен, өзелеп сагынды. Кайтыр, балаларны бик ярата иде бит ул, алар хакына булса да кайтыр дип көтте. Чыннан да, гомер көзенә кергәндә тормышын өр-яңадан башлаган иргә бик авыр булды. Яңа урындагы яңа эш, көн-төн чабарга мәжбүр иткән тормыш мәшәкатьләренә яшь хатынының булдыксызлыгы да өстәлде. Һәрвакыт әзер ашка кайтып кергән, зәвык белән жыештырылган йортта яшәгән, эшен бик мөһим санап, хужалык мәшәкатьләрен күбрәк хатыны жилкәсенә өйгән кеше иде шул Мөнир. Гөлмәрьям белән яши торгач, хис кайнарлыгы белән аңышмаса да, бераздан күзе «ачыла» башлады. Калган ризыкны жылытып ашау, юылмаган савыт-саба, жыелмаган өй — болар бар да гадәти күренешкә әйләнде. Кызын бакчага урнаштыра алмагач, эшләмәде дә югыйсә Гөлмәрьям. Ул арада балага узды. Өендә тәртип булдырып, эштән арып кайткан ирен тәмле рызыклар пешереп кенә каршыларга мөмкинлеге бар иде, әлбәттә. Әмма ул, мавыгып, мәхәббәт романнары укырга яратты. Кызын житәкләп, кибетләрдә, парк-кино шикелле жирләрдә йөрде, дус-ишләр тапты. Уртак кызлары тугач та тормыш рәвеше әллә ни үзгәрмәде. Инде теге дус-ишләр үзләре күбрәк аларда ята башлады. Мөнирнең кайтып керешенә еш кына өстәл янында жырлашып, күңел ачып, тегесен-монысын капкалап утыралар иде. Ачыгып кайткан ир дә, шул вак-төякне капкалап, чәй белән тамагын алдарга мәжбүр булды.

— Өйдә яшь бала да бар, Гөлмәрьям, болай итеп кеше жыеп яту кирәкмәс,— дип сүз башлады Мөнир бер кичне.

— Әй, Мөнирем, син көннәр буе эштә, үземә генә бик күңелсез шул минем,— диде Гөлмәрьям, гадәтенчә аңа сарылып. — Аннан, жаным, озакламый юбилееӊ. Балалар белән дүртәүләп кенә утырмабыз бит! Хезмәттәш дусларыңны да чакырырсың, минем дусларымны да дәшәрбез.

Алай... Ике айдан илле тула икән шул инде. Әй, карт жүләр, карт жүләр! Терсәгеңне бик тешләр идең дә, ераграк шул. Үзеңне бик акыллыга санап йөри башладың, ә үзең менә яшь хатын белән тормыш ничегрәк булачагын да күзаллый алмагансың. Гомер бәйрәмеңне хатының, балаларың, туганнарың белән гөрләшеп үткәрәсе урынга, шушы жиде ят белән билгеләп

үтәргә туры килер микәнни?! Мөнирнең башына кан бәргән кебек булды: әйе, җиде ят! Әле генә аңына барып җитте: сөяркәсен хатыны итеп кабул итә алмаган бит ул! Инде өч еллап яшәүләренә карамастан, Гөлмәрьям һаман да чит кеше икән бит аңа! Хәтта уртак кызлары Мөнирә дә теге балалары кебек якын тоелмый.

Ә балаларын сагынды, бик сагынды Мөнир. Аларны күз алдына китереп, төннәр буе йоклый алмый ята башлады. Инде берәм-берәм буй җиткереп киләләр. Гүзәленә 22 тула. Кияүгә чыгарга җиенуы да бар. Ә аның туенда кадерле әти булып утырырга тиешле кеше кайда?! Балаларын гына түгел, авылын, халкын, һәм... хатынын да сагынды. Әйе, ул аны хәзер еш исенә төшерә башлады. Үзен карарга, бераз ял итәргә вакыты бар идеме соң аның? Бергәләшеп кая барганнары булды? Хатыны уртак түшәк җәеп куйганда да, анда ятмаска сәбәп эзләп, диванда телевизор карап, йә газета укып йоклап китәр иде Мөнир. Хатынының җайлап кына өстенә япканын да, аннан түшәктә мышык-мышык елап ятканын да сизә иде ул. Әмма янына барып ятасы килми иде. Нигә, ни өчен?! Сөешеп өйләнешкән, яратышып яшәгәннәр иде бит! Бертөрлелек ялыктыра башлады шул, ә Мөнир гел сөелергә яратты, җаны назга сусады. Шуннан башланды инде барысы да. Ә чынбарлыкта — аның җанының яртысы – бернинди дә Гөлмәрьям түгел, ә Гадиләсе икән бит! Кайтса, кертер микән?! Кертер, акыллы хатын ул! Кайтуын кайтырсың да, балаларың күзенә ничек карарсың?! Кеше белән ничек аралашырсың?! Ничек, ничек бу кадәр ялгыштым соң мин?!

Ниһаять, үзен йөдәткән сорауларга җавап таба алмый гаҗиз булгач, кызы белән очрашып сөйләшергә булды Мөнир.

— Безгә иң кирәк чагында ташлап чыгып киттең, әти, — диде Гүзәле. Әйткән сүзе саен күзләренә мөлдерәп яшь тула барды. – Хәзер исеңә төштемени? Инде бу гаиләңне дә ташлап китәргә, икенче җинаятеңне эшләргә җыенасыңмы? Яшь балагыз да бар диләр. Юк инде, кайтмыйсың! Бер киселгән кире ябышмый. Без сине гафу итә алмыйбыз!

Кырт борылып китеп барган кызы артыннан инәлеп кычкырды Мөнир:

— Кызым, кызы-ым!..

Әмма кызы борылып та карамады, адымнарын кызулатты, аннан йөгерә үк башлады. Ул инде үксеп елый иде.

— Юк, юк, безгә кирәгең юк! – дигән сүзләре генә, өзек-төтек булып, Мөнир колагына килеп иреште.

Их, Мөнир-Мөнир! Үз кызың булса да, Гүзәлең хатын-кыз бит ул. Хатын-кыз белән киңәш итсәң, ул әйткәннең киресен эшлә дигәннәрен бер дә ишеткәнең юк идемени соң?! Юк йомышын бар итеп икенче көнне үк авылга чапты кызың, әнисен сөендерергә ашыкты. Балаларың аша бу хәбәр авылга да саркып чыкты... Авыл халкы да, куанычлы хәл көткәндәй бер дәрт белән, кире әйләнеп кайтуыңны көтте. Барыбер кайттың син... Әмма, ни үкенеч, җансыз гәүдәң генә кайтты шул!...

**Зөлфия МАНСУР**

*Хикәя фактларга нигезләнеп язылды. Мөнирнең үкенечле язмышы тагын кемнәргәдер гыйбрәт булсын иде.*

**Редакциядән.**
*«Тормыш язган хикәяләр»не башка авторлардан да көтәбез.*

Рашат
Низами

# ФЕТНӘ

Былтыр Карл Маркс исемендәге колхозда районкүләм семинар үткәрелгән иде. Колхозның балта осталары моның өчен шома такталардан йөз кеше сыярлык эскәмияләр рәте һәм агач трибуна әмәлләде. Ул чакта нәкъ шушы урында тарихи фетнә кубачагын беркем дә белми иде әле...

Авылның аулак, чирәмле бу почмагында инде кайнар сүзләр яңгырамый. Семинар булып узган мәйданчыкка җилләр генә хуҗа, трибуна ялгызы монаеп, йокымсырап утыра.

Чү! Мәйданчыкта ниндидер яңа җил исеп куйды түгелме? Бик кызып, ярсып, сөйләнә-сөйләнә трибунага таба тимерче Гайфүш килә икән! Берәүдән дә рөхсәт-фәлән сорап тормастан, ул ике терсәге белән трибунага таянды. Махмырдан интеккәндә баш төзәтергә ярата ул. Баш төзәтсә, тыңлаучы бармы-юкмы, эчке монологларын тышка түгә башлый. Юкка гына "лектор" дигән кушаматны чәпәмәгәннәр аңа!

Үз гомерендә бер генә мәртәбә дә трибунадан чыгып сөйләгәне булмаган Гайфүш эскәмияләр рәтенә сөзеп кенә кырыс караш ташлады:

— Җәмәгать... Житте! Тарих тәртәсен борырга вакыт! Без демократия дибез, базарга чыгабыз, дибез... Чыгарсын пычагым буш кул белән! Нәчәлество бөтенесен үз кулына элэктерде, идрит-кудрит! Байлар-буржуйлар бөтен завод-фабриканы кесәсенә салып куйдылар!.. Мин шушы тарихи мәлдә әлеге безобразиегә нокта куярга булдым! Бүгеннән авыл чишмәсен хосусыйлаштырам! Бер чиләк-көянтә су — ун тәңкә! Боерган булса, акча дигәнең тамчылап бер кулга — минем кулга җыела барачак... Инде килеп, һава турында. Менә сез көн саен саф һава сулыйсызмы — факт. Сулыйсыз. Булды, житте, бүгеннән һаваны да хосусыйлаштырам. Рәхәтләнеп сулагыз, пажалысты, тик һава хакы минем карамакта булачак. Ачуланмагыз, авылдашлар, әгәр мин тотынмасам, бу эшне көннәрнең берендә нәчәлество барыбер үз кулына алачак, әйе. Ә мин, курыкмагыз, налуг-залуг акчаларын бик зурдан каермаска тырышырмын.

Уйлап караганыгыз бармы, ни өчен безнең калхуз Карл Маркс дип йөртелә? Тo-то, безнең авылга аяк та басмаган ул сакалбай! Һәм аның калхуз кесәсенә сукыр бер тиен дә акча керткәне юк... Шулай булгач, ниемә дип аның исемен йөртә безнең радную калхуз? Һәрнәрсәнең исеме җисеменә туры килергә тиеш, әттәгенәсе!.. Баеп китсәмме, калхузны бар дирбиясе белән сатып алсаммы?.. Гайфүш, ягъни Гайфетдин Сәйфетдинов исемендәге калхуз булыр ул, Алла боерса!

Гайфүшнең кызып-дәртләнеп сөйләгән нотыгы шушы урында өзелде. Чөнки нәкъ шул мәлдә участок милиционеры аны култыклап алган иде. Һәм ул фетнәче лекторны хатынының каты һәм кырыс кулларына илтеп тапшырды...

Карл Маркс колхозында купкан беренче фетнә әнә шулай башланган иде. Инде ишетәбез — чишмәләрне хосусыйлаштырырга йөрүчеләр берәү генә түгел икән. Нинди чишмәле урын — элэктереп калу нияте белән чабалар. Кайда шәп туфрак, хосусыйлаштыручылар чираты. Шәп һавалы урыннарның да һавасын анализга тапшырып маташалар ди. Менә сиңа Гайфүш үрнәге!

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Атабай

Атабай авылы Кама Тамагы районында, район үзәге Кама Тамагы эшчеләр бистәсеннән — 40, җирле үзидарә советы үзәге Каратал авылыннан 2 чакрым ераклыкта утырган. Авыл тимер юл станциясе Чишмәдән (Ключи) — 25, Тәмте (Теньки) пристаненнән шулай ук 25 чакрым ераклыкта урнашкан.

Тарихи чыганакларда, халык авыз иҗаты әсәрләрендә Атабай атамасына әледән-әле тап буласың. Авыл Казан ханлыгы чоры документларында искә алына. Атабай авылы янында борынгы болгар чорына мөнәсәбәтле кылыч сыныгы табылган. Авыл тирә-юне борынгы заманнарда тарихи урын булган,

Өлкән буын кешеләре сөйләвенә караганда, Атабай һәм Бортас авылларын Атабай белән Бортас исемле кешеләр нигезләгән. Атабай бабайның бозавы югала. Ул бозавын эзләп йөргәндә шушы матур урынга килеп чыга һәм шунда утырып калырга ниятли. Атабай бабай Олы Бортастан килгән дип сөйлиләр. Бортас авылы да Казан ханлыгы чоры чыганакларында искә алына. Аксакаллар сөйләвенчә, Атабайда морзалар да яшәгән, аларның җирләре аерым булган.

Авыл халкы үз араларында керәшен нәселләре булуын әйтә. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң башланган чукындыру сәясәте шаукымы, күрәсең, бу авылны да читләтеп үтмәгән. Ләкин ул керәшен татарлары инде хәзер янадан исламга кире әйләнеп кайтканнар. Бу фикерләр тарихи чыганаклардагы мәгълүматлар белән дәлилләнә. Бер тарихи чыганакта Атабай авылында 41 йомышлы, 8 ясак түләүче, 10 керәшен татары яшәгәнлеге күрсәтелә.

Атабай халкы күршедәге утызлап авыл белән бергә Чабыр исемле җыен бәйрәме үткәргән.

Авыл урынында элек калын урман шаулап утырган. Моны без авыл тирәсендәге географик берәмлек атамаларыннан да ачык күрәбез. Авыл янында Имәнлек дигән җир бар. Таулар юнәлешендәге басу агачлардан чистартылган, шул сәбәпле басу ышна исеме алып калган.

Халык телендә ике тау атамасы еш кулланыла. Аның берсе — Кала, икенчесе — Тәмте тавы. Авыл яныннан Үләмә суы агып уза. Шомыртлык борыны дип аталган урында Баса күле бар. Анда гомер бакый киндер салганнар. Бу күл тирәсендә элек кыргый үрдәкләр бала чыгарган. Хәзер бирегә үрдәкләр килми. Көянтәгә ошаганы өчен Көянтәлек дип аталган урыннан бераз гына арырак та күл булган. Анда балык бик күп үрчегән, кайберсенең озынлыгы метрдан да артып киткән дип сөйлиләр. Кызганыч, хәзер ул күл беткән. Авылдан ике чакрым ераклыкта Җәмәки коесы дигән борынгы кое бар.

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

***

Атабай атамасы алган авыл Лаеш районында да бар. Атабай авылы район үзәге Лаеш эшчеләр бистәсеннән — 88, Казаннан 58 чакрым ераклыкта урнашкан.

Казан ханлыгы дәверендә булган авыллар исемлегендә Атабай авылы телгә алына. Атабай авылы тирәсе борынгы археологик табылдыклар белән бәйле. Авыл яныннан соңгы болгар чорларына мөнәсәбәтле акчалар һәм XIII — XIV йөзләрдә ясалган сука тимерләре, кискечләр табылган.

XVIII йөз мәгълүматлары тупланган тарихи чыганакта Атабай авылында 58 ясак түли торган, 2 керәшен татары яшәгәнлеге әйтелә.

И.А.Износков (XIX йөз) мәгълүматларына караганда, Атабай авылы Каманың уң ягына утырган. Авылдагы 92 хуҗалыкта ислам дине тотучы 347 ир-ат һәм 250 хатын-кыз көн күргән. Авыл янында иске зират булган, аның Кама юган урыннарыннан кеше сөякләре һәм көмеш акчалар тапканнар. 1898 елда авылда татарлар яши дип искәртелә. Атабай авылы В.П.Семенов редакцияләгән тарихи чыганакта түбәндәгечә сыйфатлана. «Атабайда 800ләп татар кешесе яши, мәчет, почта станциясе һәм Кама аша кичү бар».

Авыл атамасының килеп чыгуы турындагы риваятьләрдән берсе түбәндәгечә. Атабай авылы аша бер кеше узып барганда, авылның матурлыгына бик сокланган һәм туктап: «Сез монда ата бай булып яшисез икән», — дигән. Шуннан авыл Атабай булып киткән, имеш.

Риваятьнең икенчесе дә халык этимологиясенә нигезләнгән. Булачак авыл урынына бер кеше килеп утырган һәм: «Мин моннан нәрсә булса да табам, табаем», — дигән. Шул рәвешле авыл Табай аталып калган, имеш (авыл халкы авыл исемен кыскартып, кайвакыт Табай дип кенә йөртә).

Атабай авылы Кама Иделгә кушылган җиргә, табигатьнең матур почмагына утырган. Авылның уң ягын урман чолгап алган, ә сул ягында Идел һәм Кама чайкала. Авыл икегә бүленгән. Бер өлешен Мишә Тамагы, икенчесен Атабай дип йөртәләр.

Атабай авылы Идел суы күтәрелү сәбәпле өченче урынга күчеп утырган. Элек Идел тар булган, Атабайдан Кама Тамагына ишкәкле көймә белән тиз генә чыгып житкәннәр. Ә хәзер Атабай тирә-юнендәге урманнар, болыннар, кырлар, инеш-сулар, күл-сазлыклар барысы да су астында калган.

Авылда элек зур мәчет эшләп килгән. Совет хакимияте елларында аны мәктәп итеп файдалана башлаганнар. Авылда хәзер дә мәчет эшли.

Атабай бүген үсеш чоры кичерә. Авылга шәһәрдән килеп күп кешеләр дачалар төзи.

## Баландыш

Баландыш авылы Теләче районында, район үзәге Теләче авылыннан 16 чакрымда, тимер юл станциясе Арчадан — 62, Казаннан 94 чакрым ераклыкта урнашкан. Авыл үзе җирле үзидарә советы үзәге. Авыл исеме шактый күп тарихи чыганакларда берегеп калган.

Җөри юлы өстендәге Баландыш авылы Казан ханлыгы чоры авыллары исемлегендә китерелгән.

Д.А.Корсаков бастырып чыгарган белешмәдә (XVIII гасыр) Баландыш авылында 98 ясаклы татар яшәгәнлеге искәртелә. 1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә күрсәтелгәнчә, Баландыш суы ярына утырган Баландыш авылындагы 104 хуҗалыкта 409 ир-ат һәм 146 хатын-кыз көн иткән, мәчет эшләгән.

И.А.Износков мәгълүматларына караганда, Баландыш авылында ислам дине тота торган 442 ир-ат һәм 429 хатын-кыз көн күргән. 1898 елда басылып чыккан белешмәдән күренгәнчә, Баландыш авылында татарлар яшәгән. К.П.Берстель белешмәсендәге мәгълүматларга караганда, авылда 1171 татар кешесе теркәлгән.

Баландыш авылы халкы июнь ае урталарында күршедәге Мамалай, Урта Саба, Сатыш, Орымширмә, Иске Җөри, Зур Тиләҗе, Урта Мишә, Зур Мишә, Елыш,

Югары Шытсу, Түбән Шытсу, Чәбки Саба, Бигәнәй, Теләче, Казанчы-Бигәнәй авыллары белән бергәләшеп Мамалай жыены бәйрәм иткән.

Олылар сөйләвенә караганда, элек авыл янында балан куаклары күп үскән. Авыл шуна Баландыш исеме алган.

Авыл Мишә суы янына утырган. Авылны урталайга ярып агучы Инеш Мишәгә килеп кушыла.

Авыл чишмәләргә бик бай. Яналары да килеп чыгып тора. Халык телендә авылның элекке урам исемнәре бик яратып кулланыла: Олы урам, Сәйкә урамы, Чүлмәк урамы, Зәйни урамы, Чүлмәк атавы, Черек күл, Тау башы һ.б.

## Балчыклы

Балчыклы авылы Кама Тамагы районында, район үзәге Кама Тамагы эшчеләр бистәсеннән 34 чакрымда, жирле үзидарә советы үзәге Олы Бортас авылыннан 5 чакрым ераклыкта урнашкан,

Балчыклы авылы Казан ханлыгы чоры документларында Булчиклы рәвешендә теркәлгән. Зөя өязенен теркәү кенәгәсендә Балчыклы авылы искә алына. XVIII гасыр тарихи чыганагында авылда 48 ясак түли торган, 31 йомышлы татар, 10 керәшен татары яшәве күрсәтелгән.

Балчыклы авылы халкы күршеләрендәге утызлап авылда яшәүчеләр белән июль ае башында Чабыр жыены бәйрәм иткән.

Авыл аксакалы Гарифулла ага Хәлиулла улы сөйләвенә караганда, авыл борынгы заманнарда оешкан. Анда шактый жир биләмәләре булган, морзалар да яшәгән.

Балчыклы авылы халкы да чукындыру сәясәтеннән котылып кала алмаган. Авыл халкының бер өлеше чукындырылган. Авыл янында керәшен зираты бар. Соңыннан алар барысы да ислам диненә кире кайтканнар. Хәзер ул зиратка беркемне дә жирләмиләр.

Балчыклы авылының элекке урыны 2 чакрым читтәрәк булган. Ул урын хәзер Иске Авыл дип әйтелә.

Авыл янында елга-инешләр, чишмә, күлләр шактый. Коры Үләмә елгасын авылда Олы Су дип атыйлар. Авыл яныннан үтеп Коры Үләмәгә килеп кушыла торган суны авыл халкы Инеш яисә Кече Су дип йөртә. Рәим чокыры дигән чишмә бар. Таллы Күлнең суы яз көннәрендә генә була, чишмәсе юк. Бу күлгә сүс сала торган булганнар. Басу-кырлардан Таштау һәм Муштуп кыры бар. Муштуп кыры элек алпавыт жире булган. Революциядән соң ул Балчыклы халкы карамагына бирелгән.

Авыл зур түгел. Ул Түбән оч һәм Югары оч урамнарыннан тора.

***

Балчыклы авылы Түбән Кама районында да бар. Ул Шәнгәлче үзидарә советына керә. Д.А.Корсаков хезмәтендә (XVIII гасыр) авылның икенче исеме Баран дип тә йөртелә. Ул Балчыклы елгасы ярына урнашкан. Анда 71 керәшен татары, дворовый кешеләр яшәгән.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# М

**МӨХӘММӘДОВ** Шакир Мөхәммәтша улы (20.5.1865, Сембер өязе, Буа ш. — 10.11.1923, Оренбург ш.), язучы, нәшир, журналист. 1879 дан Оренбургта яши. Кибеттә хезмәтче, приказчик вазифаларын башкара, 1884 тән сәүдәгәр Хөсәеновлар конторасында хисапчы булып эшли. 1890 елларда Мәскәүгә күчә; бухгалтерлар курсын тәмамлап, һөнәре буенча эшли. 1900-01 елларда Харбин ш. (Кытай) яши. Аннан Буага кайта, татар мөселман яшьләре арасында җәмәгать эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. 1903 тә янә Оренбургка кайта: Хөсәенов Гани бай конторасында эшли, 1906-07 елларда «Карчыга» сатирик ж-лының нәшире һәм мөхәррире. 1917 дән соң приказчик һәм конторщик профсоюзларын төзү б-н шөгыльләнә, төрле оешмаларда хезмәт итә. Татар сәүдәгәрләренең тормышын һәм табигатен тасвирлауга багышланган «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай» (1901), «Яфрак асты, яхуд Мәкарҗә ярминкәсе» (Оренбург, 1901) исемле беренче повестьлары язылa. Язучы геройларының үз катламнарына хас булган сыйфатларын гына күрсәтеп калдырмыйча, аларның һәрберсен индивидуаль характерлар, гадәтләр б-н дә баета. Геройларын мәгърифәтчелек күзлегеннән чыгып бәяләп, М. аларның саранлыгын, наданлыгын тәнкыйтьли, укырга, белем эстәргә өнди. М.нең «Япун сугышы, яки Доброволец Батыргали агай» (1905) повесте еш кына зәһәр сатирага әйләнгән, нечкә юмор, ирония б-н сугарылган. Язучы рус-япон сугышы барган чорда татар һәм рус сәүдәгәрләренең ялган патриотизмын көлке утына тота. «Доброволец»лар Батыргали б-н Шубинны крестьяннан чыккан сугышчыларга каршы куеп, автор фәкать халыкның үзе генә чын баһадирларны үз сафларында үстерә алганын күрсәтә. Мавыктыргыч сюжет, төгәл билгеләнгән образлар, кеше психологиясенең нечкәлекләрен яхшы белү әсәрнең популярлашуына сәбәп була. «Хан кызы» (1908) исемле романтик хикәядә хан кызы Фатыйманың Иран шаһы улы Ширин исемле әсир егеткә булган мәхәббәте тасвирлана. Егетнең исеме, геройларның очрашуын тасвирлау, вакыйгаларның алга таба үсеше укучы күңелендә урта гасыр татар әдәбияты сюжетлары (Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е, Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлделсен»не) б-н охшашлык тудыра. Бу әсәрдә М. кодрәтле, ирек сөючән хатын-кыз идеалын тудыра. Оригиналь бетем (кыю кызны ашап йоткан, аллегорик аждаһа образы пәйда булуы) хикәянең традицион укылышын (ата-ана сүзен тыңламау һәлакәткә китерә) фәлсәфи мәгънә (кеше кимчелекләре мәхәббәт, бәхетне җимерү генә түгел, хәтта үтерүгә китереп җиткерергә мөмкин) б-н баета. М. поэзиясендә гражданлык, публицистик мотивлар өстенлек итә («Дума членнарына», 1907; «Жир кирәк», 1907 һ.б.). «Яңа Бәдәвам» (Оренбург, 1903) сатирик шигырь керешендә автор: «... милләтебез хастадыр. ... Безнең хасталыгыбыз наданлыктыр. Наданлык дәвасы, әлбәттә, гыйлем вә мәгърифәт вә укудыр», — дип яза. Публицистик мәкаләләрендә М. татар җәмгыятенең актуаль мәсьәләләрен күтәрә, төрле катлам халыкның демократик үзгәрешләргә карата мөнәсәбәтен яктырта, халыкны укырга өнди, татар уку йортларына реформа кирәклеге турында яза, кадимчеләрне тәнкыйтьли. М. әсәрләре аңлаешлы тел б-н язылган, тексттагы чит тел сүзләренә аңлатмалар бирелгән, әйтем һәм мәкальләр киң кулланган.

Әс.: Сайланма әсәрләр. К., 1958.

Әд.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX века. К., 1975; История татарской литературы нового времени (XIX — начало XX в.). К., 2003; Закирҗанов Ә. «Заманыбыз тәрәккыят заманыдыр...» // Казан утлары. 2005. №5.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**МӨХӘММӘДИЕВ** Ринат Сафа улы (10.12.1948 Мамадыш р-ны Кече Кирмән ав. туа), язучы, әдәбият белгече,

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынинан басылып килә.*

әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1970-73 елларда ТАССР МСның Телевидение һәм радиотапшырулар к-тында телевизион тапшырулар мөхәррире, 1976-86да «Казан утлары» ж-лында бүлек мөхәррире һәм баш мөхәррир урынбасары. 1986-89да Татар. кит. нәшр. директоры, 1989-99да Татарстан язучылар берлеге рәисе, бер үк вакытта 1990-93ләрдә РСФСР ЮСның мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе. 2000 елдан Мәскәүдә. 2005тән «Татарский мир» («Татар дөньясы») газетасы мөхәррире. Әдәбиятка 1970 еллар башында Х.Туфан, С.Хәким, Н.Арсланов кебек шагыйрьләр турында тәнкыйть мәкаләләре, әдәби образлар, иҗат портретлары белән килеп керә («Әгәр без янмасак...»,1980; «Проблемы формирования татарской литературной критики», 1982; «Якутлар табыладыр вакыт белән», 1983 җыентыклары). Әдәбият сөючеләр арасында М. үзенең «Беренче умырзая» (1983; рус теленә тәрҗемәдә «Первый подснежник», М., 1987), «Ак кыялар турында хыял» (1995) исемле лирик повестьлары, авыл проблемаларын яктырткан «Истәлек өчен — Гыйлемханга» (1986; шул исемдә нәфис телефильм, 1995) әсәре белән танылды. Автор авылның әхлагы югалу, кешеләрнең табигатькә, җиргә битараф була баруларының сәбәпләре турында уйлана. 1989 елда социаль-психологик романы — «Кенәри — читлек кошы»н (рус теленә тәрҗемәдә «Львы и канарейки», или Невинные забавы мафии», М., 1992) бастыра. М.нең иң зур иҗади уңышы—сәяси һәм дәүләт эшлеклесе М.Солтан-Галиевкә багышланган «Сират күпере» романы (1992; рус теленә тәрҗемәдә «Мост над адом», М., 1996; ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе, 1993). М. шулай ук «Утлы таба өстендә» (1995; русчага тәрҗемәдә «На раскалённой сковороде», М.,1997; «Крушение» исеме белән тулыландырган варианты, М., 2001; 5 басма 2005; М.А.Шолохов исем. Халыкара әдәби премия, 2002) док. повесть, «Алланың кашка тәкәсе» (2003; рус теленә тәрҗемәдә «Пуп земли», М., 2007), «Кош булып очар идем» (М., 2007) романнары авторы. 1990-93 елларда РФ ЮС, 1995-99 да ТР халык депутаты.

Әд.: Галиуллин Т. Сәфәр чыгар аты бар // Мирас. 1998. №12; Галимуллин Ф. Кече Кирмәннең олы Ринаты // Казан утлары. 1998. №12; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

**МӨХӘММӘДОВА** Гөлсем (Өммегөлсем) Даут кызы (19.9.1903, Әстерхан шәһ. — 11.3.1988, Казан), язучы, тәрҗемәче, биол.фән.канд. (1956). Әстерхан рус гимназиясен тәмамлагач (1919) татар башлангыч мәктәпләрендә укытучы булып эшли. 1922 елда Казанга күчеп килә, Казан ун-тының медицина ф-тында укый, бер үк вакытта ТАССР ХКСның юридик бүлегендә тәрҗемә эшен алып бара. Сәмәрканд медицина ин-тын тәмамлый (1944). Ире — Г.Ибраһимовның шәхси сәркатибе вазифаларын башкара; аның татар иҗтимагый фикере үсеше тарихы һәм революцион хәрәкәтенә багышланган «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре. 1 бүлек» («Татары в революции 1905 года», 1926) хезмәтен рус теленә тәрҗемә итә. 1927-33 елларда Ялта шәһ. авыру ирен карый. 1934-41 дә Симферополь шәһ.дә: кырым-татар язучылары турында китап чыгаруда катнаша, архив идарәсендә эшли, «Кызыл Кырым» газетасы редакциясе белән хезмәттәшлек итә. 1941 дә Сәмәрканд шәһ.нә эвакуацияләнә, башта хастаханәдә табиб, соңрак Бөтенсоюз каракүл сарыклары үрчетү фәннитикшерену ин-тында фәнни хезмәткәр булып эшли. Г.Ибраһимов аклангач, аның тормышына кагылышлы мәгълүматлар җыю белән шөгыльләнә, язучыны белгән кешеләр белән хатлар алыша. «Г.Ибраһимов турында истәлекләр» (1966) җыентыгын бастырып чыгаруда катнаша. Г.Ибраһимовка багышланган «Большая жизнь» (1968) мемуарлар җыентыгы, «Яшьлек көннәре»(1975) док. повесте, язучының тормышын һәм иҗатын, аның даирәсен колачлаган «Эзләнүләр» (1987) һәм «Олы юл» (1994) исемле истәлекләр җыентыгы авторы.

Әд.: Хәмидуллин Л. Тирән хатирәләр иясе // Мәдәни җомга. 2003.19 сент.; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Л.Х.Хәмидуллин.*

**МӨХӘММӘТ** Садыйк Иманколый (10.9.1870, Казан — май 1932, Пермь өлкәсе Красновишерск а.), дин эшлеклесе, шагыйрь. Дини белемне Бохарада ала. 1894-1932 елларда Казанда Яңа бистәнең 6 нчы мәчете имамы булып тора. 1919-24 елларда Казанның мөхтәсибе. 1931 дә «кулак муллалар оешмасы»нда катнашкан өчен кулга алына, 5 ел лагерьга хөкем ителә. Белобалтлагта чирләп үлә; вафатыннан соң аклана. Дини хезмәтләр, шигъри әсәрләр, уку әсбаплары, сүзлекләр авторы. Танылганнары арасында: «Сәләтыйн ислам...» (1909) дини әсәре, «Тәрҗеман руси, фарси вә төрки» (1909) сүзлеге, «Тәсһилел-бәйан фи тәфсирель-Коръән» (т.1-2, 1910) исем-

ле Коръән тәфсире (1996 да Катарда «Урта Азия мөселманнары арасында таратырга» дигән формулировка б-н репринтта басыла), «Мәрсия император Александр II вә тәһния император Николай II» (1910). 2000 дә Казанда кульязмалар рәвешенә сакланган мөнәҗәтләре, газәлләре, касыйдәләре басылып чыга.

Әс.: Перевод-самоучитель для русского, персидского и тюркского языков, употребляемых в Туркестане. К., 1915; Мөнәҗәтләр. Газәлләр. Касыйдәләр. К., 2000; Тәсһилүл бәян фи тәфсирил Коръән: Коръәннең 30 нчы парәсы тәфсире. К., 2002.

Әд.: Ахунов А. Мухаммад-Садык Иманкулый// Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 3/4; Гайнутдинов М. В тисках безвременья: Классики 20-х гг. К., 2002; Әхмәтҗанов М. Шагыйрь һәм дин галиме // Мирас. 1995. № 9.

*А.М.Ахунов.*

**МӨХӘММӘДШӘРИФ** Габдеррәшид угылы (18 йөз ахыры—1834), шагыйрь. Морад мулла хәрәкәтендә катнашкан 1нче Казан мәчете имамы Габдеррәшид хәзрәт улы. Сатирик эчтәлекле «Мөнәҗәтә кәҗә», «Чәй бәете», «Кече хатын» һ.б. шигырьләр авторы. Көндәлек тормышны тасвирлап, эзоп телен кулланып, М. рәсми мөселман руханиларын тәнкыйтьли. Кульязмалары РФА Шәрекъ белеме ин-ты Петербург бүлеге кульязма фондында саклана.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 том.

*А.М.Ахунов.*

**МӨХӘММӘДЪЯР** Мәхмүд Хажи угылы (1496 яки 1497—1549), шагыйрь. Чыгышы буенча дин эшлеклеләреннән. Гомеренең соңгы елларында Казанда Мөхәммәдәмин хан төрбәсенең караучы-мөҗавире булып тора. 1549 нең көзендә Иван IV гаскәре Казанны алганда чолганышта һәлак була. Безнең көннәргәчә сакланып калган ике поэмасы һәм бер шигыре мәгълүм. «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге», 1539-40) лиро-эпик поэмасында шагыйрьнең гуманистик карашлары, кешеләр тату, тыныч яши торган идеаль җәмгыять турындагы хыяллары чагыла. Поэманың лейтмотивы, социаль-этик концепция үзәге булып гаделлек идеясе тора. Игътибарның төп объекты — табигать тарафыннан акыл, матурлык, чибәрлек, нәфислек, тугрылык, тыйнаклык б-н бүләкләнгән кеше. М. фикеренчә, кеше үзен җәмгыятькә хезмәт итүгә, тәкәбберлек, мактанчыклык, икейөзлелек б-н көрәшергә багышларга тиеш. Поэма лирик чигенешләр б-н чиратлашкан, аның аерым кисәкләрен бәйләп, ш.б. аны бербөтен иткән, җиде хикәяләүдән тора. Шаһ Һарун, акыл иясе Заһид, мәрхәмәтле кыз, аның усал әтисе һ.б. турында язылган зур булмаган хикәя-притчаларда автор шул замана гореф-гадәтләрен тасвирлый. Үзе яшәгән чор җәмгыять төзелешен ул ислам әхлагы карашыннан, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре тәгълиматыннан чыгып бәяли. М.ның гуманистик вәгазе максаты — әхлакны төзәтү , шәхес һәм җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрне камилләштерү һәм шуның аркылы Аллаһка якынаю. М.ның җәмгыять тормышында, шәхеснең формалашуында телнең роле турындагы фикерләре аеруча игътибарга ия. Шагыйрь өчен тел — илаһи бүләк. Тел аша кеше акылы дөнья турындагы карашларын тапшыра, җиткерә ала. Туры сүз туры эш-гамәлләрне билгели. Тел ялганга корылган булса, барысы да ялган булачак.

«Нуры содур» («Күңелләр нуры», 1542) дидактик поэмасында шагыйрь хөкемдарларга хас булырга тиешле әхлакый сыйфатлар турында фикер йөртә. Әсәрнең төп лейтмотивы — М. фикеренчә игелек, тыныч һәм шат тормышның чыганагы — гаделлек: «Бер сәгать гадел кылмак йахшырак, Кем гыйбадәт алтмыш йылдин озакрак». Тасвирлы чагыштырулар б-н шагыйрь золымга чик куярга, хөкемдарларга йогынты ясарга, аларны гади халыкка карата юмарт һәм мәрхәмәтле булырга чакыра. Шулай итеп, М. урта гасыр Шәрекънең алдынгы гуманистик идеяләрен үстерә. «Гаделлек белән, шаһ, чыкты атыгыз, Дөньяда һәрвакыт булсын затыгыз. Гадел хөкемennән куркып, шаһ җиһан, Көчле көчсезгә һич тидермәс зыян»,—дип яза автор. Алай булганда: «Бүре белән сарык бергә су эчәр, Үрдәк белән карчыга бергә очар».

М. феодаль-теократик тәртипләрне, хөкем итүчеләрнең эш-гамәлләрен тәнкыйтьли, киң халык массаларының мәнфәгатьләрен чагылдыра. Ул хезмәт кешесен мактый, аның намуслылыгына, әхлак пакьлыгына дан җырлый. М.ның гуманизмы ш.у. хатын-кыз б-н ирләр, өлкәннәр б-н балаларның бертигез булуын тануда чагыла. Шагыйрь күзаллавы буенча Аллаһ — бар нәрсәнең башы. Кеше — акыл индерелгән гүзәл зат. Ләкин тормышка аяк басканда, аның бертөрлесе мәрхәмәтле була, икенчесе — явызга әйләнә. Гөрләп алга барган ил, М. фикеренчә, гаделлеккә нигезләнә. Аның гаранты булып хөкемдар тора.

Поэмада Шәрекъ әдәбиятының иң танылган әсәрләре йогынтысы сизелә («Кәлилә вә Димнә», Низами Гәнҗәвинең «Хәмсә»се, Й.Баласагунинең «Котадгу белек»е, Сәгъдинең «Гөлестан»ы һ.б.). М. ш.у. татар фольклорының байлыгын да оста файдалана. Мәкальләр, әйтемнәр, аерым гыйбарәләр, шигъри юллар б-н органик рәвештә кушылып китеп, текстны кыска һәм ачык, образларны тере һәм тәэсирле итәләр. Поэма лексикасында гарәп-фарсы алынмалары, халыкның сөйләм теле элементлары, диалектизмнар урын алган.

М. иҗатын өйрәнүгә М.И.Иванов юл сала; «Татар хрестоматиясе»нең («Татарская хрестоматия», 1842) икенче бүлегендә ул аның «Нәсыйхәт»ен бастыра. 1846 да шәрекъчы И.Н.Березин С.-Петербургның Азия музее фондларында «Төхфәи мәрдан» поэмасының кульязмасын таба һәм үзенең «С.-Петербург библиотекаларындагы төрек-татар кульязмаларының тасвирламасы» («Описание турецко-татарских рукописей, находящихся в библиотеках С.-Петербурга») мәкаләсендә аның турында беренче мәгълүматлар бирә. Аның фикеренчә, «Төхфәи мәрдан», казан диалекты борынгы ядкәренең берсе буларак, ... зур игътибарга лаек». Соңыннан поэманың аерым өзекләрен Березин үзенең «Төрек хрестоматия»сенең («Турецкая хрестоматия», т. 1-3, 1857-90) 1 нче томына кертә. М. иҗатын язучы Н.Исәнбәт дәвам иттерә. 1941 дә «Совет әдәбияты» ж-лында (№4), «Нуры содур» поэмасының Татарстан җирендә табылган һәм күчерелгән нөсхәсенә нигезләнеп, мәкалә бастыра. 1947 дә тарихчы Х.Гыймади И.Н.Березин тапкан поэма күчермәсенең урынын ачыклый. 1940-50 елларда М.ның иҗади мирасы б-н галимнәр Б.Яфаров, Л.Җәләй, Н.Ф.Калинин һ.б. шөгыльләнә. 1956, 1957 елларда М. поэмасыннан өзекләр «Татар поэзиясе антологиясе»ндә («Антология татарской поэзии») басылалар. М. әсәрләрен җентекләп өйрәнергә 1950 елларда Ш.А.Абилов алына. 1966 да ул ике поэма текстын, 1997 дә поэмаларның тулы текстларын һәм «Нәсыйхәт» шигырен бастыра, аларның бүгенге татар әдәби телендә тәрҗемәләрен, аңлатмаларын бирә. Поэмалар күчермәләре (12 чамасы) С.-Петербург, Казан, Уфа архив һәм китапханәләрендә саклана. «Төхфәи мәрдан» (1600) поэмасының иң борынгы күчермәсе Казан университеты Фәнни китапханәсе сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә саклана. М. әсәрләре М.Колый, Г.Кандалый, Акмулла, Г.Тукай, Дәрдемәнд иҗатларына зур йогынты ясый.

Әс.: Төхфәи мәрдан. Нуры содур. Поэмалар. К., 1966; Нуры содур. Поэмалар, шигырь. К., 1997.

Әд.: Мухаммедьяр и его время. К., 1997; Кадирова Э.Х. Поэмы Мухаммедьяра «Тухва-и Мардан» и «Нур-и Содур»: Лексика. К., 2001.

*Ш.А.Абилов, А.М.Ахунов.*

**МӨХӘММӘТШИН** Газиз Фазлый улы (23. 12.1932, Минзәлә р-ны Яңа Бикчәнтәй ав. — 17.2.1972, Казан), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1956). 1958-63 елларда «Чаян» һәм «Ялкын» ж-лларында әдәби хезмәткәр, 1963-65 тә «Совет әдәбияты» ж-лының җаваплы мөхәррире. 1960 елда М. «Сер итеп кенә» дигән беренче хикәяләр җыентыгын бастыра. «Йолдызлар астында» повесте (1964) геологлар тормышы һәм хезмәтенә багышлана. «Без әле җирдә яшибез» (1963; русчага тәрҗемәсе «Мы живем на Земле», М., 1977) повесте һәм «Йөрәктәге эзләр» романында (1971) мәхәббәт, гаилә тормышы, балалар тәрбияләү турында сүз бара. Шулай да М.ны үзенчәлекле язучы итеп таныткан жанр — хикәя. Аның иң яхшы үрнәкләре «Мой характер» (М., 1968), «Тәрбия сәгате» (1973), «Кадерле бүләк» (1979) җыентыкларына тупланган.

Әсәр.: Саумысыз, аккошлар! К., 2006.

Әд.: Гыйләҗева Н. Газизебез бар иде //Казан утлары. 2005. №4.

**МӨХӘММӘТШИН** Галим (Галимҗан) Мөхәммәтша улы (7.2.1911, Казан губерниясе Казан өязе Зур Солабаш а. — 10.5.1938, Казан), шагыйрь. Балалар өчен язылган «Үсеш балалары» (1931), «Пионерия» (1932), «Яшьлек» (1933), «Шигырьләр» (1935), «Яшьлек дәвам итә» (1958) шигъри җыентыклар авторы. Нахакка репрессияләнгән; вафатыннан соң акланган.

Әд.: Рафаэль Мостафин. Репрессияләнгән татар әдипләре. // К., 2009.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

## Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ИСТАНБУЛДА ТУКАЙ ҺӘЙКӘЛЕ

Май аенда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов рәсми визит белән Төркиядә булды. Татарстан делегациясе составында Татарстан Президентының Тышкы элемтәләр департаменты җитәкчесе Искәндәр Мөфлиханов, вице-премьер — сәнәгать һәм сәүдә министры Равил Зарипов, мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Ринат Закиров бар иде.

Анкарада «ТҮРКСОЙ» төрки мәдәниятләр халыкара оешмасының штаб-фатирында Татарстан делегациясе картиналар һәм фоторәсемнәр күргәзмәсен карады. Аннары Рөстәм Миңнеханов әлеге оешманың генераль секретаре Дүсән Касеинов белән очрашты. Кичен делегация әгъзалары Анкара опера һәм балет театрында Татарстан сәнгать осталары концертын карады.

— Төрек һәм татар халыкларының мәдәнияте, теле, тарихы бер-берсенә бик якын. Узган ел Төркиядә Г.Тукайның 125 еллыгына багышланган бәйрәм чаралары үткәрелгән иде, бүгенге концертны мәдәни казанышларыбызны уртаклашу буларак кабул итәргә кирәк, — диде Татарстан Президенты.

Истанбулда шәһәр мэры Кадыйр Топбаш белән очрашканнан соң, Р.Миңнеханов Төркия — Татарстан сәүдә-инвестиция форумында катнашты. Форумда ике арадагы икътисади мөнәсәбәтләрне ныгыту турында сүз барды. Төркиянең икътисад министры Зафәр Чаглаян сүзләренә караганда, төрек ширкәтләренең чит илләрдәге 15 миллиард долларлык инвестициясеннән 1 миллиарды нәкъ менә Татарстан өлешенә туры килә. Ә бу күп нәрсә турында сөйли. Без алга таба да төрек компанияләренә Татарстанга барырга тәкъдим итәчәкбез», — диде З.Чаглаян.

Президент Р.Миңнеханов әйтүенчә, төрек ширкәтләре Татарстан турында күбрәк белсен өчен, шундый ук чараны безнең республикада да уздырырга кирәк: «Татарстан — төрек бизнесы өчен Россия төбәкләре арасында иң аңлаешлысы. Республика аша алар башка төбәкләргә дә җәелә ала. Татарстанда гамәлгә ашырыла торган «Форд-Соллерс» проектында Төркия компанияләре дә актив катнаша. «Татнефть», «КамАЗ», «ТАИФ», «Казаньоргсинтез» кебек эре компанияләребез Төркия белән хезмәттәшлеккә әзер», — диде Президент.

Форум кысаларында ике килешү имзаланды. «Татарстан» авиакомпаниясе һәм «Төрек һава юллары ширкәте» ике арадагы хезмәттәшлекне тагын да ныгыта барып, Истанбул-Казан маршруты буенча атнасына 7 очкыч җибәрергә ниятли. Ә «КамАЗ», «Пари ТЭК» һәм «Katmerciler» компанияләре вәкилләре Төркиядә газ двигателе куелган «КамАЗ»лар сатачак.

Форумнан соң, Татарстан делегациясе вәкилләре мәдәни чараларда катнашты. «Топкапы» паркында урнашкан «Татар йорты»нда яңа экспозиция ачылды. Музей комплексы составына кергән «Татар йорты» бирредә 2009 елдан бирле эшли инде.

Истанбулның Әюп районындагы Г.Тукай исемен йөрткән мәйданда бөек татар шагыйренә һәйкәл куелды. Монументның авторы — танылган сынчы Асия Миңнуллина. Истанбулның иң матур урынnarыннан берсе — Солтанәхмәт мәйданында Сабан туе үткәрелде. Шәһәр мэры К.Топбаш һәм Татарстан Президенты Р.Миңнеханов анда котлау сүзләре белән чыкты.

Эш сәфәренең ахырында Р.Миңнеханов Төркия Хөкүмәте башлыгы Рәҗәп Тайип Әрдоган белән очрашты.

### БОЛГАР ДӨНЬЯДА ТАНЫЛА

Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм Дәүләт Эрмитажы директоры, «Яңарыш» республика фонды попечительләр советы әгъзасы Михаил Пиотровский Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгында булдылар.

Болгар шәһәренә экскурсия Болгар цивилизациясе музее белән кушылган Елга вокзалыннан башланды. Бу объектта төзелеш эшләре ахырына якынлаша. Болгар музей-тыюлыгы директоры Рафаэль Мәхмүтов кунакка Елга вокзалы музее функцияләре турында сөйләде. Минтимер Шәймиев белән Михаил Пиотровский казу

эшләре барган урында булды. Михаил Пиотровский 922 елда Идел буе Болгарстаны тарафыннан Ислам динен рәсми кабул итүгә багышланган Истәлекле билге объектында быелның 21 маенда куелган иң зур басма Коръәнне, Ибн Фадлан сәяхәте маршруты картасын, музей галереясендә татар, рус, инглиз, алман һәм гарәп телләрендә Ибн Фадланның Иделгә сәяхәте турындагы язмасын зур кызыксыну белән карады. Аннары кунаклар Кече манарада, Сәхабәләр һәйкәлендә, Икмәк музеенда булдылар. Михаил Пиотровский бигрәк тә «Ак мәчет» комплексына соклануын белдерде. Ул борынгы Болгарда алган хис-кичерешләре белән уртаклашты: «Мин биредә бары 3 кенә ел булмадым. Үзгәрешләр шаккатырлык. Менә Ак мәчет, ул шәһәр читендә салынган, барлык кагыйдәләр дә үтәлгән. Археологлар өчен база булдырыла, алар берничә ел биредә тыныч кына эшли ала. Казу эшләре вакытында табылган әйберләрне урнаштыру өчен музейлар бар. Болар барысы бергә борынгы шәһәрне янадан ачу мөмкинлеге бирә», — диде ул.

Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, экскурсияне тәмамлап: «Михаил Пиотровский бу җирне, аның тарихын, Болгар белән Зөядә эшләрнең нидән башлануын һәм ничек дәвам итүебезне — барысын да яхшы белә, — диде. — Бу 2 елда торгызу эшләре фән һәм халыкара институтлар таләпләре кысаларында уза. Без, Болгарны тулысынча ачарга кирәк, дип тә белдердек инде. Әлбәттә, бу эшләр бер елда гына башкарылмый, яңа объект ачу белән берьюлы аларны саклау өчен җаваплылык алуны исәпкә алу зарур. Хәзер бу өстенлекле бурычларның берсе булып тора».

## ЕВРАЗИЯ КҮЧМӘЛӘРЕНӘ БАГЫШЛАНА

«Эрмитаж-Казан» үзәгендә «Евразия күчмәләренең империягә юлы» дигән уникаль күргәзмә ачылды. Анда Дәүләт Эрмитажының 2190 экспонаты тәкъдим ителгән. «Мондый күргәзмәләр беркайчан да булмады, бу — империяләр үсеше хакында энциклопедик язма сыман һәм аны бары тик Дәүләт Эрмитажы гына күрсәтә ала», — дип билгеләп үтте Михаил Пиотровский.

«Эрмитаж-Казан» үзәгенең 10нчы юбилей күргәзмәсен ачу тантанасында ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Эрмитажы директоры Михаил Пиотровский, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева һ.б.катнашты.

Тантанада Зилә Вәлиева билгеләп үткәнчә, Казанда яшәүчеләр «Эрмитаж-Казан» үзәгендә кызыклы күргәзмәләр узуына инде күнегеп бетте, әмма бүгенгесе аеруча уникаль. Күргәзмәне ачу идеясен ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Рафаэль Хәкимов тәкъдим иткән. Михаил Пиотровский, күргәзмәдә алтын һәм шулай ук гади бизәнү әйберләре дә бар, дип белдерде. Аның сүзләренә караганда, күп кенә экспонатлар Дәүләт Эрмитажы музееннан беркайчан да чыгарылмаган, аларны бары тик Казанда гына күреп була. Минтимер Шәймиев күргәзмәнең РФдә Тарих һәм ТРда Тарихи-мәдәни мирас елында ачылуын искәртте. Аның сүзләренчә, бүген Болгар белән Зөя торгызылган вакытта мәдәни кыйммәтләрне барлауга һәм саклауга кызыксыну арта. Ә инде әлеге күргәзмәгә килсәк, ул төрки халыкларның тарихын тагын да яхшырак белү өчен зур мөмкинлек бирә.

Дәүләт Эрмитажы директоры Михаил Пиотровский рәсми чыгышлардан соң Минтимер Шәймиевкә, Рафаэль Хәкимовка һәм ТР Милли музее генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗиповага академик Николай Лихачевның тууына 150 ел тулуга багышлап Эрмитажда узган «Звучат лишь письмена» күргәзмәсе каталогын бүләк итте.

## «НӘҮРҮЗ» ҮРЛӘР ЯУЛЫЙ

Казанда төрки халыкларның II халыкара «Нәүрүз» театр белеме бирү фестиваль-форумы үтте. Бу форумда Татарстан, Башкортстан, Чуашстан, Тыва, Хакасия, Саха (Якутия), Дагыстан, Әзәрбайҗан, Казахстан, Төркмәнстаннан 200ләп театр эшлеклесе катнашты.

«Бүгенге көндә Россиядә, гомумән, бөтен дөньяда театр белеме бирү фестиваль-форумнары үткәрү — сирәк күренеш», — диде «Нәүрүз» фестиваль-форумының пленар утырышын ачкан вакытта Берлиндагы «Aktzent» халыкара театр үзәге һәм Европа театр мәдәнияте ассоциациясе җитәкчесе Юрий Альшиц, Россия Театр әһелләре берлеге сәркәтибе, Россия Милли театрлар шурасы рәисе Рифкат Исрафилов үз чыгышында Казаныбызга һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына зур ихтирамын һәм «Нәүрүз» фестиваль-форумының Россиядә генә түгел, чит илләрдә эшләп килә торган милли театрларның үсеше өчен зур этәргеч икәнен белдерде.

«Хәзерге заман театры төрле, художник мөмкин кадәр ирекләрәк булырга тиеш», — диде танылган театр белгече, РУТИ-ГИТИС профессоры Анна Степанова. — Форумда төрледән-төрле фикерләр ишетергә мөмкин булачак».

Татарстан мәдәният министрының беренче урынбасары Ирада Әюпова үз чыгышында быел «Нәүрүз» фестиваль-форумында секцияләр санының артуын уңай күренеш буларак билгеләп үтте. «Бүгенге көндә тормыш-яшәешебез зур тизлек белән үзгәрә, хәятебезнең көзгесе булган мәдәният, шул исәптән театрлар да үзгәрергә мәҗбүр, — диде ул.

Пленар утырыштан соң секцияләр эше башланды. Ю.Альшицтан — актерлык осталыгына, А.Степанова һәм Р.Исрафиловтан

— режиссура серләренә, И.Овчинников һәм К.Учительдән менеджмент күнекмәләренә һәм PR-технологияләргә өйрәнергә мөмкин иде.

Шул ук көнне кичен Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә күренекле режиссер Эймунтас Някрошюс куелышында «Идиот» спектакле күрсәтелде.

«Нәүрүз» фестиваль-форумында җәмгысе 32 семинар, 6 спектакль, 3 осталык дәресе, Ю.Альшиц (Германия), Н.Кирай (Венгрия), И.Расмуссен (Дания), П.Руднев (Россия) һ.б. танылган театр әһелләре белән очрашу-аралашулар булды.

### ШАГЫЙРЬГӘ ХАЛЫКАРА БҮЛӘК

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинга «Европа-Азия» халыкара гуманитар академиясенең югары бүләге — «Планетаның тынычлык илчесе» номинациясендә «Тынычлык розасы» алтын медале тапшырылды.

«Европа-Азия» академиясе үз эшчәнлеген ЮНЕСКО химаясендә алып бара һәм мәдәният-фән әһелләре, алдынгы карашлы җәмәгать лидерларын, дәүләт, финанс-икътисад һәм мәгълүмати структуралар житәкчеләрен халыкара интеллектуаль бергәлеккә берләштерү идеясенә хезмәт итә. Бүләкне тапшырганда, ЮНЕСКО дөнья мәдәнияте институты ректоры, Халыкара гуманитар академия президенты академик Энгель Таһиров Равил Фәйзуллинга «Тынычлык розасы» алтын медаленең республика интеллектуаль потенциалын куәтләндерүгә, тынычлык идеяләрен һәм кыйммәтләрен, толерантлыкны, халыклар һәм цивилизацияләрнең кешелек алгарышы хакына этноконфессиональ килешүен ныгытуга керткән өлеше өчен бирелүенә басым ясады.

### ТАТАР ПЕН ҮЗӘГЕНДӘ

Республика Милли китапханәсе бинасында Татар ПЕН-үзәгенең чираттагы жыелышы булды. Үзәкнең президенты Разил Вәлиев соңгы чорда башкарылган әһәмиятле гамәлләр турында искә төшереп үтте. Аннары оешманың башкаручы директоры Әхәт Мушинский хисап тотты. Чыгышлардан күренгәнчә, безнең әдипләребез Халыкара язучылар берләшмәсенең төрле илләрдә уздырылган чараларында актив катнашып, татар халкын киңрәк таныту, ана телебезне яклау, тарихи-мәдәни мирасыбызны саклау буенча зур кайгыртучанлык күрсәтә. Татар ПЕН-үзәге милли әдәбиятыбыз классикларының әсәрләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен инглиз һ.б. телләрдә чыгарып, аларны дөнья җәмәгатьчелегенә тәкъдим итү юнәлешендә дә зәлекле эшләп килә. Әлеге проект буенча бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 125 еллыгы уңаеннан да китап әзерләнде һәм ул чит илләрдә яшәүче киң катлау укучыларга барып ирешге. Татар пенчылары жыелышында халкыбызның рухи-мәдәни гормышына кагылышлы, аерым алганда, милли мәгарифебезгә бәйле көнүзәк мәсьәләләрне дә игътибар үзәгендә тоту зарурлыгы хакында искәртеп үтелде, алдагы чорда башка күп кенә чаралар үткәрү кичектергесез әһәмиятле эшләр планына кертелде.

Татар ПЕН-үзәге жыелышында оешманың президиумы, ревизия комиссиясе составлары яңартылды, шулай ук язучылар Рабит Батулла, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Галиуллин, Рүзәл Мөхәммәтшин яңа әгъзалар итеп алынды, Зиннур Мансуров үзәкнең вице-президенты итеп сайланды.

***

Фәнне үстерүгә, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш керткәне, актив фәнни-педагогик һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен Казан (Идел буе) федераль университетының теоретик кибернетика кафедрасы профессоры **Сөләйманов Җәүдәт Шәүкәт улына** «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, әдәбият һәм мәдәният үсешенә зур өлеш керткәне өчен «Татмедиа» ААҖ филиалы «Казан утлары» журналы редакциясенең проза бүлеге мөхәррире **Закиров Марат Хәлил улына** һәм сәнгать бүлеге мөхәррире **Бәйрәмова Гөлзадә Әүхәди кызына** «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Шәһри Болгардагы яңа ачылган Ак мәчет.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә **Рифә Рахман**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде. 28 майда каты авырудан соң 84нче яшендә атаклы татар актеры, СССРның халык артисты, РСФСР һәм ТАССРның халык артисты, Россия Федерациясенен К.Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенен шәрәфле әгъзасы Шәүкәт Хәсән улы Бикмимеров вафат булды.

Ш.Биктимеров 1928 елның 28 октябрендә дөньяга килә, Татарстанның Саба районы, Мингәр авылында үсә. 1949 елда Казан театр техникумын тәмамлаганнан соң, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры труппасына кабул ителә һәм гомер буе шушы театрда эшли.

Ш.Биктимеров күпкырлы иҗади шәхес, атаклы сәхнә остасы иде. Ул татар актерлар мәктәбенең сәхнәдә ышандырырлык, дөрес итеп уйнау, персонаж характерының психологик асылына тирән үтеп керү кебек иң яхшы традицияләрен үзенә туплады. Якты таланты, эшләү, фикерләү сәләте һәм югары дәрәҗәдәге сәнгать культурасы Ш.Биктимеровка күп еллар дәвамында данлыклы театрның әйдәп баручы артисты булып калырга ярдәм итте.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 60 елдан артык эшләү дәверендә Ш.Биктимеров классик һәм хәзерге заман драматургиясенә караган 130дан артык образ иҗат итте.

1967 елда Ш.Биктимеров Ч.Айтматов повесте буенча куелган «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә Байтимер ролен башкарган өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Т.Миннуллин пьесасы буенча сәхнәләштерелгән «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклендәге Әлмәндәр карт образы Ш.Биктимеровның гаять зур казанышына әйләнде. Бу рольне башкарган өчен ул РСФСРның К.Станиславский исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Спектакль 35 елдан артык сәхнәдән төшмәде, бу әсәр берничә буын тамашачылар һәм актерларны тәрбияләде, Ш.Биктимеров башкаруында Әлмәндәр образы милли сәхнә вакыйгасына әйләнде, ул милләтнең әхлакый кыйбласын чагылдырды.

Ш.Биктимеровның иҗади тормышы зур иҗтимагый эш белән янәшә барды, ул Казан шәһәр Советы, ТАССР Югары Советы, СССР Югары Советы депутаты итеп сайланды.

Татар халкының иң популяр һәм иң яраткан артистларыннан берсе, XX гасыр театр сәхнәсенең атаклы остасы Шәүкәт Хәсән улы Биктимеровның иҗат һәм тормыш юлы театр сәнгатенә тугры һәм фидакярләрчә хезмәт итү үрнәге булып тора.

Татар театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән, Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Ш.Биктимеров «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде.

СССРның халык артисты Шәүкәт Хәсән улы Биктимеровның күпкырлы иҗаты халык йөрәгенә мәңгелеккә үтеп керде, ул халкыбызның казанышына әйләнде. Аның якты истәлеге безнең күңелләрдә һәрвакыт сакланыр.

**Р.Миңнеханов, М.Шәймиев, Ф.Мөхәммәтшин, И.Халиков, Ю.Камалтынов, И.Метшин, А. Сибагатуллин, Рәис Миңнеханов, Ф.Бикчәнтәев, А.Славутский, Р.Заһидуллин.**



**Рифә Рахман**

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)